
# Казан утлары

3

март
1968



Б. АЛЬМЕНОВ эше.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

3

МАРТ

1968

## Бу санда:

А. М. ГОРЬКИЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ел

Г. БӘШИРОВ. Үзебезнең Горький . . . . . . . 3
Х. ТУФАН. Тәрәзә. Шигырь . . . . . . . . . 8
М. ГОРЬКИЙ. Акулина әби. Хикәя . . . . . . . 9
Ш. САДРЕТДИНОВ. Тамчыда кояш чагыла . . . 17

8 МАРТ БЕЛӘН КОТЛЫЙБЫЗ!

К. БУЛАТОВА. Еллар миңа...; Мин зур үскәч...; Табигатьтә...; Яр буйларын... Шигырьләр . . . 18
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Йозак; Яңгырдан соң... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 19
Ф. ШИҺАПОВА. Күңелле; Тамчылар. Шигырьләр. 20
В. ХӘЙРУЛЛИНА. Төнге урман; Чулпы җыры; Әнисә; Урамда... Шигырьләр . . . . . . . 21
Ф. ХӨСНИ. Заманалар һәм язмышлар . . . . . 22
З. НУРИ. Синең җырың; Адашу. Шигырьләр . . 29

ЯШЬ ТАЛАНТЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН

ЗӨЛФӘТ. Тимерче турында баллада . . . . . 30
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Мин диңгездә утрау күрдем. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . 31
Г. РӘХИМ. Авылым. Шигырь . . . . . . . . 31
А. ХӘЛИМ. Түбин җыры. Шигырь . . . . . . 32
Р. ХАРИСОВ. Ат. Шигырь . . . . . . . . . 32
Р. МИНГАЛИМОВ. Таш дивардай... Шигырь . . . 33
Т. КАМАЛИЕВ. Абыйлар. Шигырь . . . . . . . 33
Х. АЮПОВ. Аргымагым. Шигырь . . . . . . . 34
П. АПУШЕВ. Ишкәкләр минем кулда. Шигырь . 34
Р. ЯГЪФӘРОВ. Диңгезче сүзе. Шигырь . . . . 34
В. НУРУЛЛИН. Шинельсез солдатлар. Повесть . . 35
А. ГАНИЕВ. Янәшә. Хикәя . . . . . . . . . 77
С. ХӘКИМ. Тукайларны эзлим. Мәкалә . . . . . 88

ДУСЛАР ҖЫРЫ

П. ТЫЧИНА. Муса Җәлил Киевта. Шигырь . . . 91
Р. МУРАД. Яулар кичтем; Йолдыз; Композитор. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 93
Р. ХАЛИД. Татарстан шагыйрьләренә; Күк миләүшә кебек; Еллар...; Диңгезне сөйгәндәй... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 95
Р. БУРНАШ. Туганнар кабере; Ышанмыйм...; Кояш белән Җил. Шигырьләр . . . . . . . . . 97
А. МЕФАЕВ. Минем теләк; Сөям. Шигырьләр . . 98

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

**Ч. АЛИ.** Хезмәттер...; Көзең кебек...; Тәрәзәмне бүген... Шигырьләр . . . . . . . . . 99
**Э. ФАЗЫЛ.** Ана; Миләүшә; Ике көрешү. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 100

**«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНА 50 ЕЛ**

**Г. МИНСКИЙ.** Якын дустыбыз, акыллы киңәшчебез. Мәкалә . . . . . . . . . . . . . 101

**ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘСӘРЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ**

**Г. АХУНҖАНОВ.** Мәкаль һәм әйтем. Мәкалә . . 104
**Ф. УРМАНЧЕЕВ.** Халык хикмәте әсәрләре. Мәкалә 112
**М. ГОСМАНОВ.** Мәкальләр — тарихи чыганак. Мәкалә . . . . . . . . . . . . . . . 115

**МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП**

**Р. МОСТАФИН.** Батырлар елмаеп үлделәр . . . 118

**ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ**

**Л. ИХСАНОВА.** Җир хуҗалары . . . . . . . . 134
**Я. МОСТАФИН.** Бронзадагы җөйләр . . . . . 140

**ИСТӘЛЕКЛӘР**

**В. ХАНГИЛЬДИН.** Көтелмәгән бер очрашу . . . 146

**ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ**

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ.** Халык онытмас . . . . . . . . 148
**М. МЕРЗАБЕКОВ.** Кәрвансарай. Мәкалә . . . . 149

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫННАН МАТЕРИАЛЛАР**

**М. МӘҺДИЕВ.** Шәкертләрнең авыз иҗаты . . . 151

**Ә. КАМАЛГА 60 ЯШЬ**

**Ш. ЗӘЙНИ.** Драматург үткән юл . . . . . . 154
Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . 156
Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 159

***Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый***

---

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/I-1968 ел. Басарга кул куелды 29/II-1968 ел. ПФ 09009. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 65346 экз. Заказ Д-80. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1968 ел.

*Гомәр Бәширов*

# ҮЗЕБЕЗНЕҢ ГОРЬКИЙ

Мин Казанның шау-шулы тынгысыз урамнары буйлап барам. Бераз барган саен кечерәк кенә, җыйнак кына агач йортлар каршында туктыйм да, моннан күп еллар элек булып узган истәлекле хәлләрне күз алдыма китерергә тырышып, уйланып торам. Менә бу йортта ул пекарняда эшләгән, камыр баскан, икмәк әвәләгән. Монысында Гурий Плетнев белән алар яшерен прокламацияләр басканнар. Казанның менә бу тирәсе элек Марусовка дип йөртелгән. Нинди тамашалар гына булмаган монда! Кабак, фахишәләр, караклар, хәерчеләр, гариплләр, муен тиңентен пычрак... Шундый имәндергеч тормыш сазлыгында яшәп тә, рухыңны гарипләндермичә, күңел сафлыгын саклап калу, шул чокырдан кешелек мәдәниятенең югары баскычына күтәрелә алу үзе үк могҗиза түгелме соң!!

Бу йортларга карап уйланып торуы күңелгә бик хуш килә. Бу кечкенә йортларда, ул йөргән урамнарда аннан нидер калган шикелле. Ул үзе күзгә күренмәстәй, әмма бик газиз, кадерле. Шушы минутта мин онытылмастай җанлы тарихның үзе белән күзгә-күз очрашамдыр кебек.

Казанга беренче мәртәбә килүендә Алеша Пешков текә яр өстендәге менә бу бер катлы, сөйкемле генә агач йортта, Николай Евреиновларда яшәгән, Казан университетына укырга керү турында хыялланып менә шушы тын урамнарда уйланып йөргән. Шуннан бик аз гына соңрак, нәкъ бу йортның күршесенә Сембердән Ульяновлар гаиләсе килеп урнашкан. Хәзер инде шул ук урамнан җитез хәрәкәтле, өлгер һәм үткен яшь егет — Володя Ульянов университетка йөри башлаган. Бу урамнар, менә бу карт йортлар Володя Ульяновның сөекле Ватанны бөлгенлек һәм хәерчелектән, коллык һәм наданлыктан коткару юллары турында иптәшләре белән сүз көрәштерүләрен, кайнар бәхәсләрен ишетеп калганнар.

Бу тирәләрдән мин дулкынланып атлыйм. Ифрат та игътибарга лаеклы бер хәл: Володя Ульянов белән Алексей Пешковның ялкынлы яшьлек еллары, аның да бөек вакыйгаларга бай һәм кешелек тарихына онытылмастай истәлек калдырган иң әһәмиятле бер чоры бер үк шәһәрдә, бер үк тирәдә, бер үк вакытта диярлек күкрәп үткән. Минем алар я менә шушы урамнарның берсендә, я булмаса, университет тирәсендә, берсен-берсе танымыйча гына булса да, һичшиксез, очрашканнар булыр дип уйлыйсым килә. Шулай булмыйча мөмкинмени! Бөтен дөньяга мәгълүм бит: университетта әлеге тарихи җыелышны оештыручыларның берсе Володя Ульянов булса, шуның өчен Казаннан сөрелүче студентлар язган мөрәҗәгатьне яшерен типографиядә Алексей Пешков бастырып тараткан.

Кулларына авыр кәрзин алып, ныгып җитмәгән иңенә үз ихтыяры белән бөтен ил кайгысын, патша коллыгында иза чигүче барлык хезмәт кешеләренең сыйнфый борчуын күтәреп, тугры сүзле, көрәшкә омтылучы гадел һәм намуслы егет Алексей Пешков бу урамнарда Казан байларына күмәчләр, булкилар ташыган. Мин дә аның эзләреннән атлыйм. Бара торгач, ничектер, үзеннән-үзе як-ягыма карапам. Шушы өзлексез халык агымыннан кара сатин күлмәк кигән, озын буйлы, күе коңгырт чәчле рус егете Алеша Пешков та килеп чыгар кебек.

Янсә ярты гасыр вакыт күз йомган арада үтеп китә дә, икенче сулышта ул минем күз алдыма 1928 елда Казанга кайтканда ничек булса, шул рәвешендә килеп баса — озын буйлы ир уртасы кеше, башында зур кара эшләпә. Казандагы искиткеч үзгәрешләр һәм кинәт кенә исенә төшкән яшьлек хатирәләре аны дулкынландыра. Ул салынып төшкән мыек чылгыйларына бармак очлары белән генә кагылгалап, гаҗәпләнеп һәм сокланып, калын тавыш белән:

— Алай, алай... — дип куя.

Кремль янындагы калкулыктан, Муса Җәлил һәйкәле яныннан Идел өстенә күз салам. Бишбалтадан аз гына сулдарак Идел эченнән кечкенә генә коры җир кисәге калкып торган сыман күренә. Элекке пристань, Алеша Пешковның гомерендә беренче мәртәбә хезмәт дәртен, аның рухландыргыч поэтик ләззәтен татыган истәлекле урын әнә шул инде. Байтак еллар узганнан соң, ул үзе бу хакта шушылай язган иде:

«Мин капчыкларны элеп кенә алам да йөгерәм, илтеп ташлыйм да тагын эләктереп йөгерәм. Миңа ул чагында мин үзем дә, минем тирә-ягымдагылар да ашкынулы бер бию көенә бөтереләләр кебек тоела иде... Эштә шундый акыллы һәм җитез, эш белән шулай үз-үзләрен онытырдай булып мавыккан бу ике аяклы киекләрне кочаклыйсы, үбәсе килә иде.»

Бу юлларны беренче мәртәбә нинди дулкынланып укуымны әле дә хәтерлим. Минем өчен бу әдәбиятта чын-чыннан яңа ачыш иде. Грузчикларның кеше җелеген суыра торган авыр хезмәтендә язучының поэзия күрә белүе, аны шундый соклангыч итеп, җыр кебек ялкынлы итеп яза белүе мине хәйран калдырды. Чөнки хезмәт кешесенең кара эше турында минем беркайчан да, бер китапта да мондыйны укыганым юк иде.

Шуннан бирле, халкыбызның иҗади хезмәте, хезмәтнең поэтик матурлыгы турында язу теләге тудымы, бик еш Горькийның җыр кебек яңгыраган әнә шул поэтик юллары искә төшә. Андый вакытта үзеңне тагын да җаваплырак хис итә башлыйсың. Күңел югарыга, ялган белән фальш менеп җитә алмастай, чын хакыйкать үзе генә, аның да иң кирәкле һәм кадерлесе генә языла торган шигъри биеклеккә омтыла, уңмастай яңа буяулар, иң дөрес, иң көчле сүзләр эзләргә тотына.

Шулай атлый торгач, янәшә баручы юлдашым Хәсән Туфанның дулкынланып әйтелгән ягымлы сүзләрен ишетәм:

— Беләсеңме, ул безне, чыннан да, бик ярата иде. Хәтереңдәдер, язучыларның беренче съезды татар әдәбияты турында махсус доклад тыңлады. Ул бит көн тәртибенә Горький тәкъдиме белән кертелгән иде. Шул съездда көндезге бер тәнәфес вакытында безне, татар язучыларын, Лидия Сәйфуллина эзләп тапты. «Картыгыз сезне шул арада сагынып та өлгерде, үз янына чакыра», — ди бу. Барсак, аның янына үтеп керә алмаслык. Бөтен тирә-ягын хәбәрчеләр, фотографлар, кино кешеләре әйләндереп алган. Ә ул, бернигә карамастан, безне янына утыртты да, эти кеше кебек, бөтенесен белешергә, сораштырырга тотынды.

Әйе, ул безне ата үзенең улларын яраткан кебек ярата иде. Аның безнең әдәбиятны даими кайгыртуын татар язучылары һәрвакыт сизеп тордылар.

Горькийны татар халкы да үзенең сөекле язучылары белән бер дәрәҗәдә үз итте һәм яратты. Әгәр мин Горькийга кадәр башка халык язучыларыннан берсе дә татар халкының шулкадәр тирән мәхәббәтен казанмаган, берәү дә аның кебек халыкның күңел түренә тирән үтеп керә алмаган, рухи дөньясын болай дөрес аңлый алмаган иде дисәм, шат ялгышмамдыр.

Бу дуслык хисе, күрәсең, Горькийда аның бала чагында, Нижний Новгородта ук тугандыр, аннан соң, 1884—88 елларда Казанда яшәгәндә чәчәк атып, тагын да ныгып, тирәнәеп киткәндер.

Гомеренең Казанда узган чоры турында М. Горький үзе бик яратып язган иде.

«Физик яктан мин Нижний Новгородта туганмын, ә рухи яктан — Казанда. Казан минем иң яраткан университетларымның берсе».

Иң мәшһүр әсәрләреннән берсе булган «Минем университетларым»да Горький үзенең Казан кешеләренә булган ихтирамы, татар халкына мәхәббәте, аларның үзенчәлекле тормышлары белән һәр даим кызыксынуы турында күп тапкырлар язды.

«Китап укыганны тыңлап утыруы күңелсез (народниклар түгәрәге утырышы турында сүз бара — Г. Б.), татар бистәсенә чыгып китәсе килә иде. Анда нинндидер үзенә бертөрле пакъ тормыш белән яхшы күңелле, ягымлы кешеләр яши. Алар рус телен бик кәмит итеп бозып сөйлиләр... Мин татарларның бөтен тормышы бөтенләй башкача корылган дип уйлый идем. Ул тормыш миңа таныш түгел; мин белгән һәм мине куандырмый торган тормышка охшамый иде.»

Горький бөтен гомере буена Казан белән элемтәсен өзмәгән. Ул Казанны һәм татарларны, татар әдәбиятын бөтен дөнья күләмендә танылган мәшһүр язучы булып

киткәннән соң да, дөньякүләм иҗтимагый-политик вакыйгалар эчендә кайнап башлагач та, ифрат катлаулы һәм зур колачлы әдәби әсәрләр иҗат итү белән мәшгуль вакытында да онытып тормаган. Безнең әдәбиятның ветераннары бу хәлне зур канәгатьләнү белән, Алексей Максимовичка ихтирам белән искә төшерәләр.

М. Горький Габдулла Тукайны да, башка язучыларны да белгән, аларның ничек үсүләрен, әдәбият дөньясына нинди яңа әсәрләр бирүләрен дусларча күзәтеп торган. Үзенең Казандагы таныш һәм белешләре аша ул татар әдәбияты турында Нәҗип Думавидан очерк яздырып, аны 1911 елда «Современник» журналында бастырып та чыгарган.

Алексей Максимович Горькийны без халыклар дуслыгының аваз салучысы, төрле халыкларның үзара мөнәсәбәтендәге бу изге юнәлешне революциягә кадәр үк фидакарьләрчә тырышлык белән алга сөрүче интернационалчы буларак та ихтирам итәбез. Кайсы гына милләт вәкиле булмасын, ул һәркемдә бәрыннан да элек аның кешелек горурлыгын ихтирам итте, һәр кешедә үз халкына хас булган иң якты, иң күркәм кешелек сыйфатларын күрергә омтылды, гасырлар буенча самодержавие итеге астында изелеп килүче халыкларга тирән ихтирам һәм дуслык хисе белән яшәде. Болар аның бөтен иҗатында якты бер юл булып балкып торалар.

Искә генә төшереп карыйк: үзенең әдәби әсәрләрендә рус булмаган халык вәкилләренең образларын Горький нинди мәхәббәт белән иҗат итә торган булган! Әле бит шунысын да истән чыгарырга ярамый: ул чорда, патша заманында, рус булмаган халыкларны мыскыллап һәм кимсетеп «инородецлар» дип атыйлар, патша хөкүмәтенең рәсми органнары һәм чиркәү әһелләре, матбугатта булсын, дини вәгазьләрдә булсын, ничек тә аларга дошманлык тойгысы уятырга тырышалар иде.

Ә ул, хезмәтчел Россиянең мәгърур улы, революциянең давыл хәбәрчесе — Горький бөек тарихи вакыйгаларның өлгереп килүләрен, халыкларның язмышын һәм киләчәген пәйгамбәрләрчә алдан ук күргән. Без хәзер горурлык һәм шатлык белән «какшамас халыклар дуслыгы» дип йөрткән бөек бер иҗтимагый көчнең озакламыйча барлыкка киләчәген, әйтерсең, алдан ук сизенгән. Шунлыктан ул революциягә кадәр үк тә, аннан соң да халыклар дуслыгының чәчәк атуына һәм ныгуына талантының бөтен көче белән ярдәм иткән.

М. Горький иҗатында башка халык вәкилләренең образларын, өстәрәк әйткәнемчә, бик еш очратабыз. Шулардан, мәсәлән, «Ана» романында Андрей Находканы, «Мордовка» дигән хикәясендә мордва хатынын һәм башка бик күпләрне искә төшерергә була. Әмма мин шулар арасында татарлар М. Горькийның һәрвакыт диярлек игътибар үзәгендә булып, аның әсәрләрендә аеруча күренекле урын алганнар дияр идем. Мәсәлән, бөек язучының «Тормыш төбендә», «Матвей Кожемякин тормышы», «Евграф Букеев», «Макар тормышыннан бер вакыйга», «Өлгәмә» һәм башка кайбер әсәрләрен генә искә алып узыйк. Бу әсәрләрдәге татар образларын мин М. Горький чын күңелдән яратып иҗат иткән дияр идем. Болардан һәм гомумән башка хезмәтләреннән күренүенчә, Алексей Максимович безнең халыкның тормышын, аның психологиясен, үзенчәлекле төп сыйфатларын, ни белән һәм нигә өметләнеп яшәвен, кая таба омтылуын яхшы белгән. Кимсетелеп, җәберләнеп килүче халыкларны кара көчләрдән якларга омтылучы буларак, бу бөек гуманист татар халкының характерындагы иң күркәм, иң прогрессив сыйфатларны беренче итеп күрергә тырышкан, рус укучысына да иң элек шул яхшы сыйфатларны күрсәтүне максат итеп алган булса кирәк.

М. Горькийның байтак кына мәшһүр әсәрләренең идеясе Казанда яшәгән чагында туган дияргә була. Кайбер әсәрләренең язылуына, һичшиксез, безнең тирәдә булып узган төрле вакыйгалар һәм очрашулар сәбәпче булган. Без, минемчә, моның белән дә, ягъни бөек әдипнең иҗатына Казан һәм Идел буе халыкларының зур уңай тәэсире белән дә хаклы рәвештә горурлана алабыз.

Иксез-чиксез Россия киңлекләре буйлап ил гизәме, зәңгәр диңгезләрнең арьягында чит илләрдә яшиме, кайда гына булмасын, М. Горький үзенең Идел буендагы дусларын беркайчан да онытмаган. Татарстанның 10 еллык бәйрәме алдыннан, республика хөкүмәтенең аны кунакка чакыруына җавап буларак, М. Горький 1930 елда Соррентодан болай дип язган:

«Татарстан республикасы халкына чын күңелдән сәлам. Хезмәтчел татар халкының рус эшче халкы белән дусларча берлектә үз тормышын үзе корырга хаклы булган көннәренә кадәр яшәвемә мин бик шатмын... Милләтләрнең бердәмлегенә уңайсызлап торган киртәләрне җимерүче кешеләр яшәсен!

Мин яраткан татарларның Совет Социалистик Республикасы яшәсен!»

Татар зыялыларының да Горькийга ихтирамы зур булган. Аның әсәрләрен революциягә кадәр үк яратып укый башлаганнар. Минемчә, бу бик табигый хәл. Чөнки ике катлы изелү, полиция күзәтүе, цензура кысуы астында яшәп, иркен бер сулыш алырга, үз теләгән белдерергә бер мөмкинлеге дә калмаган алдынгы интеллигенция матбугатта яңгырап киткән һәр кыю фикерне ул вакытта ләббәйкә дип каршы алган, яңалык егъдә итүче һәр яктылыкка бөтен көче белән омтылган. Әле кайчан гына Казанда грузчик һәм бакчачы, икмәк пешерүче һәм дворник булып эшләгән гади рус егетенең озак та үтмәстән, кояшка таба очып менгән мифик космонавт Икар кебек, әдәбиятның югары баскычларына күтәрелүе ул шартларда игътибарны үзенә җәлеп итәрдәй, сокланырдай гаҗәеп бер хәл түгелмени! Шуңа тагын ул биеклеккә аны зур таланты гына түгел, бәлки искиткеч тырышлыгы, фидакарь хезмәте күтәрүен дә өстәсәк! Шул рәвешчә, Горькийның шәхси яшәеше, тормыш юлындагы кыенлыкларны батырларча үз көче белән җиңеп чыгуы, полициядән курыкмаслык, патша «хәзрәтләренә» тел-теш тидерерлек көчкә ия булуы, бик күпләргә рухландыргыч үрнәк булып хезмәт иткән дип әйтергә мөмкин. Шунлыктан, Горькийның «Язгы мелодияләр»е Казан эшчеләре арасында матбугатта күренү белән үк таралып өлгерә. Әмма полициянең бу «крамоладан» коты чыга да аны тиз генә җыеп алалар.

Ләкин тормыш хакыйкатен мәңгелеккә биклэп куюмөмкинмени! «Давыл хәбәрчесе»ндәге ирекkә өндәүче ялкынлы сүзләр, Горький пьесасындагы эшче Нил фикерләре татарча һәм русча яшерен өндәмә һәм прокламацияләрдә басылып чыга. Горькийның хөррият һәм кешелек горурлыгы хакында әйткән кыю фикерләре солдат казармаларына, эшче баракларына үтеп керәләр. Алар беренче Рус революциясе көннәрендә ирек өчен көрәш юлына баскан хезмәт кешеләренә дәрт бирәләр.

Мәгълүм ки, Россиядә реакция котырынган елларда моның шаукымы прогрессив язучыларга да бик каты бәрелә. Горький исеме тирәсендә дә шау-шу кубаралар. Казанда һәм Петербург белән Мәскәүдә чыга торган буржуаз матбугатта Горькийның авторитетын төшерү, әсәрләренең тәэсир көчен киметү нияте белән, аның өстенә төрле чүп өяргә, язучы буларак аны кимсетергә, аңа булмаган төрле гаепләр ташларга керешәләр. Имештер, Горький әсәрләренең әдәби кыйммәте бик түбән, имештер, ул соңгы вакытта игътибарга лаеклы әллә ни бирә алмады һ. б., һ. б.

Татар халык мәкале «Башка яла ягылганда, яклый торган дус булыр» ди. Нәкъ шуның кебек кара реакция елларында (1908) татар пролетариат әдәбиятының башлап җибәрүчеләреннән берсе булган Гафур Коләхметов, үз әсәрен буржуаз матбугатка капма-каршы куеп, «Яшь гомер» пьесасының титул битенә:

«Бу әсәр мәшһүр рус мөхәррирләреннән Максим Горькийга тәкълидән язылмыштыр», дип язып чыга. Татар артистлары М. Горькийның «Мещаннар» пьесасын сәхнәгә куярга рөхсәт сорап, цензурага мөрәҗәгать итәләр. Цензура рөхсәт бирмәгәч, алар пьесаны яшерен рәвештә хәзерләргә керешеп, аның премьерасын 1917 елның Октябрь көннәрендә күрсәтәләр.

Утызынчы елларның кайбер әдипләре Горькийны бөтен җир йөзенә яктылык бәркеп торучы язгы кояшка, икенчеләре югары күтәрелгән һәм алга, биеклеккә өндәүче кызыл байракка охшаталар. Бу сүзләр, һичшиксез, чын күңелдән әйтелгән, алар язучыларның бөек әдипкә тирән ихтирамын һәм мәхәббәтләрен белдергәннәр.

Шулай да бу охшатулар Горькийның шәхес буларак рухи үзенчәлегенә, аның холкына юш килмәстәй артык күперенке төс алмыйлармы икән! Горький буй җитмәстәй биеклектә торып башкаларга акыл сатып утыручылар кавемендә исәпләүне һич өнәми торган кеше иде. Әгәр мондыйрак охшатулар аның колагына чалынса, ул, һичшиксез, каршы чыгар, җитмәсә, бик яман ачуланып ташлар иде.

Алексей Максимович Горькийның иҗтимагый һәм әдәби аренага чыгуы Россия халыкларының язмышы берничә гасырга алга таба хәл ителгән вакытка туры килде. Андый тарихи бөек үзгәрешләр чорында шундый романтик рухлы, шул ук вакытта, киләчәкне ерактан ук күрергә сәләтле булган реалист бер көчнең пәйда булуы

ифрат дәрәҗәдә кирәк, хәтта зарури иде. Рус әдәбиятын һәм гомумән күп милләтле совет әдәбиятын хәзер ансыз күз алдына китерүе дә кыен.

Татар совет әдәбияты яңа гына оешып, яңа гына аякка баскан елларда мин әле әдәбиятка килер-килмәс кенә йөрүче тәҗрибәсез бер һәвәскәр идем. Шулай да әдәбиятның төп көчләре, аны әйдәп баручылар төрле «изм»нарга, берсен-берсе инкарь итүче төрле төркемнәргә бүленеп, үзара кылычларын чәкәштергәндә, алардан чәчрәгән очкыннар безнең өскә дә сибелде. Андый чорда шундый бәхәсләр, аяусыз бәрелешләр булуы гаҗәпмени! Халыкның моңарчы гасырлар буенча басылып, кысылып яткан иҗат көче Октябрьда азатлык алу белән, киң дөньяга чыгарга омтыла башлый. Таң калырдай шундый үзгәрешләр, шундый көрәш эпопеясе хакында тизрәк аваз саласы килә башлап, ялкынлы итеп, бөтен дөньяга ишетелердәй яңгыравыклы итеп әйтү, шуның өстенә тагын, бөтенләй яңача әйтү теләге уяна.

Ләкин ничек! Дәрт бар, дәрман юк дигәндәй, тәҗрибә җитенкерәми. Менә шундый шартларда партиянең әдәбиятка дөрес юнәлеш бирүе өстенә, М. Горькийның зур тәҗрибәсе, тирән белеме, аның акыллы киңәшләре бик күп язучыларны халык мәнфәгатеннән, партиянең бөек идеалларыннан читкә алып китәрдәй тар сукмакларга тайпылудан саклап калды. Ул үзенең бөтен иҗаты белән чынбарлыкны ничектер яңача күрергә, революциянең һәм гомумән яшәешнең асыл мәгънәсен тагын да тирәнрәк аңларга, художникларча күрергә, аны тагын да ялкынлырак сөяргә ярдәм итте.

Горькийның һәрвакыт, һәр тармакта нинди дә булса яңалык ачарга, нәрсәнедер булдырырга, табарга, оештырырга, яңартырга омтылуы, гомумән аның ифрат та эшчән кеше булуы мине хәйран калдыра иде. Аның тынгысыз акылы нәрсәгә генә барып юлыкмасын, ул һәр тармакның аңа кадәр игътибардан читтә калып килгән нинди дә булса бер яңа яки әһәмиятле ягын ачты.

Әйтик, әкиятләр һәм җырлар аңа кадәр тегеләй дә, болай да ничек кенә иләнмәгән, бөтен дөнья матбугатында халык иҗаты ничек кенә җентекләп тикшерелмәгән дә, ул хакта ниләр генә язылмаган!! Болай карауга ул турыда берәр яңа сүз әйтергә урын да калмаган, әйтеләсе күптән әйтелгән кебек иде. Әмма язучыларның беренче съездында Горькийның фольклор турындагы фикерләре белән танышкач, миңа бу өлкәне ул бөтенләй яңадан ачкан кебек тоелды.

...Горькийның үз урамыннан бара торгач, мин аның бакчадагы сыны янында туктыйм. 80 еллар чамасы элек Алеша Пешков төрле авыр уйлар белән газапланып, якты хыяллар белән мавыгып йөргән борынгы урамнарга ул хәзер бакыр Горький булып, тыныч кына карый. Әмма әгәр ул үзе сөйгән татар халкының хәзерге башкаласын күреп торса, халык ирешкәннәр турында белә торган булса, ул хакта, һичшиксез, ничектер бик үзенчә, нәкъ Горькийча итеп нидер әйтер, үтемле һәм матур итеп, көчле итеп әйтер иде.

Менә өч урам чатында аның төп йорты. Шушы музей йортына ел саен килә торган 80—90 мең кешене, биек пьедесталда торып, Алеша Пешков үзе каршы ала.

«Горький яшь егет чагында Казан халкына икмәк пешереп ашаткан. Олы кеше булып җитешкәннән соң ул бөтендөнья халкына рухани икмәк, социалистик икмәк пешереп калдырган». (ГДРдан килгән Шарметта Мюллерның музей дәфтәрендә калдырган язмасы.)

«Башыма нинди дә булса борчу төшсә, мин шушы йортка киләм. Безнең остазларыбызның берсе монда учак ягып калдырган. Шул учак яктысында безнең хәзерге яшәешебез дә, ата-аналарыбыз тормышы да тагын да ачыграк күренә». (Шул дәфтәрдәге язмалардан.)

Ул учак меңнәрчә кешеләрнең күңелләрендә якты очкыннар кабыза. Ул очкыннар яшәешнең ямен һәм тәмен тирәнрәк төшенергә, матурны матур, ямьсезне ямьсез итеп күрергә ярдәм итәләр.

Бу йортта бөек әдип образы миңа тагын да якыная төшә, күңел күзем алдына тагын да ачыграк булып килеп баса. Шунысы да бар: мин Горькийны, ничектер, юк кеше, вафат кеше итеп түгел, бәлки безнең заман кешесе итеп күз алдына китерәм.

——◆——

*Хәсән Туфан*

# Тәрәзә

Кайсыбыз юксынмый аны,
Кайсыбыз сагынмый соң,
Казанның
Ленин кебек үк
Иң якын, самим дусын,
Кем генә юксынмый соң?.,

Үткәнгә кайту, гомумән,
Шактый ук авыр миңа.
Без әле ничә килербез,
Максимыч, тагын сиңа,
Без әле ничә күрербез
Шушы ук залда дисәм...
Күзләрем талганчылар ла
Карыйсым калган икән...

Гөрлибез йөзләрчә телдә:
Тәнәфес Колонныйда.
Кемнедер эзләп йөри күк
Лидия Сәйфуллина...

Ул чорда әле берәү дә
«Күрәзә» түгел иде:
Болары яшәр... Болары
Нишләр соң? — дими иде.

Кечеләр — зурны, ә зурлар
Кечене яклый иде.
Кыскасы — «кофе чүбенә»
Берәү дә бакмый иде.

Бер кочак шатлык күтәргән,
Ашыккан илче кебек,
Лидия безнең арага,
Уртага килеп кереп,
Максимыч сезне сорый бит! —
Диде ул кызу гына, —
— Әйдәгез, киттек, татарлар,
Картыгыз хозурына!

Күреште безнең белән ул,
Кул биреп, хәлне сорап
Тәнәфес барган арада
Казанга кайткан сымак...

Эчләре пошкан чагында,
Элекке пекарь егет
Татарлар торган урамга,
Бистәгә килгән кебек,
Сөйләште безнең белән ул
Әдәби әти кебек...

Без әле ничә килербез,
Күрербез әле дисәм...
Керфекләр талганчылар ла
Карыйсым калган икән.

Дөрес лә, Теркин, синең сүз:
Тераксез калса йөрәк,
Шундыйда барып шакырлык
Тәрәзәң булу кирәк.

Ул исә нәкъ бит менә шул
Тәрәзә иде, җаным...
Кайда соң нәкъ шул тәрәзә?
Алмашы кем соң аның?

Кайда ул... Утыз ел инде
Рәсәйне байкый күңел.
Күп тә бит өлкәннәребез
Тик алар Горький түгел.

Иң якын дусын татарның,
Сыналган тиңсез дусын
Кайсыбыз сагынмый аны,
Кайсыбыз юксынмый соң...

*1967*

*Максим Горький*

# АКУЛИНА ӘБИ

*1968 елның мартында бөек рус язучысы М. Горькийның тууына 100 ел тула. Шул уңай белән Татарстан китап нәшрияты Горькийның Казан чорына бәйләнешле автобиографик әсәрләрен һәм Казан темасына язылган кайбер хикәяләрен бер китапка туплап чыгара. Бу санда без шул җыентыкка керәчәк яңа тәрҗемәләрнең берсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

Акулина әби, хәер эстәп кайтышлый, көзге бозлавыкта таеп егылып, бик каты имгәнә. Ул, торырга азапланып, урамда тыпырчынып ятканда, аны таныш полицейский күреп, янына килә дә, карчыкны гадәттәгечә «әчкән» дип уйлап, тиргәнергә тотына.

— Тагын салгансың икән, җен карчыгы! Кайчан дөмегерсең инде син? Синең аркада күрмәгән мәшәкать калмады! Ах син... — ди.

Ул карчыкка кырыс карый, тавышы да ачулы, төксе, ләкин боларның берсе дә Акулина әбине каушатмый. Ул полицейскийның яхшы күңелле солдат икәнен, аны юкка җәберләмәячәген, частька озатмаячагын белә. Акулина әбине ничәмә ничә тапкыр урамда яткан җиреннән торгызырга туры килгәне бар бит аңа!

Полицейский аны беркайчан да «каталажка»га озатмый, һәрвакыт өенә озата. Тиргәнә икән, анысы әллә ни түгел, — мәшәкатьләгән кеше не чыннан да тиргәми булмый ләбаса.

Һәм карчык, үзенең гаебен йоларга тырышып, бөтен көчен җыеп, торырга азапланып карый, ләкин ыңгырашып, ах-ух итеп, яңадан сузылып ята.

Полицейский:

— Иске себерке! — дип, аны күтәреп торгыза башлый.

— Никифорыч, күгәрченем, тимә миңа! Имгәнгәнмен, ахрысы.

— Я! Тор! Имгәтерсең сине... Имгәнмәгән кая...

— Никифорович, җа-аным, аягым авырта... уң аяккаем... кагылма, сабыр ит! Үләм.

— Син нәрсә, кортка! Ничек инде ул кагылмаска? Нәкъ кеше күз алдында акырып ятасың. Бер-бер хәл булган икән, әнә теге почмакка китебрәк ят ичмаса...

— Әҗәлем җитте, Никифорыч! Өйгә илтеп куйсаңчы!

— Синең белән генә мәшәкатьләнәсе калган миңа, йөнтәс шайтаннар!.. Извозчик!..

Берничә минуттан инде алар икесе извозчикта баралар. Акулина әби пролетканың төбендә ах-ух килеп утырып бара, караңгы чырайлы Никифорыч исә, кашларын җыерып, карчыкның башын тоткан хәлдә:

— Әй, мунча пәрие! Җитәр инде... шыңшыма!.. — дип, аны юата.

— Авырта бит, күгәрченем, — ди карчык.

— Авыртса, кем гаепле?

— О-ой! Акчам да коелган. Югалтып бетергәнмен, карт тиле.

— Нинди акча ул?

— Сәдака акчасы... җиде тиен акча!

Никифорыч мыек астыннан гына көлеп куя:

— Бик күп икән! Пыф!

— Минем кулда ни чаклы халык бит, җанкисәгем! Һәрбер валчыгы да эшкә ярый аның. Ой! Акрынрак барырга куш әле шул извозчикка.

Никифорыч һичбер сәбәпсезгә, күрәсең, кинәт ачуланып кычкырды:

— Әй, син! Авыл букәне! Авыру хатынны алып баруыңны күрмисеңме әллә? Тигезрәк атлат.

Ул извозчикның аркасына кырыс күз белән карап куйганнан соң, сүзен дәвам итеп, карчык белән инде элеккегә караганда йомшаграк сөйләшә башлады:

— Кулыңда халык, имеш. Бик ахмак карчык син. Пычагыма кирәкме сиңа ул халык? Ха-алык! Җыен йолкыш, жуликлар, әллә нинди кызлар тагын. Ә ул халык ди! Тиле син, кортка, менә нәрсә, һәм зарарлы тиле, — чөнки кешеләрне бозасың... Син булмасаң, алар эшләрләр иде, син аларны тыгындырасың... Алар шат, билгеле, — Акулина әби дә Акулина әби, имеш. Ә үзләре әбинең җилкәсенә менеп атланганнар. Шайтаннар! Камчы белән суктырырга иде аларны, халыкны иркәләп бозма дип, сине дә шунда беррәттән суктырырга иде. Әй-е! Әй! Син... култык таяклы изге җан! Йокладыңмы әллә? Ә?..

Ләкин Акулина әби, башын полицейскийның тезенә куеп хәрәкәтсез чалкан яткан килеш, бернинди җавап кайтармады. Аның бите күгәргән, тешсез авызы яртылаш ачык, күзләре эчкә баткан һәм башындагы ертык соры шәле артка шуышып, аннан, яртылаш чаларса да, әле һаман куе, бөдрә чәче тузгып чыккан иде.

Аңа текәлебрәк караганнан соң, Никифорыч: «Чынлап та имгәнгән, ахрысы, бу», дип уйлап куйды һәм извозчикка эндәшеп: «Үлгәндер бу бәлки?» — диде.

Извозчик хәерче карчыкка иңбашы аша гына күз төшереп алды да кыска гына җавап бирде:

— Хода белсен! Үлмәгән бугай әле.

— Чын, тәне җылы чөнки. Шулай да аны больницага илтергә кирәктер.

— Ник! — диде извозчик, — өе якынрак бит. Әнә генә ич!

Никифорыч бер сүз дә әйтмәде. Извозчик атын ашыктырды:

— Ну, син! Боламык...

Акулина әбине өенә китерделәр.

* * *

Юеш, караңгы подвалдагы кечкенә генә бүлмәдә, тактадан корыштырылган сәке өстендә чалкан яткан әбине исәпләмәгәндә, барлыгы сигез кеше иде. Чаларган чәчле, өсте-башы ертык, эчә-эчә бите-күзе шешенеп беткән илле яшьләр чамасындагы Адвокат өстәл өстендә утыра. Аның сөяркәсе Марька Прощелыга да шунда кунаклаган. Тулы гәүдәле, аңгыра соры күзле ярым дивана ул хатынны барысы да диярлек кызык өчен дөмбәсләргә ярата. Ләкин Марька моңа бер дә үпкәләми, һәрвакыт гаҗәпләнә генә һәм әле генә шаяртып аны муеныннан кочкан яисә кабыргаларын капшаган кешегә түгәрәк күзләрен текәп карап тора. Идәндә дүртәү утыралар: караклык өчен инде өч тапкыр хөкем ителгән унҗиде яшьлек Ярлык; аның остазы, өстенә ертык халат кигән, ябалак күзе төсле түгәрәк яшел күзле, озын чандыр гәүдәле йолкыш Мамочка; хуҗасының акчасын туздырган өчен өч ай төрмәдә утырып, аннан күптән түгел генә ireккә чыккан, сакал-мыеклы, ак чырайлы, олысымак кыяфәтле Петр Исаевич Бух дигән егет һәм Настенька.

Алар «коры куанычка» карта уйныйлар. Банк Настенька кулында. Ул үзенең шактый сөйкемле, ләкин бик нык кыйналу аркасында кара

көеп, суелып беткән йөзен әле бер партнерына, әле икенчесенә таба борып, карлыккан тавыш белән кычкыра:

— Өләшәм! Күпме? Мен суммы? Бара! Йөзлекме? Суктым! Сезнең барыгызны да туныйм мин, җанкисәкләрем! — ди.

Башкалар стена буена караңгыга елышканнар. Ә сәкедә, Акулина эбинең аяк очында, алыптай гәүдәле, сүлпән чырайлы, чем-кара күзле, зур башлы ниндидер монах — Дьякон Атай утыра. Аның кылдай каты кара тузгак чәче салам, мунчала, тавык йоны һәм шуның ише чүп-чар белән бизәлгән.

— Бәрәңге табып уып, ипи белән шуны аягына ябарга иде! — диде стена янында торучы берсе.

Мамочка идәндә утырган җиреннән:

— Оекка уксуслы балчык тутырып, тәннең бәрелгән җиренә куйсаң да әйбәт була, — диде дә пырхылдатып борынын сеңгерде.

— Кешенең бар авыруына да иң шифалы нәрсә аракы инде ул! — диде аңа каршы Дьякон Атай.

Ул арада Акулина эби:

— Күгәрченкәйләрем!.. — дип ыңгырашырга тотынды.

Һәм аның тавышы шундый юаш, шундый кызганыч иде, подвалда берьюлы тынлык урнашты. — Бәгырькәйләрем... бичара балакайларым... Ходай хакына мине берәр нәрсә эшләтегез!.. Суегыз мине... Кадап үтерегез... артык чыдар хәлем юк!.. терелә утта янам... О-ох!..

Карта уйнаучылар бераз каушап калгандай булдылар, барысы да урыннарыннан кузгалдылар, Настенька исә картасын ике тапкыр сул якка салды.

Дьякон Атай үзенең тузгак башын кашырга тотынды, Адвокат, йөткеренеп, ни өчендер терсәге белән Марьканың янтавына төртеп куйды. Тегесе гадәтенчә аңа игътибар итмәде.

Ләкин озакламый барысы да элекке хәлләренә кайттылар.

— Син нишлисең, кара!.. — диде Ярлык Настенькага кырыс тавыш белән. — Яңа баштан тарат...

Настенька, көрсенеп, карталарны җыеп алды да араластырырга тотынды. Адвокат, югары карап, ниндидер эчпошыргыч көйгә сызгырырга кереште.

— Ярый инде, әбекәй, беразга түз, — диде Дьякон Атай һәм җырларга җыенгандай бик каты тамак кырып куйды.

Карчык:

— Түзәр хәлем юк... Балакайларым, бәгырьләрем... — дип инри бирде.

Мамочка аны өметләндерергә тырышты:

— Рәтләнерсең, борчылма... таза карчык бит син, эби...

— Бөтен гәүдәм сызлый.

Дьякон аңа:

— Бернишләр хәл юк, катырак ыңгыраш, алай җиңелрәк була, авыртуны кычкыру белән алдала, — дип киңәш бирде.

— Я ходай! Илаһым! Ой! Нихәл итим... Үләсе иде...

Шул арада Настенька:

— Суктым! Ничаклы откан булыр идем, акчага уйнаган булсак, — дип шатланып кычкырып җибәрде.

* * *

Акулина эби, ыңгырашуыннан кинәт туктап, үзенең урынында ярты сәгать чамасы тын гына кузгалмыйча ятты.

— Карчык йоклады! — диде Дьякон һәм карта уйнаучылар янына барып чүгәләде дә авыз эченнән генә нәрсәдер мырылдарга тотынды.

Адвокат, кашын җыерып, өстәлдән төште, Дьякон урынына койкага

күчеп утырды һәм әбинең йөзенә текәлеп карагаңнан соң, карлыккан тавыш белән:

— Чыннан да... Йоклый!.. — диде.

Ләкин ялгышты ул.

Әби, тешсез авызын ачып, ымсынгандай иренен чапылдатып куйды һәм кызганыч тавыш белән сөйләнергә кереште:

— Никифорыч, дус кеше! Ходай хакы өчен хәер-сәдака җыеп бир... кешеләр көтәләр бит... Җиде тиенне дә эзләп тап, шунда гына ул, койма янынннан капшап кара әле... ике икешәр тиенлек... берсе иске, икенчесе яңарак... Атакаем — барин! Фәкыйрь карчыкка икмәк алырга бер тиен бирсәгезче! Семьям бар. Балакайларым! Әнә ул тубал... ашагыз, бүген күп анда... икмәк. Ә эчәргә юк! Эх! Акчалата бирмиләр шул... Кичке гыйбадәт вакытында булса гына инде.

Л-ларион жаным, иркәм!
Й-йөрергә чыксаң икән.
Мин яшь кенә кыз бала,
Салкында сине көтәм...

Кинәт карчыкның тавышы өзелгәндәй булды һәм ул:

— Тюх! Тюх! Тюх! — дип такмаклап, сәламәт аягын дырылдатып як-якка боргаланырга тотынды.

— Саташа... — диде Адвокат, борын өстен кашып.

Карта уйнаучылар барысы да, идәннән торып, авыру карчык янына җыелдылар һәм кызыксынып елмаеп карап тора башладылар.

Ярлык:

— Кара син аны, бии бит! — дип шаркылдап көлде.

Адвокат күңелсез генә:

— Биерсең, — диде. — Аңа ни дә булса эшләргә кирәк, туганнар, ул чынлап та авырый бугай.

— Аракы бирергә иде. Зур гына бер стаканны тутырып, — диде Дьякон, көрсенеп, иренен ялаштырып.

Мамочка коры гына:

— Больницага озатырга кирәк, — дип, әби яныннан китте.

Кайсыдыр өметсез көлеп аңа җавап кайтарды:

— Алырлар инде анда, алмаган кайда, тот капчыгыңны.

— Анысы да дөрес, кәгазьләре юк бит... — диде Адвокат, аның сүзен раслап. — Аннан тагын ничек озатырга әле. Извозчик кирәк... тегесе, монысы... ә акча?

Настенька:

— Теге юлы Федяшканы илткән төсле, больница янына илтеп ташлап калдырганда... алырлар иде алай! — дигән тәкъдим кертте.

— Илт соң... Яхшы ат булсаң иде син, пролетка гына юк менә, — диде Ярлык көлеп.

— Балакайларым, ашагыз! Кәбестә бөккәне бар анда, бөтен ул... лотоктан чәлдердем, ул читкә караган арада, мин... Никифорыч! Кыйнама мине, әчкече карчыкны...

Адвокат:

— Эх син, әбекәй! — дип көрсенеп куйды.

Почмактан берсенең тавышы ишетелде:

— Ашарыбызга бармы? Ничек?

Мамочка, аңа кушылып:

— Чыннан да ашыйсы иде! — дип куйды.

Ярлык Настенькадан:

— Карчыкның капчыгы кайда? — дип сорады.

Капчыкны эзләргә тотындылар, ләкин тапмадылар.

Бу хәл барысына да начар тәэсир итте.

Кайсыдыр:

— Эх, шайтан! — дип сүгенеп куйды.

Барысы да бер-берсенә карашып алдылар да, бер үк нәрсә турында уйлап булса кирәк, тын калдылар.

— Карчыкка ул-бу була калса, без ничек туенып торырбыз икән, туганкайлар? — диде Дьякон мескен тавыш белән.

— Әй-е-е!

— Чынлап та?

— Дөресен әйткәндә, карчыкның хәер-сәдакасы белән үлми яши идек бит!

— Хәзер үзебез турында үзебезгә кайгыртырга туры килер: карчыкның башына життек, — диде Адвокат кырыс гына.

Барысының да чырае караңгыланды һәм гәүдәләре бөрешеп калгандай булды.

Акулина әби саташып сөйләнә бирде:

— Ашагыз, балакайларым, мин исән чакта... Мин сезне...

Ә аның кадерле оныклары, бу хәлнең чын мәгънәсен аңлагач, бик уңайсызландылар.

* * *

Акулина әби Задняя Мокрая урамының филантропкасы иде. Ул хәер-сәдака җыя һәм өстәмә кәсеп рәвешендә, җае туры килгәндә, бераз урлаштыра да иде. Аның янында һәрвакыт биш-ун «онык» сыенып яши, һәм ул аларның барысын да ашату, эчертү җаен таба. Ул «оныклар» төрле сәбәпләр аркасында вакытлыча үз кәсепләре белән шөгыльләнә алмаган, тәмам эштән чыккан эчкече сукбайлар, караклар, фахишәләр була иде.

Акулина әби кешеләрнең игътибарга лаеклымы, лаексызмы икәнен аера белми һәм язмыш аның землянкасына китереп керткән кешеләрнең барысына да бердәй җылы, ачык чырай белән карый иде.

Аны бөтен урам белә, һәм аның даны күрше урамнарга да чыккан. Ләкин шулай да «аның оныклары рәтенә эләгү» сукбайлар һәм хәлдән тайган мескеннәр телендә иң авыр хәлгә төшү дигән сүз иде. Шуңа күрә Акулина әби үзе тормыш җайсызлыкларының иң соңгы чиген гәүдәләндерә дияргә була һәм яхшылык итүе белән зур дан казанса да, үзенә сыенган кешеләрнең мәхәббәтен казана алмый иде.

Аның янында көн кичерүнең бер бик җайсыз ягы да бар: аны полиция үтә яхшы белә һәм үзен кызыксындырган берәр бәндәне эзләгәндә һәркайчан диярлек иң элек Акулина әби землянкасыннан эзли башлый. Ачлы-туклы булса да, әле ничек тә көн итә алырдай сукбайлар әбигә якын юламыйлар, бары тик бөтенләй өметсез хәлгә калу һәм киләчәктә ачлыктан үлү куркынычы гына кешеләрне аның янына куып кертә иде.

Шуларның барысы өстенә Акулина әбинең тышкы кыяфәте дә бик шыксыз иде. Ул тәбәнәк буйлы, һәрвакыт диярлек ярым исерек, искиткеч шакшы, сәләмә киемнән була. Үзенең «оныклары» ук ясаган яраларның җөйләре аның җыерчыклы битен тагын да ямьсезләтәләр. Һәрвакыт кызарып яшьләнеп торган күзләре янында бүртенгән кызыл борын калкып тора. Карчыкка урамда күптән инде «убырлы карчык» кушаматы такканнар һәм бу кушамат аңа бик туры килә иде. Картлык аркасында гәүдәсе дугадай бөгелгән ул карчык кулындагы таягы белән җиргә тук-тук бәреп, тешсез кара авызы белән һәрвакыт елмаеп, үз алдына сөйләнеп барган чакта, җирәнгеч, сасы тере пычрак кантары булып күренә. Әйе, аның кеше күңеленә ошармын дип өметләнерлеге калмаган инде. Ләкин шулай булуга карамастан, карчык, үзенең бәхетсезлегенә каршы (хәер, аның бәхетсезлек икәнен ул үзе сизмәгәндер дә бәлки), кешесез яши алмый һәм язмыш аның янына «оныклар»

куып кертмәгән чакларда, Акулина әби язмышның шул игътибарсызлыгын төзәтергә тырыша һәм иртә алган кешеләрне үзе иртеп алып кайта иде.

«Җәмгыять ташландыклары» дөньясы дип йөртелгән хәсрәтле һәм моңлы дөньяның үз эчендә дә читкә кагылган кешеләр була һәм Акулина әби шундыйларның берсе иде.

* * *

Ярлык, гомуми киеренке тынлыкны бүлдереп:

— Менә сиңа мә! — дип кычкырып куйды.

— Безнең эшләр хөрти! — диде Дьякон.

Адвокат та караңгы чырай белән аларның фикерен раслады:

— Соңгы куышыбыздан мәхрүм булдык!

Мамочка аны тынычландырырга теләгән тавыш белән:

— Куышы безгә калыр анысы, — диде. — Ләкин бүген ничек, нәрсә белән туенырбыз — менә шунсы бар.

Дьякон күңелсез генә:

— Әй-е, бүгенгә көндә без ризыктан мәхрүм, — дип куйды.

— Чыйкылдарсың, мыйкылдарсың да буш корсак белән ятып йокларсың, — дип көлде Ярлык.

Авыру карчык, күзен ачып, акрын гына:

— Балакайларым... су бирегезче... — диде.

Настенька аңа су китереп бирде. Эчеп туйганнан соң, карчык калтыранган кулы белән чукынды да, барысына да күз йөртеп чыкты. Аннан соң, авыр көрсенеп, чүпрәк өеме өстендәге башын әллә ничек сәер кузгатып куйды.

Һәм хәлсезлектән калтыранганга күрә элеккедән дә ямьсезрәк яңгыраган шыгырдавыклы тавышы белән сөйли башлады:

— Ярабби, сез ничаклы! Әнә тегесен мин белмим... син кем соң?

— Мин — Бух...

— Ярый, Бух булсаң — Бух бул, алла юлдашың булсын... Барыбер син дә кеше. Без барыбыз да кешеләр. Менә мин үләм инде, туганкайларым. Үләм мин, алла юлдашыгыз булсын! Яшәдем, гөнаһларым булды, эчтем, урладым... Менә үләрмен дә андый эшләрнең берсен дә эшләмәм инде.

Дьякон шаяртып:

— Анысын дөрес әйтәсең, үлгән кешенең беркайчан да эчәсе килми торгандыр, — дип, аның сүзен җупләп куйды.

Әби аңына килгәч, бүген бәлки берәр нәрсә ашарга мөмкин булыр дигән өмет туган иде аңарда.

— Күңел берни дә теләми, әйе. Сез мине гафу итегез... Алла да сезнең барыгызны да гафу итәр. Мин карчыкны яратмый идегез сез, ярый, анысы сезнең эш. Мин сезне ярата идем, билләһи!.. Бәхил булыгыз, алланың рәхмәте яусын сезгә!

Карчык тагын чукынды.

— Ул сүзеңне ташла, әбекәй, — диде Адвокат сүрән генә. — Торырсың әле... бераз ятарсың да аягыңа басарсың...

— Юк, тормам инде. Бөтен гәүдәм ватылган, бавырым имгәнгәндер, мөгаен. Күрәсезме ничек янам... Бәхил булыгыз!

Мамочка:

— Куй әле, әби! — дип аның сүзен бүлдерде. — Син менә шуны әйт: бүген берәр нәрсә җыйдыңмы?

— Минме? Зиһенем таралган, хәтерләмим. Җыйдым, бугай... Ничек җыймаска? Һәрвакыт җыя идем бит...

— Ә кая китте соң ул җыйган әйберең? — диде Дьякон.

— Белмим... Кем кутэреп торгызды соң мине? Никифорычмы? Анардадыр...

— Бар, Настенька, йөгереп кенә барып, белеп кайт.

— Шундый кыйналган бит белән урамга чыгам ди мин!

— Үзеңне алып бәрсәм, җәяүләп түгел, очып барырсың!

— Иблис!

— Тиргәшмәгез, балалар... Кирәкмәс... нинди дә булса бүтән төрле сүзләр иштеттерсәгез иде миңа. Үләм бит... ышаныгыз — үләм. Менә нәрсә, балакайлар: баш очымда бәләкәй тартмада кәгазь өч сумлык бар... аны үземә гробка... хәстәрләгән идем... мин үлгәч... алыгыз ул акчаны...

Аның тыны кысылды, маңгаена тир бәреп чыкты...

Барысы да, житди кыяфәт белән күзләрен карчыкка текәгән хәлдә, тып-тын тордылар, һәм бу тынлык бер-ике минут дәвам итте. Аннан Дьякон сүз башлады:

— Акулина эби...

— Әү?

— Менә нәрсә, минем сүзгә хәтерен калмасын. Тик мин шуны әйтәм... үлгән кешегә барыбер... сиңа берни дә кирәкми, ә без тере кешеләр. Сиңа нәрсә? Гробта яттың ни, гробсыз булдың ни... барыбер; гробны һәрвакыт полиция дә бирә. Син өчлегеңне безгә бир, — без тамак ялгап алыр идек.

Адвокат:

— Син ни сөйлисең... кирәкми, — дип пышылдады.

Дьякон башкаларга күз йөгертеп чыкты һәм барысының да, бу эшнең ахыры ни белән бетәр икән дип, комсызланып көтеп торганнарын күрде. Аннары:

— Безгә дә үләргәмени инде? — дип шыпыртлап кына җавап биргәннән соң, карчыкка таба иелеп: — Ничек соң? Алыйкмы? — дип сорады.

Акулина эби, авызын ачып, иреннәрен чапылдатканнан соң, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Алыгыз. Мин дә шул карт тиле... Кара инде, үләр алдыннан сезне оныта язганмын... алыгыз. Менә монда... әйе, шулай шул... гробны полиция дә бирер... тиле карчык, — диде.

Шулай диде дә тынды.

Дьякон, карчыкның баш очындагы бәләкәй генә ак кәгазь тартманы тартып чыгарып, тантаналы кыяфәт белән:

— Ярлык! Бар, оч! Җилдерт! — дип пышылдады.

Ярлык, йөзен чалшайтып, күздән югалды.

Сизгер Дьякон башкаларга:

— Без карчык яныннан читкәрәк китик, кешегә тынгылык бирергә кирәк, — диде.

Барысы да Акулина эби тирәсеннән читкә тайпылдылар. Карчык чүпрәкләр өеме өстендә бер үзе ятып калды. Аның соры йөзе чүпрәкләр фонында тагын да аермачыграк күзгә ташланды. Ул хәрәкәтсез ята һәм тик ара-тирә генә ишетелер-ишетелмәс ыңгырашып куйгалый иде.

Аның ни вакытта үлгәнен берәү дә сизмәде.

* * *

Аны икенче көнне күмделәр. Гроб арба өстенә куелган. Арбаның бер як читеннән, кулына эш язулары тараткандa йөртә торган кнәгәсен тотып, Никифорыч атлап бара. Икенче яктан баручы ялан башлы извозчик аңа мыгырданып зарлана иде:

— Мин дөресен әйтәм. Ярагаи эшме инде шул? Кешене тотып ал да — син илт диген! Менә алып барам! Ә миңа бер сумны кем өстәп бирер? Ә-ә? Мин икмәк базарында бер ярым сумлык эшләгән булыр идем, ә монда миңа илле тиен көмеш төртерләр. Ә соңыннан анда эләгеп булмаячак. Сезнең белән күпме вакыт маташырмын әле? Ә илле тиен атка ашатырга да җитми, менә нәрсә, дус кеше.

Ләкин Никифорыч извозчикның мыгырдавына игътибар итмәде. Үз гомерендә күпне күргән ул карт солдат белән янәшә бөтенләй бөгелеп төшкән Адвокат бара. Үзе ялан баш, колакларын керле чүпрәк белән бәйләгән, кулларын ниндидер сәләмә кыска кием кесәсенә тыккан. Никифорыч аңа бик тәэсирле итеп сөйли.

— Сез шайтаннар өчен әни кеше иде бит ул карчык. Салгалый иде салуын, ләкин анысы әллә ни түгел. Урласа да, сезнең өчен урлый иде, күрәсеңме? Һәм менә мин аны озата барам, син дә барасың. Озат дип әйтмәсәләр дә, үзем эштән сорап китеп, карчыкны озата барган булыр идем. Аңладыңмы? Кешеләрне үтәдән үтә күрәм мин, брат. Әй-е. Ә менә син үлсәң... син озакламый үләчәк, брат, мине алдый алмассың, юк, кыяфәтеңнән үк күреп торам: озакламый үләсең син! Ләкин сине озата бармаячакмын, бар дип, җибәрмәсәләр, һич-һич! Чөнки син кем, нәрсә? — Бер күгәрек.

Адвокат, төссез күзләре белән Никифорычка карап, авызын кыйшайтып елмаеп куйды.

— Кирәгең юк, барма...

— Бармам да. Кабергә бер үзең бар.

— Бик исең киткән икән! Барырмын.

— Барырсың шул, — чөнки син нәрсә? Ә карчык сезгә ана иде... Йөрәге бар иде аның. Аңладыңмы?

Җепшек көн, ябалак кар ява иде.

Эре кар бөртекләре Акулина әбинең гробы өстенә лач итеп килеп төшәләр дә буяусыз гади нарат гробы өстендә эреп, аны чылаталар иде.

Задняя Мокрая урамының филантропкасы булган угры, хәерче Акулина әбине әнә шулай күмделәр.

Сәрвәр Әдһәмова тәрҗемәсе.

———◆———

# ТАМЧЫДА КОЯШ ЧАГЫЛА

А. М. Горькийның татар әдәбияты үсешенә көчле йогынты ясавы, әдипләрнең генә түгел, ә бөтен татар хезмәт ияләренең олы ихтирамын һәм мәхәббәтен казануы мәгълүм хакыйкать. Ләкин бөек әдип әсәрләренең татар теленә кайчан тәрҗемә ителә башлавын әлегә кистереп кенә әйтүе кыен. Моңарчы язылган хезмәтләрдә А. М. Горький әсәрләре татар теленә 1907 елда тәрҗемә ителә башлый, дип күрсәтелә. Һәм мисалга Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасына С. Рәмиев тарафыннан тәрҗемә итеп кертелгән «Кояш чыга да, бата да» җыры китерелә иде.

Әмма бу фикер төзәтмә кертүне сорый. Яңа мәгълүматларга караганда, Сәгыйть Рәмиев бу җырны 1906 елда ук тәрҗемә иткән. Җырның тәрҗемә ителү тарихы һәм аннан соңгы язмышы да гаҗәп кызыклы һәм гыйбрәтле.

«Таң йолдызы» газетасы редакторы С. Рәмиевне, революцион-публицистик эшчәнлеге өчен, 1906 елның 21 июлендә кулга алалар һәм төрмәгә алып китәләр. «Мине 4 нче частька илтеп, озынлыгы өч аршин, киңлеге ике аршин бер тар камерага кергезеп, өстемнән шаптыр-шоптыр китереп йозаклап алдылар», — дип яза ул соңыннан «Йорт басучылар» дигән мәкаләсендә.

Мәкалә «Таң йолдызы» газетасының 1906 елгы 20 санында басылган. С. Рәмиев төрмәдә үткән көннәре, шул көннәрдә кичергән уйлары турында яза һәм болай ди: «Максим Горькийның «Солнце всходит и заходит, а в тюрьме моей темно» дигән җыры искә төшеп, шуны җырларга тотындым. Ул төрмәдә вакытта бигрәк тә яхшы чыга икән һәм дөресрәк тоела икән; миннән соң керcharacterгән кешеләргә укырга булсын дип, шул җырны тәрҗемә итеп:

Кояш чыга да, бата да,
Төрмәм мәңге караңгы;
Көннәр-төннәр зобанилар, их,
Тәрәзәмне караулый.

Караулагыз теләгәнчә,
Мин барыбер качалмыйм,
Бик шат качар идем дә шул, их,
Богавымны ачалмыйм...

дигән сүзләрне язып куйдым».

Күрәсез, җыр, төрмәдә тәрҗемә ителеп, беренче тапкыр 1906 елның 21 июлендә камера стенасына язылган икән. Соңыннан шагыйрь аны тагын да җентекләбрәк эшкәртә һәм ул 1907 елда Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасында да урын ала.

С. Рәмиев бу җырны гаҗәп зур осталык һәм аһәң белән тәрҗемә итә. Татар халкының үз күңеленнән чыккан, үз телендә туган җыр шикелле ул. «Марсельеза» һәм башка революцион җырлар кебек үк, ул татар хезмәт ияләре, завод-фабрика эшчеләре, укучы яшьләр арасында бик тиз тарала.

...Рус халкы күңелендә туган азатлык идеяләре, бөек Горький иөргә аша үтеп, татар халкының да рухи хәзинәсенә әверелделәр. Бу хәзинәне татар халкы иң авыр, иң караңгы елларда да югалтмыйча, күңел түрендә саклап килде. Кара реакция чоры башлангач, бик күп революционерлар, богауланып, сөргенгә озатылдылар. Алар үзләре белән ялкынлы һәм моңлы, дәртле һәм күтәренке җырларын да йөрәкләрендә саклап алып киттеләр. Алар арасында М. Горький җырының татарча тәрҗемәсе дә булган. Ул Себердә «Каторжаннар җыры» дигән исем белән киң таралган һәм безнең көннәргә хәтле сакланган. Җырга яңа строфа өстәлгән. Бу строфада тоткында яткан революционерларның коллыкта газапланган хокуксыз халыкны якты, азат тормыш өчен көрәшкә чакыруы яңгырый:

Әй туганнар, без бушаныйк!
Бу хәлгә чыдау бармы?!
Тартыйк-өзик, җимерик-ватыйк
Зобани богауларны!

Бу җырны 1959 елның июлендә Себергә оештырылган фольклор экспедициясе члены Р. Кәримов Омск өлкәсе Качуново авылында яшәүче 76 яшьлек пенсионер М. Салиховтан язып алып кайткан иде. Соңгы строфа С. Рәмиевнең үзе тарафыннан өстәлгән булганмы, әллә соңыннан башкалар тарафыннанмы, әлегә билгесез.

Бу җыр — бер факт. М. Горькийның олы иҗат диңгезеннән бер тамчы гына. Ләкин җем-җем итеп торган шул бер тамчыда да даһи язучы күтәргән гуманистик идеяләрнең мәңге сүнмәс кояшы чагыла.

ШӘЙХИ САДРЕТДИНОВ

*Бәйрәмегез белән котлыйбыз,*
*хөрмәтле хатын-кызлар!*

*Клара Булатова*

●

Еллар миңа миһербанлы булды.
Юк, зарлана алмыйм язмышка.
Яшьлек баерак, кыйммәтлерәк була
Икенче кат килсә тормышта.
Тәүге яшьлек ул һәркемдә була,
Ул тормышның тигез бүләге.
Ә бусын мин үзем яулап алдым,
Җаным аңа кыйммәт түләде.
Җаным аңа кыйммәт түләде шул,
Җыеп яшим барын бер юлы:
Шатлыгымда хәсрәт орлыгы бар,
Хәсрәтемдә бәхет орлыгы.

●

„Мин зур үскәч...» — дибез бала чакта.
Үзе генә шушы сүз безгә
Әллә ниләр инде вәгъдә итә,
Әллә ниләр
Килер кебек безгә.

«Мин зур үскәч...» — дибез,
Шушы сүзгә
Хыялларны теркәп сөйлибез.
Сәгать, көнне,
айны, елны куып
Зур үсүне көтеп йөрибез.

Ә зур үскәч,
тик бер кайтыр өчен
Гамьсез үткән якты көннәргә
Бу зурлыкның барын бирер идек,
Бирер идек әллә ниләр дә.

●

Табигатьтә, җирдә күпме сөю,
Бер-берсенә гашыйк бары да:
Иркәләнеп дымга гөлләр сыена,
Ишкәкләргә дулкын сарыла.

Бу дулкында күпме тормыш кайный,
Күпме саллар аның өстендә.
Яр көнләми аны, яр күпсенми,
Яр тикшерми аның берсен дә.

Бу агымга бары ышана ул,
Бу агымга барын кичерә.
Шушы ярлар кебек олы җанлы
Булсын иде барлык кеше дә.

Иркәләнеп дымга гөлләр сыена,
Ишкәкләргә дулкын сарыла.
Җир өстендә күпме үлчәүсезлек,
Җир күтәрә шуның барсын да.

●

Яр буйларын томан урата,
Томан төшсә ярлар дым тарта.
Томан төшсә, ярлар, ай, дым тарта,
Томан төшсә, җанда моң арта.

Яр буйларын томан урата,
Томанлы яр сагыш уята.
Син ул якта, томан, ай, бу якта,
Син булган яр нигә еракта!

Яр буйларын томан урата,
Пәрдә кора томан суларга,
Томаннарны ярып ике якка
Чыгар кебек булам юлларга.

*Гөлшат Зәйнашева*

## Йозак

Нигә, дисәм, ишек-капкаларыбыз
Бикләнә йозаклап! —
Йозак бит тора гаделлекне саклап,
Яманлыктан яклап.

Ишек-капкалар бикләнмәсен иде,
Бетсен иде йозак.
Биксез ишектән йөреп, кешенең
Булсын иде йөзе ак!..

●

Яңгырдан соң сызылып киткән
Салават күпере кебек,
Сызылдың син күңелемдә
Төрле төсләргә кереп.

Сызылдың ал, яшел булып,
Дөньям яктырып китте.
Күзләреңнән күзләремә
Җылы нур явып үтте.

Миңа гына ява микән
Синең күздән җылы нур!
Мөмкин булса, гомер буе
Миңа шулай җылы бул!..

*Фирая Шиһапова*

## Күңелле

Җир сылуга туры карап,
Кояш-егет көлгәнгәме;
Тирә-юньне нурга күмеп,
Ап таң туып килгәнгәме,
Белмим, никтер, бик күңелле миңа.

Әллә инде көмеш чыклар
Җем-җем итеп күз кысканга;
Әллә инде җиркәемне
Охшатканга Гөлстанга,
Белмим, никтер, бик күңелле миңа.

Зәңгәр күктә ап-ак, ап-ак,
Бөдрә болыт йөзгәнгәме;
Күңелкәем таң җиленең
Иркәләвен сизгәнгәме,
Белмим, никтер, бик күңелле миңа.

Дусларымның һаман көләч,
Гел шат йөзен күргәнгәме;
Я кояшның иртәгә дә
Чыгачагын белгәнгәме,
Белмим, никтер, бик күңелле миңа.

## Тамчылар

Көмештәй тамчылар
Кояшка күз кысып,
Асфальтка сикерә
«Тып»та «тып», «тып» та «тып».

Тәңкәләр чыңлаган
Тавышлар чыгарып,
Биешә тамчылар:
«Тып» та «тып», «тып» та «тып».

Кара син аларны
Җырыннан туктатып!
Сикерешә тамчылар:
«Тып» та «тып», «тып» та «тып».

*Вәсимә Хәйруллина*

## Төнге урман

Карт имәннәр башкайларын иеп,
Кочаклашкан килеш оеган.
Йокы аша каен көлеп куя,
Болытларга ак ай сыенган.
Ай әкият сөйли.
Шомлы, ахры —
Усак әнә куйды чымырдап...
Тынычлыкны бозган ат артыннан
Ачулана ак кар шыгырдап.

## Чулпы җыры

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңнарына
Кушып парлы чиләк моңнарын,
Иңнәренә көянтәсен салып,
Каршылаган алар таңнарын.

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңнарына
Кушып җитеш урак җырларын,
Ай урагын айда ялтыратып,
Гизгән алар иген кырларын.

Чулпы чыңы кебек яшьлекләре
Әбиләрнең күптән еракта.
Чулпы җыры булып оныкларның
Тавышлары чыңлый
колакта.

## Әнисә

Ап-ак халатын кия дә,
Косынкасын чөя дә,
Узып китә минем яннан,
«Саумы, абый» — дия дә.
Сизмидер шул мин сөйгәнне,
«Абый» дия Әнисә.
Алай зурлап эндәшкәнче,
Ни була «җаным» дисә.

●

Урамда ата һәм бала.
Бала сорый атадан:
— Әти, теге машинаның
Исеме ничек атала!

— Тора телемнең очында,
Оныттым бит ләбаса.
— Телеңнең очында булгач,
Телең күрсәт алайса!

——◆——

*Фатих Хөсни*

# ЗАМАНАЛАР ҺӘМ ЯЗМЫШЛАР

Монда сүз, барыннан да элек, хатын-кыз язмышы турында барыр. Дөресен генә әйткәндә, сүздән түгел, җырдан башларга кирәк булгандыр, бәлки. Әйе, әйе, алар — сөя һәм иркәли белүче, кешелек дөньясының нарасый чорын күкрәк сөте белән туендырып торучы, вакыты белән тиргәп, вакыты белән назлап, безнө, ирләр токымын, корытмыйча алып баручы, башкалар өчен шатлык тудырып, үзләре кай арада зур гына кайгыларны да эчләренә йота килүче ул кешеләр — хатын-кызлар, дөньяның барлык хатын-кызлары — алар соң мактау җырына лаек түгелмени! Кайдадыр, Норвегия җирендә, дуслар мәҗлестә утырганда:

— **Син яшә, мин яшим.**

**Дөньядагы барлык матур хатын-кызлар яшәсен!** — дигән сүзләр белән үзара тост әйтешәләр, имеш. Норвегия халкының бу матур тостына кушылганым хәлдә, мин аны шулай да:

— Дөньядагы барлык кешелекле хатын-кызлар — матурлары да, ямьсезләре дә — яшәсен! — дип, яңадан редакцияләр идем. Шулай булгач соң, барлык бөек художникларның да диярлек иҗатларында, әллә кайдан ук балкып торучы «йөзек кашы» булып, хатын-кыз образы гәүдәләнүе гаҗәпмени. Кыскасы, алардан башка тормыш булмаганы кебек, алардан башка сәнгать тә юк.

Зурдан кубып, дөньяны һәм тыныч кына яткан Норвегияне кузгатып башлаган бу мәкаләмдә мин, хәлбуки, гаять конкрет бер нәрсә турында — татар әдәбиятында сурәтләнгән кайбер хатын-кыз образлары турында үземнең уйлануларымны бүлешмәкче булам. Әлбәттә, барлык хатын-кыз образлары турында түгел. Телгә алынганнарының да барлык якларын әйтеп түгел. Чөнки татар әдәбияты — үзенең күп кенә классик үрнәкләрендә дә, бүгенге торышында да — хатын-кыз образларына бай әдәбият ул. Ул образларның берсен икенчесенә якынайта торган яклары булган кебек, берсен икенчесеннән аерып тора торган үзенчәлекле характер төрләре дә күп. Әйтик, революциягә кадәрге әдәбияттан Ш. Камалның Газизәсен («Акчарлаклар») алыгыз. Басынкы һәм моңсу, һәр яктан тыйнак һәм яшертен сөя белүче бу шигъри күңелле гади татар кызы образын, шул ук революциягә кадәрге әдәбияттан, кем белән булса да чагыштыру мөмкинме соң? Кыскасы, күп һәм төрле алар. Аларны бер омтылуда гына кочып алу, гәрчә нәфесең бик зурдан булса да, мөмкин эш түгел.

Ә менә социаль активлыкларының ачыла бару ноктасыннан карап, бигрәк тә революция йогынтысында хатын-кыз язмышында килеп туган үзгәрешләр турында уйланырга бик мөмкин һәм кирәк.

Бу очракта мин, конкрет булырга теләп, барыннан да элек, әдәбиятыбыздан өч образны — өч исемне телгә алам. Болар: Хәят, Нәфисә, Халидә образлары. Төрле жанрда, өчесенә өч төрле темперамент салынып, өчесе өч каләм белән язылган бу өч персонажны бу очракта уртак бер тема — чорына һәм заманына карап хатын-кыз язмышындагы социаль активлыкның ничек ачыла баруы темасы берләштерә.

Менә әдәбиятыбызның классик вәкиле Фатих Әмирханның бик тә яратып, ә бәлки, билгеле бер дәрәҗәдә үз чоры хатын-кызының канат ярып килүче яшь үрнәге итәргә тырышыптыр, язган һәм заманында яшьләр арасында кайбер шау-шулар кузгатырга сәбәп булган Хәят образы. Сүз дә юк, үзенең Хәятыннан бизәкләрен һәм

күңел нурын җәлләмәгән Фатих Әмирхан. Хәят яшь тә, матур да, үзенә игътибарны җәлеп итәр дәрәҗәдә чак-чак кына кыланчык та. Һәм аны, язучының үзеннән башлап, бөтенесе дә ярата. Үзенең якын танышлары, бала чактан бергә үскән дуслары да ярата аны, ул бөтенләй яратмаган кешеләр дә ярата. Һәм сез аның үзе яратмаган кешеләргә карата булган мөнәсәбәтенә игътибар итегез. Яшьлек һәм байлык аркасында килеп чыккан җиңелчә генә кыланчыклыгын искә алмаганда, ул нәзакәтлелек, әдәп-затлылык дигән нәрсәләрне бер вакытта да онытмас. Сез аның тупаслыгын, кабынып эндәшүен, берьюлы өзеп-кисеп ташлавын күрмәссез, ул үзенең кемгә булса да игътибарсызлыгын, исе китмәгәнлеген сиздергәндә дә һаман шул бер Хәят, нәзакәтле һәм нәфис Хәят булып калыр. Янә дә сез аның киенүенә, күзгә каршында бөтерелүенә игътибар итегез. Киенә-ясана белә ул, шайтан алгыры. Һәрвакыт кабарып торучы куе чәчләре арасына кунышы гына менеп утырган килешле калфагы үзе генә дә ни тора!

Ә әйе, калфакка хәтле, дус кызы Лиза алдында бераз мактанырга теләгәндәй, күзгә каршына килеп басасы, тагын бер бөтереләсе, чәчләрен туздырасы бар икән бит әле. Болай бөтерелүенең сәбәбе дә юк түгел. Дус кызы Лиза Мясникова, яшь гимназистка, җиңел фаэтонга яхшы ат җиктереп, ат башына кучер утыртып, Хәятны вечерга алмага килгән. Мясниковларның шәһәр артындагы дачасында бүген яшьләр — студентлар, офицерлар җыелачак. Алар арасында Хәятның кечә яшьтән белешеп-танышып үскән, хәзер инде студент, җәйге каникулга кайткан танышы Михаил Мясников та булачак. Алай гына да түгел, Лизаның кайбер ишарәләренә караганда, Михаил инде Хәятны көтә, имеш. Мясниковлар гаиләсе белән Хәятның әти-әниләре дә таныш, бу ике гаилә инде байтактан аралашып йөриләр. Татар купецы Борһан Гыймадов интендантствода эшләүче рус полковнигы Мясников белән кайчандыр төшемле сделкалар ясап алырга да өлгергән булса кирәк.

Башы бик үк әйләнмәсә дә, шулай да күңеле кунышынырга, күзгә алдында бөтерелергә сәбәп бар Хәятка. Кызык иҗ: бала чак дусты белән очраша. Җитмәсә, ул хәзер студент. Менә инде әлеге тегә пәхтә калфак та чәчкә менеп кунаклады. Өстендә итәге җилкәнгә охшап күпереп торучы җиңел ал күлмәк, болай да нечкә биле тагын да кысыла төшкән, аккош мамыгыннан тереңгәндәй күренүче ул нечкәбил, менә-менә канатларын бер җилпер дә очып ук китәр кебек...

Юк, очып түгел, җиңелчә генә ак болытлар арасыннан бу ике кызга «оялчан карагандай» елмаеп калучы кичкә кояш астында, фаэтонга утырып киттеләр алар. Хәлбуки, соңга таба бу «җиңелчә генә болытлар»ның куера башлаганлыгын, Хәят тормышына символик күләгәләр сала барганлыгын күрәбез без. Хәтта шул китүдән дә, күз явын алырлык матур киенеп, гаять күтәренке кәеф һәм шигъри хыяллар белән канатланып барган әлеге шул Мясниковлар дачасыннан да, ничектер, күңеле кырылып, каршылыклы уйларга чумып кайта безнең Хәятыбыз.

Карап торуга барысы да үз урынында, бөтенесе килешкән, бөтен нәрсәдән бәхет исе аңкый кебек иде, югыйсә. Җәйге тын кич иде. Резинка көпчәкле җиңел фаэтон. Шәһәр тузаныннан, дөнья ыгы-зыгысыннан читтә, агач күләгәләре арасында утыручы челтәрле дача өйләре. Бала чактан ук бергә уйнап үскән егет белән очрашу. Алтын яшьлек: студентлар, офицерлар, булачак яшь коммерсантлар. Күңелле флирт. Мактау сүзләре. Эчке мәгънә салынган серле елмаюлар. Музыка. Вальслар. «Почта» уены. Төрле мактау сүзләре белән тулган чәчәкле открыткалар... аларның березлексез Хәятка явып торулары...

Әмма шулай да... Өйгә әйләнеп кайтканнан соң без Хәятыбызны ничектер үзгәргән, аптырабрак калган, күңелен борчыган сорауларга җавап таба алмыйча өзгәләнгән бер хәлдә очратабыз.

Ах алла! Нәрсә генә булды соң безнең ул гүзәлебезгә? Болай күңелсезләнергә бер генә дә сәбәп юк кебек иде ләбаса. Ә менә булган икән шул. «Почта» уены вакытында килгән хат һәм язуларны, кабат-кабат кулга алып, укып карый Хәят. Шулар арасыннан берсе аны сискәндереп җибәрә. Бик тә ачык һәм тәкәллефсез язылган шул: «Сүз юк, сез матур, ләкин үзегезнең мөселман кызы вә мондагы егетләрнең рус егетләре икәнлеген онытыгыз гына килешми», дигән сүзләр язылган анда. Гәрчә Хәят моның кенчә кул — кызлар кулы белән язылганлыгын чамалап үзен тынычландырырга тырышса да, дусларына ышанып карарга өйрәнгән бу саф күңелле кызның кәефен кыру өчен шул бер тамчы «дегет» җитә кала.

Шуңа тагын кызның бала чагыннан ук

иске фикерле гаиләдә алган тәрбиясе, әти-әниләренең элек-электән колакка тукып килгән үгет-нәсихәтләре, сәбак абыстаеннан кереп калган һәртөрле хорафатлар килеп өстәлә. Шулар барысы бергә кушылып, дөньяга карашы ныгып җитмәгән һәм тәэсиргә тиз бирелүчән яшь күңелне шомландыра башлый. Һәм бу каршылыклы уйлардан тәмам башы каткан безнең Хәятыбыз, ниһаять, үзенең Михаилга булган яшьлек мәхәббәтеннән ваз кичәргә дә әзер: «Хәят кинәт Михаил белән үз арасында үтеп булмый торган чокыр барлыгын сизде».

Ә бит барысы да үз урынында, барысы да ал да гөл кебек иде. Хәят белән Михаил бер-берсен гөнаһсыз яшьлек мәхәббәте белән яратышалар да кебек иде. Хәятыбыз бала чагыннан ук алар белән аралашып, бергә уйнап-шаярышып үскән, русчасы да рус яшьләреннән һич аерылгысыз иде, үзе алар мохитенә кушылып китәргә бик-бик әзер иде. Бактың исә, бу яшьлек флиртларына караганда көчлерәк, аларга караганда тупасрак, катып калганрак икенче, өченче «законнар»-да, иске гореф-гадәт, шәригать һәм дин законнары да чекерәеп торган, имеш. Яшь кыз Хәят, бәлки, бу чәбәләнгән иске йолаларның бөтен каршылыгына төшенеп тә җитмәгәндер, бу баш әйләнүләрне ул шундук оныта, Михаилны да оныта, аны шундук икенче, өченче кешеләр мавыктыра башлыйлар.

Юк, Хәят күбәләкне аның сөйкемлелеге, киенә-ясана белүе, энҗеле калфагы гына ул вакыттагы каршылыклы язмыштан коткарып кала алмый. Хәтта аны керсез күңелендә уянган беренче мәхәббәте дә коткара алмый. Борһан Гыймадовлар өендә күзгә күренмичә элек-электән һаваны тутырып килгән иске гадәт-йолалар, шуның өстенә мулла-абыстайлар тарафыннан, мәчет тарафыннан көн саен, сәгать саен колакка тукылып киленгән дин-шәригать кагыйдәләре сөякләре чыныкмаган яшь кыз өстенә күтәреп чыга алмаслык кара болыт булып авып төшә. Хәятны күрмәгән-белмәгән бер кешегә, аның каравы «үз татарыбыз»га, җитмәсә тагы эше «чәчәк атып» килүче сәүдәгәргә кияүгә бирәләр. Шулай итеп, художникның шашынып-шашынып язган гүзәл Хәяты, чәчәк тә атмас борын кырау төшкән назлы гөл кебек, тормыш юлының башында ук шиңеп кала. Шул рәвешчә, хатын-кыз язмышы бер стена арасыннан икенче стена арасына кереп кысылу белән бетә, без Хәятның шуннан соңгы язмышы ни белән беткәнлеген язучының штрихлар белән билгеләгән планыннан чыгып кына чамалыйбыз. Хәер, ул вакыттагы татар хатын-кызының күпчелеге кичергән язмыштан чыгып фараз кыла калсак, Хәятның язмышы, шулай ук, гражданлык язмышына әверелеп, үсмәгәндер, шул дүрт стена арасында калгандыр, дип уйларга гына туры килә.

Хәят язмышының мондый чикләнгән язмыш булып очлануында, әлбәттә, объектив сәбәпләр — хатын-кызны курчак итеп караучы, аның турында «чәче озын, акылы кыска» дигән гайбәт таратучы иске тормыш, дин һәм шәригать законнары гаепле. Ләкин, яшерен-батырын түгел, бу иркә кызның үзенең дә йомшак ягын күрсәтә торган «Ахиллис үкчәсе» бар. Игътибар иттегезме икән, безнең ул мактаулы Хәятыбыз эш белән, хезмәт белән бер дә дус түгел бит, егетләр. Әлбәттә, «ул бит әле бик яшь, ул чибәр кыздан ни сорыйсың?» дип яклап чыгучылар да табылыр. Юк, мин аңардан таулар күчерүен сорамыйм, безнең бүгенге хатын-кыз башкара торган эшне дә башкара алмас ул. Ләкин кеше булгач аның эшкә, хезмәткә, һич югы өй эшенә генә булса да ниндидер мөнәсәбәте булырга тиештер бит инде! Ә без Хәятның нинди дә булса эштә катнашуын түгел, хәтта аның — башкага бик уңган кызыбызның — эш һәм хезмәт турында ничек тә булса берәр мөнәсәбәт күрсәткәнен дә сизмибез. Хәтта өй эшендә дә катнашмый булса кирәк ул. Характерлы бер деталь: менә ул Мясниковлар дачасыннан кайтты. Кайтты да, өстен-башын чишенеп, әйберләрен кайсын кая атып бәрде. Исәбе кыска: асрау кыз Биби соңыннан җыяр әле.

— Биби, акыллым, — дип асрауны янына чакырып китерә ул аннары, — минем ботинкаларымны гына чиш әле, үзем бик иренәм.

Бары тик бер генә реплика. Ләкин шул бер репликада, бер тамчы суда чагылып күренгән кара таш кебек, безнең ул мактаулы Хәятыбызның эш сөймәслеге, кеше көченнән файдаланырга әзер торуы ямьсез булып чагылып кала. Ахыр чиктә, аның бу алама гадәтен дә объектив сәбәпләр белән, кызның шундыйрак бер мохиттә тәрбияләнеп үсүе белән аңлатырга мөмкин. Ләкин бит кеше үзе өчен үзе дә бик нык җаваплы! Шуның өстенә тагын

без, бүгенге совет кешеләре, кешене барыннан да элек аның хезмәткә мөнәсәбәтеннән чыгып бәяләргә өйрәнгәнбез. Шулай итеп, гүзәл кыз Хәят, безнең бүгенге көн карашыннан чыгып бәяләгәндә, бер яктан, үзенең сизгер табигате, нәфислеге тоя белүе, нәзакәтлелеге һәм зур дөньяга — прогресска омтылуы белән безне үзенә җәлеп итсә, икенче яктан, фаҗигале язмышы һәм хезмәткә битараф мөнәсәбәте белән ул безнең алда кызганыч бер фигурага әйләнеп кала: нинди кешене имгәтеп ташлаганнар бит ул каһәр төшкән иске заманда!

Чагыштырып карау өчен түгел, — икесе ике заман кешесен чагыштыру мөмкинме соң — ә бәлки заманалар үзгәрү белән хатын-кыз язмышында килеп туган үзгәрешләрне ачыграк билгеләү өчен, шушы уңайдан минем икенче бер хатын-кыз язмышына — язучы Гомәр Бәшировның «Намус» романында тасвирланган Нәфисә образына тукталасым килә. (Җәяләр эчендә генә искәртеп үтим: монда мин талантларны берсен икенчесенә охшату, яки берсен икенчесенә каршы кую турында сүз алып бармыйм, монда сүз — иҗтимагый шартлар һәм аларның шәхескә йогынтысы турында бара.) Әдәби образ буларак коелулары ягыннан, Хәят һәм Нәфисә — икесе ике котып кешесе диярлек. Янә дә килеп, Хәятның бик яшь булып, Нәфисәнең инде 25 тирәләреннән узган һәм авыр сугыш елларында хәрәкәт итүче хатын икәнлеген дә онытып булмый. Хәят башка, Нәфисә башка. Бигрәк тә тышкы бизәкләрне иренмичә сала белү ягыннан, безнең барыбызның да Ф. Әмирханнан күп нәрсәгә өйрәнәсебез бар әле. Ләкин геройның җилкәсенә салып алып бара торган иҗтимагый нагрузкасы ягыннан караганда, безнең Нәфисәбез Хәяттан күп мәртәбәләр алда һәм берничә баскыч өстен тора. Бөек пролетар революциясе тарафыннан һәм аннан соңгы илле еллык янарыш чоры белән совет кешеләренең аңында, дөньяга карашында тәрбияләнгән гражданлык хисе, әлбәттә, безнең хатын-кызларыбызны да, аерым алганда татар хатын-кызларын да, читтә калдырмады. Әлбәттә, Нәфисәләр дә күктән төшмәгән. Шулай ук, узганнан бөтенләй аерылган хәлдә тиз генә кызарып пешкән Мичурин «алмалары» түгел. Аларны узганнар белән бәйли торган, шул ук Хәятлар, бигрәк тә Газизәләр белән бәйли торган уртак сыйфатлар табарга була. Шул ук вакытта, җәмгыятькә, хезмәткә, мәхәббәткә мөнәсәбәтләре ягыннан, без Нәфисәләребездә әйтеп бетергесез күп үзгәлекләр дә табабыз. Бер сыйфат аеруча күзгә ташлана — тормышта да, әдәбиятта да. Бу — безнең хатын-кызларыбызда гражданлык тойгысының сизелерлек көчәя баруы. Юк, безнең хатын-кызларны син дүрт стена арасында, бары тик ир кулына карап кына утырта алмыйсың инде. Хатын-кыз язмышы бездә көннән-көн ныграк булып гражданлык язмышы белән органик үрелә бара.

Нәфисәбезне дә без, барыннан да элек, җәмәгать эшендә, халык эшендә, коллектив эшендә җиң сызганып йөрүче, бөтен шатлыкларын һәм борчуларын, табышларын һәм югалтуларын шул олы юлда башыннан кичерүче хатын-гражданка итеп күрәбез. Автор аны, Ф. Әмирхан үз героинясын иркәләгән кебек, иркәләми, аккош мамыкларына төрми, дөресен әйтергә кирәк, урыны-урыны белән күңелгә: «Ай-һай ла, без үзебезнең героиныбызны тиешенчә сөеп җиткермибез түгелме соң?» дигән шөбһәле уйлар да килә. Нәфисә тупас кирзовый итектән йөри, аның каравы ул дүрт стена арасында тончыгып ятмый, ул һавада, иркен кырларда, колхоз эшендә чаба, ул олы мәхәббәт, зур тормыш белән яши.

Әлбәттә, аның тормышы бәйрәмнән генә гыйбарәт түгел. Дөресрәге, бәйрәм турында ул өлегә бары тик хыялланып кына яши. Мәшәкатьләре, борчулары, сагышлары да зур аның. Авыр сугыш елларында колхозның бер бригадасына җитәкчелек итүче бригадир буларак, Нәфисәгә күп кенә кыенлыклар белән очрашырга туры килә. Бригадада эш куллары җитми, тарту көче җитми, чәчүлек орлык җитми, тагын бик күп, бик күп нәрсәләр җитми. Шуның өстенә тагы баштарак колхозда председательлек итүче Сәйфи дә бик үк туры куллы кеше түгел. Боларның барысы өстенә тагы яшь киленчәк өстенә әйтеп һәм кичереп бетереп булмаслык олы кайгы да ишелеп төшә: Нәфисәнең бары тик өч кенә ай торып калган фронтовик ире Газизнең үлгән хәбәре кайта. Әнә шулар барысы да әле тиешенчә ныгып та җитмәгән бер җилкәдә — Нәфисә җилкәсендә, барысы да кешеләрнең күз алдында. Ә кешеләрнең төрлесе бар, кешеләрнең үзләрендә дә бәйрәм түгел, берсе синең кайгыңны уртаклаша, икенчесе, тыштан синең хәлеңә кергән булып,

эчтән генә сөенә: янәсе, бик әллә кем булмакчы идең, әһә, борының төштеме!

Шунда ук тагы кеше бик белеп җиткермәгән икенче, өченче борчулар да баш калкыта. Нәфисәнең кайнанасы Хәдичә карчык, килене турында юк гайбәтләрне ишетеп, авыз эченнән мыгырданып йөрергә тотына. Үзенең борынгычарак язылган «уставы»ннан чыгып, кирәк-кирәкмәс сүзләр әйтеп, үгет-нәсихәт белән сару кайнатып йөри. Ул да түгел, контузия алган гармунчы Зиннәт — Нәфисәнең кыз вакыттагы беренче мәхәббәте — фронттан кайтып төшә. Әлбәттә, ул инде «онытылган җыр», ләкин Нәфисә тарафыннан гына онытылган. Шук җанлы һәм заманасында авыл кызларының теленнән төшмәгән Зиннәт, сугыштан бераз акылга утырып кайтса да, «онытылган җыр»ны кабаттан искә төшерүдән бер дә ерак тормый. Кыскасы, Нәфисәнең җәрәхәтләнгән җанына тәшвиш салу өчен ул да килеп өстәлә. Ай-һай ла, бер дә кура җиләге түгел Нәфисә киленчәкнең тормышы.

Әмма, ничек кенә булмасын, безнең Нәфисәбез кыенлыклар алдында тез чүкми. Без аны, борчуларын эченә йоткан хәлдә, гел эшләп йөргән җирендә, уңыш өчен тынгысыз көрәштә күрәбез. Һәм чынлап та, Нәфисә бригадасы шул чор өчен рекорд булырдай бодай уңышы ала. Шулай ук күңелне иләсләндерә торган «татлы тәшвишләр»не дә якын җибәрми ул, үзенең кешелек горурлыгын саклый белә.

Кайдан алды соң әле ул көч? Шәхси сөйкемлелеге дә, бәлки, ярдәм иткәндер. Ләкин бу яктан ул үзенең элгәре, революциягә кадәрге Хәяттан шактый ук калыша дидек түгелме соң! Алайса сер нәрсәдә? Сер шунда: безнең Нәфисәбездә Хәятта булмаган ике асыл сыйфат бар. Беренчедән, совет власте еллары, безнең бөтен гамәлебез, көнкүрешебез, строебыз аңарда какшатып булмастай ихтыяр көче — кыенлыклар алдында баш имәү көче тәрбияләгән. Икенчедән, Нәфисә гади бер хатын гына түгел. Нәфисә бер үк вакытта хатын да, гражданка да. Хатын-кызлык тойгысы белән гражданлык тойгысы аңарда бергә сыеп тора гына түгел, бергә янып, бергә көч-энергия дә тудыра.

Ул авыр сугыш елларында без Нәфисә белән авылда, колхоз кырларында очрашсак, гражданлык хисләренең ныклыгы, иҗтимагый эшчәнлеге, Нәфисәнекеннән артык булмаса, аңардан һич ким булмаган икенче бер хатынны — Сания Ибраһимованы (Мирсәй Әмир — «Саф күңел» романы) шул ук сугыш елларында без шәһәр шартларында, тагын да җаваплырак бурычлар башкарганда күрәбез. Элек мәктәп директоры, соңыннан шәһәр Советы председателе урынбасары буларак, Сания Ибраһимова бик читен шартларда, бер караганда, хатын-кыз көче җитмәстәй күренгән эшләр башкара. Ләкин көче җитә, көчне аңарга әлеге шул Нәфисәгә сәләт биргән хакыйкать — үз иленең ихлас күңелле гражданкасы булуы, иленә һәм халкына авырлык килгәндә, ул авырлыкның бер өлешен үз җилкәсенә алырга әзер торуы бирә.

Нәфисә белән Саниянең шәхси тормышларында да зур гына уртаклык бар. Икесенең дә ирләре сугышта калган, гаилә китеклеген икесе дә бердәй диярлек кичерәләр.

Шул ук вакытта бу ике хатын-кыз образының икесенә дә хас булган уртак кимчелекләре дә бар. Аларны җәмәгать эшчәнлегә сферасында күрсәтүгә артык нык басым ясап, хатын-кыз буларак тәфсилләбрәк тасвирлауга тиешенчә игътибар ителмәгән диясебез килә. Җәмәгать эшендә, колхоз эшендә актив булу аларның хатын-кыз булуларына зарар китермәгәндер бит. Ә хатын-кыз буларак, алар, бәлки, башка хатын-кызларга хас кайбер сөйкемле вакльшклардан да имин түгелләрдер. Нигә, әйтик, Хәят кына чәчләрен туздырып, көзге каршында бөтерелергә тиеш икән дә, эштә бик уңган безнең хатын-кызларыбызга нигә әллә нидә бер көзге алдына килеп басарга, я булмаса ялгыздан-ялгыз калып, үзләре өчен генә булса да иңбашларын сикерткәләп купшыланырга, һич югы, баш астына салып ятучы булмаганлыктан (ирләре фронтта) әрүчә кабарган ятим мендәрләргә карап, хатын-кызларча бер моңаерга ярамас икән? Бу аларның эшчәнлек яки гражданлык сыйфатларына тап төшермәс иде ләбаса!

**Быть можно дельным человеком**
**И думать о красе ногтей...**

ди Пушкин. Шагыйрьнең бу сүзләрендә мыекка урардай мәгънә бар, егетләр. «Безгә мыек нәрсәгә, без мыексыз да, көзге каршына басмыйча да шәп кешеләр!» дип кенә кул селтәсәк инде.

Бусы — үзенә бер тема. Моның әһәмиятен һәм хатын-кыз образы алдында, аны кеше һәм хатын-кыз буларак сурәтләү ягыннан, безнең әлегә күпкә һәм бик күпкә бурычлы икәнлегебезне без һич югы белеп торырга тиешбез. Ләкин шулай да бу мәкаләнең бурычы хәзергә ул түгел.

Еллар үтә, ун ел, егерме ел үтә, сугыш яраларын төзәтәбез, кайтасы кешеләребез кайта, кабарып торган мендәрләргә башлар куела... Ләкин артык иркәләнергә җыенганыбыз юк, алдыбызга яңадан-яңа, катлаудан катлаулырак бурычлар куела тора, җиңнәр сызганулы, һәркайсыбызның үзенә күрә эше, бурычлары, мәшәкате бар, барыбыз да походта. Шул җөмләдән хатын-кызларыбыз да, әлбәттә, ирләр белән берләттән зур йөкләр алып баралар.

Һәм... Нәфисәләр, Санияләр белән танышканнан соң егерме еллап вакыт узгач, менә без шул ук плеяданың тагын бер вәкиле, ләкин егерме ел электәгеләргә караганда киңрәк офык астына, еракрак юлга чыккан, җыры да, моңы да, ә кем белә, бәлки хәсрәте дә тегеләрнекенә караганда куерак булган өченче бер хатын-гражданка белән очрашабыз. Мин шагыйрь Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша» дигән поэмасындагы Халидә образын күздә тотам.

Халидә, бәлкем, Нәфисәләргә, Санияләргә караганда яшьрәк буыннан, ләкин аның да шәхси язмышында тегеләрнеке белән зур гына уртаклык бар. Халидәнең дә ире сугыш кырында ятып калган. Әле нинди генә ир, андый ирләрне егерме, утыз еллар гына оныттыра алмый.

«Янар Ярулла» кушаматы тагылган шук җанлы, җырны һәм кешеләрне ярата торган, шул ук вакытта үз кадерен дә белүче, вакыты белән чак кына мактанырга да яратучы ул кешенең менә сезгә исән чагындагы портретыннан бер штрих:

Яруллаһы гадәтедер инде,
Син вакытсыз аңа ялынма.
Юк, урманда түгел, җырын сузыр
Нәкъ урманны чыккач Ярулла.
Кайткан чакта күрше авыл аша
Ул күтәреп бәйләр ат башын,
Юк, урамда түгел, башлар җырын
Узу белән басу капкасын...

. . . . . . . . . . . . .

Ярулладан алда йөрде моны,
Яруллага барсы табынды.
Кырдан килгән тавышына карап,
Әзерләде авыл табынны.

Тукта, чү! Маузугымны саташтырдым. Ярулла турында түгел, аның тол калган хатыны Халидә турында бара иде сүз. Дөресен әйткәндә, монда саташмыйча мөмкин дә булмады: әнә нинди ирләрне алып калды бит ул сугыш. Яруллаңы искә төшерү — бу шул ук Халидә турында сөйләү бит инде. Нишләп моңлы булмасын Халидә: әнә нинди ирен югалткан бит ул!

Нәфисәләрдән, Санияләрдән егерме ел соңрак хәрәкәт итүче буларак, Халидә тегеләргә караганда, әлбәттә, тәҗрибәлерәк һәм, ихтимал, зирәгрәк тәдер. Сугыштан соңгы егерме ел, яңа дәртләр, яңа мәхрүмлекләр белән тулган егерме ел әллә бушка үткәндер дисезме! Халидәне чолгап алган офык та башка, шулай ук ул хәрәкәт итә торган мәйдан да чагыштырмаслык киң — Әлмәт районындагы Кәләй авылы тирәсеннән башланып, Дон, Днепр елгалары, Карпат таулары аша үтеп, Демократик Германия җирләренә барып тоташа аның юлы. Дуслык юлы, «Дуслык трассасы» дип атала ул юл. Халидә анда торбалар төрүче гади бер эшче булып эшли һәм бу торбалар буйлап безнең еракдагы дусларыбызга — Польша, Чехословакия, Демократик Германия илләренә Татарстан җиренең эчке мае — нефть ага. Юк, нефть кенә дә түгел, татар халкының йөрәк җылысы, моңы, «Сарман»ы ага. Әйтерең бармы, барысы да тирән мәгънәле символика белән төрелгән монда.

Ә иң кызыклы символика тагын шунда: бу тирәләрдән, бүген Халидә «Дуслык трассасы» үткәзә торган көнбатыш районнарыннан, шул ук Орел, Курск дугалары, Днепр елгасы, Карпат таулары аша моннан егерме ел элек Халидәнең ире — солдат, «Янар Ярулла» үткән. Ләкин Халидә суза торган юл белән «Янар Ярулла» үткән юл арасында зур аерма бар. Берсе моның сугыш юлы булган булса, икенчесе дуслык юлы. Әмма аңлап булмаслык каршылык юк. Ахыр чиктә, «Янар Яруллалар» да бит сугышны бик тансыклаганнан, ансыз тора алмаганнан түгел, Гитлер чирүләре бәлане безнең бугазга китереп терәгәннән соң, тетрәткеч мәҗбүрият астында, җирләреннән һәм җырларыннан аерылып киттеләр. Гади генә хатын Халидә моны тирәнтен аңлый, алай гына да түгел, бу аянычлы хакыйкать шул гади авыл хатынын әледән-әле фәлсәфи уйлануларга китерә: юк, аның «Янар Ярулласы» үлмәгән, ул гүяки исән, кайдадыр шунда Халидәләр белән бергә бара, арган-талган, моңаеп калган

минутларында Халидә белән сөйләшә, аны юата, тынычландыра.

Шул яктан караганда, Халидәнең Ярулласы бүген дә безнең арабызда кала, безнең белән бергә хәрәкәт итә. Һәм Халидәнең башкаларга караганда зирәгрәк булуы да шул яктан: ул сугышта корбан булган ирен кайгырып искә алу белән генә чикләнми, ул, үзенең бүгенге эшендә аны исән итеп гәүдәләндерүе белән, гүяки, үлемне тормышка хезмәт иттерә.

Куелган темага әйләнеп кайтып, яки аны очларга азапланганда дигәндәй, минем һич яшерелмәгән кайнар пафос белән шуны әйтәсем килә: революциягә хәтле күбесенчә дүрт стена арасында кысылып һәм язмыш колы булып яшәгән татар хатын-кызы, революция куйган канатлар нәтиҗәсендә, кай югарылыкларга менеп китмәде! Сөя һәм киенә белә торган, ләкин иске гадәт-йолаларга каршы торырга көче җитмәгән гүзәл кыз Хәят белән аның бүгенге сеңелесе Халидә арасында, күп халыклы, күп җырлы, күп шаушулы «хор» составында, әмма үзенең шәхси моңын һич югалтмыйча, «Дуслык трассасы» үткәрүче Халидә арасында никадәр аерма бар! Әйе, кайчандыр хатын-кыз язмышы, аның мең төрле шартлар белән бәйләнгән бәләкәй генә «өлеше» бар иде, хәзер ул бер үк вакытта хатын-кыз һәм гражданка язмышы булып әверелде. Хәзер без менә шуны җырлыйбыз.

—— ◆ ——

*Зэки Нури*

## Синең җырың

Урманнарга барып керәм,
Чыгып китәм кырларга —
Бер ялгызым калып кына
Синең җырны җырларга.

Ул синең мине тирбәткән
Чактагы сүзең, әни.
Кушылып минем йөрәккә
Җырлыйсың үзең, әни.

Ул синең назың яктысы,
Ул синең түзем җыры.
Ул синең караш чаткысы,
Ул синең күзең җыры.

Ул синең җылы сулышың,
Ул синең яна белү.
Иң матур җыры тормышның —
Минемчә, ана булу!

Кайларда йөртмәде юллар,
Кайларга омтылмадым...
Күңелгә син салган җырлар
Юк, әни, онытылмады.

Күеңне ятлыйм, кабатлыйм
Синең сүз белән, әни.
Син — кояш. Синсез таң атмый! —
Мин шуны беләм, әни.

*1967*

## Адашу

Теләмәдем моны, һич көтмәдем,
Я йөрәкнең гаебе, я башның:
Синең күе кара керфекләрең
Арасына кереп адаштым.

Гаепләмим, юк, бу гаеп түгел,
Мин үземне хәтта кичерәм.
Кереп батты кинәт ике күңел
Гыйшык дигән бер күл эченә.

Бар газабын күтәрт бу тормышның,
Һәм сагышын күтәрт, һәм йөген:
Мин батырмын хәзер, мин тырышмын! —
Бу бит бары синең гаебең.

Җылы алсам синең сулыштан да
Салкынына кышның чыдармын.
Бу адашу миңа булышканда
Туры юлга тизрәк чыгармын.

*1957*

*Узган елның 12—15 декабрендә Татарстан язучылары союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты яшь язучыларның III республика конференциясен үткәрде. Анда республикабызның төрле районнарыннан йөздән артык яшь талантлар катнашты. Шулай ук Оренбург, Чиләбе өлкәләрендә, чуваш, мари, удмурт, башкорт автономияле республикаларында яшәүче авторлар да чакырылды. Дүрт көн дәвам иткән конференциядә яшьләр әдәбиятыбызның күренекле вәкилләре — язучылар һәм галимнәр белән очраштылар, укучылар алдында, радио һәм телевидение буенча чыгышлар ясадылар. Төрле жанрлар буенча үткәрелгән семинарларда 40 авторның кулъязмасы тикшерелде. Поэзия семинарларын Х. Туфан, С. Хәким, Н. Дәүли, Ә. Исхак, Н. Арсланов, Ә. Юныс, Ш. Галиев һәм башкорт язучысы Гайнан Әмири кебек күренекле шагыйрьләр алып бардылар.*

*Журналыбызның бу санында без шул семинарларда яхшы бәя алган кайбер яшь шагыйрьләрнең шигырьләрен урнаштырабыз.*



*Зөлфәт*

## Тимерче турында баллада

Язмышын да чүкеп ясаган ул,
Сандалына салган ачуын,
Сандалында яньчемәкче булган
Бөлгенлекне, сугыш, ачлыгын:
«Тимернең син аның зәгыйфь җирен —
Йөрәк турын таба бел генә, —
Кызган чакта кизәнеп бер суксаң,
Тимер түгел, чорт та бөгелә!»
Дине дә шул тимер иде аның,
Чүкеч тавышы булды догасы.
Берлиннарга кадәр алып барды
Җирән кашкасының дагасын.
...Кызган тимер кебек яшәде ул,
Кызган килеш керде сугышка —
Кызган тимер сукты йөрәгенә,
Кызган килеш ауды камышка.
— Ә... синмени! —
диде тимергә ул, —
Син... сугарга... уйладыңмыни!
Врешь, брат! Күпме генә сукма —
Кызган чакта ирләр бөгелми!
Бөкте тимер, кызган тимер бөкте!
Тик бер мизгел калгач үлемгә,
Кызган тимергә ул әйтеп куйды:
— Йоклап алыйм әле мин менә...
Ә аннан соң... Кайнар килеш торсаң,
Нәни кадак ясыйм үзеңнән...
...Ул белмәде соңгы тамчы каны
Акканын шул тимер эзеннән.

...Мин китәрмен, ахры...
Яңа бер утрау эзләргә.
**Р. Гатауллин.**



*Фаил Шәфигуллин*

●

Мин диңгездә утрау күрдем,
Гаҗәп утрау.
Хуш ис бөркеп, балкып торган
Чәчәк утрау.
Ымсындырып чакырды ул
Үзенә мине.
Анда инде ләкин кемдер
Булган иде...
Кагылса да чәчәкләргә
Кеше кулы,
Саклый иде утрау һаман
Кыргыйлыгын.
Сайрар кошлар суза иде
Моңлы бер җыр:
«Безне ташлап киткән шагыйрь
Кайлардадыр!..
Ник кайтмыйдыр (кәтә-кәтә
Гөлләр сула),
Үзе ачып, исем биргән
Утравына»!
Гөлләре дә аны көткәч
Зарыгып бик,
Нигә калыйм бу утрауда! —
Мин монда чит.
Йөзәм уйлап:
«Тирә-якта
Диңгез генә —
Кайта алыр микән шагыйрь, —
Дим, — тиз генә!
Күрә алыр микән тагын
Утравын ул! —
Диңгездә бит була җилләр,
Була давыл».



*Гәрәй Рәхим*

## АВЫЛЫМ

Авылым!
Син безнең кебек түгелсең шул.
Гомер үткән саен һаман яшәрәсең.
Бизәнәсең һаман яңа йортлар белән.
Шулай кирәк,
Яшәр дә син, яшә дә син.

Бер көн безнең чырайларны картлык
басып,
Вакыт безне кирәк җиргә алып китәр.
Син китмәссең безнең белән,
Әй, авылым,
Сине һәркем баласына мирас итәр.

Нишлисең бит,
Безнең гомер кыска инде,
Тик без моңа уфтанмыйбыз һичбер чакта.
Һаман сине төзибез без,
Яшәртәбез.
Картайсак та, арысак та, авырсак та.



Айдар Хәлим

## Түбин[1] җыры

Ирәндекәй — кыя, туган оя,
Оясында бөркет хәл җыя.
Уңга канат тертсә — Европа шул,
Сулга канат тертсә — Азия.
Түбин, Түбин,
Алтын калясы.
Моңланмачы, дала баласы.

Ирәндектән йөгереп суга төштем,
Сапсал-суны бүлә кирт-кирт яр.
Җырдан алып җырга салганда да
Җырга туймас халык — башкорт бар.
Түбин, Түбин,
Алтын калясы.
Бу кадәр моң каян аласың!

Йөз ярып ла ята Ирәндек,
Ташта пешә курай кызарып.
Бәрәкәтле Түбин туфрагында
Кияү чыкмый калган кызлар юк.
Түбин, Түбин,
Алтын калясы.
Моннан мәллә кәләш аласы!

[1] Түбинск — ераkларга даны таралган алтын юучылар поселогы. Элек рудниклар хуҗасы бертуган Рәмиевләр булган. Коточкыч изүгә дучар булган эшчеләр «Зимагурлар» көен монда уйлап чыгарганнар. (Автор.)

## Ат

Тояклары сары сөяк,
Бәкәлләре буз кебек ак,
Сыйраклары нәфис, озын —
Сөлек кебек бу кызыл ат
Әкияттән чыккандыр дулап.
Танаулары киерелгән —
Һава җитми аңа, җитми.
Башын чөеп һава тешли,
Ертмак булып күкнең читен.
Маңгаенда ап-ак тасма
Җилләр канатын каера.
Ул — давылда һәм кояшта
Үз төсен югалткан байрак.



Ренат Харисов

Ә ике күз — ике беләү,
Тот та булат хәнҗәр кайра.
Аңында ашкыну кошы, —
Ул кан күрде микән чыкта —
Кошның ике канаты очы
Колак булып бәреп чыккан.
Сары ялы җилкәсеннән
Ялкын булып агып тора.
Ул тояклар астындагы
Чаткылардан кабынгандыр...
Сырты аның — әзер ияр.
Озын, хәтәр юллар башы...
Сул кул тезгенгә ябышкач,
Уң кул кылыч сорый башлый!
Юк,
Мин аңа
Атланмыймын...



Рөстәм
Мингалимов

•

Таш дивардай кайгы ауды өстемә,
Ә син күрдең минем йөздә тынычлык;
Күкрәгемә кунып шатлык талпынды,
Баккан идең, үзгәрмәдем — мин шул ук;
Һәм син киттең минем яннан «Җансыз бу,
Кайгы-шатлык белми торган кеше!» дип.
Моннан зуррак кайгы барын беләм мин,
Моннан зуррак шатлык көтеп яшимен.

## Абыйлар

Ят малайлар тия башласа,
Аралыйлар килеп абыйлар,
Булса гаеп синең үзеңдә,
Китә берне биреп абыйлар.

Тар басмалар аша чыкканда,
Курыкма дип көйләр абыйлар:
Артыңнан мин карап торырмын,
Син бар да бар, дияр абыйлар.

Иртә таңда илгә яу килсә,
Алдан моны белә абыйлар,
Сез соңыннан ди-ди,
Иң башлап
Ут эченә керә абыйлар...

Без шуларга охшап үсик, әй,
Таш юллардан туры, таймый бар!
Абый-абый диеп,
Безгә дә
Сыена торган булсын сабыйлар.



Тәүфикъ
Камалиев



Харрас
Әюпов

## Аргымагым

Уйлар дигән аргымагың барда
Ашкынмыйча ничек түзәсең!..
Еракларга алып китсен дисәң,
Тезгеннәрен генә җибәр син.

Аргымагым кая юл алды соң,
Йөгәнеме әллә салынган!
Дулап-дулап чыгып киткән уйлар
Кайтып керми синең ягыңнан.

Кычкырып та, сызгырып та карыйм,
Юк, ишетелми тояк тавышы.
Шул йөгәнсез аргымакны эзләп
Үзем бармый булмас, ахрысы...

## Ишкәкләр минем кулда

Елганың буе озын да
Ярлары икәү генә.
Шул елгада дулкын ярып,
Минем дә көймәм килә.

Елга, ярларына ымлап,
Алдыма сорау куя:
Бер якта болын, чәчәкләр,
Бер якта ташлы кыя,
Сине көймәң ташлар икән
Шуларның кайсысына!

Шөбһә юк, кырыс дулкыннар
Бәрсә дә уңга, сулга.
Мин түгел язмыш иркендә,
Ишкәкләр минем кулда!



Павел
Апушев



Рәшит
Ягъфәров

## Диңгезче сүзе

*(Укытучыларыма багышлыйм)*

Карт диңгезче белән ак көймәгә
Җилкән тарттык диңгез ярында.
Дулкыннарга кушылып пышылдады
Ярдан аерылган чагында:
— Диңгез ярсу, улым.
Анда давыл, анда шторм,
Кара аны: яннан бәрмәсеннәр —
Син аларга каршы бар, улым!

Куллар талып, әгәр туктап калсам,
Күреп алда җилен, давылын,
Ерак ярдан ул кычкыра сыман:
— Дулкыннарга каршы бар, улым!



*Вакыйф Нуруллин*

# ШИНЕЛЬСЕЗ СОЛДАТЛАР

*Повесть*

*Язучының әдәбиятка килү юлы күп төрле. Берәүләр иң беренче әсәрләре белән үк ялтырап күренәләр. Икенче берәүләр байтак кына эзләнәләр һәм, үз башларыннан кичкән хәлләрне язмый торып, үз тавышларын таба алмый аптырыйлар.*

*Яшь язучы Вакыйф Нуруллин моңарчы берничә хикәя, тәрҗемәләр бастырды, ләкин ул әле телгә алла ни кереп китә алмаган иде.*

*Бүген аның «Шинельсез солдатлар» исемле кечерәк кенә повесте укучылар хөкеменә тапшырыла. Монысында инде, һич шикләнми әйтергә мөмкин, яшь авторның үзе белгән, үзенчә тудырган кызыклы дөньясы һәм күңелгә ятышлы геройлары бар.*

*Илдә сугыш, олылар фронтта, авылда бала-чагалар да хатын-кызлар өелеп калган. Атлар җитми, машиналар юк, шуның өстәвенә сугыш кырларыннан кара конвертлар килеп тора. Бу безгә танышмы? Әйе, без моны кайбер әсәрләрдән укыдык инде. Әмма «Шинельсез солдатлар» безне барыбер дулкынландыра, безнең өчен яңа бер дөнья булып, бөтенләй икенче ягы белән күз алдыбызга килеп баса. Чөнки яшь автор тормышка мөнәсәбәтне унбер яшьлек үсмер Равил күзлегеннән карап сурәтли. Әле беркайчан да сугыш кебек вәхшилек белән очрашып карамаган бала күңелендә туган аптырашлар, рәнҗеш-газаплар укучыга сугыш заманын бөтен аяусызлыгы белән күрергә ярдәм итә. Минем үземә яшь авторның кырыс реализмы, кешеләренең вакыйгаларга кыска һәм үткен итеп бәя бирүләре, барыннан да бигрәк, халыкның сабырлыгы, зур җиңү хакына ачы хәсрәтләрне йота белүе ошый. Повесть нык һәм ышанычлы кул белән, зур оптимистик позициядән чыгып язылган.*

*Төкле аягың белән, Вакыйф!*

**Гариф АХУНОВ.**

## Балачакның соңгы көне

Туу турындагы таныклыгым буенча миңа хәзер утыз ике яшь. Ә үземчә әле егерме өчтә генә кебек. 1932 елда түгел, 1941 елның җәендә генә тудым шикелле, чөнки ана кадәр бу якты дөньяданиләр булган, мин нәрсәләр эшләгәнмен — берсен дә анык кына хәтерләмим. Ә 1941 елның җәе...

Күрше малайлары Миңлеәхмәтләр, Фәрзетдиннәр белән таякка атланып «ат-ат» уйнап йөри идек, кинәт авыл халкы куркыша, кычкыраша башлады:

— Сугыш чыккан!

— Гирман безгә каршы сугыш ачкан!

Аннары кайсы кайда кырда эшләүче ир-атлар да, җиккән атларын чаптырып, авылга кайттылар.

Барысының йөзләре җитди, борчулы иде.

Ә без, малайлар, бу хәлгә бераз сәерсенеп тордык та, берни булмагандай, яңадан уеныбызны дәвам иттердек. Чөнки, кайда сугышалар, кемнәр сугыша? дип соравыбызга каршы Миңлеәхмәтнең атасы:

— Ерак ул, оланнар, моннан күренми, — дигәч, безнең өчен ул сугышның кызыгы беткән иде инде.

Хәзер утыздан узган акыл белән уйлап карыйм да, ул көнне уеныбызны дәвам иттерү әйбәт булган әле дип, куанып куям. Без уеннан туктаганга карап кына сугыш барыбер туктамас иде бит.

Икенче көнне иртүк авылның ир-атлары, җиккән атларга утырып, авыл буйлап җырлап йөри башладылар.

Китәбез инде, китәбез,
Без китмичә, кем китәр?
Илне дошманнардан азат
Без итмичә, кем итәр?

Менә монысы безгә кызык иде! Агайларның җырларын тыңлап, бер адым да калмыйча, аларга ияреп йөрдек без.

Җырлашучы агайларның үз-үзләрен тотышына караганда, алар әле тиз генә тукталмаслар, көн буе шулай йөрерләр, һәм бу кызык кичкә кадәр дәвам итәр шикелле иде. Ләкин алай булмады. Нибары утыз җиде йорттан торган авылыбызны өч тапкыр гына әйләнделәр дә атларын туктаттылар. Җырлар өзелде. Кешеләрнең йөзләре караңгыланды. Елашулар, хушлашулар китте.

Без малайларга шунысы сәер иде: карап торуга зур-зур кешеләр булсалар да, ник балалар сыман итенә икән бу олылар? Ничек инде ул: әле җырла, әле ела? Син тагын шунысын әйт: Миңлеәхмәтнең энисенә тикле елый бит! Миңлеәхмәт кайчакта киреләнеп чак кына шыңшый башласа да:

— Җылама, улым, җылаган кешенең бәхете булмый аның, — дия иде. Ә үзе... әнә ничек сулкылдап-сулкылдап елый.

Ул елашу, ул саубуллашу, белмим, тагын күпмегә сузылыр иде икән, ләкин шул чак Кече Әшнәк юлыннан авыл советы секретаре Мөсфирә апа килеп җитеп:

— Ярый, иптәшләр, елашмыйк, елаудан мәгънә юк хәзер. Киресенчә, ныграк, каты күңеллерәк булырга кирәк безгә! Әйдә, матур гына итеп саубуллашыгыз да, озатыйк китүчеләрне! — дигәч, барысы да тынып калды.

Әмма озакка түгел. Мөсфирә апа үзе утырып килгән тарантастан төшеп, атын Хәбир бабайлар коймасына бәйләп килгән арада баягыдан да битәррәк шау-шу, хушлашу, елашу башланды. Ул да түгел, әле генә кешеләрне каты күңелле булырга өндәгән Мөсфирә апа үзе дә, сугышка китәсе абыйсы янына килеп, кычкырып еларга тотынды. (Ул үзе безнең авыл кызы, авыл советында эшләгәнгә күрә генә Кече Әшнәктә яши иде.)

Монысы инде минем өчен чамадан тыш сәер хәл иде. Чыннан да, ничек инде ул, Мөсфирә апаны әйтәм, үзең шундый зур урындагы кеше бул, үзең ела? Ә мин, юләр, андый кешеләрнең күзеннән яшь чыкмый торгандыр, дип йөри идем... Бик акыллыдыр ул, бик башлыдыр дип уйлый идем мин Мөсфирә апаны. Чөнки ул безнең авылда бердәнбер зур белемле — җиде класс тәмамлаган кеше. Авыл халкы да ярата үзен: «Ай-яй, башлы булып чыкты ул кыз, укып та бетерде, сиклитар да итеп куйдылар. Менә күрерсез, районга да берәр нәчәлник итеп алырлар әле шуны», — дип сөйлиләр иде аның турында. Ә ул, кара, ничек балавыз сыга!..

Әмма, ничек кенә булмасын, башкалар кебек дөньясын онытып, озаклап еламады Мөсфирә апа: ике-өч минут та үтмәгәндер, абыйсы

күкрәгенә сыенып елаганда як-якка шуышып төшкән кап-кара озын толымнарын селтәп аркасына салды да тагын элекке хәленә кайтты. Костюмы кесәсеннән челтәрле матур кульяулык алып, яшьләрен сөрткәч:

— Ярар, иптәшләр, кузгалыйк! — дип, китүчеләргә эндәште. Аннары аты янына китте. Тарантасына утырды. Тагын бер тапкыр, бу юлы барысы да ишетерлек итеп:

— Кузгалыйк, иптәшләр! — диде дә атын районга бара торган юлга борды.

Китәсе кешеләр дә арбаларга утырдылар. Атлар кузгалды. Һәр ике яктан да яулыклар җилферди башлады. Китүчеләрнең соңгы җыры яңгырады:

Без авылны чыккан чакта
Күтәрелде тузаннар.
Ул-бу булып, кайталмасак,
Сау булыгыз, туганнар...

Китүчеләрне тәмам күздән югалганчы карап торганнан соң, моңарчы кул болгап, яулык болгап торган озатучылар, күз яшьләрен сөртә-сөртә, атлар-атламас кына авылга борылдылар.

Иртәдән бирле кызык карап йөргән без малайларга да ничектер дөньяның яме бетеп, аны хәвеф, шом каплап алгандай булып калды.

* * *

Күрәсең, безнең йорттан берәү дә китмәгәнгә шулай булгандыр, башта мин сугышына да, китүчеләргә дә әллә ни шаккатмадым. Әммә сугыш башлануга атна-ун көн дигәндә этинең энесе Искәндәр абыйны да районга чакыртып, аңа да машинасы белән фронтка китәргә дигән кәгазь биреп җибәрүләреннән соң, дөресен әйтергә кирәк, эшләр хәртиләнде минем. Соң, шулай булмыйча! Авылыбызның бердәнбер машинасын йөртүче кеше ич минем Искәндәр абыем! Бөтен колхозның йөген бер үзе ташый дип әйтергә була бит аны. Ул да киткәч, колхоз нишли инде? Аннары, колхоз гына түгел, мин дә бар бит әле дөньяда. Ярты гомерем Искәндәр абыйларда үтә ич минем...

Әмма беркем дә минем теләк белән исәпләшеп тормады. Тиешле көне килеп җитүгә, абыйны да озаттык. Башкалар көчкә-көчкә генә аерылып киткәнгә күрә, Искәндәр абый да шулай булыр инде дип уйлаган идем. Ләкин ник бер тамчы яшь күрсәтсен Искәндәр абый! Еламады да, җырламады да. Ни кыстап карасалар да, шофер кешегә ярамый ул әйбер дип, аракыны да авызына алмады. Нәкъ башка көннәрдәгечә, колхоз әйберләрен ташып йөрде-йөрде дә, тәмам китәр сәгате килеп җиткәч кенә, машинасын капка төпләренә куеп, бик әйбәтләп ашап чыкты. Аннары, машинасына утыртып, үзен озатырга җыелган авыл халкын урам әйләндерде. Аннары, янә капка төпләренә тукталып, барысы белән дә саубуллашты да элек хатыны Нәсихә җиңгине, соңыннан мине кочаклап үбеп:

— Исән булсам — кайтырмын, кайта алмасам — үпкәләмәссез, — дип, шаяра-көлә машинасын кабызып, китеп барды. Хәтта районга кадәр озата барырга теләгән җиңгине дә алмады: — Күпме барсаң да, барыбер бер аерыласы булыр инде, Нәсихә җаным, лутчы шушында гына кал, — диде.

Искәндәр абый шулай шаярып-көлеп киткәч, мин артык борчылмадым. Әни дә әллә ни озак еламады, әмма Нәсихә җиңгинең елавына чик-чама булмады инде. Тәмам хәле бетеп, күзеннән яшь, авызыннан сүз чыкмый башлагач кына тукталып, йоклап китте ул...

Ул көнге үрсәләнүенә караганда, жиңги Искәндәр абыйдан башка бер ай да ялгыз яши алмас: я хәсрәтеннән саргаеп үләр, яисә акылыннан язар төсле тоелды миңа. Шуңа курыктым, шуңа бик кызгандым мин аны.

## Үсканче көтәргә туры килмәде

Искәндәр абыйны озаткан көнне, әни белән жиңги бик хафаланганга аптырап:

— Нигә шул тикле елыйсыз соң сез? — дидем мин әнигә. — Немецларны жиңгәч кайта бит Искәндәр абый! Башкалар да кайта. Гомергә китмәгәннәр ич алар! Искәндәр абый үзе еламаганны сез елап торган буласыз тагы, эч пошырып.

Мин бу сүзләрне чын күңелемнән әйттем. Чөнки минем Искәндәр абый, гәүдәгә гадәти генә булса да, бик таза, бик куәтле кеше. Авылыбызда гына түгел, бөтен районда сабан туе батыры булып калды ул быел. Икешәр потлы ике герне туп урынына чөеп кенә уйный торган иде. Шулай булгач, мин аның сугышта да немецларны жиңәчәгенә, аннары исән-сау килеш авылга кайтачагына шикләнми идем.

Ләкин әни башкачарак уйлаган булса кирәк, чөнки ул, минем белән бик үк килешеп бетмәгән сыманрак итеп:

— Әй, улым! Яшь шул әле син, сабыйлыгың аркасында аңлап житкермисең ул сугыш дигән фетнәнең мәгънәсен! — дип жавап бирде.

— Аңлатып бир алайса, әни?

— Ярар инде, улым, аңламый торуың әйбәтрәк хәзергә. Үсә төшкәч аңларсың әле, исән калсак...

Бу жавабыннан канәгатьләнеп житмәсәм дә, әнине бүтән борчып тормадым. Рас ул «белми торуың әйбәтрәк» дигән икән, димәк, шулай кирәк дип уйладым. Ләкин...

Әле кар яумаган, әмма жир таштай туңган һәм шунлыктан чамасыз суык тоелган ноябрь кичләренең берсендә әнине колхоз идарәсенә чакырттылар. Үзем генә өйдә калырга куркып, мин дә әнигә ияреп киттем.

Колхоз председателе Самат абый чакырткан булган икән. Без килеп кергәндә, идарәдә үзе генә утыра иде.

— Менә нәрсә, Мәгъсүмә иптәш, — диде ул, кырыс кына итеп, — бүген районнан күрсәтмә килде. Окоп казырга кеше жибәрергә кушканнар. Так...

Шкафтан ул нидер алырга тели иде.

Гәүдәсе кечкенә булганлыктан, элекке председатель утырган урындыктан үрелеп кенә шкафны ачарга буе житмәгәч, Самат абый өстәлдән азрак читкәрәк куелган шкаф янына үзе барды. Аннары яңадан урынына килеп утырды да, ябалакныкына охшаган түгәрәк, зур күзләрен безгә текәп, дәвам итте:

— Разнарядка буенча, безнең колхоздан егерме бер кеше окоп казырга барырга тиеш. Сиңа да шунда барырга туры килә. Бар, хәзер кайт та әзерләнә башла! Берсекөнгә юлга чыгарсыз.

— Минем йорт-жирем, терлек-торышым нишли ди соң инде, Самат абый? Равилемне кайда калдырыйм мин? — диде әни, тәмам коты алынып.

Ә мин куркуымнан еларга ук тотындым. Соң, шулай булмыйча! Менә монда да өйдә үзем генә калырга курыкканга килдем бит мин! Әни киткәч, бер үзем нишләрмен?.. Ах, чулак шайтан! Председатель булып эшләргә тотынганына әле бер ай бар микән, кара, ничек итеп бугазын киерә башлаган! Элек — сугышка кадәр амбар-урам каравылчысы булып эшләгән чагында — бер дә алай түгел иде. Ир-ат сөйләш-

кәндә, авыз ачарга да кыймыйча, башкаларны тыңлап кына тора, хәтта төчкерәсе килгәндә дә читкә китеп төчкерә торган иде. Ә хәзер...

Тик мин юкка гына әтәчләнгәнмен икән. Барысын да уйлап, хәл итеп куйган булып чыкты Самат абый.

— Беләбез, барысын да беләбез, Мәгъсүмә иптәш, — диде ул, әнинең каршы килүенә һич тә исе китмичә. — Бер дә борчылма, барысы да хәл ителгән. Син дә хафаланма, наным Равил. Бер сыерың, ике сарыгың бармы әле синең, Мәгъсүмә иптәш?

— Әйе, — диде әни.

— Значыт, менә болай, Мәгъсүмә иптәш: хайваннарыңны да, Равилеңне дә килендәшең Нәсихага калдырасың, ул карый торыр. Ә үзеңне биклап торасың. Бәрәңгеңне генә идән астында калдыра күрмә. Ягылмаган өйдә өшер ату, базыңа тутырып куй.

Менә бит нинди кеше икән ул Самат абый! Һәр ягын уйлап-үлчәп куйган бит. Әле ярый бая теге уйларымны кычкырып әйтмәдем. Югыйсә...

Хәзер инде мин әнинең китүенә дә каршы түгел, ул үзе дә ризалашыр дип көттем. Әмма, гомер-гомергә җитәкчеләр алдында куркып, калтыранып тора торган оялчан, юаш кеше булса да, бу юлы ризалык бирергә ашыкмады.

— Алай итеп мәшәкатьләнгәнче, окопка Нәсиханың үзен генә җибәрү мәслихәтрәк булмасмы соң? — диде ул. — Аның бала-чагасы да юк, миңа караганда яшьрәк тә, тазарак та.

Карале, әни дөрес әйтә ләбаса, чыннан да, шулай ич!

Ләкин Самат абый бу мәсьәләне дә алдан ук уйлап куйган булып чыкты.

— Беләбез, Мәгъсүмә иптәш, барын да беләбез, — диде ул. — Анысы да уйланган. Әмма Нәсиханы окопка җибәреп булмый. Ул монда кирәгрәк. Галәви ике көннән фронтка китә, менә шуның урынына завхуз итеп куябыз Нәсиханы.

Менә сиңа кирәк булса! Галәви абыйның бер күзе кылый бит аның. Андыйларны сугышка алмыйлар дип әйткәннәр иде ләбаса...

— Башка кеше юкмыни соң Галәви урынына? — диде әни, әле һаман да ризалашасы килмичә.

— Син соң кемне куяр идең? Я, әйтеп кара! Или үзеңне генә завхуз итикме әллә? Мин аңа да каршы түгел, булдыра алсаң. Әмма башка кеше юк!

— Һей, Самат абый! — диде әни, куркуга төшеп. — Завхуз булырлык кешеме соң инде мин, ике класс белем белән... Миннән башлырак кешеләрнең дә күбесе буталып бетә бит ул эштә. Юк, юк, авызыңны да ачма, анда эшләп башны җибәргәнче, лутчы акупка китәм мин. Түлке әйтүем шушы, Самат абый, син авылның хуҗасы, малайга син дә күз-колак бул. Килендәшнең карахтеры тырт-пыртрак аның, малайга бер-бер хәл ясый күрмәсен.

— Син алай ук каты куйма мәсьәләне, Мәгъсүмә иптәш. Прсидәтел дигәч тә, мин малайлар карап йөрергә әбәзен түгел. Ну, шулай да борчылма артык. Кулдан килгәнчә тырышырбыз.

Аннары әни мине җитәкләде дә кайтырга чыктык.

— Курыкма, әни, — дидем мин идарә күтәрмәсеннән төшкәч, аны юатырга тырышып. — өч айга ничек тә түзәрсең. Җиңги ярата ул мине, хайваннарны да ач итмәбез, ничек тә карарбыз. Бәлки сугыш та бетеп куяр әле.

— Әй, улым, — диде әни, барган уңайга башымнан сыйпап, — нилэр генә әйттең иде дә бит бетсә! Алай тиз генә бетәр чамасы күренми шул әле ул афәтнең. Мәскәүгә якынлаша ди анда немецләр, һаман безнекеләрне куып килэләр, ди. Бигрәк бәхетсез заманага туры килдең шул, балам!

— Миңлеәхмәт белән Фәрзетдиннең әниләре дә барамы соң ул окопка?

Болай соравымның сәбәбе шул: әгәр әни «Алар да бара» дисә, мин аны: «Алай булгач, нигә мине генә бәхетсез дисең, дөньяда бер мин генә түгел ич әле ялгыз калучы», — дип юатмакчы идем. Әмма мин көткәнчә булмады: Миңлеәхмәтнең дә, Фәрзетдиннең дә әниләре окопка бармаячак икән.

— Аларның аталары сугышта шул, улым, — дип җавап бирде әни, мин нигә бармый соң алар, дип сорагач. — Әтиең сугышта булса, мине дә җибәрмәсләр иде дә бит...

Минем әти миңа өч тулып дүртенчегә киткән елны үлгән. Шунлыктан моңарчы мин аны белмәдем дә, юксынмадым да. Ә менә хәзер, эшләр болайга киткәч, әтиле буласым килә башлады. Бик-бик кирәк иде ул миңа хәзер. Нигә яшереп торырга, үлгәч-үлгәч, фронтка китеп үлмәвенә дә хәтерем калды.

Сугыш!.. Шулай итеп, аның нәрсә икәнен белү өчен, үскәнче көтәргә туры килмәде миңа. Бүген колхоз идарәсеннән өйгә кайтып баргандa ук тоя башладым мин аның мәгънәсен... Мине һәм минем шикелле бик күп балаларны әнкәләреннән аерырга чыккан бәла икән ул.

## Их, әнием булса...

Самат абый әйткән көнне әниләр окоп казырга китте, ә мин Нәсиха җиңгиләрдә калдым. Шул ук көнне, авылның ир-атлары сугышка китеп беткәннән бирле ат җигеп йөри башлаган Фәйрүзә апа белән Мәүлиха апаларны кушып, Самат абый безнең тезмәдәге барлык печәнне җиңгиләргә күчерттерде. Хайваннарны да аларга алып килдек. Шуннан башка үзгәреш булмады. Әнине дә әллә ни юксынмадым, күңелсезләнмәдем дә ул көнне. Ә кичен, җиңги пешергән токмачлы ашны ашап җибәргәч, минем эшләр бөтенләй шәбәеп китте. Ихтимал, сугыш башланганнан бирле андый тәмле аш ашаганым юклыктан шулай булгандыр инде.

Аштан соң, җиңги табак-савытларны җыештырган арада, мин аларның йонлач бохар песие белән уйнадым. Аннары җиңги пружиналы тимер караватка урын җәйде дә йокларга яттык.

Белмим, җиңгинең җылы куены шулай рәхәт булгандырмы, әллә йомшак караватка яткангамы икән — башым түшәккә тию белән йокыга киткәнмен. Йоклаганда бик матур бер төш тә күргән идем дә, тик нинди төш икәнлеге хәтеремдә калмаган.

Ә менә иртән җиңгинең мине ничек итеп йокыдан уятуын аерымачык хәтерлим.

Үзебездә соң гына, кояш тәрәзәбез каршындагы алмагач биеклеге күтәрелгәч кенә тора идем мин. Ә безнең ул алмагач кечкенә түгел, юанлыгы минем беләктән чак кына кайтыш аның. Озынлыгы да ярыйсы гына: миннән ике тапкыр биегрәк. Әгәр инде кояш шул алмагач башына менеп җиткәч тә торасым килми икән, әни ул чакта да бер сүз дә әйтми торган иде.

Күрәсең, әнә шулай туйганчы йоклап өйрәнелгәнгәдер инде, теге көнне иртүк, әле көн яктырганчы ук, җиңги үзенең нык, йомры куллары белән беләгемнән эләктереп:

— Равил, тор инде, тор, тор! — дип йолыккалый башласа да, башта күзләремне ачасым килмәде. Әмма ул: — Ах, әле син шулаймы?.. Торасыңмы, юкмы? Хәзер сөйрәп урамга чыгарып ташлыйм бит! — дип ныклап ук ачуланырга керешкәч, җылы түшәктә яту бик-бик рәхәт булса да, тизрәк торудан башка чара калмады.

Әле һаман да йокы исереклегеннән айнып житә алмыйча, өс-башымны киенгән арада жиңги миңа:

— Хәзер озаклап йоклар заман түгел, малай, аң бул аны! Хәзер сугыш вакыты, авыр чак. Бүгеннән алып, укуыңны да ташларга кирәк булыр. Әнә, сугыш *беткәч укырсың! — диде.

Шушы соңгы сүзен әйткәнче, башыма таяк белән сукса, мең өлеш артык булыр иде. Ни уйлап әйтте икән ул моны? Сугыш дип, ничек укуымны ташлыйм ди инде мин? Булмаганны! Укымагач, ничек шофер булырмын соң? Искәндәр абый кебек шофер буласы кеше ич мин!..

Ачуым килгән иде, түзә алмадым, тоттым да:

— Әбиең сызгыра беләме, жиңги? Бабаң утырмага килсен яме! — дидем тегеңә. — Әйтмә дә, сөйләмә дә, укыйм булгач — укыйм!

Жиңги миннән мондый кискен жавап көтмәгән иде булса кирәк: болай да зур зәңгәр күзләрен тагын да зуррак ачып, гажәпләнеп, байтак вакыт миңа текәлеп карап торды. Башка чакта бик матур иде аның ул зәңгәр күзләре. Искәндәр абыем башка кешегә түгел, нәкъ менә шушы зәңгәр күзле Нәсиха жиңгигә өйләнгәнгә куанып, малайлар арасында горурланып йөри идем. Әмма бу юлы нигәдер ямьсез, куркыныч булып күренде жиңгинең күзләре. Һәм мин жиңги үземне я бик нык орыша, яки тотып кыйный хәзер дип көттем. Тик эш алай зурга китмәде: күрәсең, мин-бала белән булашып, вакланып торасы килмәгәндер инде.

— Ә мин әйтәм укымыйсың! — диде ул, иплэп кенә. — Укыр чак түгел хәзер. Әллә сезнең ул хайваннарны мин карар дип беләсенме? Көт алланнан! Әнә, ишек катында фләге бар, хәзер шуны... тукта, башта бар, тәрәзәдән кара әле, кар яумаганмы анда?

— Юу-у-ук, — дидем мин, барып урамга карагач.

— Алайса фләгене алып чыгып арбага утырт та су апкайт! — диде жиңги, кырт кисеп. — Хайваннарыгызны эчерәсе булыр. Аннары абзарларны жыештырырсың. Ишек алдын да себерергә кирәк. Тиресләрен дә түгәрсең.

Гомеремдә бу тикле эш эшләргә туры килгәне булмаса да, мин болай итәргә уйладым: суны тиз генә алып кайтам да ишек алдын себереп ташлыйм. Аннары ялт кына ашап алам да мәктәпкә йөгерәм. Ә абзарны төштән соң, мәктәптән кайткач, жыештырам. Иптәшләр белән уйнарга вакыт калмый инде калуын, ләкин нишләмәк кирәк? Әнә бит, жиңги әйтеп тора: уен заманы түгел, ди.

Шулай итеп, жиңгинең дә күңелен күрмәкче, укуымны да дәвам итмәкче идем. Һәм бу минем өчен әллә ни кыен да булмас шикелле иде. Әмма гел син теләгәнчә генә булмый икән шул. Кая ул!..

Арбаны яр кырыена куеп, яр астыннан суны яртышар чиләкләп ташып, фляганы тутырганчы гына да дөнья хәтле вакыт үткән булып чыкты. Ә арбаны дыңгырдык юлдан көч-хәл белән жиңгиләргә алып кайтып житкергәндә, ачуым да килмәгәе, төш житә язган иде инде. Шулай да минем өмет тәмам өзелмәгән, соңга калып булса да, мәктәпкә бармакчы идем. Кичә дә, башта әнине озатып, аннары жиңгиләргә күченеп йөреп, дәрес калдырган кеше ич мин...

Тик бу ниятем дә барып чыкмады. Тирләп-пешеп капка төбенә кайтып туктавым булды, жиңги мине пыр тузып орышырга тотынды. Имеш, эчендә жаны булган кеше бу тикле озак йөриме соң: тиккә генә түгелдер бу, юлда уйнап йөргәнмен, янәсе... Китте тезеп, китте тузынып — чыда гына!

Кара инде син аны, ә? Мин, ярылырга житешеп, ашыгып йөргән булам, ә ул әнә ни кылана! Их, әнием булса! Болай кадерсезлектә йөри торган кешеме соң мин?..

Жиңги шулай пыр китереп ачуланып торгач, мәктәп кайгылары китте миннән. Ничек итеп курыкмыйча ул турыда сүз кузгатмак кирәк?

Күңелемнән тотып ашарлык дәрәҗәдә ачулансам да, тыштан берни дә сиздермәдем җиңгигә. Тамакка капкалап алдым да калган эшләргә тотындым. Алары су алып кайту кебек читен дә булмады, әллә ни озакка да бармады. Кичке якта уйнарга да бераз вакыт калды әле.

Ул көнне без — Фәрзетдин, Миңлеәхмәт, мин — ындырда ашлык сугучылар янында булдык. Чөнки, әле кар төшмәгәнлектән, чана шуып булмый, тәгәрмәч тәгәрәтеп уйнарга да салкын. Ә ындырда, салам арасында, рәхәт. Күпме телисең, шул чаклы уйна! Һәм без, туйганчы ук булмаса да, шактый уйнадык. Салам тарттыручы атның салам бәйли торган бавына тотынып, чабышып та йөрдек; ат куучы апаларны ял иттереп, алар урынына атларын да кудык; көлтә ташучыларга утырып, кырга кибән янына да барып килдек. Кыскасы, рәхәтләндем мин ул көнне. Җиңги янына тәмам караңгы төшкәч кенә кайттым һәм, нигә яшереп торырга, кушып калдырган эшләрен эшләп куйган өчен мактар да әле үземне дип өметләнгән идем. Әмма өметем акланмады.

— Кушкан эшләрне үтәвең яраган анысы, — диде ул, ишектән килеп керүемә үк, — ә менә шушы вакытка тикле уйнап йөрүең өчен нишләтергә инде сине?! Әйтмәдеммени мин сиңа, хәзер сугыш заманы дип. Гел әйткәнне генә эшләргә дигәнмени сиңа! Беләсең ич минем эштә икәнне, бәрәңге әрчи торсаң, кулың корыр идемени? Ярар, искә алырмын әле мин боларны, табармын мин сиңа эш...

Ә мин, юләр, иртәгә мәктәпкә барырга да рөхсәт итәр әле җиңги дип өметләнгән идем тагы. Көт болай булгач, җибәрер, җибәрәме соң!

Әнә шулай уйладым да, картлар әйтмешли, бу шайтаннан барыбер иман алып булмас, ахры, дип, гомеремдә ул нәрсәгә кулым бармасын белсәм дә, тәвәккәлләп:

— Мин сиңа бала-чага түгел, җиңги, ачуымны кабартып торма, яме! Эшләгән эшнең кадерен белмисең икән, тотармын да өеңә ут төртермен, — дидем.

Яхшылык белән ярый алмагач, куркытып, усаллык белән җиңеп булмасмы дип уйлаган идем. Әмма соңыннан ник авыз ачканыма үкенеп бетә алмадым.

— Әһә, әле син шулаймы! Аш белән атканга таш җибәрергә җыенасыңмы! — дип, гөлт итеп кабынып китте дә тотынды җиңги кыйнарга, тотынды кыйнарга — җанымны ала язды. Һәм әйтте:

— Әгәр тагын теш агартып шундый сүз ычкындырасы булсаң, болай гына калдырмам, билләһи, үтергәнче сугам! — диде.

Нигә шулай тиз, танымаслык булып үзгәрә икән бу җиңги? Моңарчы мин аңардан да матуррак кеше юктыр бу дөньяда дип йөрдем бит. Һәрвакыт елмаеп кына тора, иплəп кенә сөйләшә торган иде ул. Бигрәк тә Искәндәр абый белән сөйләшкәндә ярата идем мин аның тавышын: шундый йомшак, шундый җылы итеп әйтә иде сүзләрен, күңелләр әллә ничек рәхәтләнеп китә дә тыңлаган саен тыңлыйсы килеп тора иде.

Хәзер дә шул ук җиңги бит инде югыйсә: буе да, сыны да шул ук — бар җире элеккечә. Әмма, шулай булса да, ул инде Искәндәр абый вакытындагы җиңгигә тамчы да охшамаган. Йөзе караңгы, тавышы ямьсез. Зур зәңгәр күзләренең дә нуры качып, ничектер тоныкланып калган...

Эшләр болайга киткәч, бүген мине ашатмас та инде бу, дип уйладым мин. Ләкин, белмим ни хикмәт булгандыр, элекке хәленә үк кайтмаса да, кинәт әйбәтләнә төште җиңгәм:

— Бар, Равил, кече якка кер дә аша! — диде.

Үзе урын җәяргә тотынды.

Мин тамакны туйдырып олы якка чыкканда, җиңги инде чишенеп урынына яткан, әмма йокыга китәргә өлгермәгән иде әле.

— Кил, Равил, ят! — диде ул, минем идән уртасында кыюсыз гына басып торуымны күргәч. — Кил, ят, ачуым бетте инде.

Шулай дисә дә, шикләнебрәк кенә янына барып ятуым булды — җиңги үземне кочаклап та алды. Аннары, гафу үтенгәндәй итеп:

— Үпкәләмә инде син, яме? Ачуым бик килгән иде шул... Үзең дә инде, шундый чакта шулай дип торасың аны, — диде.

Мин дәшмәдем. Болай җайланып киткәч, җиңгигә ачуым сүрелгән, шул ук вакытта гаепне үз өстемә алырга да күңелем тартмый, чөнки ул суккан урыннар әле дә авырта иде.

— Ярар, бетсен ул, Равил, — диде җиңги, эссе, йомшак куллары белән әле һаман мине кочаклаган килеш, — онытыйк без бүгенге хәлне, яме?

Шулай диде дә ике битемне үбеп алды. Мин нигәдер җиңгине кызганып куйдым да, тынычландырмакчы булып:

— Борчылма, җиңги! Ачу саклый торган гадәт юк миндә, — дидем. — Күптән оныттым инде мин син кыйнаганны. Курыкма, сәвиткә дә барып чакмам. Үзем гаепле булганмын инде, җиңги.

— Әйе шул... Беләсеңме нәрсә, Равил?..

Ул нидер әйтмәкче иде, ләкин тыелып калды һәм ни турындадыр уйланып ятты.

— Беләсеңме, Равил, — диде аннары, — бүген Мәдинә апаң килде бит безгә. «Равил нишләп мәктәпкә бармады?» — ди.

— Син ана ни дидең соң, җиңги?

— Ашыкма, тыңла яхшылап! Мин аңа: «Равил үзе барырга теләмәде, укыйсым килми дип әйтте», — дидем.

— Нигә алай дип әйттең, җиңги? Минем укыйсым килгәнне беләсең ич.

— Нигә алай әйттемме?.. Шулай кирәк булды. Әйтелде бит инде сиңа, укуыңны ташларсың дип. Әйттем бит, укудан башка да эш житәрлек дип. Иртәгәдән мин зафхуз булып эшли башлыйм, көннәр буе амбарда булырга туры киләчәк. Шулай булгач, йорт-җир эшләре гел сиңа гына кала.

Шунда тукталып, җиңги тагын бераз уйланып ятты да, тавышын йомшарта төшеп, дәвам итте:

— Мәдинә апаң иртәгә дә килер әле, киләм дип китте. Әгәр, ник укырга йөрмисең, дип сораса, укыйсым килми диген. Нигә укыйсың килми дисә, әнине окопка җибәрмәсеннәр иде, шуңа укымыйм, диген.Ниләр генә әйтеп куркытырга тырышсалар да, курыкма, сине берни эшләтә алмый алар. Түлке, кара аны, бу сүзләрне мин әйтте дип ычкындыра күрмә! Алай-болай мин әйтте дип әйтә калсаң, иман заты көгмә, бүгенге шикелле генә итмәм, бер бирүдә тынсыз ясармын. Ишеттеңме?

Ишетмәгән кая инде! Җилекләремә үтте! Әмма «ишеттем» диярга телем бармады. Күрәләтә ялган сөйләр өчен үз азызым белән ризалык бирәсем килмәде.

— Ишеттеңме? — дип кабатлады җиңги.

Ул моны шундый кискен итеп әйтте, җавапсыз калу һич тә мөмкин түгел иде.

— Әй-е-е, — дидем, сузып кына, — ишеттем, җиңги.

— Нәрсә ишеттең?

— Шул син әйткәннәрне инде.

— Яле, мин нәрсә дидем, кабатла әле!

Нишлисең, ул әйткәннәрне кабатлап чыгарга туры килде.

— Менә шулай! — диде җиңги, кырыс кына. — Онытма, Мәдинә апаңа да шуларны әйтерсең!

Бары шуннан соң гына тынычлангандай булды ул һәм, караватны сытарлык дәрәҗәдә шыгырдатып, стенага таба борылып ятты.

Күрәсең, көндез эшләп, кичен минем белән булашып ул да шактый талчыккан булгандыр инде, биш-ун минут дигәндә пуфф-пуфф итеп йоклап та китте. Ә мине, ни тырышсам да, тиз генә йокы алмады. Шушылай бәхетсез булып дөньяга килүем өчен башта үземне-үзем орыштым. Аннары, сугышка тикле генә булса да яшәп, үлгәч-үлгәч, сугышка китеп үлмәгәне өчен тагын бер тапкыр әтигә үпкәләдем. Самат абый белән аяк терәп сөйләшмәгәнгә, мине шушылай кеше кулына калдырып киткәнгә әнигә дә хәтерем калды. Ул окопта булганга болай кимсетелеп йөрим бит инде мин. Югыйсә бу җиңгигә әйләнеп тә карыйсы кеше түгел. Ник кадалып китми шунда... Их, әни өйдә булса!.. Кат-кат уйлый торгач, боларның барысына да сугыш гаепледер, ахрысы, дигән фикергә килдем дә Гитлерны каргарга керештем...

## Барыбер минемчә булды

Ул көнне дә җиңги мине иртүк уятты һәм, тагын шулай караватында яткан килеш кенә, мин эшләргә тиешле эшләрне санап чыкты. Алда әйтеп үткән эшләрдән тыш, мин бүген, олаучылар колхоз болыныннан кайтканны саклап торып, аларның йөкләреннән печән йолкып алып кайтырга да тиеш булдым.

Әнә шул хәл аеруча борчуга салды мине. Соң, шулай булмыйча! Күрәләтә урлау була бит инде ул, йөк өстендә хуҗасы утырачак ич аның. Аннары кешенең әнәсенә дә кагылган малай түгел ич мин. Яшелчә каравылчысы Хәбир бабай төшке ашка өйләренә кайтып киткән чакларда башка малайлар кыярга кергәндә дә, алар өчен оялып, читкә йөгерә торган идем. Әни шулай өйрәтте мине.

— Нәрсә генә эшләсәң дә кичерергә булыр, — ди торган иде ул миңа, — әмма кеше әйберенә кагылсаң, әни дип тә әйтмә, яныма да кайтма!

Һәм чыннан да бездән ике өй аркылы гына булган Фәйрүзә апаларның бакча рәшәткәсе буенда ук күзләрне кызыктырып торган чияләренә дә кагылганым булмады.

...Ә бүген мин күрәләтә печән урларга тиеш. Башыңа төшкәч, башмакчы буласың, дип тиктомалга гына әйтмәгәннәр, күрәсең. Бүген тагын кичәге хәлнең кабатлануын теләми идем. Башка эшләрне тизтиз генә эшләп ташладым да, курка-курка гына булса да, бау тотып, печәнчеләр каршына — авыл башындагы үр буена киттем. Җиңги шулай кушты.

— Тау менгәндә олаучылар йөк өстеннән төшәләр дә арттан бара башлыйлар, — диде ул. — Менә шул чакта иң беренче йөкнең аргы ягыннан килеп йолкы да читкә ат печәнне. Беркем дә күрмәс. Аннары, олаулар үтеп киткәч, җыеп алып кайтырсың...

Әйе, аның сүзе дөрес булып чыкты: Фәйрүзә апа да, башка олаучылар да, үргә җиткәндә йөкләреннән төшеп, артка калдылар. Иң алда Фәйрүзә апа йөге. Нишләргә? Күрсә, ачулана бит инде ул. Ә минем аны ачуландырасым килми. Чөнки мин аны үз апам күк яратам. Кечкенә чагымда, әни эштә вакытларда мине карап, тәрбияләп торган кеше ул. Ул чакта Фәйрүзә апа үзе дә әле яшь, нибары унунберләрдә генә булган. Ә шулай да мине караган, ташлап китмәгән. Хәзер дә бик ярата әле ул мине. Инде мин менә шул үземне туган энеседәй күреп яраткан Фәйрүзә апаны ачуландырырга тиеш. Эшме соң инде бу, ә?!.

Мин шулай уйлап торган арада, Фәйрүзә апаның аты минем янга килеп тә җитте, узып та китте. Әмма печән йолкырга кулым бармады.

— Нишләп йөрисең монда, энем, бу суыкта? — диде Фәйрүзә апа, мине күреп алгач.

Аның башка чакта ап-ак йөзе, күрәсең, суыкта, җилдә эшләп йөргәнгәдер инде, бүген чиядәй кызарып киткән, ә аксыл-сары чәчләре шәленнән чыгып, тузгып тора иде.

— Җиңги сезнең йөкләрдән печән йолкып алып кайтырга кушкан иде, — дидем мин, алдашырга телем бармыйча.

— Ә-ә, шулаймыни? Нигә йолыкмадың соң?

— Ачуланырсың дип курыктым.

— Дөрес иткәнсең, энем. — Фәйрүзә апа тигез тешләрен күрсәтеп, ягымлы гына елмаеп куйды һәм: — Тпру! — дип атын туктатты да, йөгеннән йолкып, миңа бераз печән бирде.

— Менә, алып кайт, энем, җиңгәңә. Аның өчен бирүем түгел. Җәй буе кеше печән җыйганда йоклап ятты ул. Искәндәр абыең киткәннән соң әллә нишләп бик гамьсезләнеп калды. Сине кызганып бирәм мин бу печәнне.

— Рәхмәт инде, Фәйрүзә апа.

— Ярар, зур үс, энем. Әниеңне сагынасыңмы?

— Сагына-ам, Фәйрүзә апа.

— Сагына torгансыңдыр шул, җиңгәң бик коры кеше бит синең. Ярар, чыда инде, энем, ничек тә түз. Солдат бит син хәзер, солдат түзәргә тиеш ул.

— Нинди солдат булыйм ди инде мин, Фәйрүзә апа? Солдат булсам, сугышта булыр идем, болай бер уч печән теләнеп йөрмәс идем.

— Юк, энем, солдат син хәзер. Сугыш вакытында бөтен кеше солдат була. Барыбыз да солдат без хәзер...

Мин теге печәнне күтәреп кайтып кергәндә, җиңги ишек алдында Мәдинә апа белән сөйләшеп тора иде. Укытучымны күргәч, җаннарым рәхәтләнеп китте. Әниемнән кала иң яраткан кешем ул! Беркайчан да, беркемгә дә ачуланмый, һәрвакыт йомшак кына, ягымлы гына сөйләшә. Хәтта кайбер балалар дәресләрен белмәгән чакларда да кызып китми, иплəп, ашыкмый гына аңлата. Белмим, үземә генә шулай тоеламы икән, ул мине бик якын итә.

Менә ул, миңа карап, һәрвакыттагыча матур итеп елмайды да әйтте:

— Без синең турыда сөйләшә идек әле, Равил. Җиңгәң әйтә, Равил укуымны ташлыйм дип әйтә, ди. Чынмы бу сүз?

Нишләргә инде? Нәрсә дияргә бу Мәдинә апага? Укыйсым бик-бик килә торып, ничек итеп укымыйм дип әйтергә?

Ни дип җавап бирергә дә аптырап, җиңгинең күзләренә карадым һәм шундук кичә ул әйткәнчә әйтүдән башка юл булмавын төшенеп алдым. Чөнки ул теге зур зәңгәр күзләренең агы белән шундый итеп карап тора, әгәр дә мәгәр Мәдинә апага дөресен сөйләп бирсәм, мине шундук кабып йотар төсле.

— Укымыйм инде мин, Мәдинә апа, — дидем мин. — Укыйсым килми.

— Нишләп! — диде Мәдинә апа, кинәт сискәнеп китеп.

Миннән мондый җавап көтмәгән иде булса кирәк, ул тәмам аптырап калган иде:

— Ничек инде ул «укыйсым килми?» Класста иң яхшы укучыларның берсе ич син. Ни дигән сүз инде бу?

Мин башымны иеп, борынымны лыш-лыш тартып, ни әйтергә дә белмичә, өнсезләнеп тора бирдем.

— Әллә җиңгәң укытырга теләмиме? Яшермә, дөресен әйт! — диде Мәдинә апа, таләпчән итеп.

Әйтерсең дөресен! Әйтеп кара!

— Юк, җиңги түгел, үземнең укыйсым килми, әнине окопка җибәрмәсеннәр иде, — дидем мин, тәмам елар чиккә җитеп һәм тагын җиңгигә күз төшердем. Бу юлы аның йөзе ай да кояш иде, хәтта күзләре дә көлеп тора шикелле тоелды.

— Менә, Мәдинәкәй, әйттем бит мин сиңа! — диде ул, куанычыннан нишләргә белмичә. — Әйттем бит, үзе укырга теләми дип. Шулай булгач, мин аны нишләтим ди? Үз малаем түгел бит, тотып кыйнап булмый ич аны!

Ничектер шулай килеп чыкты, җиңгинең күз алдында ялганлап, авыз ерып торуына жен ачуларым кузгалып китте.

— Ы-ы, кыйнамассың син? Кичә ничек кыйнаганыңны оныттыңмыни? — дигәнемне үзем дә сизмичә калдым. Аннары, үз сүзләремнән үзем куркып, еларга ук тотындым.

— Әй, Нәсиха, Нәсиха! — диде Мәдинә апа. — Ничек оялмыйсыз сез шушылай алдашып торырга?. Ярар, анысын соңыннан тикшеребез. Ләкин, карагыз аны, балага кул тидерәсе булсагыз, җавабын бирергә әзер торыгыз! Ә син, Равил энем, иртәгә үк мәктәпкә кил. Курыкма җиңгәңнән, кил, ярыймы!

Шулай диде дә, җиңгине тагын бер кат кисәтеп, капкага юнәлде, ә мин шикләнеп җиңгигә карадым. Аның күзләре яңадан нурсызланып калган һәм ул мине ботарлый башлаудан үзен бик зур кыенлык белән генә тыеп тора иде.

Мондый чакта җиңги белән икәүдән-икәү калу шактый хәвефле иде. Шунлыктан тиз генә Мәдинә апа артыннан йөгердем. Куып житеп, җиңеннән тоттым да:

— Апа, мин җиңгиләрдә кунмыйм бүген, куркам мин аннан, — дидем.

Мәдинә апа, нишләргә икән инде синең белән дигәндәй, бер мәлгә аптырабрак торды да:

— Ярар, Равил, әйдә, мин сине үзебезгә алып кайтам. Минем янда кунарсың, — дип Хәбир бабайларга алып китте. Ул үзе безнең авылныкы түгел, Чистай ягыннан килгән, ә Хәбир бабайларда фатирда тора иде.

Мәдинә апа минем хәлне сөйләп биргәч, Хәбир бабай да, карчыгы Мәфтуха әби дә башта мине бик кызгандылар, аннары хәзинәләрендә булган ризыклары белән әйбәтләп туйдырдылар. Аннары йокларга яттык.

Әмма мин тагын тиз генә йоклап китә алмадым. Күңелгә әллә нинди борчулы уйлар килә: миңа үч итеп, җиңги хайваннарны ач калдырмады микән, дип тә уйлыйм; бүген ярый, монда, Хәбир бабайларда ятам, әмма иртәгә кайда кунармын, дип тә борчылам. Ләкин, барыннан да элек, әни өчен кайгырам, аны сагынам. Ул бичара кайларда икән хәзер? Көнозын төн балчыкны казып бик арый микән? Алар окоп казый торган җиргә немецлар бик якын түгел микән? Ул да мине шушылай минем кебек сагына микән?..

Иртән Мәдинә апа белән мәктәпкә баргач та күңелем укуда булмады. Кичәге уйлар һаман йөрәкне тырнап торды.

Дәресләр беткәч, иптәшләрем өйләренә таралышты, ә мин партамда утырып калдым. Кая барыйм соң?

— Бер дә борчылма, Равил! — диде Мәдинә апа, яныма килеп. — Бар, безгә кайт та шунда утырып тор. Ә мин хәзер идарәгә барам. Анда Мөсфирә апаң килгән булырга тиеш, чакыртып җибәргән идем. Курыкма, барысын да рәтләрбез, әллә кая сикерә алмас җиңгәң. Сугыш заманасы булса да, Совет властеның аңа житәрлек көнә көче бар аның...

Хәбир бабайларга кайтып, берәр сәгать утырдым микән, Мәдинә апа белән Мөсфирә апа да килеп җиттеләр. Мөсфирә апа хәзер авыл советы председателе булып эшли иде инде.

— Әйдә, энем, — диде ул миңа, килеп кереп Хәбир бабайлардан исәнлек-саулык сорашканнан соң, — киен, хәзер җиңгәң янына кайтарып куярбыз сине.

— Кыйнар дип кенә куркам мин аннан, Мәсфирә апа, — дидем мин, бишмәтемне кия-кия.

— Без аның белән бик нык лап сөйләштек инде, курыкма, энем, тимәс. Әгәр ялгыш кына кул тидерсә дә, килеп Мәдинә апаңа әйт. Белербез без аны нишләтергә.

Без өчәүләшеп килеп кергәндә, җиңги идән-сәке юып йөри иде.

— Һу, кунаклар килә икән! — диде ул, без бусагадан атлауга. — Әйдәгез, әйдә! Түргә узыгыз!

Мине гаҗәпкә калдырганы шул булды: майлап куйганнар диярсең җиңгине — шундый ягымлы, шундый ачык.

— Әйдә, Равил, син дә чишен, сагынып беттем инде үзеңне, — диде миңа. Әйтерсең, беркайчан да ачуланмаган да, кыйнамаган да мине.

Минем дә йөрәгем таш түгелдер, ахры: укырга рөхсәт итмәве өчен, үлгәнче ачу тотып йөрермен, дип күңелемә беркетеп куйган булсам да, әлеге тәмле сүзләреннән соң тагын үз итеп куйдым җиңгине. Шулай да:

— Ә мине укырга йөртәсеңме соң инде, җиңги? — дип сорамыйча түзә алмадым. Укытучы белән председатель бар чакта мәсьәләне ачыклап каласым килде.

— Йөрерсең, йөрерсең, Равил! — диде җиңги.

Шулай итеп, барыбер мин дигәнчә булды.

## Эшләр җайланган иде дә...

Җиңги миңа укырга рөхсәт иткән көнне аның үзен дә завхоз итеп куйганнар иде. Шул көннән алып, ул да хәзер элекке кебек озак йокламый, иртәрәк тора башлады. Һәм без, икәүләшеп, йорт-җир эшләрен кул-кулдан тиз генә эшләп ала торган булып киттек. Җиңги мичкә яга, аш әзерли торган арада, мин юырттырып кына су алып кайтам, чөнки инде кар яуган, фляганы үземнең үрәчәле кечкенә чанага утыртып йөрим. Ә чана арбага караганда күп җиңел ул. Җиңги мал-туарга печән сала, су эчерә торганда, мин абзарларны җыештырып куям. Аннары тиз-тиз генә ашыйбыз да, ул — амбарга, мин — мәктәпкә китәбез. Ә тирес түгү, идән юу, бәрәңге әрчү кебек вак-төяк эшләрне мәктәптән кайткач эшләп алам. Кыскасы, хәзер минем эшләр шактый көйле. Җиңги белән дә ярыйсы гына тату яшибез.

Ә тора-бара минем эшләр тагын да шәбәеп китте: төштән соң, җиңги амбарда вакытта, Миңлеәхмәтләр, Фәрзетдиннәр белән чана да шугалый башладым. Җиңги кушып калдырган эшләрне мәктәптән кайтуга бергәләп эшләп ташлыйбыз да тауга чабабыз. Ә алар миңа бик теләп булыша, чөнки мин аларга икмәк бирәм. Икмәк дигәндә, малайлар утка керергә әзер, чөнки Миңлеәхмәтнең дә, Фәрзетдиннең дә әниләре күптән инде икмәк салмыйлар. Оннары юк.

Фәрзетдин аеруча хирес ашауга. Әнисе кушып киткән эшләрне эшләмәсә эшләми, әмма борынын тырысайтып, Миңлеәхмәттән алдан кереп җитә минем янга. Керә дә:

— Бүген нинди эшләрең бар? — дип сорый. Мин санап күрсәткәч:

— Кайгырма, малай, хәзер бетерәбез без аларны. Тик иң элек ашап аласы иде бит, карын бик ачты минем, — ди.

Ләкин алдамый үзе. Ашаганнан соң җен урынына эшли. Миннән гәүдәгә дә зуррак, тазарак та ул.

Ә мин алардан ашауны кызганмыйм. Җиңги амбарда эшләгәнлектән, оныбыз бер дә бетеп тормый. Икмәкне күпме ашасам да, җиңги миңа ачуланмый. Шулай да:

— Кара аны, Равил, җиңги он алып кайта дип, кешегә-фәләнгә ычкындыра күрмә! — дип кисәтеп куйды.

Әйтәмме соң инде! Тиле түгел лә мин: халыкка ишетелсә, җиңгине ни эшләтәселәрен һәм җиңги мине ни эшләтәчәген аңларлык кына башым бар ич!

Авылыбызның Тәгъзимә исемле хатынын, әнә, ындырдан бер кесә борчак алып кайтканы өчен генә дә өч елга утырттырды бит Самат абый.

Кыскасы, картлар әйтмешли, кода сыенда яши башлаган идем хәзер мин. Әмма... Иплэп кенә, әнине сагынудан башка читенлек күрмичә генә яшәп яткан көннәрдә тагын минем өчен шактый күңелсез хәл килеп чыкты:

— Син бик тынгысыз йоклыйсың, Равил. Бөтен өстемне ачып ташлыйсың, тибенәсең, — дип, җиңги миңа мич башына ятарга кушты. Тараканнар кыштырдашканга куркып, беренче төнне йокысыз үткәрсәм дә, соңыннан анысына да күнектем.

Тик ул тынычлык та озакка бармады. Кышкы буранлы кичләрнең берсендә безгә Самат абый килеп керде.

— Мәгъсүмә малае синдә тора бугай, нишләп күренми, әллә берәр җиргә җибәрдеңме? — диде ул, өй эчен күздән кичергәч.

Мин мич өстеннән башымны сузып карап тора идем, аның сүзләрен ишетүгә:

— Мин монда, Самат абый! — дип кычкырдым. Әни турында берәр куанычлы хәбәр алып килдеме икән әллә дип өметләнгән идем. Юк икән, булса әйтми калмас иде. Ә ул:

— Әһә! Андамыни? Йокла инде, энекәем, йокла, урының җылыда икән! — диде дә, мине шундук онытып, җиңги белән пышын-пышын сөйләшә башлады. Мин аның «суган», «булса икмәк тә» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Аннары голт-голт итеп шешәдән нәрсәдер агызган тавыш килде. Аракы эчте, ахры. Бераздан җиңгине дә кыстый башлады, әмма җиңги якын да китермәде:

— Юк, юк, Самат абый! Әйтмә дә, сөйләмә дә! Әйдә, тизрәк эшенне кара да — юлыңда бул. Югыйсә, кеше әллә ниләр сөйли башлар.

— Курыкма, Нәсиха туташ, — диде Самат абый, бу юлы шактый нык кычкырып. — Сөйләрлек кеше бармыни хәзер авылда. Сөйләсәләр дә аптырама. Эт өрер, бүре йөрер!

Шулай дигәннән соң җиңгине кочакларга итте булса кирәк, чөнки җиңги:

— Самат абый, нишлисең? Җибәр, этү разбуй салам! — дип, чырыйлап кычкырып куйды.

Эшләр болайга киткәч, Самат абый шикләнә төште, ахрысы:

— Ярый, ярый, бетте, — диде. — Бүлше кагылмыйм. Тик кума гына. Синең янында утыру гына да үзе бер гомер минем өчен.

Ах, чулак шайтан! Кара ни сөйләнеп торган була бит, ә?! Их, көчем житсә! Якасыннан гына эләктереп алыр идем дә... Я менә хәзер Искәндәр абыем кайтып керсен иде. Ну булыр иде дә соң кызык хәлләр!..

— Шулай да әйт әле, Нәсиха, — диде Самат абый, байтак гомер дәшми торгач, — ниме дип чакырдың син мине, куасы булгач?

— Кем? Минме? — диде җиңги, гаҗәпләнгән тавыш белән. — Мин чакырдыммы сине? Ачуымны китереп торма, Самат абый, прсидәтел дип тормам, типкәләп чыгарырга да күп алмам. Соң үзең кереп чыгам диден лэбаса!

— Син мине нигә килә дип уйладың соң? Әллә шушы аракыны эчәр урын тапмас дип белдеңме?

— Мин берни дә уйламадым. Кереп чыгармын дигәч, кермә дип булмый ич кешегә. Ә син үзең нәрсә уйлаган идең соң?

— Ярар, исерә башладым, ахры, мин. Кая, кайтыйм әле, булмаса... Инде чыгарга дип ишек катына килгәч, тагын туктап калды:

— Ә, мижды пручим, сине окоп казырга җибәрмичә хата эшләгәнмен мин, Нәсиха. Мин сине болай ук каты күңелле булырсың дип уйламаган идем. Хата эшләнгән, хата-а!

— Ярар, ярар, Самат абый, әйе, дөрес әйттең, хата булган. Бар, кайт инде, кайт, балаларың янына кайт! — дип, җиңги тегене җилтерәтеп чыгарып җибәрде.

Шушылай борып җибәргәч, Самат абый бүтән килмәс, оялыр дип уйлаган идем мин. Әмма намус саклаучылардан түгел икән ул, икенче кичне үк килеп җитте. Тагын аракы алып килгән бу. Бераз эчеп алгач, тагын җиңгигә бәйләнергә тотынды. Тик бүген җиңги аның белән артык сатулашып тормады, яртылаш бушаган шешәсен кесәсенә тыкты да, таза, көчле куллары белән якасыннан алып, кичәгедән дә хәтәррәк җилтерәтеп, куып чыгарды.

Шуннан ары байтак вакыт Самат абый безгә килмәде.

## Бәла өстенә бәла

Көннәр акрынлап үтә торды, минем тормыш үз көенә ага бирде: укуым да әйбәт кенә бара; үземә тапшырылган эшләрне дә Миңлеәхмәт, Фәрзетдин белән бергәләп ансат кына эшләп ташлыйбыз; җиңги дә хәзер минем белән булашмый: мактамый да, ачуланмый да. Ләкин, ничек кенә булмасын, күңелем һаман тыныч түгел — өзелепөзелеп әнине сагынам. Ул кайтып, үз өебездә яши башлагач, икмәк түгел, бәрәңгесе дә туйганчы эләкмәячәген дә беләм, тик барыбер әнине тизрәк кайтарасы килә. Миңлеәхмәтләр, Фәрзетдиннәр, әнә, ачлы-туклы да торалар ич әле. Дөрес, хәлләре бик үк шәптән түгел инде түгелен. Миңлеәхмәт соңгы вакытта бигрәк нык ябыкты. Муены нечкәргәнлектән, элек тә ярыйсы ук дәү башы хәзер тагын да зураеп калды, битендәге сипкелләре дә куерып китте. Хәтта кай көннәрне дәрес барганда ничектер өнсезләнеп калган чаклары да була аның.

Әмма мин аны барыбер үземнән бәхетлерәк саныйм, чөнки ул әнисе белән бергә тора. Мин дә ничек тә түзәр идем әле. Ахыр чиктә, ачка үлсәм дә, әни кочагында үлү, җиңгидән куркып, аңа ярарга тырышып яшәүдән мең өлеш артыграк булыр шикелле. Тик әнием генә тизрәк кайтсын!..

Ә ул кайтмый да кайтмый. Киткәннәренә инде ике айдан артык вакыт үтте, әмма кайтыр чамалары юк әле. Җиңгинең сүзе хак булса, тагын берәр айсыз кайтмаячаклар, ди.

Тәки шул алдан әйткән өч айны тутырганчы тотарлар, ахры.

Тагын бер ай!.. Ай-яй озак үтә икән ул ай дигән нәрсә!.. Сугышын да әйтер идем инде, шул тикле озакка бармаса... Шулай безгә каршы торырлык дәрәҗәдә үк көчле микәнни ул немецлар, нигә тизрәк бөтереп тыкмыйлар икән инде шуларны?.. Ә алар безнең авылның байтак кешесен харап иттеләр бит инде. Җиңги белән санап караган идек, авылыбыздагы шул ңибары утыз җиде йорттан кырык өч кеше сугышка киткән. Шуларның егерме тугызы турында я «үлде», яки «хәбәрсез югалды» дигән язу да килгән инде. Әгәр гел шушылай барса, безнең авылның бер кешесе дә кайтмаячак бит! Җиңги әйтә, әле һаман фашистлар безне кысрыклый, ди. Белмим, ни белән бетәр икән инде моның ахыры!..

Мин шул рәвешле борчылып йөргән көннәрдә Фәрзетдиннең атасы турында да «Геройларча үлде» дигән хәбәр килде. Герой булып үлүе ярый инде анысы. Ни әйтсәң дә, йөзләп фашистның башына җиткәндер әле. Югыйсә алай дип язмаслар иде. Әмма, ничек кенә булмасын, ул юк бит инде, Вафа абыйны әйтәм. Кайтмаячак инде ул, беркайчан да кайтмаячак! Әй, яхшы да кеше иде үзе! Аның ат җиккәнен күрдекме,

хәзер Фәрзетдин белән арбасына менеп кунаклый идек. Бер сүз дә әйтми, авыл башына тикле утыртып барыр иде. Сугышка китәр алдыннан гына безгә мич тә чыгарып биргән иде. Әни ничек кенә кыстаса да, бер тиен хезмәт хакы да алмаган иде...

Атасы үлгәннән соң Фәрзетдин дә безгә кермәс булды. Чөнки Вафа абый турында теге өмет өзгеч хәбәрне алганнан ары, анасы еш кына авырып егыла башлады аның. Әнисен ташлый алмый шул.

Аннары Миңлеәхмәтнең атасы турында да «Батырларча һәлак булды» дип яздылар. Шуннан соң ул да миңа булышудан туктады, чөнки әнисе аңа эшне күбрәк куша башлады. Ләкин мин аларга үпкәләмим һәм без өчебез дә элеккечә бик дус яшибез. Миңа ярдәм итәргә вакытлары булмаса да, алар икесе дә көненә бер тапкыр безгә кереп чыкмыйча калмыйлар. Мин аларга я калган ашны ашатам, я җиңги миңа дип калдырып киткән икмәктән өлеш чыгарам.

Соңгы көннәрдә минем эшләр яңадан көйсезләнеп китте. Бердән, эш күп, икенчедән, уйнарга һич вакыт калмый. Аннары дусларым Миңлеәхмәт, Фәрзетдиннәр белән дә рәхәтләнеп сөйләшеп утырып булмый. Җитмәсә, Миңлеәхмәт атасы турында теге язу килгәнгә бер атна да үтмәгәндер, минем Искәндәр абыйның да хәбәрсез югалуын әйткән кәгазь килде. Монысын мин һич тә көтмәгән идем инде. Минем Искәндәр абыем гади солдат кына түгел бит. Шофер иде ләбаса ул, сугышка да үз машинасы белән киткән иде ич... Әллә машинасына бер-бер хәл булдымы икән? Пуля тиеп, ватылды микән әллә? Шулай булган тәкъдирдә дә абый немецларга бирешергә тиеш түгел. Бөтен районда беренчелекне алган батыр ич ул... Белмим инде, белмим!.. Ә бит Искәндәр абыем минем әтием урынына калган кеше иде. Туры килгәндә үзе янына кабинага утыртып йөри торган иде. Бервакыт районга да алып барган иде хәтта. Бик тиз йөри иде ич аның машинасы, җәяүлеләрне генә түгел, атлыларны да выжт итеп кенә узып китә торган иде. Үзе дөнья хәтле йөк тә төйи торган иде әле. Шуңа күрә үскәч үзем дә шофер булмакчы идем бит мин. Ә икенче теләгем — гармунчы булу иде. Минем бу уемны Искәндәр абый да белә, сугышка киткәндә:

— Исән калсам, сиңа гармун алып кайтырмын, энем, яме, — дигән иде.

Гармуны кадалып китсен, үзе исән кайтса да ярар иде әле. Ә ул, әнә, югалган. Машинасы нишләде икән инде аның? Анысы да югалдымы икән? Хәбәрсез югалган кеше кайта микән ул! Минемчә, кайтырга тиеш. Сугыш кызуында фашистларны куып алгарак киткәндер дә, юл язып, адашып кына калгандыр. Машинасы да югалмагандыр әле. Әйе, шулай гынадыр. Ә иптәшләре аны югалды дип уйлаганнардыр да җиңгигә хәбәр иткәннәрдер...

Әмма җиңги башкачарак уйлый иде, ахры. Хат ташучы теге язуны китергәч, ул бик нык куркып китте, бүтән вакытта пешкән алма шикелле булып кызарып торган йөзе кинәт агарып калды. Аннары караватына барып ауды да үзәкләрне өзәрлек итеп, кычкырып елап җибәрде. Озак, бик озак елады җиңги. Гитлерын да, алласын да, мулласын да каргый-каргый елады. Кулы эшкә, авызы ашка бармады. Ә кичен ниндидер моңарчы мин ишетмәгән моңлы бер көйгә җырлады-җырлады да:

— Их, ник чукынып китми дөньясы! Искәндәрем булмагач, ни кызыгы кала инде аның миңа? Ичмаса, бераз хәсрәтем таралмасмы! — дип, абый кайта-нитә калса аны сыйларга дип әзерләп куйган бер шешә аракысын мич астыннан тартып чыгарды. Аннары шул шешәдән бер стакан тутырып салды, аны эчеп җибәрде дә тагын озак итеп җырлады һәм, караватта утырган җиреннән бер якка кыйшаеп, гырлап йокыга китте. Өй эче шундый шомлы, шундый куркыныч булып калды,

ул кичне минем мич башына менәргә йөрәгем житмәде: бер очы жиңги астында калган юрганны көч-хәл белән генә тартып чыгардым да, шуны ябынып, караватта гына йокладым.

Әллә шуны гына көтеп торган инде, Искәндәр абыйның хәбәрсез югалуы турында язу алганның икенче кичендә үк Самат абый тагын безнең ишеккә килде. Ләкин жиңги кертмәде аны.

— Зинһар, йөрмә йөрәгемне бозып, сине көндез күреп тә туйган мин, гарык! — дип борып жибәрде.

Ә Самат тагын, тагын килде. Мин юри санап бардым, нәкъ жиде кич рәттән борып жибәрде аны жиңги. Бары тик сигезенче кичне генә түзмәде, ачты ишекне.

Тагын жиңгигә бәйләнә башламаса ярар иде дип куркып, Самат абый чыгып киткәнче йоклый алмыйча яттым ул кичне. Әмма Самат абый жиңгигә кагылмады. Матур гына сөйләшеп утырды да, алып килгән аракысының да бер генә стаканын эчеп, иплән кенә чыгып китте.

Шуннан ул һәр кичне диярлек безгә килә башлады. Аның әйтүенчә, хатыны Бибижамал апа эчкән кешене һич тә яратмый икән, шулай ук башка кешегә керергә дә яхшы түгел, колхозныкын эчә дип әйтүләре бар. Ә жиңги аңа үз кеше, бер табактан ашаучы, имеш.

— Менә шуңа киләм мин сезгә, Нәсихакаем, — дип аңлатты Самат абый, үзенең болай еш керүенең сәбәбен.

Шулай итеп, жиңгигә дә тимәгәч, вакытында чыгып та китә башлагач, Самат абыйга ничектер күнегеп киттем, ахры. Ул киткәнче үк йоклый идем хәзер. Ләкин бер дә бер кичне, һич истә-оста булмаган күнелсез хәл килеп чыгып, хәйраннарга калдырды мине.

Сәгать төнге уннар булгандыр, өйалды ишеге бик нык дөберди башлаганга уянып киттем мин. «Беттек болай булгач, немецлар безнең авылга килеп житкәннәр икән! Әнине дә күрми үләм, ахры», — дип уйлап алдым да:

— Жиңги, жиңги! — дип кычкырып, еларга үк тотындым.

Жиңги урынына бер ир кеше жавап бирде:

— Тик кенә ят син анда, малай актыгы! Пычак кердеме әллә, шул тикле акырасың? — диде ул, коры гына итеп. Мич башыннан башны сузып карасам — Самат абый икән.

Минем эчкә жылы керде. Самат абый бездә булгач, немецлар түгел, Гитлер үзе килеп керсә дә курыкмас кебек идем. Чулак һәм гәүдәгә кечкенә булса да, ир кеше ич әле ул, немецлар килеп керә калса, ничек тә ирек бирмәс...

Ә ишек һаман дөберди.

— Бар чыгып кер инде, Нәсиха, — диде Самат абый, дөбердәтүченең һич тә туктар чамасы сизелмәгәч. — Кем икәнен сора да кер, ишегеңне ачасы булма!

Кем булыр икән бу вакытта? Әни кайтмагандыр бит? Әллә Искәндәр абый микән? Нигә тизрәк керми икән соң ул кеше?

Мин шулай уйлап, баш ватып яткан арада жиңги әйләнеп керде дә, Самат абый янына барып:

— Нишлибез инде менә хәзер? Бибижамалың килгән бит! — диде. — Безнеке сездә булырга тиеш, өенне кереп карамыйча китмим, ди. Менә, әйттем мин син йолкышка аракыңны эч тә чыгып кит, дип. Булмастайны лыгырдап утырма, дип. Хәзер бөтен дөньяны сасыта инде!

— Ах, ан-насын... Кая, идән астыңны ач әле, сеңелем Нәсиха, — диде Самат абый, өтәләнеп.

Ул арада өйалды ишеге баягыдан да битәррәк дөберди башлады.

— Ә-ә-ә! Шулаймыни? Әле син качып котылырга уйлыйсыңмыни? — диде жиңги, белмим нигәдер бик каты ачуланып. — Юк инде, алай итмибез аны! Куркырлык булгач, минем жанымны кыйнап утырмаска иде!

Шулай диде дә ишеккә юнәлде.

Самат абый мыгырдана-мыгырдана нишләргә дә белми аптырап торган арада җиңги чыгып ишекне ачуы булды, авызыннан утлар бөркеп, Бибиҗамал апа килеп тә керде. Килеп кергән уңайга:

— Ах, әле син шулаймы! — дип, иренең коелганнан калган сары чәченнән эләктереп алды да типкәләп чыгарып та ыргытты. Бибиҗамал апага каршы сугу түгел, авыз ачып сүз әйтергә дә өлгерә алмый калды Самат абый. Хәер, хатыны да таза иде инде. Самат абыйдан буйга да күп озын, аркауга да ике-өч мәртәбә калынрак иде шул Бибиҗамал апа.

Ире белән эшен бетергәч, ул бер очтан җиңгигә дә очып кунмакчы иде, әмма җиңги якын да китермәде. Гәүдәгә Бибиҗамал ападан күп кайтыш булса да, каушап калмады:

— Якын киләсе булсаң, миңа үпкәләмә! — дип кулыннан тотып алды да ансат кына читкә кагып куйды тегене.

Күрәсең, көч белән алдырып булмаслыгын сизенгәндер, Бибиҗамал апа җиңгигә бүтән ыргылмады. Әмма тел белән... дөньядагысын калдырмады инде!

Ә җиңги, берни булмагандай, бөеренә таянып тыныч кына тыңлый бирде. Аннары, шулай ук кызмыйча гына, хәтта бераз көлемсерәп:

— Ахмак син, Бибиҗамал апа! — диде. — Ахмак булмасаң, берни белмәгән килеш, нахакка бәйләнеп тормас идең. Болай дөнья сасытып йөрмәс идең. Акылың булса, үзең уйлап кара әзрәк: синең ул өрсәң очып китәргә торган йолкышыңны өемә бик теләп керткән дип уйлыйсыңмы әллә? Үзе эрсезләнеп йөри ич ул. Теңкәмне кортты инде прәме. Башка замана булса, мин аны бусагамнан атлату түгел, урамда очратканда да төртеп егып китәр идем дә бит, заманасын алла каһәрләгән! Син миңа ачуланма инде, Бибиҗамал апа җаным, бар, әнә Гитлерга ачулан. Нигә, сугыш ачып, колхозны синең Саматың кулына калдырды икән?

Бу сүзләрне җиңги бер дә ашыкмыйча, иплэп кенә әйтте. Күрәсең, аның мондый сабырлыгы Бибиҗамал апага да кучте булса кирәк:

— Сугы-ыш! — диде ул, тирән сулап. — Әй, шул Гитлерны тотып асасы иде, каһәрне!.. Ә син, Нәсиха, шулай да минем сүзләрне дә колагыңа ал әле, наным: Саматны, килсә дә, борып җибәр.

— Бик борасы да бит, китми шул ул. Бер-ике минутка гына, бик ашыгыч йомышым бар иде, дигән булып керә дә утыра, җыен юк-бар белән җанны кыйнап. Прсидәтл кеше бит, ничек типкәләп чыгарасың аны? Үзең дә авызыңны ачып йөрмә, Бибиҗамал апа: күз-колак булгалап тор иреңә.

— Аны карыйммы, биш баламны карыйммы, кайсына гына житешим соң? Тукта әле, кайтып тагын бер изим әле үзен! — дип, Бибиҗамал апа бик хәтәр ачуланып чыгып китте. Мин дә, хәлнең болай ансат кына тәгәлләнүенә куанып, мич өстеннән башны алдым.

Тиз генә йокыга китеп булмады. Җиңги белән Бибиҗамал апа арасында булып үткән әлеге сөйләшү гаҗәпкә калдырды. Соң шулай булмыйча! Бигрәк кызык икән бу олылар: башта пыр тузышып ачуланыштылар, аннары шундук татуланышып та киттеләр. Ә без, малайлар, бер-беребезгә үпкәләшсәк, өчәр көн сөйләшми йөргән булабыз...

## Күрәселәребез алда икән әле

Бибиҗамал апа тузынганда үзен бик тыныч кына тоткан кебек булса да, теге төнге вакыйга җиңгине дә тетрәткән иде, ахры: шуннан соң ул күзгә күренеп үзгәрде, усалланып китте. Миңа да, бер дә гаебем юк шикелле булса да, тагын теге зур зәңгәр күзләренең агы белән

карый, Самат абыйны да кертми, кире борып җибәрә башлады. Шулай ук йорт-җирдән дә күнеле суынды аның. Хәзер ул амбардан ит тә, он да алып кайтмый, ашау-эчүгә дә игътибар бирми: пешерсә пешерә ашны, пешермәсә — юк. Калдык-постык ашыйбыз да ятабыз.

Хайваннарны да элекке кебек вакытында ашатмый хәзер җиңги. Мин моны шуннан әйтәм, соңгы көннәрдә безнең сыер күзгә күренепябыга башлады. Ә мин сыерыбызны яратам, аны күрсәм, әнине күргән шикелле булам. Менә шуңа бик борчылып, җиңгигә сүз катып караган идем каравын, нәтиҗәсе булмады.

— Сезнең ул сыерыгыз сыер гына түгел, — диде җиңги, кашын-күзен җимереп, — тәмугы ул! Барлы-юклы ике йөк печәнне шушыңар-чы төткәргәнгә рәхмәт әйт!

Менә сиңа, кирәк булса! Соң әле кышның уртасы гына бит, инде шул ике йөк печән бетте дә микәнни соң? Әни аны, колхоз бераз са-лам бирсә, бөтен кышка житәр дип әйткән иде ләбаса! Дөрес, халык окоп казудан кайткач, салам бирмәкче булалар бугай. Соң инде печән беткәч, коры салам белән генә сыерны ничек кыш чыгармак кирәк? Тукта әле, иртәгә тезмәләренә менеп карыйм, җиңгиләрнең үз печән-нәре ни хәлдә икән, Үз сыерына да безнекен ашатып ятмады микән?..

Икенче көнне тезмәгә менсәм — шаклар каттым: җиңгиләрнең үз печәннәре мин аларда тора башлаганда күпме булса, хәзер дә шул килеш. Ә безнеке, күп булса ун көнлек нәрсә калган! Кара инде, ә! Үз сыерына да, сарыкларына да безнең печәнне ашатып яткан ич бу, болай булгач... Их, үзем ашаткан булсам, белер идем мин аның каде-рен! Юк шул, миңа ышанмаган булды:

— Курмыны үзем ашатырмын терлекләргә, син әрәм-шәрәм итәр-сең, я тезмәдән егылып төшәрсең, — диде.

Ярар, печән әни кайтканчы житсә, әни ничек тә җаен табар әле...

Үз-үземне шулай юатып, ике күземне дүрт итеп, әнине тагын да ныграк көтә башладым. Ләкин булмады, тормады сыер ул кайтканчы! Әниләр кайтырга ике көн калды дигәндә бозаулады да, белмим нигә-дер, шул көннең кичендә үк үлде. Мин, барыбер тормас бит аның боза-вы, имезергә әнкәсе юк ич аның дип, кайгырып-куркып торганда, Миңлеахмәтнең әнисе бер чүлмәк сөт алып керде. Аннары шуңа бар-магын тыгып бозауның авызына китерде һәм — гаҗәп хәл! — бозау чупылдатып имә башлады.

Көтә торгач, окоп казучылар кайтыр көн дә житте. Ул көнне мин иртүк тордым. Үземә тиешле эшләрне тиз-тиз генә эмәллэп ташладым да, чанамны тартып, авыл башына әнине каршыларга киттем. Мәктәп кайгысы түгел иде бүген миндә, әнине тизрәк күрәсем килә иде.

Җиле, бураны булмаса да, көн шактый салкын. Мин авылны чык-кач, тагын да салкынайтып җибәргәндәй булды. Йортлар ышыгында чакта гына сизелмәгән икән, җиле дә бар, ара-тирә җаяүле буран да себерткәләп куя. Күк йөзе аяз, кояшлы, шуңлыктан урман да, тирә-яктагы кырлар да бик яхшы күренә иде.

Әниләр кайтасы юлга карап тора-тора туңа башлагач, авыл читен-дәге тауга бардым да чана шуарга тотындым. Ләкин таудан өч-дүрт мәртәбә шуып төшүгә бу уенның кызыгы бетте. Башка көннәрдә, уйныйсы килсә дә, вакыт булмый, ә бүген киресенчә: вакыт күп, уйнар-га дәрт юк. Шулай да салкын үзенекен итте, мине әледән-әле тауга куып менгерә торды.

Менә төш вакыты да житте, үтеп тә китте, ә әниләр һаман юк әле. Инде карыным да ача башлады. Барыбер өйгә кайтмадым — әнине авыл башында ук каршылыйсым килде.

Ниһаять, дөньяны кичке эңгер каплый башлагач, урман ягыннан чаналар шыгырдавы, атлар пошкыруы, кешеләр сөйләшүе ишетелә башлады. Мин шундук аларга каршы йөгереп бардым да әнием коча-

гына ташландым. Әни мине күтәреп үк алды, кайнар иреннәре белән салкын битләремне үбәргә тотынды. Аннары юлга бастырды да йорт-җир, хайваннар турында сораштыра башлады.

— Кит аннан! — диде ул, мин әле өченче көн генә сыерыбыз үлүен әйткәч. Беркавым аптырап, өнсезләнеп торды.

— Әйе, әни, бозаулаган көнне үлде ул, ә бозавы исән, — дидем мин, үземчә аны юатмакчы булып.

— Ярар, улым, — диде әни, мөлдерәп аккан күз яшьләрен сөртеп.— Без күрәсен кеше күрмәс, күрәчәгебез булгандыр инде... Ярый әле үзең исән-сау икәнсең, шунысы әйбәт.

Шуннан соң без туп-туры үз өебезгә кайттык. Әни мичкә ягып җибәрде.

Ә бераздан безгә җиңги килеп керде. Бик кайгырган атлы булырга тырышып, сыерның ничек-ничек үлүен сөйләргә тотынды.

— Ярар, килендәш, рәхмәт инде, тырышкансың, — диде әни, ачуланмыйча гына. Башка бер сүз дә әйтмәде, кисәвен алып, мичтәге утыннарны рәтләргә тотынды.

Әни ачуланмагач, җиңги сөенер инде дип уйлаган идем. Алай булмады. Киресенчә, ничектер күңелсезләнеп, кара янып китте ул. Аннары:

— Фи! Тыңламаган да була, әйтерсең, аның сыерын мин бәреп үтергән! — диде дә, ишекне шартлатып ябып, чыгып китте. Шул китүеннән соң, миннән башка беркем дә ышанмаган-көтмәгән хәл килеп чыкканга тикле, ул безнең өйгә аяк басмады.

Мичкә тәгәрәтеп пешергән бәрәңгене ашарга утыргач, әле яңа гына күргәндәй булып, әнигә карап тордым мин. Артык үзгәрмәгән иде ул: керфекләре дә элеккечә кара, озын, чәчләре дә һаман шулай коңгырт, калын; уң як битендәге энә күзе тикле генә бер бөртек миңе дә нәкъ үз урынында иде. Тик йөзе бераз сулыгып, һаман җилдә, суыкта йөргәнлектән каралып калган да гәүдәгә азрак кечерәеп киткән. Ә элек аның йөзе алсу һәм түгәрәк иде...

Тамакларны туйдыргач, шул ук кечне кул чанасы тартып бардык та бозауны җиңгиләрдән үзебезгә алып кайттык. Ә иртәгесен, мин йокыдан торганда, (ул төнне мин рәхәтләнеп, туйганчы йокладым!) әни сарыкларны да алып кайткан иде инде.

Аннары, бәрәңге алмакчы булып, базны ачтык. Ачтык та шаккатып калдык. Суыкка чыдый алмыйча, базның өстендәге җир ярылып, бәрәңгебез дә өшегән булып чыкты. Кичә күршеләрдән әҗәткә алып торган бер чиләк бәрәңгене түләрлек булса да исәннәре чыкмасмы дип, ни эзләсәк тә бер сау бәрәңге дә таба алмадык.

— Хәзер бу базны ябып торудан мәгънә юк инде, — диде әни, тәмам өмете өзелгәч, — буласы эш булган монда...

## Әтием белән очрашу

Өшегән бәрәңгене таза бәрәңге белән чагыштырып булмый, әлбәттә. Ләкин, нужа бабай муеныңнан кысып тоткач, алай авызга алмаслык ук дәрәҗәдә начар да түгел икән ул. Һәрхәлдә, җан асрап була икән аның белән. Эссе суга салып кабыгын сыдырып аласың да, кирәк икән шуннан аш пешерәсең, кирәксә — шул килеш ашарга да була.

Ләкин безне мәсьәләнең икенче ягы борчый иде: орлыкка бәрәңге кайдан алырга? Өшегән бәрәңгене утыртып торасы да юк — барыбер тишелмәячәк.

Әни белән әнә шул турыда кайгырышып йөргән көннәрдә Самат абый килеп керде безгә:

— Ишеттек, Мәгъсүмә иптәш, ишеттек, казалы булгансыз икән, — диде ул, — зур казалы булгансыз икән! Хәзерге заманда сыер — крестьянның бөтен байлыгы, бөтен өмете, бөтен куанычы ул. Анысы һәркайсыбызга мәгълүм. Әмма да ләкин син артык хафаланма, Мәгъсүмә иптәш. Илдә чыпчык үлми диләр, бер рәте чыгар әле. Без дә кулдан килгән тикле ярдәм итәргә тырышырбыз. Әле, менә бүген, идарә членнары белән сөйләштек тә бозавыгыз ашый башлаганга тикле һәр көн калхуздан дүртәр литр сөт биреп барырга булдык. Бәрәңгегез дә өшегән икән, аны да искә алдык, и менә болай итәргә булдык: давай, күпме бәрәңгегез бар, барысын да фирмыга илт, дуңгызларга ярар, тамакларына тыгылып калмас әле. Ә үзең аның урынына калхуз подвалыннан өшемәгәннәрен алып кайт.

Самат абыйның бу сүзләрен ишеткәч, шатлыгымнан чак кына кычкырып җибәрмәдем. Әни дә чамасыз куанган иде бугай:

— Рәхмәт инде, Самат абый, бик зур рәхмәт инде! Орлыкка бәрәңге каян алырбыз дип ут йотып йөри идем. Ниләр генә әйтсәм дә аз булыр күк бу яхшылыгың өчен, — диде ул.

— Анысы шулай инде, Мәгъсүмә иптәш, кулдан килгәнчә тырышабыз инде аны, — диде Самат абый, нигәдер утырган урынында калкынып куеп, — тик, кунак ашы — кара каршы дигәндәй, үзең дә безне этеп җыкмассың инде, калхузга булышырга туры килер, диюем...

— Һәй, Самат абый, нәрсә сөйлисең инде син, калхуз яралганнан бирле бер көн дә эштән калганым юк лабаса! Моннан ары да кая кушсагыз — шунда эшләрмен. Булмаганны... Калхуз эшенә каршы килә торган кешемени мин?

— Тукталс, Мәгъсүмә иптәш, — диде Самат абый, нигәдер йөзен чытып, — ашыкма әле син. Мин бит син начар эшлисең диюем түгел бу. Дөрес аңламадың, ахры. Без синең исемеңне менә шул яхшы эшләвеңне искә алып, атвитственный урынга куймак булдык...

«Атвитственный» дигәне шул: колхоз фермасына дуңгыз караучы кирәк икән, әнине шунда куймакчы икән Самат абый.

Ферма эше — ялгыз кешегә шактый җайсыз эш: бер караңгыдан икенче караңгыга тикле йөрергә туры килә. Башка чак булса, ихтимал, әни ризалык бирергә ашыкмас иде ул эшкә. Әмма хәзер, колхоз шундый зур ярдәм итәргә торганда, каршы килә алмады.

— Ярар, ярар, Самат абый, мин риза, кайчан эшли башларга кушасыз соң? — дип кенә сорады ул.

— Бүген үк фирмыга менәргә туры килер, Мәгъсүмә иптәш, — диде Самат абый. — Теге сорхантай — моңарчы дуңгызлар караган кызны әйтәм — кичә дуңгызларын ташлап, каядыр башка авылга чыгып сызган. И әйткән: «Мине көтмәсеннәр, тиз генә кайтасым юк, кайтсам да, фирмыда эшләмәячәкмен, дуңгыз карап кияүгә чыкмыйча калыр хәлем юк, ансыз да кияү табулары бик кыен хәзер!» — дигән. Кайта-нитә калса, кияү табып бирер идем мин аңа бирүен. Шундый политика тараткан өчен, бер сигез-ун елны сылаттырыр идем сылаттыруын!..

Шулай итеп, әни фермада эшләргә тотынды. Ул тизрәк эшен бетерсен өчен, мин дә аңа булышкалый башладым.

Өйдә үзем генә калырга курыкканга, башта мин дә әни белән фермада кунып йөрдем. Ә аннары, күрәсең, әнине кызганыптыр инде, ферма каравылчысы Шәйхи бабай минем белән генә куна башлады.

Бик әйбәт кеше ул. Без аның белән төннәр буе сөйләшеп утырабыз. Ул миңа үзенең башта, патша вакытында, немецлар белән, аннары Чапаев дивизиясендә аклар белән ничек сугышып йөрүләрен, төрле кызыклы вакыйгалар, әкиятләр сөйли.

Инде әйткәнемчә, мин этине хәтерләмим. Аның холкы, гадәтләре нинди булганлыгы да билгеле түгел иде миңа. Әмма кышкы озын төн-

нәрнең берсендә Шәйхи бабай миңа әтием хакында шундый итеп сөйләп бирде — мин әтиемне чыннан да тере килеш күргәндәй, хәтта аның белән сөйләшкәндәй булдым. Минем әти озынчарак кара тут йөзле, калын кара кашлы, гәүдәгә шактый зур һәм таза булса да, бик җиңел сөякле кеше булган. Аны зирәклеге, карусыз булганлыгы өчен яшьтән үк яратканнар. Зиһене дә бик әйбәт булган. Хәтта безнең авылдан бер үзе, Ильиновка исемле күрше авылга йөреп, русча да укыган ул. Шунлыктан «русчаны су урынына эчкән». Егерме яшендә, 1929 елны, колхоз председателе итеп сайлаганнар аны. Әнигә дә шул елны өйләнгән. Бабай белән әби (әнинең әти-әнисе була инде): «Кызыбызны рус сабагы укыган коммунист кешегә бирмибез», — дип, башта аяк терәп каршы торсалар да, әти тегеләргә төн уртасында барып кереп: — Яхшылык белән миңа Мәгъсүмәне бирмәсәгез, икегезне тың тынсыз итәм! — дип наганын чыгарып төзәгәч, теге бичаралар берсүзсез риза булганнар һәм соңыннан, инде әти белән әни кавышып матур гына тора башлагач, җитәкләшеп килеп, әтидән гафу үтенгәннәр.

Колхозны да «уйнатып кына, бер дә көчәнмичә генә» җитәкләп барган әти. Әни белән дә тату яшәгән. Мине дә бик яраткан. Хәтта идарәгә килгәндә дә мине үзе белән алып йөри торган булган.

Менә шулай матур гына эшләп, әйбәт кенә гомер итеп торганда, 1935 елның кышында, районнан кайтышлый әти көчле буранга юлыга. Аты юлдан язып туктап кала. Әти юлны эзләмәкче булып чанасыннан төшүгә, яшь айгыр нәрсәдәндер өркеп, кар ерып чабып киткән. Шул караңгы төндә япан кырда бер үзе калган әти. Җитмәсә өстендә дә юка, кыска пинжәк кенә икән, толыбы чанада киткән. Катып үлмәс өчен арлы-бирле йөрергә керешкән ул. Ләкин ел озынлыгы кышкы төн үзенекен иткән — әти тәмам арыган да, бераз ял итеп алырга дип, кар өстенә утырган һәм... шунда йоклап киткән.

Ихтимал, ул шунда туңып үлгән дә булыр иде. Ләкин таң вакытында буран басылгач юлга чыккан күрше авыл олаучылары коткарган аны. Дөресрәге, олаучыларның эте коткарган: әти янына килеп өрергә тотынгач, тегеләр килеп тапканнар әтине һәм, шундук танып алып, безнең авылга алып кайтканнар. Өйгә керүгә, мич башына менеп яткан әти һәм шул ятудан бүтән тора алмаган; суыктан җылыга кергәч, үпкәләре шешенеп киткән дә үпкә авыруы башланган. «Колхоз тикле колхозны алып барырга башы җиткән кеше иде атаң, әмма мич башына менәргә ярамавын уйлап җиткерә алмаган, мәрхүм, — дип сөйләде миңа Шәйхи бабай. — Әнә шул гына харап итте аны. Авырып сигез ай ятты да үлде. Әй, үләсе килмәде дә инде үзенең. «Шушы Равилем җиде-сигез яшькә җиткәнче торсам да үкенмәс идем», ди торган иде, бичара. Ничәдә инде син, улым?

— Майда ун тула, Шәйхи бабай.

— Кара инде, ә? Гомернең үтүен сизми дә каласың. Су күк ага да тора... Ичмаса, замананың да бик болгавыр чагы. Ну, бу сугышны!.. Ярар, йокла инде улым, ял ит, иртәгә мәктәпкә дә барасың бар. Сабагыңны әзерләп куйгансың бит?

— Әзерләдем, Шәйхи бабай. Мәктәптән кайткач ук әзерләп куйдым. Монда кунасы көнне гел шулай итәм мин.

— Алай икән, йокла инде алайса, мин хайваннар янына чыгып керим әле, сарык-фәлән бәрәнләп ятмый микән.

Шәйхи бабай фонарен алып чыгып киткәч, каравыл өе дөм караңгы, тып-тын булып калды. Кызык: фонарь яктысында утырганда җылы шикелле иде, ә хәзер кинәт салкынаеп киткәндәй булды. Күрәсең, шул кеп-кечкенә генә фонарьның да җылысы бар. Әллә шулай тоела гына микән?.. Мин туңып-калтыранып куйдым да бишмәтемнең якасын күтәреп, аркамны стенага терәп яттым. Тизрәк йоклап китмәкче булып, күземне йомдым...

Төшемдәме, әллә өнемдәме, анысын төгәл генә әйтә алмыйм, ул төнне мин төн буе әтием белән сөйләшеп чыктым. Сүзне әти үзе башлады:

— Улы-ы-ым, Ра-ви-и-ил! — дип кычкырды ул кайдандыр бик ерактан. — Ишетәсеңме минем тавышны, улы-ы-ым?

— Ишетә-ә-әм, әтием! Син үзең кайда соң? Нигә минем яныма килмисе-е-ең? Нигә бер генә тапкыр булса да күренмисең?

— Менә мин синең янында бит инде-е-е!

— Алай булгач, нигә күрә алмыйм соң мин сине-е-е?

— Күрәсең, улым, күрәсең! Син — шул мин бит инде ул! Иртәгә өйгә кайткач көзгегә кара әле. Анда күренгән кеше мин булырмын, ми-и-ин!

— Син түгел бит ул, мин бит ул әткә-ә-әй!

— Син — шул мин бит инде, улым! Мин үземне сиңа калдырып киттем бит!

— Нигә алай иттең соң, этие-е-ем? Нигә безне калдырып китте-е-ең?

— Үпкәләмә инде, балам. Болай булырын белсәм, ул көнне районга барып та йөрмәс идем мин. Барсам да, кунып, буран басылгач кына кайтыр идем. Кем уйлаган бит аны болай буласын.

— Бер дә үпкәлисе түгел дә бит, нишлим соң, бик кыен лабаса миңа синсез! Әнигә дә кыен.

— Аңлыйм, улым, бик яхшы аңлыйм хәлегезне! Әмма берни дә эшли алмыйм шул, балакаем! Монда килеп эләккәч, берни дә эшләп булмый икән шу-у-ул!.. Улым, тыңла әле мине, киңәшләрем бар сиңа. Тыңлыйсыңмы?

— Тыңлыйм, әткә-ә-әй!

— Әгәр атаң тыныч кына ятсын дисәң, улы өчен аның оялып, борчылып ятуын теләмәсәң — беркайчан да әниең сүзеннән чыкма! Сине начарлыкка өйрәтми ул, балам. Әниеңә булыш, ярдәм ит аңа! Синнән башка ярдәмчесе юк аның. Бөтен өмете, бөтен карап торганы син генә. Ишетәсеңме, улы-ы-ым?

— Ишетә-ә-әм!

— Онытмассыңмы минем бу сүзләремне?

— О-ныт-ма-а-ам! Тик син дә мине онытма, этием, шушылай минем белән сөйләшкәләп, исемә төшергәләп, киңәшләреңне биргәләп тор, я-ме-е!..

Шәйхи бабай миңа әкиятләр сөйләү белән бергә, чабата үрү белән дә шөгыльләнә. Чын-чынлап, бөтен күңелен биреп эшли. Аның чабаталарын безнең авыл халкы гына түгел, күрше авыллардан да килеп алалар, мактый-мактый кияләр.

Чабата үрү башта миңа бик читен, баш җитмәстәй эш булып күренгән иде. Әмма, ныклап торып тотынганда, бер дә алай искитмәле нәрсә түгел икән. Шулай Шәйхи бабайның эшен игътибар белән карап йөри торгач, мин үзем дә хәйран гына маташтыра башладым ул нәрсәне. Ә язга таба, Шәйхи бабай ярдәменнән башка да, баштанаяк үзем үрә торган булып киттем. Аннары инде үземә генә түгел, әнигә дә үреп бирә башладым. Эх, күрсәгез иде сез әнинең бу һөнәремә ничек куанганын! Хәер, үземнең дә башым күккә тигән иде бугай.

Бер ияләшкәч бик кызык икән ул чабата үрү. Берсен үреп бетермисең, икенчесенә тотынасы, анысын тагын да матуррак итәсе килә, күңел үскәннән-үсә бара. Шуның өстенә хәзер авыл халкы да, мине мактап:

— Әнә Мәгъсүмә малае нишләтә: үзе калыптан печтик кенә зуррак булса да, коеп кына куя чабатаны, — дип сөйли башлагач, ничек куанганымны үзем генә беләм.

## Дүрт көн эчендә алты мәет!

Саескан сумалага төшкән. Башын алса, койрыгы ябыша, ди. Безнең дә хәлләр шулайрак булып чыкты.

Үксез бозавыбыз да үсеп килә, чабатаны да сатып алмыйбыз, кара җиргә аяк бассак, ничек тә үлмәбез, дип кенә торганда, кинәт бәрәңгебез бетеп китте. Бетте дигәч тә, бөтенләй үк бетмәде ул, унбиш чиләкләп бар әле барын. Әмма аны, ашарга ярамый аны, улым, орлыкка кирәк, ди. Хәзер безнең ризык — әлмә каерысы да юкә кабыгы. Көненә бер мәртәбә бер уч арыш ярмасыннан пешерелгән аш эләгә. Күршекүләннең дә эшләре мөшкелләнде булса кирәк — сөт, катык кертеләүне туктаттылар.

Кар озаграк яткан булса, нишләгән булыр идек икән, безнең бәхеткә яз иртә килде. Кырлар алалана башлауга, колхозның узган елгы бәрәңге җиренә черек бәрәңге җыярга киттек. Сөт-май булганда шул черек бәрәңге онынан пешергән ботканың нинди тәмле булуын әйткән дә юк инде. Хәтта, кабыгын да әрчеп тормыйча, учакка күмеп пешерелгәнен ашаганда да дөнья рәхәте була. Тик күбрәк кенә булсын.

Ләкин аны да күпләп җыеп булмады. Без ике генә көн иркенләп йөреп калдык, аннары, бездән күреп, бөтен авыл кырга чыкты һәм өч-дүрт көндә бәрәңге җирен актарып ташладылар.

Нужа калач ашата, диләр. Безгә калач ук ашарга туры килмәде килүен, шулай да күп нәрсәгә өйрәтте безне нужа бабай. Черек бәрәңге җыелып беткәч, халык узган елда коелып калган башакны җыярга ябырылды. Без дә, башагыннан аерып җилгәргәннән соң, бер чиләккә якын ризык җыйдык. Зур хәзинә иде бу безнең өчен. Икенче төрле итеп әйтсәк, кузгалак, какы һәм юалар үсеп җиткәнче яшәргә була дигән сүз. Ә аннары кычыткан, ат кузгалагы, алабута өлгерәчәк. Әни әйтмешли, алла яңгырларын гына бирсен дә, дөньяны кызу гына көйдермәсен.

Тик кайберәүләргә кычыткаңнар үсеп җиткәнче торырга насыйп булмаган икән шул. Һич тә көтмәгәндә, иста-оста юк чакта, бер көнне минем кечкенәдән бергә уйнап үскән дустым, яшьтәшем, күрше малае Миңлеәхмәт кинәт кенә үлеп китте. Аны күмеп кенә кайтканнар иде, Фәрзетдин дә дөньядан китеп барды. Аннары башкалар... Кыскасы, ике көн эчендә безнең кечкенә генә авылдан алты кеше вафат булды.

Элек, сугышка кадәр, мәетне зиратка ирләр күтәреп алып барып күмә торган иде. Хатын-кызлар ул тирәгә якын да бармый иде. Кабер казырга берәү дә әйтеп тормый, кешеләр үзләре белеп килләләр иде. Ә хәзер, ирләр булмагач, әлеге мәетләрне Самат абый махсус наряд биреп, хатын-кызларга күмдертте, кабер казучыларга хезмәт көне дә язган дип сөйләделәр.

Мин Миңлеәхмәтнең дә, Фәрзетдиннең дә үле гәүдәләрен карарга кермәдем. Аларны күмгәндә зиратка да бармадым. Әле кайчан гына үзем белән бергә уйнап йөргән иптәшләремнең кинәт үлеп китүе коточкыч хәл булып тоелды. Шунлыктан аларның мәетләрен карарга йөрәгем җитмәде.

Соңыннан беленде: Миңлеәхмәт тә, Фәрзетдин дә һәм башкалар да теге кар астында кышлаган башак бодаен ашап агуланганнар икән.

Эшләр болайга киткәч, районнан врачлар килеп тикшерделәр дә кемнең күпме җыйган бодае бар — барысын да күрше совхоздагы спирт заводына илтеп алыштырырга куштылар. Шуннан соң агуланып үлүләр тукталды...

Тукталуын тукталды да, тик Миңлеәхмәт белән Фәрзетдин юк шул

инде. Ә бит без гомер буе дус булырга, бергә җиденче классны тәмамлаганчы укырга, бергә армиягә барырга, аннары барыбыз да шофер булырга сүз куешкан идек...

## Булыр, әни...

Яшь күңел барыбер үзенекен итә икән. Атка атлану рәхәтенә ирешү өчен, язын, колхоз сабанга чыккач, иртәнге өченче яртыдан торып, кәнүшнигә бара торган булып киттем. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар: барыбер игелек күрсәтми алар дип, Самат абый колхоз дуңгызларын дәүләткә тапшырттырып бетергәч, әнине ат караучы итеп куйдылар. Ә мин, элеге дә баягы шул куркаклыгым аркасында, һәрвакыт иртән әнигә ияреп кәнүшнигә йөри башладым. Менә шунда колхозчы апалар атларны җитәкләп кырга җир сөрергә чыкканда, мин дә аларның бер атына атланып, сөрә торган җирләренә кадәр барам. Аннары, атка атланганнан соң күңелдә туган рәхәтлеккә чумып, чатыр-чотыр өйгә йөгерәм. Анда әни иртән кушып калдырган вак-төяк эшләрне тиз генә эшләп ташлыйм да тагын кырга чабам. Тагын атка атланып кайтам.

Шулай берничә көн йөргәч, Фәйрүзә апа (мин күбесенчә аның «Дүплән»енә атланып йөри идем) миңа, атларны үзем тотып, җир сөреп карарга да рөхсәт итте. Монысы инде атка атланып йөрү генә түгел, аннан ун өлеш рәхәтрәк. Бер кулың белән дилбегәне, икенчесе белән сабан тоткасын тотасың да, төрәннәрнең җир кантарын ничек әйләндереп салуын карап барасың. Бернинди кыенлыгы юк. Атлар — берсе буразнадан, берсе сөрелмәгән җирдән — салмак кына атлап бара. Әйләнгән саен җирнең сорысы кими, ә карасы — кояш нурында ялтырап, түшәктәй күпереп ятканы — арткааннан-арта бара. Синең эшләгәненне күреп, шуңа сөенешеп, күккә эленгән тургайлар сайрый. Тик җир башында борылуы гына бераз кыенрак, сабанны күтәрергә көч җитеп бетми. Ләкин бу кыенлык күпкә бармады, Фәйрүзә апа миңа ул бәладән котылу юлын да өйрәтте.

— Атлар борылып җиткәндә сабан тоткасын чак кына үзеңә таба каерып җибәр син, нәнем, — диде ул. Минем белән бер әйләнеп, ничек-ничек итәргә икәнен күрсәтеп-аңлатып чыкты да, җир башына барып, сырмасын баш астына куеп, ятып йоклады. Ә мин төшкә тикле аның җирен сөрдем. Төштән соң да бармакчы идем дә, әни җибәрмәде:

— Вакыты җиткәч тә ватылырга өлгерерсең әле, балам, йөрмә! — диде. — Йорт-җир эшләрен караштыр әнә. Бик эшлисең килсә, урманга кер дә коры-сары утыннар җыеп кайт, учакка ягарлык кына булса да, бер аш пешерергә җитсә дә ярар, зыяны тимәс...

Әни дөрес әйтә, бик нык вата икән ул җир сөрү. Көнозын сабан койрыгы тотып йөреп, аяклар калмый. Ләкин барыбер җир сөрәсем килә иде минем.

Колхозыбыз кечкенә булганлыктан, бездә бригадир юк, бөтен эшне әлеге шул председатель Самат абый алып бара. Аны бик үк яратып бетермәсәм дә, бер көнне идарәдән чыкканын саклап тордым да, миңа атлар биреп җир сөрергә рөхсәт итүен үтендем.

— Ниятең әйбәт, энем, — диде ул, ябалакныкы кебек түгәрәк кызгылт-кара күзләрен кыскалап мине тыңлаганнан ары, — тик атка йөгән ора алырсың микән соң? Камыт та кигерәсе була бит әле аңа.

Әйе, ул хаклы — атка йөгән кидерерлек буем юк. Ләкин каушап калмадым:

— Фәйрүзә апа кидереп бирер әле, Самат абый, — дидем. — Без гел аның белән бергә сөрербез.

— Карале! — диде Самат абый, кинәт елмаеп җибәреп, — атаңа охшыйсың, ахры, син, малай актыгы. Башың эшләр төсле күренә синең

Давай, болай итәбез: иртәгә Мәүлиха апаның атларын ал да җир сөрергә чык, аңа башка эш бирербез. Аякларым сызлый дип сукраңа иде, аңа да бераз ял булыр.

— Әни! — дидем мин, шатлыгымнан кая басканымны да белмичә йөгереп кайтып. — Әни! Иртәгәдән мин эшли башлыйм! Самат абыйдан сорадым. Ул Мәүлиха апа атларын җигәргә кушты. Әни, барам, яме, ачуланма, яме!

— Әй, улым, улым! — диде әни. — Бик яшь бит әле син. Әле яңа унберенче яшь китте ич сиңа. Көннәр буе ат артыннан йөгерер вакытың түгел ләбаса! Синең түгел, олыларның да җелеген суыра торган эш ич ул. Белмим инде, белмим, нәрсә эшләп болай ашкынасың икән! Булдыра алырсыңмы икән соң, улым?!.

— Булыр, әни, менә күрерсең! Мин хәзер зур бит инде.

Шулай дигәч әни каршы килмәде:

— Карап кара инде, алай бик эшлисең килгәч, — дип ризалык бирде.

Ләкин Мәүлиха апа атларын җигеп эшкә чыкканның беренче көнендә үк чамасыз нык арыдым мин. Кояш батканны көтә-көтә җаным чыга язды. Шулай да сер бирәсем килмәде, Фәйрүзә апага ул турыда бер сүз дә әйтмәдем. Бары кайтырга чыккач кына:

— Фәйрүзә апа, Самат абыйга әйт, иртәгә эшкә чыкмыйм мин, бик арыдым, — дидем.

— Шулайдыр шул, энем, — диде Фәйрүзә апа, — кечерәк шул әле син. Синең күкләр, әнә, берсе дә мондый авыр эштә эшләми. Без лутчы болай итик: мин Самат абыйга әйтермен, сине тырмага кушсын, анда җиңелрәк булыр, атка атланып йөрерсең.

— Самат абый рөхсәт итәрме икән соң?

— Итәр, Равил, итми хәле юк, бер кешене бишкә ярырдай заман бит хәзер. Дөнья хәтле чәчүлек орлык алып кайтасы бар әле районнан. Күтәреп ташыйсы ич аны, атлар җир сөрергә дә такы-токы гына бит!

Ахры, чыннан да шулай булгандыр, икенче көнне Самат абый миңа тырмага чыгарга кушты.

— Атларга чиратлап — төшкә кадәр берсенә, төштән соң икенчесенә — атланып йөрерсең, — диде ул һәм үзе үк атка атлану өчен ничек итеп баудан баскыч ясарга икәнен өйрәтте...

Шулай итеп, мин язгы чәчү беткәнче тырмада йөрдем. Күрәсең, олылардан ким эшләмәгәнмен — чәчү беткәннең икенче көнендә колхоз идарәсе тарафыннан бүләкләнүчеләр арасында минем исем дә бар иде. Яхшы эшләвем өчен мактый-мактый, Самат абый үз кулы белән миңа соры ситсы бирде. Бик ярап куйды ул. Күлмәгем тузып, менә бетә, менә тәмам төшеп кала дип курка-курка гына йөргән чакта кулыбызга эләккән шул ситсыдан бик әйбәтләп бер күлмәк тә, кыска булса да, бер ыштан тегеп бирде әни. Шуның өстенә, байтак кына хезмәт көне дә эшләгән идем әле.

## Бүген генә түзәм дә...

Язгы чәчүдән соң колхозда парга сөрү, тирес түгү кебек эшләр башланды. Болары миңа ярарлык эшләр түгел иде: тирес түгәргә барсаң, арба аударасы була, ә җир сөрүдә авызым бер пеште инде. Шуңа күрә Самат абый да ирексезләмәде, үзем дә ашкынып тормадым.

Ул арада печән өсте дә килеп җитте. Самат абый мине, атка атланып, богыл өючеләргә печән тарттырырга кушты. Монысы инде тырмада йөрү түгел — мең өлеш күңеллерәк. Болында кырдагы кебек түзан да юк, көннәр буе бер ялгызың кеше белән сөйләшергә зар бу-

лып, бик аптырагач, ат белән дә сөйләшеп йөрмисең. Инде килеп, Хәбир бабай әйтмешли, хайван түгел, үзең тотып ашарга яраклы җиләкле, чәчәкле, ямь-яшел печәннең хуш исе үзе генә дә җәннәт рәхәте бит ул!

Хатын-кызлар печәнне җыеп, чүмәләгә өеп тора, син шуны тарттырып богыл янына илтеп торасың. Бер чүмәлә китергән саен, богыл биегәеп, Хәбир бабай югарырак күтәрелә бара, әнә шул күренеш күңелдә әйтеп бетергесез горурлык хисе тудыра.

Башкалардан шактый кечкенә булганлыктандыр инде, минем корсак печәнчеләргә бирелә торган аш белән дә тула, ә үземә тиешле икмәкне әнигә алып кайтам. Гомеремдә онытасым юк, беренче көнне икмәк алып кайтып биргәч:

— Әй, заманалар! Синең кулдан икмәк ашарга тиешме соң инде мин?! Беләм бит, балам, ашыйсың килмәгәннән алып кайтмагансың син моны. Көн буе эштә йөргән кешегә, башка замана булса, бу икмәк чәп итәргә дә җитмәс иде. Заманы каһәрләнгән шул! Ярар инде, балам, бик зур рәхмәт! — дип, елый-елый аркамнан сөйде әни.

Хәер, әни сүзендә дә дөреслек бар: богылга печән биреп торучы Фәйрүзә апалар ничек чыдаганнардыр, хәтта мин дә, атка атланып йөрсәм дә, шактый нык арыйм. Ник дисәң, һаман юыртып йөреп тә җитешеп булмый. Богыл башында торучы Култи бабай:

— Давай, малай, тизрәк! Давай, давай! — дип кычкырып кына тора.

Култи дигәнем — әлеге шул әлек яшелчә каравыллаган Хәбир бабай инде. Гражданнар сугышында кулын имгәтеп кайткан ул. Сул кулының бармаклары культиватор кискечләре сыман тырпаеп торганга, ачуыбыз килгән чакларда — үзе ишетмәгәндә, билгеле — Култи дип йөри идек без аны. Гарип булса да, сугыш чыкканнан бирле яшелчә бакчасын ташлап, төрле эштә йөри башлады ул һәм эшкә дә бик таза үзе. Сәнәк сабын теге «култиләре» арасына кыстырып куя да иртәдән алып төшкә, төштән алып кичкә чаклы һаман шулай: «Давай, давай!» — дип куыра.

Берәү дә ныклап ачуланмый аңа, чөнки һәркем белә: үзе өчен «давайламый» бит ул, колхоз өчен тырыша. Әгәр дә берәрсе сукрана башласа:

— Чыда, балакай, минем өчен эшләмисең бит. Вакытында шушы җиләк күк печәнне җыеп алмыйча, узган кыштагы кебек, быел да колхоз хайваннарына түбә саламы ашатмыйк инде. Бакчи, көне нинди матур. Түз, балакай, яңгырлар киткәнче ничек тә бетерик, яңгыр көнне ял итәрсең, яме. Сугыштагы кешеләргә моннан йөз тапкыр кыенрак. Алар да түзә. Немечләрне дөмектергәнче ничек тә түзегез, аннары болай ук читен булмас, — дип, көйләп тә куя Хәбир бабай...

Барлы-юклы көч белән тырышып, колхозның печәнен чабып өеп бетергәнче, арыш та өлгереп җитте. Авылның аз гына булса да кыймылдый алган карчыкларыннан алып, урак тотарга көче җиткән кыз балаларына тикле кырга чыкты.

Уракка төшүгә берәр атна үтте микән, сугу эшләре башланды. Хәзер инде печән өстендәге кебек кенә түгел! Печәнне, теләсәң дә, чык кипмичә җыярга ярамый. Ә көлтәне тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ташы. Халык көндез урак урда, ә төннәрен, ике көннең берендә үз сыерларын җигеп, ындырга көлтә ташыйлар.

Ат җигеп йөрүчеләргә дә ансат түгел. Көндез ындырга көлтә ташысалар, төнлә дәүләткә ашлык илтергә китәләр. Заготзерно безгә унсигез километр. Анда барып кайтканнан соң, куян койрыгыдай кыска җәйге төннең күпмесе кала? Шул ук атлар, шул ук кешеләр көндез тагын я көлтә ташыйлар, я җир сөрергә чыгалар...

Ул чорларда мин ат кудым. Безнең колхозда трактор-фәлән юк, игенне дә алты ат көче белән эшли торган машина белән сугалар. Шул алты атның икесен мин куам. Без, өч малай (алар миннән олылар), иртәнге алтыдан кичке тугызга кадәр бер түгәрәк эчендә әйләнәбез. Барабан туктаусыз үкереп, авызына Хәбир бабай таратып тыккан көлтәләрне йотып тора, хатын-кызлар кайсы саламын селки, кайберләре арышын, бодаен, кыскасы, нәрсә сугылса — шуны җилгәрүчеләргә тырма белән эшереп илтеп тора. Ындыр табагыннан күтәрелгән тузан болыт булып күкләргә аша...

Хатын-кыз бар җирдә сүзсез генә эшләү булмый, ындыр табагындагылар да үзара сөйләшкәннәрдер, әлбәттә, тик безгә аларның тавышы ишетелми. Әмма Хәбир бабай сүзләрен аерым-ачык ишетеп торабыз:

— Малайлар! Йокламагыз! Солдат бит сез хәзер!

— Малайлар, ...корт чаккырлары, давай!

Хәтта беркөнне, барабанын ташлап, култи бармакларын селти-селти йөгереп килеп, Габделгазизгә эләктереп тә ала язды. Хәер, Габделгазизнең үзендә дә гаеп булды. Атларын яхшылап кумаган иде. Хәбир бабай бик дөрес пыранлатты аны. Кусын атларын яхшылап, югыйсә, безнекеләр дә трактор түгел ич, авырга килә бит атларга!..

Әмма үзем дә бик арыйм.

Дөрес, Хәбир бабай миңа:

— Тәртәгә утырып йөр, улым, синең әллә ни авырлыгың юк, — дип әйтә әйтүен. Ләкин, Гәрәй белән Габделгазиз утырмагач, ничек бер үзем генә утырып йөрим инде. Габделгазиз әйтмешли трутны барыбызга да бертигез язалар ич, шулай булгач...

Ә Хәбир бабай тегеләргә утырып йөрергә һич тә рөхсәт итми. Кичкә таба бик арыгач тәртәгә менеп кунакласалар, култиен күрсәтеп, хәзер себереп төшерергә генә тора. Ашерен-батырын түгел, бик арыган минутларда мин машинаның ватылуын тели идем. Ә ул, үч иткәндәй, тагын да шәбрәк үкереп эшли башлый. Шундый көннәрне үз-үземә: «Бүгенгә генә түзәм дә, иртәгә үтерсәләр дә чыкмыйм ат куарга. Әнә минем шикелле малайлар рәхәтләнеп уйнап йөриләр», — дим. Ә иртән, төнлә йоклап ял иткәннән соң, кешеләр: «Булмады, йомшак икән Мәгъсүмә малае, укулары башланганчы да түзә алмады, биреште — ташлады эшен!» — дип әйтмәсеннәр өчен, шул ук вакытта хезмәт көне эшләп әнигә дә булышу нияте белән, йөгәннәремне иңемә асып, тагын кәнүшнигә менәм...

## Укыйсым бик килә дә бит...

Шулай көн артыннан көн үтте, мин түземсезлек белән көткән вакыт — уку башланыр чак та килеп җитте. Укыйсым бик-бик килә. Яз көне дә, Мәдинә апа авырып киткәнлектән, укудан бик иртә — апрельнең егерме өчендә үк туктаган идек. Аннары — уку миңа бик җиңел бирелә. Мәдинә апаның аңлатканын тын да алмый тыңлап утырам да барысын да хәтерләп калам. Өйдә озаклап дәрес әзерләп торырга кирәк түгел, арифметикадан бирелгән мисаллар белән язма күнегүләрне генә эшлим дә — вәссәлам. Ә башка фәннәрне икенче көнне дәрес башланыр алдыннан бер кат күз йөртеп, китаптан карап чыгам да шул җитә. Әйтмәгәнем булсын, тфу-тфу, моңарчы әле бер вакытта да «яхшы» яки «бик яхшы»дан түбән билге алганым юк.

Ә мәктәптә Мәдинә апаның нурлы йөзенә карап утыру үзе нинди зур бәхет! Бүтән балалар да шулаймы икән, үлеп тә яратам мин Мәдинә апаны. Дөньяда аннан да зур белемле, аннан да акыллырак кеше юктыр шикелле. Башкалар шикелле гади генә кеше түгелдер ул.

Шулай булмаса, ул тикле дә түзем була алмас иде. Бер ук бүлмәдә утыручы дүрт класс баласын берьюлы укыта бит ул. Утыз тугыз баланы. Икенче төрле итеп әйткәндә, бер сәгать эчендә дүрт класска дүрт төрле дәрес аңлата... Инде килеп, шофер буласы кеше ич мин. Ә укымыйча ничек шофер булмак кирәк? Менә ни өчен уку башланыр көнне ике күземне дүрт итеп көтеп алдым.

Ләкин беренче сентябрь көнне башкалар белән бергә укырга барырга туры килмәде: әни мине укытырга теләмәде.

— Укып мулла булмассың, балам, — диде ул. — Аннары бөтен кеше укый башласа, кызыгы да калмас аның. Калхузда эшләүчеләр дә кирәк бит. Бер трут эшләсәң дә файдасы булыр. Үземә генә бик кыен бит, улым. Түләүләребез дә бик күп бит әле. Әнә кичә үзең күрдең лабаса: «Шушы айда тиешле итегезне түләп бетермәсәгез, бозавыгызны алып чыгабыз», — диделәр ич.

— Бер сарыкны илттек бит инде, әни, — дидем мин, әле һаман түләү бетмәгәнгә гаҗәпләнеп.

— Бер сарык кына житми шул, балам, кырык кило кирәк бит! Менә шуңа әйтәм мин сиңа, укыма дип. Икәүләп эшләсәк, калхуз икмәк бирсә, шуны сатып түләрбез итне. Әтү, син дә эшләмәсәң, бозауны да алып китәрләр. Сугыш бит, улым, сугыш! Сау булсаң, сугыш беткәч укырсың, балам...

Хәзер әнинең ни өчен мине укытасы килмәве аңлашылды. Ни хәл итәсең — үпкәләп тә булмый аңа.

Менә шуңа күрә, бик укыйсым килсә дә, әнигә каршы килмәдем. Рас ул укыма ди икән, димәк, белеп әйтә, бүтән чара калмаганга, ярдәм итәр кешесе булмаганга әйтә. Теге вакытта жиңги мине бары тик килелеге, ялкаулыгы аркасында гына укытмаска исәпләгән иде бит. Ә әни нужадан, аптыраганнан мине эшләтмәкче. Шулай булгач, ана ничек каршы киләсең ди? Аннары шоферлыкка укырга да яшем житми әле минем.

Менә шуларны уйладым да, сугыш беткәч тә соңга калмам әле дип, укуга бармыйча, ат кууымны дәвам иттем. Хәзер эштә минем кадер тагын да арта төште. Чөнки Гәрәй дә, Габделгазиз дә укыйлар, ә аларның атларын дүрт классны инде өч-дүрт ел элек үк бетереп чыккан олырак кызлар куа. Миңа хәзер тәртәгә утырып йөрергә дә ярый, оят түгел, чөнки мин кечкенә ич әле... Тик акыл белән әни яклы булып, аныңча эшләп йөрсәм дә, иртә-кичләрен мәктәп яныннан үткән чакларда күңел һаман шунда тарта.

## Тилермә, Мәгъсүмә апа!

Укымый йөрү бик кыен миңа. Мәдинә апа да минем өчен борчыла. Ике мәртәбә өйгә килеп, әни белән дә сөйләшеп карады инде. Хәтта соңгы килүендә:

— Яхшылап әйткәнне тыңламасаң, без закон нигезендә дә мәҗбүр итә алабыз! — дип өркетеп китте.

Үн көнләп вакыт үтте инде, мине мәҗбүр итүче юк әле. Ихтимал, әни әйткән сүз дөрестер: безнең ише тамагы ач, өсте ялангач кешеләрне закон да берни эшләтә алмый торгандыр. Эшләтсә — бик әйбәт булыр иде кана. Мин үзем дә укуга атлыгып торам да бит! Ләкин ни хәл итәсең? Хәбир бабай әйтмешли, солдат мин хәзер... Уку дип, мең бәла белән тернәкләндереп, исән-сау саклап алып калган бердәнбер бозавыбыздан коры калырга да ярамый лабаса!

Бозау дигәннән, без аны тәки саклап алып калдык бит, әй. Әнинең сүзе чыннан да дөрес булып чыкты: колхоз хезмәт көненә биргән икмәкнең ике потын сатып, шуның акчасына кәҗә алып дәүләткә тап-

шырдык та түләүдән котылдык. Ә бозау инде зур, тана хәтле булып килә. Бер дә үксез бозау димәссең. Түп-түгәрәк, йоп-йомры гәүдәле, нәкъ әнкәсе төсле, аклы-каралы. Шундый акыллы тагы үзе: көтү каршына барып торасы да юк — туп-туры өйгә кайта. Мине күреп алды исә, исәнләшкән сыман итеп, «мме-у» дип сузып бер кычкырып җибәрә дә, көн буе кырда йөреп арган булуына карамастан, яныма йөгерә үк башлый. Күрәсең, үксез үскәнгә, кече-кечкенәдән миңа ияләшкәнгә шулай итә торгандыр инде... Я ул кайтуга мин әзерләп куйган чәчәкле, хуш исле яшел печән исен чамалаптыр... Яки колак артларын, муеннарын кашытасы, койрык очларына, корсак асларына ябышкан кырмавыклардан арынасы, шуларны чүпләтәсе килептер... Ничек кенә булмасын, мине сагынып, минем янга тизрәк кайтып җитәргә ашыга бит ул. Мин аның шулай булуын сизәм дә күземә яшьләр килә...

Көз җитте. Көннәр салкынайды, яңгырлар ява башлады. Ләкин яңгыр чиләкләп ормаган көннәрдә ашлык сугуны туктатмыйлар. Андый чакта алдан ындырга ташып, кибәнгә өеп куйган игенне сугалар. Башкаларга ярый, алар балаган эчендә эшлиләр, ә миңа безгә, ат куучыларга, кыен. Яңгыр сибәләп кенә торса да, көннәр буе ачык һавада йөргәч, барыбер өс-башны манма су итә.

Ярый әле минем шинель әйбәт. Әйтергә онытып торганмын: узган кыш окоп казырга барган җиреннән, ярты бөтен ипигә алыштырып, әни алып кайткан иде аны. Бик игелекле булды ул шинель. Алып кайтканда миңа озын булгач, кистермәкче идем, әни риза булмады, итәген, җиң очларын бөкләп тегеп кенә куйды. Ә менә хәзер, мин үсә барган саен, әни аның итәген дә, җиңен дә түбәнрәк төшереп, озынайтып тегә тора. Шулай итеп, мин һаман үземә «таман» гына кием киеп үсәм.

...Шинель әйбәт булгач, көнозын яңгыр астында йөргәндә дә артык тундырмый. Тик нигәдер тешләрне генә бер-берсенә тиереп булмый. Тиерә башладыңмы, хәзер шыкылдарга тотыналар. Соңыннан аның да хәйләсен таптым — авызны ачып йөри башладым. Кызлар туңдык дип елаша башлаганда да мин еламадым. Хәбир бабай:

— Әнә, Равилне карагыз, сездән кечкенә булса да, сукранмый! Түзегез, балакайлар, заманасы шундый бит, сугыш вакыты ич, — дип тегеләрне юатканда, мин аның үземне башкаларга үрнәк итеп куюына куанып торам һәм, тешләремне шыкылдатмаска тырышып:

— Әйе шул, Хәбир бабай, эшлик әле бераз, яме, — дигән булам. Ә үзем секунд саен машина ватылуын теләп, тизрәк җылы урынга кайтып егылу турында уйлыйм инде, югыйсә...

Белмим, мондый хәл күпме дәвам иткән булыр иде, бер көнне, һич тә көтмәгәндә, әнине дә, мине дә колхоз идарәсенә чакырттылар. Авыл советы председателе Мөсфирә апа килгән икән, ул дәштергән булып чыкты. Аның янында, култык таякларын тотып, бер рус агае һәм Мәдинә апа утыра иде.

Миңа шунысы гаҗәп тоелды: Мөсфирә апа бу юлы нигәдер бик нык үзгәреп киткән. Теге озын, кап-кара толымнарын кистергән, җете кызыл булып, балкып тора торган түгәрәк бите агарып, озынчаланып калган, карашы кырысланган иде аның.

— Нихәл, энем Равил? — диде Мөсфирә апа, әни белән салкынрак кына исәнләшкәннән соң.

— Әйбәт әле, — дидем мин.

Ә үзем, әллә укымаган өчен әнине дә, мине дә гаепләмәкчеләр микән дип, куркып куйдым.

— Әйт әле, Равил, укыйсың киләме синең?

Ни дияргә инде моңа?

— Килүен килә дә бит...

— Ә нигә мәктәпкә йөрмисең, әллә әниең җибәрмиме?

— Мин укырга йөрсәм, трут эшләүче калмый, — дидем мин, әнине якларга тырышып, — трут булмагач, колхоз икмәк бирми. Ә икмәк булмаса, яшәп булмый. Менә шуңа йөрмим мин мәктәпкә.

Мөсфирә апа ачуланмады, көлеп тә җибәрмәде микән әле. Аннары янында утырган теге култык таяклы кеше белән (соңыннан белдем, роно мөдире булган ул) русча нидер сөйләшеп алды да, әнигә карап:

— Менә нәрсә, Мәгъсүмә апа: иртәдән башлап, малаеңны мәктәпкә җибәр, яме! — диде.

— Әллә сугышлар беткәнче укымый торса да ярар микән, Мөсфирә, — диде әни, гадәтенчә куркып-оялыбрак кына. — Үземә генә бик кыенга туры килә, түлисе түләүләрем дә күп ич әле.

Әмма Мөсфирә апа үз сүзендә кала бирде:

— Кыен икәнен беләм, апа, — диде ул, — бик беләм. Шулай да малаеңны укытырга кирәк булыр. Соңыннан, менә шушы Равилең укып кеше булгач, үзең үк миңа рәхмәт әйтерсең. Сугыш беткәнне көтәргә ярамый. Безнекеләр хәзер немецны кысрыклый башладылар инде башлавын, әмма сугышның тиз генә бетәр чамасы күренми әле. Кем белә, бәлки тагын ике-өч елга сузылыр ул. Өч-дүрт ел малаеңны укытмый торырсыңмыни?.. Юк, ярамый алай, тилермә, Мәгъсүмә апа! Мөмкин кадәр үзебез дә булышырбыз... Ирең фронтта үлгән булса, ронодан да ярдәм сорап булыр иде дә бит... солдат балаларына ярдәм фонды бар аларның. Әмма... Ярый, авыл советыннан ничек тә ярдәм оештырырбыз. Анысы өчен борчылма, Мәгъсүмә апа, укыт малаеңны! Сугыш гомергә бармас, ә менә малаеңа уку гомер буена кирәк булыр. Аннары закон дигән нәрсәне дә онытма, Мәгъсүмә апа. Яхшылык белән тыңламаган кешеләрне закон тәртибендә мәҗбүр дә итәргә була.

Мөсфирә апаның үгет-нәсихәте күпме тәэсир иткәнен әйтә алмыйм, әмма «закон» сүзенең тәэсире бик зур булды әнигә.

— Ярый инде алайса, — диде ул, кинәт каушап-куркып китеп, — укыр алай булгач, нишлисең бит.

## Куып та җитәрбез, узып та...

Гаҗәп хәл: мәктәпкә йөрергә мөмкинлек булмаганда күңел гел шунда тартып, атлыгып тора иде, ә хәзер, инде әнидән рөхсәт булып, укырга мөмкинлек тугач, мин мәктәпкә теләр-теләмәс кенә килдем. Ихтимал, иптәшләрем белән бергә укый башламаганга, алардан ике айга якын соңга калганга шулай булгандыр инде бу.

Сигез туларга биш минут калганда Мәдинә апа да мәктәпкә килеп керде. Исәнләшеп, исемлек буенча барлык дүрт класс укучыларын барлап чыкты да дәресләрне башлап җибәрде.

Исемлектә минем фамилиям юк иде. Мәдинә апа әллә мине бөтенләй күрмәде, әллә күреп тә, монарчы укырга йөрмәвемә үпкәләгәнлектән, юри күрмәгәнгә салышты микән — ләм-мим дәшмәде. Менә шул хәлгә бик нык борчылып утырдым мин. Соң шулай булмыйча! Я берәр җылы сүз әйтсен иде ул, я, ачуы килгән булса, орышсын иде. Барыбер җиңелрәк булыр иде. Ә болай... әйтерсең, мин кеше дә түгел, әйтерсең, ниндидер бер бөҗәк кенә аның каршында. Китапларың бармы, Равил, ручкаң, дәфтәрләрең бармы, дип сорамаса да, һич югында, килдеңме, дисә дә күңелең булыр иде...

Төрле фикерләр үтте ул дәрестә башымнан. Әллә бу Мәдинә апа хәзер мине яратмый башлады микән, шуңа сүз әйтергә теләми микән дип тә уйландым; инде иптәшләремнән ике айга якын соңга калдым ич, укый алырмынмы, аларны куып җитә алырмынмы дип тә борчылдым. Уйлый торгач, шундый нәтиҗәгә килдем: әгәр Мәдинә апа калган өч сәгатьтә дә бер сүз дә әйтмәсә, мәктәпкә әйләнеп тә карамыйм...

Менә дәресләр дә бетте. Ә Мәдинә апаның миңа сүз катып караганы юк әле.

Иптәшләрем сумкаларын җыештырып, өйләренә тарала башладылар. Болай булгач, мәктәпкә йөрмим, дип мин дә ишеккә таба юнәлдем.

— Син калып тор әле, Нәҗметдинов! — диде Мәдинә апа.

Әһә, бөтенләй үк күрмәгән түгел икән! Күргән икән ул мине. Тик нигә шушы вакытка тикле эндәшмәде икән соң? Нишләтмәкче була икән? Ачуланырга исәплиме, әллә үземә генә дәрес өйрәтмәкчеме? Озак тотмаса ярар иде, карын ачты бит, Бәрәңге күпкә барамыни ул?

Мәдинә апа китапларын, дәфтәрләрен җыештыра торган арада мин шулай уйландым.

Әйберләрен җыештырып бетергәч, Мәдинә апа мин утырган иң арттагы парта янына килде дә, гадәтенчә, мөлаем гына:

— Ашыйсың килдеме, Равил? — дип сорады.

Каян сизде икән ул минем карын ачканны? Әллә кешенең нәрсә уйлаганын да белеп тора микән бу укытучылар? Минем иртәгә мәктәпкә килмәскә булуымны да сизде микән әллә?

— Юк, Мәдинә апа, — дидем мин юри, аны саташтырырга тырышып, — ашыйсым килми.

— Шулаймы? Алайса бик яхшы — Мәдинә апа минем янга, парта арасына кереп утырды — Әйдә әле, Равил, бераз сөйләшеп алыйк әле...

Ул миңа иптәшләремне куып җитәргә кирәклекне, ләкин бу эш шактый кыен булачагын аңлатты.

— Менә шуңа күрә, — диде аннары, — сине мин төштән соң үзенне генә укытырмын. Һәр көн мәктәптән кайткач безгә килерсең, ярыймы? Югыйсә, ялгызың гына булдыра алмассың.

Юк, төштән соң да укырга риза түгел мин. Моңа әни дә риза булмас, өйдә эш күп. Әни әйтмешли, ишек алды себерсәм яки ипигә бәрәңге кырсам да файда бит. Аннары, кар яугач, чана шуасы да бар ич әле. Җәй көне дә гел эшкә йөреп, бер көн дә уйнап булмады.

— Кирәкми, төштән соң укымыйм, — дидем мин Мәдинә апага, — әни дә орышыр. Әле болай да көчкә-көчкә генә ризалык бирде. Аннары барыбер башкаларны куып җитә алмам.

Бу сүзләрем өчен Мәдинә апаның ачуланасын белә идем, әлбәттә, Ләкин, барыбер бер әйтәсе булыр дип, тәвәккәлләгән идем. Әмма Мәдинә апа ачуланмады.

— Әниең каршы килмәс, мин аның белән сөйләшермен, — диде ул. — Ә куып җитү турында борчылма. Менә күрерсең, куып та җитәрбез, узып та китәрбез әле без аларны.

Әнә шул «без» дип, якын итеп әйтүе әллә нишләтеп җибәрде мине. Күңелем рәхәтләнеп, ышанычым артып киткән төсле булды һәм шундук төштән соң да укырга ризалык бирдем. Шулай да башта әниең ризалыгын алырга кирәк икәнлекне әйттем...

Чыннан да, барысы да Мәдинә апа әйткәнчә булды бит, әй. Шул сөйләшүдән соң һәр көн төштән соң бер-ике сәгать Мәдинә апа янына йөри башладым. Бу бер дә кыен булмады, хәтта күңелдә ниндидер горурлык хисе дә уянды әле. Чөнки Мәдинә апа мине ярата. Мин юкта үтелгән темаларның барысын да иренмичә, кат-кат аңлата.

Белмим, бу Мәдинә апа кебек әйбәт бүтән кеше бармы икән бу дөньяда? Мөгаен, юктыр. Соң үзегез уйлап карагыз: туганым түгел бит ул минем, бөтенләй чит-ят кеше. Мин үзем аңа берничек тә ярдәм итә алмыйм лабаса! Һәм, ничек кенә теләсәм дә, тиз генә ярдәм итә алачак кеше дә түгел. Дөрес, исән-сау үссәм, дөньяның аргы читеннән табып булса да, яхшылык итәчәкмен мин аңа. Әмма аңарчы бик озак бит әле. Һәм бу уйлануларымны ул белми дә әле. Ә шулай да ярата

мине. Яратмаса, ничек итеп, бер тиенсезгә, һәр кичне икешәр-өчәр сәгать мине укытып-өйрәтеп йөрсен ди? Әллә вакытын кая куярга белмәгәннән алай итәдер дисезме? Юк, билгеле. Мине ратканга күрә тырыша ул... Яки менә монысы: дөресен генә әйткәндә, ул елны киез итек киеп йөрү турында хыялланырга да курка идем мин, чөнки сарыкларыбыз инде күптән беткән иде безнең. Әмма кырык өченче ел башында Мәдинә апа мине итекле итте. Кышкы каникулга әтиләре янына кайткан җиреннән, белмим ничек юнәткәндер, бик яхшылап олтан салынган бер пар киез итек алып килде ул миңа. Алгарак китеп булса да әйтим, мин ул итекләрне, ел саен олтанын яңарта-яңарта, кырык җиденче елга тикле киеп йөрдем.

Юк, гади генә кеше түгелдер ул Мәдинә апа, изге җандыр ул. Югыйсә, барысын да ничек алдан белеп торсын ди? Ул миңа теге вакытта «куып та җитәрбез, узып та китәрбез әле» дип әйткән иде бит, әйеме? Узып киту мәсьәләсендә өзеп кенә әйтә алмыйм, әмма кышкы каникулга чыкканда иптәшләремне тулысынча куып җиттем мин...

Мөсфирә апа да сүзендә торды: миңа авыл советы хисабына бер бүрек һәм уку әсбаплары алып бирдертте.

## Әйткән идем бит «исән» дип!

Бала булсам да, күңелем дөрес сизенгән икән, әй! Искәндәр абыйның хәбәрсез югалуы турында хәбәр килгәч, мин аңа тамчы да ышанмаган идем. Югалырга тиеш түгел ул, исән булырга тиеш, берәр җирдә адашып кына вакытында кайтмый калгандыр да иптәшләре, юкка чыкты, ахры, бу дип уйлап, безгә теге кара кәгазьне җибәргәннәрдер дигән идем. Тәки минем сүз хак булып чыкты.

Адашып йөргәндерме, әллә немецлар кулына эләгеп, аннан качып кайткандырмы — анысы әлегә миңа билгесез. Ләкин шунысы ачык: Искәндәр абый исән-сау! Фашистларны тукмап йөри. Хатында үзе шулай дип язган. Әйе, үзе! Җиңги әйтә, аның кулы бу, тәгаен аның кулы язган бу хатны, ди. Сөенеченнән нишләргә белми бичара. Әле март башы гына булуга карамастан, абыйның хатын тотып, кая басканын да белмичә, күлмәкчән килеп керде безгә. Эни окоптан кайткан көнне кереп чыкканнан бирле өебезгә аяк та басканы юк иде. Урамда очрашканда эни белән дә, минем белән дә туктап сөйләшкәне юк, күрмәмешкә салышып үтә иде безне. Ә бүген, әйтерсең, алыштырып куйганнар җиңгине. Куанычына чыдый алмыйча:

— Менә, Равил наным, абыең исән икән бит, бәлки озакламый кайтып та китә алмаммы әле дигән!.. Кара инде, Мәгъсүмә апа, исән икән бит! Кем уйлаган аны болай булырын! — дип туктаусыз сөйләнеп утырды.

Шул ук вакытта нигәдер борчыла да иде бугай ул. Мин моны шуннан чыгып әйтәм, чөнки җиңги, бердән, чамасыз нык сырпалана, икенчедән, әлеге шул «кем уйлаган болай булырын» дигән сүзне шактый еш кабатлый иде. Аннары энине дә, мине дә үзләренә итле аш ашый барырга үтереп кыстарга тотынды. Ә башка вакытта, безнең хәлнең мөшкеллеген бик әйбәт белеп торса да, тешен дә агартмый иде ул хакта.

Менә шулай кинәт кенә үзгәреп, әйбәтләнеп, туган җанлыланып китүенә шактый ачуым килсә дә, ашын ашап кайтырга каршы түгел идем мин. Әмма эни аны якын да китермәде:

— Юк инде, килендәш, — диде ул, — рәхмәт! Алай бик туган итәсең килгәч, алданрак, хәлебез авыр чакларда дәшкәләргә иде аны. «Әзегез дә, эшегез дә булмасын минем йортымда!» — дип син әйткән идең түгелме соң әле кайчан гына?

Әйткән идем бит, нигәдер борчыла бугай, дип. Әнинең шушы сүзләреннән соң җинги еларга ук тотынды.

— Мәгъсүмә апа! Килендәшем! Җаным-бәгырем дип әйтәм: Искәндәр кайта-нитә калса, зинһар, мине харап итмә инде син! Белсә — үтерә ул мине. Бер минут та тотмый, холкы шундый аның. Зинһар, дип әйтәм, ул кунакка кайтып киткәнче генә аны-моны шауламый тор, яме. Аннары ул бөтенләй кайтканчы берәр җае чыгар әле.

— Әй, Нәсиха, Нәсиха! — диде әни, җингине кызганган да һәм аңа хәтере калган да сыманрак тавыш белән. — Әйттем бит мин сиңа, төкер шул чулакка дип, якын китермә шуны, бер син генә түгел тол хатын, бөтен авыл, бөтен ил хатыннары тол хәзер, алар түзә бит, син дә түз, дип. Дөнья эшен белеп булмый, тереләр үлә, үлеләр терелә торган заман дип әйтмәдемме мин сиңа?.. Курыкма, миннән чыкмас анысы. Ачу саклап йөри белмим мин алай. Кайтса, атна-ун көнгә кайтыр, Искәндәрне әйтәм. Болай да йөрәге бозылып беткәндер инде сугышта. Тагын шунда, үлем каршына китәсе кешегә ул турыда сүз катарга аллам сакласын!

Исемен атап әйтмәсәләр дә, сүзнең Самат абыйның җинги янына килеп йөрүе хакында баруын чамалап алган идем инде. Бер яктан, кыен хәлдә калган җингине кызганам, икенче яктан, абыем өчен дә борчыла идем.

— Белмим инде, килендәш, аптыраган инде үзем дә, нишләргә дә аптыраган, — дип сөйләнгәләп, пышык-пышык елап, байтак утыргач, шыпырт йомышым бар иде сиңа дип, җинги әнине өй алдына алып чыгып китте. Мыдыр-мыдыр сөйләшеп, алар анда байтак вакыт торып керделәр. Аннары җиңги мине тагын үзләренә чакырырга кереште. Ул бик борчылып:

— Итле аш та ашарсың, минем янда кунып та кайтырсың. Ату үзем генә кунарга куркам бүген, әллә ничек шунда, үз-үземне берәр нәрсә эшләтермен төсле, — дигәч, әни дә хәзер аның сүзен куәтләп торгач, мин риза булдым.

## Барысы да шул Самат аркасында...

Ә икенче көнне, әнигә йорт-җиренә күз-колак булып торырга кушып, үзем өч-дүрт көнә көнгә кунакка барып кайтам дип, җинги Баткаклыга — туган авылына китте. Анда аның әти-әнисе (безнең кода бабайлар) яши иде.

Сүз уңаенда җингинең безнең авылга ничек тап булуын да әйтеп үтим инде. Әнинең сөйләвенә караганда, егет чакта, районга барышлый Баткаклы авылын үткәндә, юл читендә кулын күтәреп торучы бик матур бер кызны күргән Искәндәр абый. Машинасын туктаткан да:

— Әйдә, утыр, чибәрем! Бер үбәр булсаң, дөньяның аргы ягына да илтеп куям үзеңне! — дигән.

— Алай ук еракка илтмәсәң дә ярый, абыкаем, әмма районга тикле утыртып барсаң, мең-мең рәхмәтләр әйтер идем, — дигән кыз. Шулай дигән дә, ялт итеп, кабинага Искәндәр абый янына менеп тә кунаклаган.

Сөйләшеп, танышып киткән болар. Кызның шәһәргә китәргә икән исәбе, шуңа паспорт юлларга барышы икән.

— Ничектер шулай туры килгән, — дип сөйләде миңа әни, — кайтканда тагын очраткан Искәндәр абыең теге кызны. Тагын машинасына утырткан да, юлың уңдымы соң, дип сораган.

— Юк шул, абый җаным, — дигән кыз, — уңмады әле, тагын бер атнадан килергә куштылар. Бигрәк бәхетсез икәнмен инде...

Шуннан абыең юатырга керешкән тегене. Аннары, сүз арасында җаен туры китереп, шаяра-көлә:

— Әйдә, чибәрем, мин сине үзебезгә генә алып кайтыйм, — дигән. Күрәсең, чәчләре чәчкә үк бәйләнеп туганнардыр инде — кыз, башта икеләнебрәк торса да, соңыннан риза булган. Менә шулай итеп кавыштылар синең Нәсиха җиңгәң белән Искәндәр абыең...

Өч-дүрт көнгә генә дип туган авылына киткән җиңгәбез бер атнадан соң да кайтмады. Башта без моңа әллә ни шаккатмадык, чөнки җиңгинең хәзер терлек-торышы юк: сыерын саткан, сарыкларын күптән суеп ашаган иде. Шулай булгач, аның өендә эш күп түгел: бәрәңгесе өшемәсен өчен, көненә бер тапкыр миченә ягасы да өч тавыгын, бер әтәчен ашатасы гына иде.

Ләкин күршеләр җиңгинең болай озаклап ятуына шактый тынычсызлана башлаган иде инде. Бер көнне кич безгә кереп, мәрхүм Миңлеәхмәтнең әнкәсе әнигә менә болай диде: «Тикмәгә түгелдер бу, Мәгъсүмә, килендәшеңнең кайтмавын әйтәм. Бардыр моның берәр хикмәте. Соңгы көннәрдә юанаеп, калынаеп та киткән төсле ие, Искәндәр кайтканчы дип, ябыгып йөрми микән ул анда. Баткаклыда шундый эшләр белән чуала торган бер карчык бар диләр ие. Югыйсә, җаны бар кеше болай онытылып ятамы соң? Бардыр берәр тамаша, бардыр...»

Әмма барысыннан да битәррәк Самат абый борчыла иде булса кирәк:

— Кайтмадымы әле? — дип көненә өчәр тапкыр килеп сорый ул бездән.

Ул арада тагын бер атна вакыт үтте, ә минем җиңгәм һаман юк иде әле. Эшләр болайга киткәч, әни дә ныклап торып пошаманга төште. Җиңгинең әни окопта чакта эшләгән усаллыклары исемнән чыкмаса да, мин дә аны юксына башладым. Аннары эш кешесе дә ич ул. Колхозның бөтен байлыгы аның өстендә бит. Әни әйтмешли, ул чулак Саматка ышаныч юк: җиңги озаграк ята калса, колхоз икмәген төрле якка таратып бетерер дә аннары җиңги өстенә аударып калдырыр.

Без әнә шул рәвешле уйлап, борчылып йөри торгач, ниһаять, мәсьәлә ачыкланды: киткәненә нәкъ унтугыз көн дигәндә, безгә кода бабай (җиңгинең атасы) килеп керде. Минем аны күп мәртәбәләр күргәнем бар, шуңа бик яхшы белә идем. Һәрвакыт шат күңелле, шадра булса да якты, мөлаем йөзле, таза гына бер кеше иде ул. Сүзгә дә бик җор, картаеп баруына карамастан, әле буй-сыны да бик төз, күркәм иде. Әмма бу юлы башта танымый тордым мин аны. Ничектер ябыгып, кечерәеп калган, кыяфәте дә мескенәйгән иде аның. Күрәсең, хәвеф барын шундук сизенеп алгандыр:

— Берәр хәл булмагандыр ич? — дип сорады әни, кода бабай безгә килеп керүгә.

— Булды-ы! — Шушы сүзне әйтүгә, кода бабайның күзләреннән мөлдерәп яшь чыкты. — Булды, наным Мәгъсүмә, мантый алмады килендәшең, кичә төштән соң дөнья куйды. Син беләсеңдер бит аның нинди эш белән йөргәнен. Киткәндә әйткәндер бит ул сиңа?

— Әйткән иде әйтүен...

— Менә шул инде, наным Мәгъсүмә, шуннан үлде инде. Врач әйтә, нигә башта ук больнискә алып килмәдегез, ди. Без аны коткарып калган булырыек, ди. Мин дә әйтеп караган ием кана да бит, үзе риза булмады Нәсиха, курыкты. Теге сихерче Хөппениса карчыкны әләктерәсе килмәде. Менә хәзер үзе дә әрәм булды, Хөппениса пәрине дә кулга алдылар бүген. Әй, бала, бала-а!.. Искәндәр кияү кайтам дип торганда гына бит, житмәсә!..

Шунда сүзен туктатып, шактый вакыт тыныч кына оеп утырды кода бабай. Аннары җиңгине җирләү өчен кирәк булачак кайбер әйберләрне алып китәргә кирәклеген әйтте дә:

— Үзебезнең Баткаклыда гына күмәргә булдык инде, наным Мәгъ-

сүмә, монда хәзер беркеме дә юк бит аның, — диде. — Соңгы тапкыр хушлашып, күреп калыйм дисәң, әйдә, миңа утырып барырсың.

Атларны карарга үз урынына башка кеше куеп торуын үтенеп, әни тиз генә Самат абый янына барып кайтты да кода бабай белән Баткаклыга китте. Мин дә бармакчы идем дә, әни риза булмады:

— Юк, юк, балам, суык туңдырып йөрисе түгел, аннары өйне дә бикләп китәргә ярамый ич инде, — диде. — Әнә, кич белән Фәйрүзә апаң керермен диде, аның белән кунарсыз...

Бер кичкә — кер мичкә, диләр. Анысы өчен аптырамый идем мин. Ә менә җиңгине күрә алмый калуыма үкенеп бетә алмадым. Яхшымыяманмы, Искәндәр абыем хатыны, миңа җиңги тиешле кеше иде лабаса ул. Дөнья булгач, төрле вакыты булгандыр, шулай да кызганыч иде җиңги. Кем белә бит аны мондый хәл буласын? Һаман шул чулак Самат аркасында килеп чыккан бәла инде бу. Үзе дә капты кабуын соңыннан.

## Он итеп тартсаң...

Җиңги урынына завхоз итеп башка кешене куярга кирәк иде хәзер. Завхозны, гадәттә, еллык отчет вакытында колхозчыларның гомуми җыелышында сайлыйлар. Әмма шушындый көтелмәгән хәл килеп чыккач, Самат абый, идарә членнары белән киңәшеп, завхозны гомуми җыелыш җыеп тормыйча гына билгеләргә булган һәм бу эшкә бердәнбер яраклы кеше итеп, Фәйрүзә апаны күрсәткән. Фәйрүзә апа каршы килмәгән, тик әйткән:

— Башта колхозның бөтен икмәгенә һәм башка мал-мөлкәтенә ревизия ясарга кирәк булыр. Шунсыз мин бу эшкә тотынмыйм, кеше өчен җавап бирер хәлем юк, — дигән.

Самат абый андый мәшәкатьләр чыгарып тормыйча гына эшли башларга ни кыстап та, Фәйрүзә апа риза булмагач, колхоз малына ревизия ясарга булганнар. Комиссия председателе итеп (бу юлы да шул ук Самат абый тәкъдиме белән) Хәбир бабайны билгеләгәннәр иде, чөнки ел башында сайлап куелган ревкомиссия председателе ниндидер йомыш белән Казанга киткән чак иде ул. Кем белә, бәлки Самат абый берәр төрле уй белән юри җибәргән булгандыр. Һәрхәлдә, халык шулайрак сөйләде ул вакытта...

Белеме бик чамалы — исем-фамилиясен язарга гына җитәрлек булгангадыр, күрәсең, Мәдинә ападан рөхсәт сорап, Хәбир бабай мине ревизия көннәрендә үзенә ярдәмче итеп алды.

Ревизия дүрт көн буена сузылды. Ул көннәрдә мин Хәбир бабай әйткән саннарны, әйбер исемнәрен язып тордым. Аннары идарәгә кайтып, кенәгәләр буенча нәрсәнең күпме булырга тиешлеген карап, чагыштырып чыктылар. Нәтиҗәдә колхоз амбарында унбиш центнер чәчүлек бодай, фәлән хәтле ит, фәлән хәтле май һәм фәлән хәтле балның ким чыгуы мәгълүм булды. Әйе, ул Саматка ышаныч юк, дип әни дөрес әйткән икән шул. Соң аннан башка кем кагылсын ди инде ул әйберләргә? Җиңги амбар ачкычларының барысын да аңарга калдырып киткән иде лабаса!

Билгеле, җиңги үзе дә сөттән ак, судан пакь булмагандыр. Әмма хәзер ул юк ич, җавапка тартып булмый аны. «Ну эләгә инде, болай булгач, Самат абыйга!» — дип уйлаган идем мин. Чынында алай булып чыкмады. Районнан килеп тикшереп-тикшереп карасалар да, Самат абыйны гаепли алмадылар, чөнки ул бар гаепне мәрхүмә җиңги өстенә аударган дип сөйләделәр.

Эшләр болайга киткәч, җитмәгән әйберләрне чигереп ташлау өчен, колхозчыларның гомуми җыелышын җыйдылар. Хәбир бабай җыйдыртты ул җыелышны.

Ревизия эшенә катнашмаса да, белмим ни өчендер, ревизия нәтиҗәләрен Самат абый сөйләргә тотынды. Башта, колхоз милкенә салкын каравы өчен, инде гүр иясе булган җиңгине озак итеп орышты. Аннары ким чыккан нәрсәләрне санап күрсәтте дә болай дип нәтиҗә ясады:

— Күрәсез, җәмәгать, житмәүчелек зур. Моның өчен, әгәр исән булса, тотып атарга кирәк иде Нәсиха Хәйретдинованы. Шушындый кыен чакта, сугыш вакытында, колхоз малын туздыручыларга закон бик каты хәзер. Әйе... Әмма да ләкин Хәйретдинова безнең арада юк, бәхете — үлеп котылды. Шулай булгач, иптәшләр, нинди чара кала инде? Бердәнбер чара шул: житмәгән продуктыларны, гаепле кешесе инде вафат булганлыктан, вафат кешене хөкем итеп тә, аңардан түләтеп тә булмаганга күрә, списайт итәргә. Башка юл юк, иптәшләр! Фәйрүзә Әхмәтҗанова иптәшне дә гомуми җыелыш карары белән беркетеп китик инде, иптәшләр. Сез аның завхуз булып эшләвенә каршы түгелдер бит? — Самат абый елмаеп, ваемсыз кыяфәт белән җыелыштагыларга карап торды. Сүз әйтергә җыенучы юк иде булса кирәк, барысы да тып-тын утыралар иде. — Даваегыз, алайса, — диде аннары председатель, — фурмасын китерү өчен, кул күтәреп, хәер-фатиха бирик Фәйрүзә сеңелкәшкә.

Җыелыш дәррәү кул күтәрде.

— Менә шулай, шулай! — диде Самат абый, иркен сулап. — Ә хәзер таралышсагыз да була инде, байтак утырдык бугай.

Ишек буендагылар урыннарыннан кубып чыга башлаганда, кинәт мич артыннан Хәбир бабай тавышы ишетелде:

— Юк әле, җәмәгать, минемчә, эш бетмәде әле монда. Җыелышны ябарга ашыкма әле, Самат туган.

Халык тагын тып-тын калды. Самат абый исә ничектер сискәнеп, куркып китте шикелле. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды. Гәүдәгә кечкенә булса да, калын тавышы белән:

— Әһе, исәнме, кодагый, өч көннән соң? — диде. — Җыелыш барганда нәрсә карадың соң син, Хәбир абый, әйтер сүзең булгач? Җыелыш тәмам дип әйттем бит инде мин, әле генә уяндыңмыни?

— Кызма әле син, Самат энекәш, — диде Хәбир бабай, бүреген йомарлап тоткан килеш халык уртасынарак үтеп. — Кызма алай, син сөйләгәндә без тыңладык бит. Бәлки, син дә әз генә безне тыңлап карарсың, ә?

— Әйдә, әйдә, Хәбир абый!

— Тыңлыйк, иптәшләр, Хәбир абый буш сүз сөйләмәс.

— Кәнишне тыңларга кирәк!

Халык әнә шул рәвешле шаулаша башлагач, Самат абый Хәбир бабайга сүз бирмичә булдыра алмады.

— Менә болай, җәмәгать, — диде Хәбир бабай, ипләп кенә. — Сез теләсә нишләгез, әмма мин үзем Саматның моннан соң да прсидәтел булып эшләвенә риза түгел. Менә без бүген бик күп тыңладык аны, матур сөйләде ул. Шушындый авыр сугыш заманында, икмәкнең грамы да кадерле чакта, шактый гына продуктыларны чигереп тә ташладык. Ярый, Самат үзе ашамаган да булсын ул ризыкларны. Ә бит ул хуҗа кеше, белергә тиеш иде икмәкнең кая киткәнен. Тәптәнрәк уйлап караганда, бөтен гаеп Саматта. Нәсиха киткәндә амбар ачкычлары анда калды лабаса...

Башлап китүче булмаганга гына авызларына су кабып утырганнар икән. Хәбир бабайның әлеге сүзләреннән соң, халык умарта күче кебек гөжли башлады.

— Дөрес, Хәбир абзый, бөтен гаеп анда! — дип кычкырды берсе.

— Колхоз җилкәсеннән булмыйча, каян алып эчсен ди ул көн дә. Соңгы айда бер аек көне булмады ич! — дип тавыш бирде икенчесе.

— Ничу монда күп сөйләп торырга, житәрлек инде инде колхоз-

ны, булды, җитте, байтак түздек, алырга да атарга урыныннан! — дип куәтләде өченчесе.

Бик нык кычкырыштылар ул көнне. Тик файдасы гына булмады. Самат абый тыңлап-тыңлап торганнан соң:

— Молчать! — дип бар көченә кычкырды да, сәламәт кулы белән өстәлгә шап иттереп сугып, барысына да чик куйды. Ә икенче көнне милиция чакыртты да Хәбир бабайны районга озаттырды.

— Менә, бер телегезгә хуҗа була алмасагыз, сезгә дә шул булыр! — дип, башкаларга да янап куйган дип сөйләделәр.

Ул көннәрдә мин Искәндәр абыйның тизрәк кайтуын көтә идем. Абый кайтып төшсә, Хәбир бабайга ярдәм итәр, аны коткарыр шикелле иде. Аннары Самат абый үзе дә Искәндәр абый каршында болай әтәчләнә алмас иде... Тик ул һаман кайтып җитә алмый иде шул әле.

Хәбир бабайны чынлап ук утырттылар, ахрысы, дип бөтен авыл халкы борчыла иде инде. Ләкин атна-ун көннән соң әйләнеп кайтты ул. Аның белән бер милиционер һәм райком секретаре — башына мамык шәл бөркәнгән бер апа да килгән иде. Шул көнне яңадан гомуми җыелыш җыйдылар. Тагын Самат абый сөйләргә тотынды. Ул үзенең бернинди гаебе дә булмавын, тырышып эшләвен һәм колхозны алга җибәрергә бар көчен салуын, ләкин Хәбир бабай кебекләрнең аңа аяк чалып, борчып торуларын кайта-кайта сөйләп бирде. Аның сүзләренә караганда, бөтен бәла Хәбир бабайда һәм Хәбир бабай инде күптән илтеп ябылырга тиеш кеше иде.

Аннары Хәбир бабайга сүз бирделәр. Ул Самат абыйның, колхозны алга җибәрүдән бигрәк, үз корсагын кайгыртучы кеше икәнлеген, күн саен салмыш булып йөрүен әйтте. Әмма райком секретаре:

— Эчкәнен үз күзегез белән күргәнегез бармы соң, иптәш Садыйков? — дип сорагач, тотлыгып калды. Бары бераздан гына:

— Юк, гөнаһысы кирәкми, шешә янында эчеп утырганын күргәнем юк. Әмма кызмача йөрмәгән вакыты сирәк аның, иптәш нәчәлник. Моны бүтәннәр дә раслар дип уйлыйм, — диде.

Халык бераз гөрләшеп алса да, сүз алып сөйләүче булмады.

— Димәк, берегезнең дә Самат Мөбиновның эчкәнен күргәнегез юк? — диде тулы түгәрәк битле райком секретаре, идарә йорты эсселәнеп киткәнлектән, мамык шәлен башыннан аркасына шудыра төшеп. — Шулай булгач, нигә узган җыелышта аңа каршы гауга куптардыгыз соң сез, иптәшләр? Ярый торган эшме инде шушы, я?

Җыелыш беркавым тып-тын торды.

— Яравын-ярамавын без, надан халык, бик үк белеп бетермибез инде, иптәш Лотфуллина, — диде аннары Хәбир бабай. — Әмма, минем уйлавымча, теге унбиш ситнер икмәк Мөбинов Самат катнашыннан башка гына юкка чыкмаган бит ул. Шушындый кыен заманда, сугыш барганда, шул тикле икмәкнең юкка чыгуы бик зур нәрсә ул, сеңелем дип әйтим инде, нәчәлник булсаң да. Он итеп тартсаң, бер пулк солдатка бер әбит ашарга җитәрлек икмәк пешереп була лабаса ул бодайдан! Җитмәсә, күз карасыдай кадерле нәрсә — чәчүлек бодай бит ул! Менә шуңа күрә алыштырырга кирәк Саматны, дип әйткән идем теге көнне. Бодайдан башка продуктылары да байтак югалган бит. Нәсихә бер үзе генә ике ай эчендә шул тикле ашамас, минемчә. Отчет сабраниесе алдыннан гына барысы да үлчәнеп, исәпкә алынган иде бит ул маллар.

— Ә Самат Мөбиновның амбардан үз өенә берәр әйбер алып кайтканын күрүче булдымы соң? Я, кайсыгыз әйтә ала?

Райком секретаре үткен кара күзләре белән җыелыштагыларны тикшереп чыкты. Кул күтәрүче юк иде.

— Димәк, берегез дә күрмәде? — диде ул, көтеп-көтеп тә сүз әйтергә теләүче булмагач.

Болай да кечкенә гәүдәсен җыера төшеп, өстәл артына посып, бер сүз дә әйтмичә утырган Самат абый, ниһаять, телгә килде.

— Мәсьәлә ачыкланды бугай инде, иптәш Лотфуллина, — диде ул, райком секретарена мөрәҗәгать итеп. — Хәзер эшкә кучәргә кирәк: Садыйков Хәбирнең нинди дизарганизатыр икәнен күргәнсездер, аны нишләтәбез? Башта ук әйтеп куям: аны шул килеш колхозда калдырсагыз, мин председателлектән кәтигәрически баш тартам, чөнки ул миңа киләчәктә дә аяк чалачак, авторитетыма тап төшерәчәк.

— Әйе, иптәш Мөбинов, сез дөрес әйтәсез, бу эшне болай гына калдырып булмый, билгеле, — диде райком секретаре.

Җыелыш ни белән бетәр иде икән, һәрхәлдә, Хәбир бабайга бик үк әйбәт булмас иде, әмма шул чак ферма каравылчысы Шәйхи бабай торып басты:

— Мин әллә ни матур итеп сөйли алмам инде, сеңелем, — диде ул, райком секретарена карап, — шулай да тыңлап кара әле. Син әйтәсең, бу эшне болай гына калдырып булмас, дисең. Садыйков Хәбиргә чара күрергә кирәк, дисең. Ни өчен? Председательгә яла яккан өчен, дисең инде син. Әмма дә ләкин алай түгел бит ул, сеңелем. Дөрес әйтә бит Садыйков Хәбир. Булды бит инде Саматның гөнаһылары. Хатын-кыз белән дә чуалмады түгел. Турысын гына әйткәндә, завхуз Нәсиха Хәйретдинованың аянычлы үлеме дә шушы Саматка барып тоташа ич инде, ничу аны яшереп торырга. Сәрхуш булып та бик еш йөри Самат. Аннан килеп, балалары урамга икмәк тотып та чыккалый, монысын барыбыз да күреп торабыз, каян килә ди аңа икмәк тә, каян килә ди эчәргә акча? Знамы колхуз амбарыннан!.. Менә мин моңарчы эчтән тынып утырдым, ул турыда сүз кузгатасым килмәде. Әйтсәм, Мөбиновка авырлык килер, дип уйладым. Инде эш болайга киткәч, Садыйков Хәбирне бер дә юкка гаепләргә җыена башлагач, әйтәм, ни булса шул, эш дөреслектә булсын, нахак белән эш кылуны сөймим мин. Менә болай булды бит, Самат энекәш, син инде туры әйткәнгә ачуланма, яме: Нәсиха китеп атна-ун көн торгач, төннәләтеп ат җигеп, амбардан бер йөк әйбер салып киттең бит, әйеме? Мин, нишләвең бу, дип сорагач.

— Син бернәрсә дә күрмәдең, яме, Шәйхи абый! Күп күрсәң, күзең сукыраер, — дип әйттең бит, әһәме? Аннары шул бер йөк икмәкнең бер капчыгын минем карчыкка кертеп калдыра киткәнсең. Әле ярый кагылмаган иек, әнә чоланда тора ул бер капчык бодай, барып карарга мөмкин. Шулай булгач, ничу гаебеңне кеше өстенә аударырга! Син миңа ачуланма, Самат туган, әгәр үзең Хәбиргә болай каты бәрелмәсәң, әйтәсе түгел ием бу сүзләрне, синең дә биш балаң бар ич, алар хакына әйтмәс ием. Әмма менә хәзер түзә алмадым... Гаепле икәнмен, мине алып китеп япсагыз да бер сүзем юк. Күп гомерем калмаган минем. Тик эш дөреслек белән барсын, нахак өскә чыкмасын...

Мәсьәләне бик ныклап берничә көн рәттән тикшергәннән соң, Хәбир бабайны акладылар. Шәйхи бабайга да берни булмады. Самат абыйны алып китеп, җәмәгать малын әрәм-шәрәм иткән өчен ничәдер елга хөкем иттеләр, ә завхоз булып эшли башлаган Фәйрүзә апаны председатель итеп сайлап, аның урынына башка кешене куйдылар.

## Тәки сүзендә торган бит!

Март та үтте, апрель дә бетте, әмма Искәндәр абый нигәдер һаман кайтып җитә алмый әле. Хаты-хәбәре дә юк хәтта. Әллә теге хатны җингигә бәрәрсе шаярып кына язган идеме икән, үлгән кешедән хат килүен күргәч, каушап калганлыктан, гомере беткәнлектән генә җиңгигә Искәндәр абый кулы белән язылган булып күренгәнме икән ул?

Басулар кардан арынып та бетмәс борын ук, бу ел да халык тагын черек бәрәңгегә ябырылды. Мәктәптән кайткач, мин дә, көрәк һәм чиләк алып, кырга йөрим. Кулларым җир казыса да, күңелем һаман абыйны уйлый, аны көтә. Бил тиңентен пычракка батып, юлым уңган булса — бер чиләк, уңмаган булса — егерме-утыз черек бәрәңге күтәреп кайтып кергәндә Искәндәр абый, медальләрен ялтыратып, әни белән чәй эчеп утыра булыр төсле тоела иде...

Ә ул һич тә истә-оста юк чакта, майның җидесенә каршы таң алдыннан кайтып төште.

— Их, кайниш, кайниш! — диде әни, абый килеп кергәч нигәдер кинәт елап җибәрде. — Исән икәнсең ләбаса! Кара син, гомере бетмәгән кеше кайта икән бит!.. Тик... менә килендәш кенә тегеләйрәк булып китте бит әле, кайниш. Тәкъдире шулай булгандыр инде, күрешергә насыйп булмагандыр инде сезгә...

— Ярар, җиңги, — диде абый, — барысын да ишеттем инде мин. Ферма йортында ут булгач, кайтышлый шунда кагылган идем, каравылчы Шәйхи абзый барын да сөйләде инде.

Шактый вакыт өй эче тып-тын торды. Әни дә, абый да, башларын аска иеп, телсез калганнар иде.

— Әйт әле, җиңги, — диде аннары абый, — Нәсиха кайчан алай чуала башлады ул Самат белән? Мин киткәч үкме, әллә теге кәгазь килгәннән арымы?

— Гөнаһысына керер хәлем юк, дөресен әйтим, кайниш: синең югалуың турында хәбәр килгәнгә тикле үзен бик әйбәт тоткан ул, авыр туфрагы җиңел булсын. «Тоткан» дип шуңа әйтәм, ул чакларда мин окоп казуда идем. Халык сүзен әйтәм. Авыл халкы белми сөйләми инде ул андый нәрсәне.

Абый байтак вакыт бик борчылып, уйланып утырды да:

— Син соң бер дә сөйләшмәдеңмени аның белән, ярамый болай дип әйтмәдеңмени, җиңги? — диде.

— Сөйләштем, кайниш, берничә тапкыр сөйләштем. Тик, нихәл итим соң: «Буласы эш булган инде. Искәндәрем дә үлгәч, бу дөньяның ни кызыгы бар миңа?» — дип әйтә иде ул. Шулай дигәч, мин нишлим?..

— Их, бу сугыш! — диде абый, көрсенеп. — Барысы да шуның галәмәтләре бит болар. Менә шушылай безнеке кебек язмышка дучар булган кешеләр аздыр дисеңме әллә!

— Һей, ник кенә сөйләп торасың инде, кайниш! Әз буламы соң! Әллә кемнәрне әллә нишләтеп бетерде инде бу афәт... Кара, сугыш дигәннән, менә син шуннан кайткан кеше инде, әйт әле, кайниш, дөресен генә, кайчан бетәр икән инде ул? Бигрәк озакка китте бит, җилекләрне суырды инде. Җиңәр чамабыз бармы соң безнең ул нимесләрне, әллә юкмы? Аптыраганнан әйтәм инде монысын.

— Бар, җиңги, бар! — диде абый, бераз ачылып китеп, — дөмектерәчәкбез фашистларны! Хәзер өстенлек бездә инде, хәзер алар безне түгел, без аларны куабыз. Кырык беренче елны гына җикеренгән иде алар, ул вакытлар үтте инде. Шулай да тәмам изеп ташлаганчы байтак вакыт узар әле.

— Ала-ай! Тиз бетмәс әле дисең, алайса... Нишлисең бит, күбенә түзгәнне, әзенә ничек тә түзәр инде халык. Без җиңәсе булгач, әйбәт икән анысы, бик әйбәт!.. Туктале, сине күрү куанычыннан сорарга да онытып торам икән, — диде әни, кинәт бик кирәкле әйберен тапкандай итеп. — Син ничек-ничек исән калдың соң?

Разведчик булган икән абый. Бервакыт иптәшләре белән разведкага киткәннәр болар. «Тел» алырга. Ләкин эшләре уңышсыз чыккан: немецларга юлыгып атыша башлаганнар да, абый шунда яраланып калган һәм әсирлеккә эләккән. Аннары, ярасы төзәлгәч, ничектер әмә-

лен табып, дошман лагереннан качкан һәм үзебезнең партизаннарга барып кушылган. Алар белән дошман тылында сугышып йөргән.

— Ә штабта мине үлгән дип уйлаганнар һәм теге кәгазьне җибәргәннәр, — диде ул.

Искәндәр абыйны көтеп йөргән чакларда мин күрү белән аның кочагына барып асылынырмын дип уйлаган идем. Абый үзе дә мине кычкырып көлә-көлә күтәреп алыр, хәлемне сораштырыр төсле иде. Әмма мена очрашкач, бер дә алай мин көткәнчә килеп чыкмады. Абыйның бик җитди, кайгылы йөзен күрүем булды — берсүз дә әйтә алмас хәлгә килдем.

— Нихәл, энем? — дип, ул күрешергә кулын сузгач, кыюсыз гына кул бирдем дә шуннан бирле аның әни белән сөйләшүен тыңлап кына утырдым. Аннары ул сөйләгәндә аңлашылып җитмәгән бер мәсьәләне ачыклау өчен, үзем дә сизмәстән:

— Ә соңыннан ничек безнең якка чыга алдыгыз соң? — дидем.

Бер яктан солдатлар, икенче яктан абый хезмәт иткән партизаннар отряды кысрыклый торгач, фашистларның бер дивизиясен тар-мар иткәннәр дә үзебезнекеләр белән кушылганнар икән. Шул сугыш вакытында, ничектер җаен туры китереп, абый немецларның бер бик зур командирын әсир иткән. Менә шул батырлыгы өчен аңа «Кызыл Йолдыз» ордены биреп, үзен ун көнгә кунакка кайтарганнар булып чыкты.

Карап торырга әллә ни зур күренмәсә дә, бик нык, бик таза һәм сугышка кадәр сабан туенда район батыры дигән исемне дә алган кеше булгач, мин абыйның орден алып кайтуына гаҗәпләнмәдем.

Күкрәгендәге орденнан тыш, Искәндәр абый бик зур, бик шәп чемодан һәм заманында яшел булган, ә хәзер уңып-агарып калган юл капчыгы да алып кайткан иде. Тышы бик матур булгач, мин аның ул чемоданы эчендә әллә нинди затлы әйберләр бардыр дип уйлаган идем. Ләкин алай зурлап телгә алырлык әйберләр чыкмады аннан: ярты кирпеч кара икмәк, азрак шикәр, кер сабыны зурлыгында ниндидер ак әйбер, сабын, бит юлыгы һәм кырыну приборы — бар булган нәрсәсе шул иде. Теге мин ак әйбер дигәне дуңгыз мае, абыйча әйтсәк, шпик булган икән. Исеме сәеррәк янгыраса да, тәме әйбәт булып чыкты ул нәрсәнең. Бик бәрәкәтле дә икән үзе: аз гына ашасаң тамак шундук туя да көн буе пух итеп йөрисең.

Кирәк нәрсәләрен чемоданнан алып куйгач, юл капчыгын чиште абый. Карап торырга сәләмә генә күренгән шул капчыктан... нәрсә килеп чыкты дисез?

Хәтерегездә микән, сугышка киткәндә:

— Исән кайтсам, сиңа гармун алып кайтырмын, энем, — дип әйтте Искәндәр абыем дигән идем. Тәки сүзендә торган: гармун гына түгел, сандык хәтле аккордеон алып кайткан! Гел пыяладан гына ясалган төсле — ялт итеп тора. Сез тагын шунысын әйтегез: гади аккордеон гына да түгел, ә абый белән бергә хезмәт иткән Михаил исемле иптәшеннән калган истәлекле аккордеон икән.

— Михаил белән бертугандай дус идек без. Разведкага да бергә бардык, чолганышта да бергә калдык, партизан булып йөргәндә дә гел бергә идек. Тик менә монда кайтыр көннәрдә генә аерылышырга туры килде, — дип сөйләде абый аның турында. — Үзебезнең гаскәрләр белән кушылу өчен сугышкан вакытта һәлак булды. Әллә үләсен алдан ук сизгән инде, шул көннәрдә генә:

— Әйтүем шушы, Искәндәр: әгәр мин алай-болай була калсам, бу аккордеонымны үзеңә ал һәм минем төсем итеп сакла. Үзең уйнарга өйрәнмәсәң, малаең өйрәнер, — дигән иде. Ул шулай дигәч, мин дә, үлә-нитә калсам, сәгатемне алырсын, дидем. Әмма минем гомерем бетмәгән икән. Михаил, мәрхүм, юк инде. Кара аны Равил, яхшылап

уйнарга өйрән! Михаил абыең сайрата торган иде аны. Шундый итеп уйнар иде, хәтта тәмам эштән чыгып талчыккан вакытларыбызда да җырлап җибәрмичә түзә алмый идек...

Менә нинди аккордеон бит ул! Болай булгач, өйрәнәм инде, шундый итеп өйрәнәм, Михаил абыйның рухын рәнҗетерлек булмасын...

Искәндәр абыемнан сорыйсы сүзләрем бик күп иде минем. Немецлар белән безнекеләр ничек итеп сугышуын да, туплар, танклар, самолетлар хакында да сорашмакчы идем. Тик кайтып төшү белән үк борчыйсым килмәде, ял иткәч сөйләтермен дип уйладым.

Әмма мин уйлаганча булып чыкмады. Кайтып кергән төннең иртәгесен абый кода бабайларга барып кайтты да:

— Мин иртәгә китәм, җиңги, оның булса, юлга азрак ризык әзерләсәң, әйбәт булыр иде, — диде.

— Соң син ун көнгә кайттым дигән идең ләбаса, кайниш, — диде әни, аптырашта калып. — Ничек була инде бу? Әллә сине ашатырлык кына азык таба алмаслар дип шикләнәсеңме? Бер дә борчылма, бүген председатель Фәйрүзә, идарәгә чакыртып, дүрт кило онга боерык язып бирде. Иртәгә үк алып кайтам, бер дә хафаланма. Кунак ич син. Кунакка кайткан кешегә колхоз һәрвакыт ярдәм итә безнең.

— Анысы әйбәт икән, җиңги, әмма мин монда тора алмыйм. Нәсиха искә төшә дә йөрәкләрем өзелеп киткәндәй була, — диде абый, һаман үз сүзендә кала биреп. — Бар, оныңны алып кайт та ипи изеп куй. Барыбер тора алмыйм мин авылда. Иптәшләр янына фронтка китәм, анда болай ук кыен булмас кебек.

Абый шулай дигәч, әни артык кыстамады:

— Үзең беләторгансыңдыр инде, алайса, — диде дә амбарга китте.

Ә кичен, сугыш башланганнан бирле мичебездә беренче мәртәбә пешкән төче коймакны ашап утырганда, әни белән Искәндәр абый арасында шушындый сөйләшү булып алды.

— Әйдә, болай сөйләшик, җиңги, — диде абый, кесәсеннән үз өйләрен бикләгән йозакның ачкычын чыгарып, — менә сиңа ачкыч, иртәгә үк минем өйгә күчегез. Күчегез дә рәхәтләнеп яшәгез. Югыйсә, — ул безнең матчасын ике җирдән терәткән өй эченә күз йөртеп чыкты, — бу түшәмнәрнең җимерелеп төшүе дә бик ихтимал.

— Анысы шулай инде, кайниш, — диде әни, уйга калып. — Түшәмебез нык түгел инде түгелен, бүген җимереләме, иртәгә төшәме дип кенә торам. Шулай да сезнең өйгә күчү бик үк килешеп бетәрме соң?

— Сугыш авырлыгы да үзгәртә алмаган икән синең холыкны, җиңги, һаман шулай оялчан икәнсең әле. Бераү булса, инде күптән кереп утырган булыр иде ул өйгә, ә син әйтә торып та икеләнәсең. Нәрсәсе ошамасын ди аның? Үзең беләсең ләбаса, мин иртәгә яңадан сугыш мәхшәренә китәм. Әллә исән калам, әллә юк мин анда. Исән калсам да, монда кайтасы кеше түгел мин. Әйдә, ташла ул сүзеңне, иртәгә үк күчегез, яме! Исән калсам, торыр урын гына табармын әле. Шулай бит, энем Равил?

— Әйе шул, абый. Син кайткач та сыярбыз әле. Өегез зур бит.


— Дөрес әйтәсең, энем! Менә шулай, җиңги, тотыгыз да иртәгә үк минем өйгә күчегез, аңладыңмы? — диде абый, каршы килергә урын калдырмаслык итеп.

— Аңладым, кайниш, ярар, рәхмәт инде алай булгач, исән йөреп сау кайтырга язсын үзеңә!

— Менә монысы икенче мәсьәлә! Күптән шулай диләр аны, җиңги! — диде абый ул турыда сөйләшүне беткәнгә санап.

Ә икенче көнне, абыйны озатканнан соң, без аның өенә күчтек.

———



*Азат Ганиев*

# ЯНӘШӘ

*Хикәя*

*«Янәшә» — Азат Ганиевнең калын журналда басылып чыга торган беренче хикәясе. Моңарчы аның парчалары Әлмәт шәһәр газетасында, Казанда «Әдәби сәхифәләр» арасында басылгалаган иде.*

*Азат 1942 елда Әлмәт районының Камы-Исмәгыйль авылында туган. Сугышка кадәр әти-әнисе укытучы булып эшлиләр. Сугыштан соң әтисе туган якларында башланган яңа төзелешләр белән мавыгып китеп, нефть эзләү эшенә күчә һәм Азат, әтиләре белән бергә, күп еллар буена авылдан авылга күчеп йөри. 1952 елларда гына алар Габдрахман авылында төпләнеп калалар. Унынчы классны Азат шушы авылда укып бетерә. 1962 елны Миңлебай газ-бензин заводында токарь булып эшли. Аннары яшь нефтьчеләр шәһәре Лениногорскида ачылган рәсем-музыка педагогик училищесында дүрт ел укып, Әлмәткә сызым һәм рәсем укытучысы булып кайта. Хәзерге вакытта Азат Әлмәт промыселларының берсендә художник булып эшли.*

*Әлмәт әдәби берләшмәсенә Азат бик яшьләй, үнҗиде яшьлек егет чагыннан килде. Дөньяны үзенчә күрә һәм үзенчә тасвирлап бирергә тырышуы аның ул чакта ук сизелә иде. Җиде-сигез ел буе ул туктаусыз диярлек яза килде һәм менә тырыш эшнең нәтиҗәсе— аның укучыларны да мавыктыра алырлык хикәяләре күренә башлады. Узган елны Әлмәттә үткәрелгән семинарда аның хикәяләр җыентыгы уңай бәя алып, Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегенә, 1969 елда аерым китап итеп чыгару өчен планга кертелде.*

*Тәҗрибәле өлкән язучылар прозаик утыз яшендә җитлегә, диләр. Азат Ганиевкә хәзер 25 яшь һәм ул инде кулга тотардай әсәрләр яза башлады.*

*Азат Ганиевкә иҗатында авыр һәм бәхетле юл телибез.*

**Гариф АХУНОВ,**

Зилә йоклый алмый. Тәненә тиеп торган бөтен нәрсә аны пешерә. Ул күптән инде өстендә булган чүпрәкләрне салып ташлаган. Шулай да бүлмәдә бөркү аңа. Зәңгәрсу-кара тәрәзәләр, ниһаять, аксыл-яшел төскә керә башлыйлар. Зилә, үзенең инде барыбер йоклый алмаячагын аңлап, торып утыра. Башы өзлексез тонык кына гүләп авырта. Башка койкалардагы кызлар изрәп йоклыйлар. Зилә аларга көнләшеп карый һәм үзен бөтенләй ялгыз хис итә. Ул, ашыга-ашыга, озын җиңле спорт майкасын һәм тар балаклы чалбарын кия. Кыскартып киселгән кара чәчен башын селкеп кенә артка ташлый, яңадан таралып йөдәтмәсен өчен, маңгай өстеннәнрәк ак тасма белән бәйләп куя. Зилә, ишек янына килеп, кулын салкын тотка тимеренә куя. Ишекнең ачылганда шыгырдап куячагын уйлый. Иптәшләре-

нең йөзенә караган килеш: «Уянмаслар микән? — дип шикләнә. — Әллә соң чишенеп ятыйммы икән?» — дип тә уйлый. Ләкин төне буе интегеп яткан ул коточкыч урынга борылып карарга курка. Ишекне кисәк кенә ачып чыга һәм баскыч буйлап, күләгәдәй, түбәнге катка төшеп китә.

Урамда инде шактый якты икән. Ләкин шәһәр йоклый әле. Зилә, урамның нәкъ уртасыннан, таушалып беткән соры кеталары белән тавышсыз гына атлап китә. Кешесез булганга, урам ташландык һәм җансыз кебек. Каты асфальт өстендәге соры яфраклар, аз гына җил иссә дә кузгалып китәргә әзер булып, селкенгәләп яталар. Болар бөтенесе Зиләнең күңеленә шом сала. Шәһәр тынлыгы үзенә бертөрле бит ул. Авыл бу вакытта инде күптән уянган була. Әтәчләр кычкыра, капкалар шыгырдый, ишек алдында шаулатып сыер савалар. Ә монда бишәр-алтышар катлы йортлар дәшмиләр. Зиләнең озын, сыгылмалы гәүдәсе генә урамга кеше күңелен җылытырлык ямь бирә. Зилә үзеннән алдарак йомры бер таш күреп ала. Таш, Зиләне үртәгәндәй, хәзер үзем тәгәрәп китәм-китәм, дип торган төсле тоела. Иөгереп килеп, ташны тибеп җибәрә. Ташка таш бәрелеп чыкылдаган авазлар йортлар арасында бәргәләнә башлыйлар.

Зилә кызурак атлап китә. Шәһәрнең бу як кырые урманга терәлеп үк тора. Бераздан инде Зилә урман эченнән бара башлый. Сукмак мул итеп алтын яфраклар белән түшәлгән. Урман тынлыгында Зилә үзен рәхәтрәк хис итә. Бәйләнчек, газаплы уйлары күнеленең түренәрәк чигенәләр. Яфраклар ныграк кыштырдасын өчен, Зилә юри аякларын сөйрәбрәк атлый. Алда, кара агач кәүсәләре арасында, сары ачыклык күренә. Бу Зиләнең аланы. Зилә аны, үзенчә, «спортзал» дип йөртә. Алан кырыенда Зилә туктый. Аягы астында яфрак кыштырдавы басылуга, бөтенләй тын булып кала. Бары тик ара-тирә нindидер кошларның йокылы-уяулы сызгырынулары гына тынлыкны бозалар. Алан уртасында каен да йоклый әле. Иңнәреннән алтын шәленең шуып төшкәнен дә сизми. Таң җиле исеп куя. Урман тирән итеп сулыш ала. Әле анда, әле монда, җиргә төшмәс өчен, әллә ниләр кыйлана-кыйлана, яфраклар оча башлый.

Зиләне яңадан ялгызлык хисе биләп ала. Ул, соры күзләрен зур ачкан килеш, кулларының кайдалыгын онытып басып тора. Арыган мие бары тик бер исемне генә кабатлый: «Исфат, Исфат, Исфат, Исфат». Бүген генә дә меңенче тапкырдыр инде.

Кинәт якында гына кемнеңдер аяк тавышлары ишетелә башлый. Зилә, аңына килеп, агач артына яшеренә. Аланда, тирә-ягына каранакарана, ашыкмый гына атлап килүче ят кеше күренә. Аның бер кулында киндер тарттырылган рам. Җилкәсенә этюдник аскан. Ул, каен янына басып, бераз тик кенә карап торганнан соң, этюднигының җыелма аякларын җәеп, җиргә бастыра, киндерен каршысына беркетеп куя. Зилә үзенең «спортзал»ына сораусыз-нисез басып кергән бу кешене ачулы карашы белән күзәтә. Ә художник ашыкмый гына үзенең хуҗалыгын кора башлый. Чакырылмаган кунак булуы аның хәбәрендә дә юк.

Зиләнең бу художникны шәһәр урамнарында күп мәртәбәләр күргәне бар һәм һәрвакыт шул әрҗәсен аскан килеш. Аның бу сәер килешкилбәте башкалардан аермалы булып игътибарны җәлеп итә. Ә ул үзе, киресенчә, бераз алга иелебрәк атлый һәм тирә-юньгә бөтенләй игътибар итми кебек. Аның аякларында сирәк кенә итеп үрелгән каеш чабата. Чалбары да арзанлы, юка материядән тегелгән. Ә кыска җиңле спорт майкасы кояшта уңып, янгырда чылана-чылана, нинди төстә икәнен белеп булмаслык хәлгә кергән. Бу киемнәре аның илтифатсыз хәрәкәтләренә комачауламыйлар, һәм ул тулысы белән табигать иркендә.

Художник, үзенең серле корылмаларын урнаштырып бетергәннән соң, кулына пумаласын ала. Һәм шунда аның бөтен торышы үзгәрә,

Гадәттәге сүлпәнлегенең эзе дә калмый. Шактый ерак арадан да Зилә аның дулкынлануын сизде. Художник хәзер ясый башлаячак күренешкә караган килеш, корбанына ташланырга әзерләнгән ерткыч кебек сагаеп кала. Зилә дә, гипнозлагандай, шул якка карарга мәҗбүр була һәм үзенең аланыннан еракка таба гаҗәеп матур күренеш ачылганлыгын күреп таң кала. Аның аланы калкулык битендә икән ич. Башта аска төшеп, аннары башны әйләндерерлек мәһабәт зур дулкындай югары күтәрелүче калкулык соргылт-сары урман белән капланган. Калкулык башындагы яңа төзелеп килгән ак шәһәрнең күтәрү краннарына, телевизор антенналарына эләгә-эләгә, лимон төсле сары кояш күтәрелеп килә. Ә алсу-яшел күк йөзе шундый чиста һәм салкын икән. Зилә ирексездән тирән итеп сулап куя. Чишмә суыдай салкын һава аның күкрәгенә чиксез бер рәхәтлек бирә. Кыз күз карашын яңадан художникка күчерә. Ул инде, эше белән мавыгып, үзенең дөньяда яшәвен дә оныткан. Зилә агач артыннан чыга. Художникның ничек эшләгәнен якыннанрак күрәсе килә аның. Художник, башын чак кына борып, аңа күз төшереп ала. Ләкин Зиләне күрмәмешкә салына. Мондый игътибарсызлыкка Зиләнең хәтере кала, шулай да ул китәргә ашыкмый. Бераздан художник игътибарсызрак эшли башлый. Бер урында киндергә бөтенләй кирәкмәс төс сала. Моны Зилә дә күрә. Художник шул урындагы буяуны кырып алганда, инде ясалып беткән күк йөзен пычратып куя. Аның кәефе кырыла, ачу белән пумаласын атып бәрә. Һәм Зиләгә карамыйча гына, кесәсеннән папирос алып, авызына каба. Зилә аның буяуга буялган озын нечкә бармакларының чак кына калтыравына игътибар итә. Художникның кабызырга шырпысы юк икән. Кесәләрен кат-кат актарып та таба алмагач, ул, ярдәм эзләгәндәй, Зиләгә карый. Зилә кулларын як-якка җәеп күрсәтә. Юк, янәсе. Ниһаять, художник кесә төбеннән сынык шырпы кисәге табып ала һәм аны ялт кына чалбарына ышкып кабыза. Тәмләп бер суырганнан соң гына ул Зиләгә борылып карый һәм дусларча елмаеп куя. Ләкин шунда ук аның йөзе үзгәрә. Чөнки Зиләнең иреннәре яргаланып канаган булуын, күзләрендәге сагышны, соңгы чиккә җиткән өметсезлекне ул хәзер генә күреп ала. Художникның түгәрәк алмазга охшаган соры күзләре Зиләнең хәлен аңлап, кызганып һәм чак кына көлемсерәп карыйлар. Ул күптәнге танышы белән сөйләшкәндәй:

— Ә син монда ни эшләп йөрисең? — ди.

Зилә ни дип җавап бирергә дә белми. Нәрсә генә дисә дә, бу кеше аңардан көлә башлар кебек. Зилә бары тик:

— Тәк, — дип кенә куя.

Художник, бик күпне белә торган картларга охшарга тырышып:

— Ала-а-ай! — ди. — Аннары Зиләгә туп-туры карап: — Димәк, гашыйк булдым дисең?

Зиләнең янагына китереп чаптылармыни! Ул, акланырга тырышкандай, кызу-кызу сөйли башлый:

— Минем бернәрсә дә әйткәнем юк. Сез моны үзегез уйлап чыгардыгыз. Әгәр беләсегез килсә, мин бу аланга көн дә физзарядка ясарга киләм. Яз башыннан бирле...

Ә художник үзенең хаклы булуына нык ышанган хәлдә көлемсери генә. Зилә сөйләвеннән туктый.

Художник яңадан пумаласын кулына ала һәм ерактагы шәһәргә караган килеш:

— Яз башыннан бирле дисеңме? — дип сорый. — Алайса, синең эшләр мөшкел икән. Син гашыйк кына түгел, ә өметсез гашыйк икәнсең, — ди.

Бу сәер кеше белән танышуына Зилә инде үкенә дә башлый. Художник тупас беркатлылык белән Зиләнең күңелендәге иң изге хисләрне бернинди тартынусыз иртәнге кояш яктылыгына тартып чыгара.

Зиләнең бу турыда яңадан сөйләшәсе килми һәм ул үзе сорау бирергә ашыга:

— Ә сез бу рәсемне нигә ясыйсыз?

Бу юлы художник аптырап кала.

— Ничек нигә?!

— Хәзер бит фотография бар. Шалт! Төшердең алдың. Әйбәтрәк тә чыга.

Художник, Зиләне беренче тапкыр күргәндәй, күзләрен йомгалап, аңа карап тора башлый. Аннары ярым шаяртып, ярым мыскыл итеп:

— Ба-ла-кай! — ди. — Син соң даһи кеше икәнсең ич! — ди.

— Әйе шул! — ди Зилә, аның көлүен аңламаганга салышып.

— Минем рәсем ясыйсым килә. Аңлыйсыңмы? Ясамыйча тора алмыйм. Менә син урманда берүзең җүләр сатып йөргән шикелле.— Художник кинәт кызып китә, кычкырып диярлек: — Ә мин рәсем ясамый тора алмыйм. Бу буяулар, бу киндер булмаса, яшәү минем өчен коточкыч бер нәрсәгә әйләнер иде, — ди.

Зилә, художникның кызып китүен күреп, аны тагын бераз үртәргә тели, булдыра алган кадәр җитди итеп:

— Әгәр, иртәгә атом сугышы башлана дисәләр дә, сез шулай рәсем ясап утырыр идегезме? — дип сорый.

Ләкин художник Зиләнең тавышындагы ясалмалылыкны шундук сизеп ала һәм кисәк кенә бөтен гәүдәсе белән аңа таба борыла. Зиләне этеп җибәрделәрмени. Ул абына-сөртенә чигенә башлый. Икесенең дә арасы шактый ераклашкач кына, ияген алга сузып, телен күрсәтә дә агачлар арасына кереп күздән югала.

Художникның яңадан пумаласына тотынасы килми. «Шайтан алсын үзеңне, — дип тирги ул Зиләне. — Бөтен эшне бозды да китте бит». Художник, каенның кытыршы кәүсәсенә аркасын терәп, җиргә утыра. Инде шактый күтәрелеп өлгергән кояш аның бронза төсендәге йөзенә туп-туры карый. Җылы нурларга иркәләнеп художник күзләрен йома. Шунда, аның күз алдына, аермачык булып, яргаланып канаган зур иреннәре белән Зилә килеп баса. Художник ирексездән кыз турында уйлый. «Ә аның күзләре дөньяга бөтенләй ямьсез карыйлар. Күрәсең, аңа нидер булган. Мондый хәлдә кешене ялгыз калдырырга ярамый».

Художник бу уйларыннан арынырга тели. Сикереп торып, чирәмдә мәтәлчек атарга тотына. Аякларын югары күтәреп, кулларына баса һәм шул килеш каен тирәли әйләнеп йөри. Куллары арыгач, гөрселдәп җиргә ава, тагын мәтәлчек атарга керешә. Ә үзе барыбер Зилә турында уйлый. «Иртәгә килерме икән? Бәлки аңа ярдәм итәргә кирәктер».

Художник җиргә утыра. Мәтәлчек ату түгел, су астына чумса да, уйларыннан арына алмасын аңлый ул. «Тукта әле, Дамир, дип юатырга тели ул үзен. — Синең ни эшең бар соң аңарда? Кем гашыйк булмый да кем газапланмый». Ләкин күңеле икенче төрле сөйли. Һәм ул очраклы танышы өчен торган саен ныграк борчыла. Ниһаять, ул: «Аны бүген үк эзләп табарга кирәк», — дигән нык бер карарга килә.

...Зилә, дәрескә соңга калуын белсә дә, урманда йөри бирә. Күк йөзен әкренләп соры болытлар каплый. Караңгы һәм юеш, урман ягымсызлана. Ә Зилә бара да бара. Бер урында басып, я утырып тора алмаганга бара. Ул үзендә теләсә кемне яшәүнең мәгънәсезлегенә ышандыра алырлык көч барлыгын тоя. Бу көч аның үзен рәхимсез рәвештә упкын кырыена кысрыклый. Кыз үзенең котылгысыз рәвештә шунда якынлаша баруын һәм моңа берничек тә каршы тора алмавын аңлый, еларга тели. Бик рәхәтләнеп елар иде дә, тик елый алмый. Зилә бөтенләй таныш булмаган җирләргә килеп чыга. Хәзер инде ул көннең кайсы вакыты булуын да чамалый алмый. Тынгысыз мие аякларына бер генә минутка да ял бирми. Ул яшьтән үк спорт яратып үсте, ул

таза. Шулай да, тулай торакка кайтып кергәндә, Зилә аягында басып тора алмаслык булып хәлсезләнә. Иптәш кызлары әле дәрестән кайтмаганнар. Зилә юеш киемнәрен салып тормастан, койкага барып ава һәм кичкә кадәр селкенмичә ята. Көлешә-көлешә иптәш кызлары кайталар, ашарга әзерлиләр, кайсылары дәрес әзерләргә утыра. Алар Зиләнең шулай ятуына гаҗәпләнмиләр. Мондый хәл беренче мәртәбә генә түгел. Кичке сәгать сигезләрдә Зилә урыныннан торып, өстен алыштыра, чәчен тарый. Ул, иптәш кызларының соравын ишетмәгәндәй, аларга җавап бирми. Зилә, сәгатькә карамаса да, хәзер Исфатның тренировкага барырга әзерләнеп йөрүен күнеле белән сизә. Аның һәр хәрәкәтен күз алдына китерә. «Хәзер урамга чыкты, — дип уйлый кыз. — Бер минуттан тулай торак янынан үтеп китәчәк. Ярты минут үтте. Ун секунд калды. Хәзер тәрәзәгә карасам, аны күрәчәкмен». Зилә тәрәзә янына килеп баса. Ул гаҗәпләнми, әйтерсен, шулай булырга тиеш. Каршы як тротуардан ике егет үтеп баралар. Кечерәк буйлысы, кулларын бутый-бутый янында баручы озын буйлы, киң җилкәле егеткә туктаусыз нидер сөйләп бара. Озын буйлысы — Исфат. Анын җилкәсендә кечкенә яшел рюкзак. Исфат кулларын беләзек турысыннан чак кына үзенә табарак бөккән. Бу аның классик көрәш белән шөгыльләнүдән калган гадәте. Ул күкрәген киеребрәк, чайкалыбрак атлый. Өстендә соры пиджак һәм пөхтә итеп үтүкләнгән тар балаклы чалбар. Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, чаттан борылып күздән югалалар. Зилә йөгереп барышлый, ишек янында торган туфлиләрен аякларына эләктереп чыгып китә. Аның аяк тавышлары башта коридорда, аннары түбәнге катка төшә торган баскычта ишетелеп тора. Аста пружиналы ишек шапылдап ябыла. Бүлмәдәге кызлар, үзара карашып, сүзсез генә елмаешалар.

Зилә, егетләрне күздән югалтудан куркып, туктаусыз йөгерә һәм, чаттан борылуга, чак кына Исфатка килеп бәрелми. Алар, борылмада бер егетне очратып, сөйләшеп торалар икән. Тәбәнәк буйлы егет Зиләгә ишетелерлек итеп русча:

— А вот и наш почетный караул! — ди. Алар, урамны аркылы чыгып, тротуардан баручы Зилә артыннан көлеп калалар. Бу тел бистәсе Фаизга ачуы килә аның. «Исфат нәрсә дип шуның белән дуслашадыр», — дип уйлый. Ләкин бераздан ачуы басыла һәм ул, дөньядагы иң бәхетле кешедәй, үзалдына елмаеп бара башлый. Чөнки ул бүген Исфатны шундый якыннан күрде, хәтта чак кына кагылып та китте бугай әле. Зилә, кешеләр арасына буталып, Исфат белән Фаизны үткәреп җибәрер өчен, акрынрак атлый. Әнә алар урамның икенче ягыннан кызу-кызу атлап киләләр. Фаиз һаман Исфатка астан өскә караган килеш, кулларын бутый-бутый, нидер сөйли. Зилә аңардан көнләшә. Фаиз аның Исфаты белән шундый якыннан атлый ала, аның белән сөйләшә ала, күпме теләсә шулкадәр аның йөзенә карый ала. Зилә аларга янадан күренмәс өчен зур корсаклы, салам эшләпәле юан абзый белән янәшә атлый. Исфат белән Фаиз алга үтеп китәләр. Зилә сөеклесенең аяк атлауларына кадәр сокланып арттан килә. Ул үзе дә Исфат кебек атларга тырышып карый. Һәм янадан үзенә-үзе елмая.

Исфат белән Фаиз культура сараена кереп китәләр. Зилә классик көрәш секциясе бара торган залның тәрәзәсе янына килеп баса. Тәрәзә биек. Кыз нигез чыгынтысына басып, рамга ябыша. Алай да әле зал эчен тулысынча күрә алмый. Ә ана башкалар кирәкми дә. Әнә Исфат өстен алыштыра. Хәзер зәңгәр спорт майкасыннан гына. Зилә Исфатның таза мускул уйнап торган гәүдәсенә сокланып карап тора. Һәм Исфатны беренче мәртәбә очраткан көнне исенә төшерә.

Ул чагында әле яз башы гына иде. Культура сараенда классик көрәшчеләр чыгышы буласын ишетеп, Зилә белән бер бүлмәдә яшәүче

кызлар кинога дип алган билетларын башка иптәшләренә бирәләр. Зиләне дә барырга кыстыйлар. Зиләнең икеләнеп торуын күреп: «Синең әле чын егетләрне күргәнең юктыр. Менә андагы егетләр егетләр, ичмасам», — диләр. Кызларның берсе арттырып ук җибәрә. «Аларны карау өчен стипендия акчасын сорасалар да кызганмас идем», — ди. Алар юл буе әлеге юмарт кыздан көлә-көлә, культура сараена китәләр. Көрәшләр башланыр алдыннан ярышта катнашачак спортсменнар сәхнә алдына бер кат булып тезелеп басалар. Төрле яктан яктырткан утлар көрәшчеләрнең корыч мускуллы тәннәрендә ялтырап кире чагылалар. Зилә уң якта, иң кырыйда басып торучы егетнең пәһлевандай таза гәүдәсенә һәм бигрәк тә аякларының матурлыгына таң кала. Ул көнне культура сарае Зилә өчен әкияттәге серле сарайга әйләнә. Шул көннән башлап, Зилә Исфатның үзенә сиздермәскә тырышып, аның һәр адымын күзәтә. Аның бөтен гадәтләрен белеп бетерә.

Берничә атнадан соң Зиләнең Исфатка булган мәхәббәтен училищедагы барлык студентлар белеп алалар. Ә Исфат моңа бөтенләй игътибар итми. Зилә кебек, аның артыннан чабып йөрүче кызлар болай да күп. Ләкин Зилә өметен өзми. Өнендә, я төшендә Исфатны күргән минутларда үзен чиксез бәхетле итеп тоя. Исфатта аз гына үзгәреш күрсә, Зилә үзенең бай фантазиясе белән аны тулыландыра, әллә ниләргә юрап бетерә. Шулай җәй үтеп китә, көз житә. Зилә бер көн калмыйча Исфатның артыннан бара, я тәрәзәдән карап кала. Исфатны бу кызның исәрләнеп йөрүе туйдыра башлый һәм ул моңа чик куярга була. Бөркөнне тренировкага барганда, Зиләнең һәрвакыттагыча артыннан килүен күреп, Исфат туктап, аны көтеп тора башлый. Зиләнең башына кан йөгерә. Хәзер бик мөһим нәрсә буласын сизә ул. Исфат янына кадәр калган ун адымны, төштәгедәй, аяк астындагы җирне тоймыйча атлый. Исфатның кимсетүле елмаюын да күрми, русчалатып:

— Ты! На кого ты тянешься! — дигән сүзләренең мәгънәсен дә аңламый. Исфат, Зиләнең бөтенләй югалып калуын күреп, бераз йомшаграк тонга күчә. — Мин сине яратмыйм. Ярата да алмыйм, — ди.— Йөрәккә боерып булмый, — ди Исфат һәм борылып китеп бара.

Зилә Исфатның сүзләрен аңлап житкермәсә дә, күңеле белән әле генә коточкыч хәл булуын тоя. Аның өчен тормыш мәгънәсез бер нәрсәгә әйләнеп кала. Алга таба ниләр буласын Зилә күз алдына да китерә алмый. Исфатны гаепләми ул. «Йөрәккә боерып булмый», дигән сүзе белән бергә Исфат мәңгелеккә аның йөрәгенә кереп урнаша. Тренировка залындагы көрәшчеләр кайтырга җыена башлыйлар. Зилә шунда гына үзенең яңгырга чыланып торуын абайлый. Исфат белән Фаиз, ишектән чыгу белән, тәрәзә төбендә басып торучы Зиләне күрәләр һәм көлә-көлә караңгыга китеп югалалар. Зилә салкын яңгыр астында бер ялгызы кала. Аны кызганучы, аңа ярдәм кулы сузучы бер генә кеше дә юк. Зилә торакка кайта. Иптәш кызлары кайсы кая таралышып беткәннәр. Бүлмәдә беркем юк. Зилә, Исфатның фотокарточкасын уч төбенә куеп, озак кына карап торганнан соң, соңгы тапкыр үбә, аннары вак кына кисәкләргә ерткалап, учына йомарлый. Шифоньерны ачып бер шешә серкә кислотасын өстәлгә китереп куя. Шунда гына Зилә үзенең бүген бернәрсә ашамаган булуын исенә төшерә. Бигрәк тә аның эчәсе килә. Кыз үтә күренмәле сыекчаны ярты стаканнан артыграк итеп сала да йотлыгып эчә. Ул авыз эченең һәм бугазының яна башлавын тоя, ләкин кычкырмый, тавыш-тынсыз идәнгә сыгылып төшә.

Художник егет Дамир ул көнне Зиләне әзли-әзли яңгырга чыланып бетә. Ул Зиләнең кайда торганын, хәтта исемен дә белми. Бары тик, бәлки, урамда очратырмын дип кенә өметләнә. Ләкин язмыш аларны очраштырмый.

Икенче көнне рәсем ясарга Дамир шул ук аланга килә һәм, Зилә турында уйлана-уйлана, башлаган эшен дәвам итә. Әгәр ул кыз бүген дә килсә һәм мин рәсемемне ул сокланырлык итеп ясый алсам, нинди бәхетле булыр идем, дип уйлый художник. Әнә шул уйлар аңа көч бирә һәм ул таң алды күренешен ясаганда үзенең табигатькә, кешеләргә булган мөнәсәбәтен дә, сүз белән әйтеп булмый торган уйларын да төсләр ярдәмендә киндергә салырга тырыша. Үзенең арыганлыгын бары тик пумаласы белән киндергә соңгы мәртәбә кагылып үткәннән соң гына сизә һәм йомшак үлән өстенә сузылып ята. Кулларын баш астына куеп, керфек какмыйча, мәңгелек тын, төпсез зәңгәр күк йөзенә карап ята башлый. Аңа хәзер алай ятарга түгел, җүләр кеше кебек сикергәләргә, бөтен дөньяны яңгыратып көләргә иде, югыйсә. Ә ул хәтта елмаймый да. Дамир тавышсыз гына елый. Аның күңелендә сикергәли торган шатлык түгел шул, бу минутта ул иң зур шатлыкны — иҗат шатлыгын татый.

Ә шуларның бөтенесенә сәбәпче булган таң кызы үзе юк. Дамирның аны күрәсе килә. Ул канатланып шәһәргә кайтып китә. Көне буе урам таптап йөри, кешеләрнең сөйләшүләренә колак сала, берничә кызны Зиләгә охшатып алдана. Кичкә таба гына ул автобус тукталышы янында кешеләрнең ниндидер бер кызның су дип белеп серкә эчүе, хәзер авыр хәлдә больницага эләгүе турында сөйләшүләрен ишетә. Дамир моның аланда очраган кыз булуына аз гына да шикләнми. Аяклары аны больница ягына алып китәләр. Ул йөгерә, кызны күрми калырмын дип куркып йөгерә. Больница бакчасына кергәч, сөенеп һәм гаҗәпләнеп туктап кала. Зилә иптәш кызлары белән эскәмиядә сөйләшеп утыра. Дамир алар янына килеп, Зиләгә караган килеш, башын чак кына иеп, сүзсез генә исәнләшә. Һәм... китми басып тора. Зиләнең иптәш кызлары бу сәер егеткә кызыксынып карыйлар. Зиләгә дип алып килгән берничә калын китапны һәм чәчәкләр бәйләмен утыргычта калдырып, китеп баралар.

— Больницада әллә берәр танышыгыз бармы? — дип сорый Зилә.— Менә минем белән дә бәхәтсезлек килеп чыкты. Ялгыш агуланып, чак кына үлми калдым. Үлүе бик тиз икән. Минем ул турыда беркайчан да уйлаганым юк иде, — ди Зилә.

Дамир берсүз дәшми. Зилә гаҗәпсенеп аңа карый һәм Дамирның чак кына көлемсерәп торуын күреп, аптырап кала.

— Нигә берсүз дә дәшмисез? — дип сорый Зилә. Аның тавышы үзгәргән. Ул еш кына, авыртуга чыдый алмыйча, йөзен чытып куя. Дамир һаман дәшмәгәч, Зилә: «Әллә бу егет акылга таман микән?» — дип шикләнә башлый. Шунда Дамир гади генә итеп:

— Нигә агуланырга уйладыгыз?

— Менә инде! Әйтәм ич, ялгыш эчтем мин аны.

— Куй юкны! — ди Дамир, сабырсызланып.— Ул әкиятеңне бүтәннәргә сөйлә.

Зилә тамагына килеп тыгылган төерне йотып:

— Әйе, мин үзем агуландым. Ләкин миңа барыбер беркем ярдәм итә алмаячак. — ди, бераз дәшми торганнан соң. — Хәтта Исфат та, — дип өсти.

Дамир аны бүлдерми, башлаган фикерен әйтеп бетерүен көтеп аңа карап тора. Зилә үзалдына сөйләгәндәй:

— Пәрәккә боерып булмый! — дип куя.

Аннары, Дамирның ихтыяр көчен күрсәтеп торган күркәм йөзенә сынаулы караш белән карап:

— Ә син бу сүзнең мәгънәсен аңлыйсыңмы? — дип сорый.

Дамирның моңа бер дә исе китми.

— Моны сиңа Исфат әйткәндер, — ди. Зилә кинәт җанланып китә.

— Син Исфатны беләсеңмени? Сез аның белән дуслармы әллә?

— Юк, — ди Дамир, — мин аның белән дус түгел.

— Ләкин ул сиңа охшый, әйеме?

Дамир бераз дәшми торганнан соң:

— Син миннән бу турыда беркайчан да сорама,— ди. — Беләсеңме нәрсә...— Ул нәрсәдер уйлап, әйтә башлаган фикерен ярты юлда бүлә, Зиләгә карамыйча гына эскәмиягә килеп утыра. Зилә, аның сүзен дәвам иттерергә җыенмавын күреп:

— Нәрсә? — дип сорый.

— Бернәрсә дә түгел,— ди Дамир коры гына.— Мин бер кеше белән дә озак дуслаша алмыйм. Чөнки мин ни уйласам, шуны сөйлим. Моның башкаларга ничек тәэсир итәчәге турында уйламыйм. Хәзер дә мин син үпкәләрлек сүз әйткән булыр идем. Синең белән ачуланышасым килми.

— Таптың! — ди Зилә, иренен турсайтып.— Әйдә, дөресен әйт. Мин үпкәләмим.

— Ярый, алайса. Беләсеңме нәрсә, Зилә, син, мөгаен, Исфатны түгел, ә үзең уйлап тапкан икенче бер Исфатны яратасың бугай. Әгәр син аны якыннанрак белсәң, мондый хәлгә төшмәгән булыр идең.

Зилә тупас кына:

— Мин аны болай да яхшы беләм, — дип аны бүлдерә.

— Әйттем ич, — ди Дамир һәм кулын селтәп куя. Ул читкә борылып, ерактагы урман өстенә төшеп килгән кояшка карап тора башлый. Икесе дә сүзсез калалар. Тынлыкны Дамир боза:

— Минем үземнең аллам бар. Минем аллам — менә бу кояш һәм табигать үзе. Ә синең, Зилә, үзеңнең аллаң бармы?

— Ә миңа алланың да, шайтанның да кирәге юк. Хәзер миңа барыбер. Нигә миңа үләргә ирек бирмәгәннәрдер. Ә мин барыбер үләчәкмен. Бу юлы суга төшәм. Ышанычлырак булыр.

Дамир бер дә исе китмәгәндәй:

— Үзеңә карыйсың, — ди. — Бу — иң җиңел юл, ә менә син бәхетне яулап алып кара. Мәгънәсезгә үлеп, кемгә нәрсә исбат итәргә телисең? Сиңа суык, ахрысы. Әйдә, йөреп киләбез.

Алар янәшә атлап китәләр. Зилә үзен әле генә йокыдан уянгандай хис итә. Юк, аңа суык түгел, тик нигәдер ул бөтен тәне белән калтырана һәм Дамирның сүзләрен йотлыгып тыңлый. Зилә бу кешедән үзе өчен бик мөһим булган бер сорауга җавап эзли. Дамирның җавап бирә алуына ул, нигәдер, шикләнми дә. Үзен рәхимсез рәвештә үпкын кырыена этәрүче дәһшәтле көчнең төтен кебек тарала баруын тоя. Аның колагы төбендәниндидер яңа көй ишетелә башлый. Дамирның тавышы Зиләгә бу көйне тыңларга комачауламый, киресенчә, шул көйгә кушылып, аны көчәйтә генә.

— Син ярата беләсең,— ди аңа художник егет.— Шуның өчен генә булса да, синең яшәргә хакың бар. Җир өстендә мәгънәсез кешеләр дә йөри. Беләсеңме, Зилә, бәлки сиңа Исфатның игътибарын җәлеп итәрдәй берәр нәрсә эшләргә кирәктер. Спорт белән шөгыльләнепме яки башка нәрсәме?

Шунда аларның каршысына ак халатлы сестра кыз килеп чыга. Ул Зиләгә укол кадар вакыт җиткәнлеген әйтә. Баш врач сиңа чыгып йөрергә әле рөхсәт итмәде, — дип ачуланып та ала. Сестра кыз Зилә белән бер яшьтә. Ул килештереп ачулана белми әле.

Зилә, кашларын җыерып:

— Кадарсың әле, — ди аңа, аннары Дамирга борылып: — Иртәгә дә кил, яме.— ди.

Дамир җилкәләрен җыерып куя.

— Әйтә алмыйм. Мин иртәгә кич белән Казанга укырга китәм. Ә аңа кадәр документларны тәртипкә китерәсе бар. Шуңа күрә ышандыра алмыйм, — ди.

Зилә белән сестра кыз больница йортына таба китәләр. Зилә берничә мәртәбә артына борылып карый. Дамир, капкадан чыгып, кешеләр арасына кереп югала. Зилә аны куып житәргә тели, бу кеше белән әле күп нәрсәләр сөйләшә алган булырлар иде бит алар. Әйтерсең, сусап хәле киткән Зиләгә зур чүмечне тотырып су бирделәр дә, иренен тидерүгә, тартып та алдылар.

Икенче көнне Дамир юл кирәк-яракларын әзерләп йөреп, кичке сәгать өчләргә кадәр бушый алмый. Өчтән соң гына Исфат яши торган тулай торакка китә. Исфат өйдә икән. Каядыр барырга җыена, ахрысы, ак күлмәген үтүкли. Бүлмәдә Фаиз һәм тагын ике егет бар. Дамир ишектә күренү белән Фаиз:

— Булачак Шишкин килә! — дип кычкыра.

Егетләр аның шаяртуына да, Дамирга да игътибар итмиләр. Күрәсең, Дамир кергәнгә кадәр, Фаиз аларга кызыклырак нәрсә турында сөйли башлаган булгандыр. Егетләр Фаизга шуны дәвам итәргә кушалар. Вакыты тар булуын искә алып, Дамир Исфатны коридорга чакырып чыгара. Ул Исфатка караганда озынрак буйлы икән. Өстән карап, бераз дәшми торганнан соң, Дамир турыдан-туры сорый:

— Зиләнең синең өчен агуланганын беләсеңме?

Исфат кулын селтәп ала.

— А-а-а! — ди ул тамак төбе белән. — Җүләрләр азмыни дөньяда!

— Ул хәзер больницада ята. Бәлки, янына барып килерсең?

Исфат йөзен җыера.

— И-и-и! Мин аңардан куркам бит. Я өскә сикерер.

Дамир башын чайкый:

— Ну, ахысы синең эш. Ярый, пока!

Больница капкасы янында аңа кичәге сестра кыз очрый. Йөзе борчулы.

— Сез Зиләне күрмәдегезме? — ди сестра. — Ул бит больницадан качкан.

Дамир җавап бирми, буага таба китеп бара. Яр башыннан аска карау белән, ул Зиләне күреп ала. Зиләнең өстендә су кергәндә киелә торган трусиктан башка берни юк. Художникның күзе Зиләнең тәз, зифа буй-сынына игътибар итә. Кыз әле суга керергә ашыкмый. Дамир яр кырыена утырып, кесәсеннән блокноты белән каләмен чыгара. Ул берничә төгәл штрихлар белән Зиләнең гәүдә торышында ук сизелеп торган әчке кичерешләрен күрсәтергә тырыша. Ничек кирәк алай салынып ташланган киемнәренең бөтенләй кирәксез нәрсәләр кебек ятуына игътибар итә. Дамир боларны да каләмгә эләктерә. Судагы, агачлардагы, яр буендагы төсләр чагыштырмасын хәтерендә калдырырга тырыша.

Зилә бер аягын суга тыгып ала. Су суык. Көзнең соңгы айлары. Озакламый кыш. Зилә суга кереп барышлый чак кына кычкырып куя. Дамир яр башында утырган килеш, Зилә белән саубуллашкандай, моңсу гына елмая. Зилә, малайларча колач җәеп, буаның уртасына йөзеп китә. Дамир аңа соңгы моментка кадәр комачауламаска уйлый. «Әгәр яшәргә теле икән, Зилә үзе шул фикергә килсен», — дип уйлый ул.

Зилә суга чалкан ята. Кулларын хәрәкәтләндерми башлый һәм акрын гына су астына төшеп китә. Дамирның йөрәге тибүдән туктагандай була. Су өстенә һава куыклары чыга. Дамир бу киеренкелеккә түзә алмый, сикереп торып, тиз-тиз генә костюмын һәм ботинкаларын салып ата. Шул чак су өстендә Зиләнең башы күренә. Зилә күзенә төшкән чәчләрен артка сыпыра һәм акрын гына көлеп куя. Яңа туган

бала үзенең яшәячәген, яшәргә сәләтле булуын бугаз киереп елап хәбәр итә. Зиләнең бу күңелендә дә шуңа охшаш бер нәрсә бар кебек тоя Дамир. Моның гади күңел булмавын, яшәү авазы икәнен аңлый. Зилә су буен яңгыратып кыйкыра, шатланып йөзә. Аның тәртипсез хәрәкәтләреннән су чәчри. Дулкын түгәрәкләре бер-берсен куыша-куыша, ярга таба йөгерәләр. Дамир ике бармагын авызына кабып, сызгырып җибәрә. Зилә аңа борылып карый: ак күлмәктән, кара чалбардан булганга, Дамирны танымый тора. Таныгач, аңа кулын изәп:

— Хэлло! Әйдә, су керәбез, — дип кычкыра.

— Катып үләргәме? — ди Дамир яр башыннан.

— Һа! Куркак!

— Минме куркак?!

Дамир күлмәген сала-сала ярдан төшеп китә. Чишенеп беткәч, чирканчык алып тормастан, суга сикерә. Салкынга түзә алмыйча, бая Зилә кычкырган кебек, чак кына кычкырып куя һәм эчкә йөзеп кереп китә. Алар бер-берсен куышып йөзә башлыйлар. Судан чыккач Дамир тәненең җиңеләеп китүен тоя. Алар сәбәпсез-нисез күлешә-күлешә киенәләр.

— Дамир, син бит бүген Казанга китәм дигән идең?

— Синең белән саубуллашырга дип больницага килдем. Беләсеңме, анда сине дөнья бетереп эзләп йөриләр.

— Эзләсеннәр. Ә син бөтенесен күреп тордыңмы?

— Әйе. Мин килгәндә әле син суга кермәгән идең.

Алар яр башына меңәләр.

— Дамир, сиңа китәргә вакыт җиткәндер ич?

Дамир сәгатенә карый.

— Минем самолет инде, — ди ул һәм, кулы белән болытларга ишарәләп, озын итеп бер сызгырып куя. — Хәерле булсын, иртәгә китәрмен.

Дамир кесәсеннән билет чыгара. Сизелер-сизелмәс кенә искән кичке җил кәгазь кисәген җиргә очырып төшерә.

— Ә син кемлеккә укырга барасың?

— Сорап торасың! Әлбәттә, художниклыкка. Я, хәзер ни эшлибез?

— Минем шәһәргә кайтасым килми, я милициягә алып китәрләр. Әйдә, урманда йөрибез.

— Әйдә.

Алар янәшә атлап урманга кереп китәләр. Күтмәгәндә очрашудан туган шау-шулы шатлык басыла төшә.

— Дамир, — дип эндәшә Зилә, акрын гына, — ә мин Исфатны онытырга булдым. Ул барыбер мине беркайчан да ярата алмаячак. Әгәр ул миңа игътибар итә башласа да, мин аның яратудан түгел, бәлки кызганудан, я башка нәрсә аркасында гына булачагын аңлыйм. Мин аны онытачакмын.

— Юк, — дип бүлдерә аны Дамир. — Син аны беркайчан да оныта алмаячаксың. Гомерең буена син аны эзләячәксең. Синең бәхетсезлегең дә шунда. Юк, бәхетсезлегең түгел, икенче сүз кирәк монда... Ә андый сүз юк, ахрысы. Бәлки сине башка бер егет яратыр, син аңа кияүгә чыгарсың һәм ул егетне чыннан да бәхетсез итәрсең. Чөнки аны иркәләгәндә, син барыбер Исфат турында уйлаячаксың.

Зилә моңа түзә алмый. Үпкәләренә күп итеп һава алып, бер сулу белән:

— Син коточкыч кеше, Дамир! — дип әйтеп сала. — Ә син каян беләсең?

Дамир аның бу соравыннан шаярту белән котылырга теләп:

— Мин тумыштан фантазер. Киләчәкне әйтеп бирергә дисәң, мин теләсә нинди чегәнне шаккатыра алам, — ди.

Ләкин соңгы сүзләрен әйткәндә инде аның йөзендәге елмаюның эзе дә калмый. Бераз дәшми барганнан соң, ул Зиләгә таныш булмаган эчке тавыш белән:

— Боларның бөтенесен үз башымнан кичердем мин, Зилә,— ди.

Зилә беренче мәртәбә башка кешеләрнең дә үзе кебек газаплана алулары турында уйлап куя һәм беренче мәртәбә Дамир турында: «Кем ул?» — дип уйлый.

— Дамир, син моңарчы беркайда да укымадыңмы? Сиңа бит инде егерме дүрт яшьләр бар.

— Укыдым. Мәскәү университетының электронный техника факультетында өч ел укыдым. Миннән яхшы гына галим чыккан булыр иде бәлки, ләкин мин аннан киттем.

— Нигә?!

— Шулай. Ул эшкә күңел тартмады. Аннары, анда укыганда да мин гел рәсем ясый идем.

Кинәт Дамир баруыннан туктап кала. Зиләнең кулыннан тотып, аны да туктата.

— Күрәсеңме? — ди Дамир, икенче кулын алга сузып. — Аланга утыртылган әнә шул кечкенә чыршылар җитәкләшеп баручы беренче класс укучыларына охшаганнар. Әйтерсең, яңгырдан качып, әнә теге каен артыннан, ашыга-ашыга, агачлар арасына кереп баралар.

— Чыннан да! — ди Зилә, ә үзе чыршыларга түгел, Дамирга карый. Дамирның әйләнә-тирәдәге күренешләрне үзенчә, җанландырып күрә белүенә соклана Зилә. Бу чыршыларны нигә мин алданрак күрмәдем икән, Дамир кебек, бер кулымны алга сузып, аларның җитәкләшеп баручы мәктәп балаларына охшаганлыкларын нигә мин әйтмәдем икән! — дип уйлый Зилә.

Караңгы төшә. Алар тар урман сукмагын югалталар. Хәер, сукмакның кирәге дә юк. Җир өстеннән шулай янәшә бару икесенә дә ошый.

—◆—

*Сибгат Хәким*

# ТУКАЙЛАРНЫ ЭЗЛИМ

Чишмәләр төрле җирләрдән: авыл янындагы тау асларыннан, таллыклардан, авылдан еракта печән үскән болыннарда, елга читләреннән ургылалар... Авылда элек чишмәләрне карап йөрүче картлар була иде. Алар таякларына таянып, кайчандыр көтүчеләр, печән чабучылар ятып су эчкән чишмәләрне эзлиләр, тыгылган булсалар, таяклары белән чистарталар, юлны ачып җибәрәләр: чишмәләр ургылудан туктамасын, томаланмасын...

Яшь язучылар иҗаты да шул чишмәләр шикелле, алар да билгеле бер вакыт узган саен барлап, тикшереп торуга мохтаҗ.

Һәр әдәбият үзенең киләчәге турында кайгырта, өлкән буын белән яшь буын арасында җеп өзелмәсен, яшьләр алдынгы традицияләрне дәвам иттерсен, үстерсен. Яшь язучыларның семинарларыннан төп максат — әнә шул.

Соңгы елларда мин күп семинарларда катнаштым. РСФСР Язучылар союзы комсомол Үзәк Комитеты белән бергәләп Читада, Кемеровода һәм 1967 елның маенда Идел буе өлкәләрендә яшәүче яшь язучыларның семинарларын үткәрде.

Рус әдәбияты — көчле, зур әдәбият. Аңа инде бер караганда артык борчылмаска да мөмкин кебек. Юк, әдәбиятның киләчәге өчен ул да борчыла, ул да туктаусыз яшь талантларын эзли, һәр семинардан Пушкиннарны, Лермонтовларны, Блокларны эзли... Ә безгә? Безгә тагын да ныграк эзләргә кирәктер, бәлки?

Мин 1967 ел ахырында Татарстан Язучылар союзы тарафыннан уздырылган семинар уңае белән туган фикерләремне әйтергә уйлыйм. Әдәбиятка кемнәр килә, нәрсә белән килә һәм ничегрәк килә? Барысын да исәплим, чамалыйм, чагыштырып карыйм. Үзебезнең рамкадан гына түгел, бөтенсоюз әдәбияты киңлегеннән торып чагыштырып карыйм. Хәзер бер нәрсә ачык: моннан утыз еллар элек милли әдәбиятларда күзгә ташланган зур аерма инде бетте дисәң дә була. Читадагы семинарда катнашкан рус шагыйренә нинди таләп куелса, Казан семинарындагы татар яшьләренә дә шул ук таләп, бернинди ташлама ясалмый. Дөресрәге, алар хәзер ташлама ясаганны яратмыйлар. Хәзерлекле, эстетик карашлары, иҗат принциплары шактый нык булган югары белемле яшьләр килә.

Яшь шагыйрьләрнең поэзиягә карашларын, әдәби дөньяларын белү өчен үзләренә сүз бирик, үзләрен тыңлап карыйк.

Рәдиф Гатауллин: «...Язам да, укыйм да. Мине дөнья әдәбияты кызыксындыра.

Табына торган аллам — Тукай булса, пәйгамбәрләрем күп: Пушкин, Гейне, Маяковский, Лорка, Такташ...

Мине туктаусыз эзләнүче, дөньяга гашыйк яшь кеше образы мавыктыра».

Рим Идиятуллин: «...Майлы ботка кебек туйдырган калыпларны, яшен яшәгән кануннарны шәхес булып күздән кичерәсе, форма һәм эчтәлек бердәмлеге диган төшенчәнең биек түбәсен күрәсе, үз мәккәңне табасы, кешеләрне фәкать ачы дөреслек һәм буяусыз матурлык алласына табындырасы иде...

Туган телемне, Тукаемны, Такташымны яратуым мине Казанга тартты. Мәхәббәтле Казан! Мәрхәмәтле бул!»

Харрас Әюпов: «Уйландырырлык итеп язасы, шигырьләрдә матуррак итеп, гадирәк итеп, тормышның үзеннән сөйләттерәсе иде».

Мин дә үзебезнең һәр семинардан Тукайларны, Такташларны эзлим. Хәзергә әле алар күренмиләр. Әмма әдәбият мәйданына бәреп чыгарга торучылар күп һәм өметлеләр. Равил Фәйзуллин теле белән әйтсәк:

Төрле көчтә,
Төрле эштә,
Төрле тында,
Төрле тонда,
Төрле тәмдә,
Төрле ямьдә
Шигырьләр дә!

Яшьләр иҗатларында зур бер сикереш ясадылар. Элеккерәк елларга хас булган озынлыктан — кыскалыкка, конкретлыкка, натуралистик тасвирлаудан — хис-фикер, уйлануларга таба сикереш ясадылар. Бу хәзер күпчелек шагыйрьләр өчен хас сыйфат.

Төрле характерлар, төрле биографияләр...

Килүчеләр арасында укучыларга инде шактый билгеле булган Фәнис Яруллин, Дифгать Сирай, Камил Мостафин, Салисә Гәрәева, Раил Шакиров, Шамил Маннапов, Зәһирә Гомәрова, Хәниф Хөснуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.

Язгы күкрәү — үз күкрәвем минем,
Үз күкрәгем аны сыйдыра...

Рәшит Әхмәтҗановның бу юллары аларның бөтен омтылышын, иҗатларының юнәлешен билгели.

Шагыйрьнең биографиясе — ул аның үткән юлы, тормышы, көрәше... Биографиясе никадәр зур булса, перспективасы да зуррак. Шагыйрь шул биографиягә таяна. Ренат Рәхимов Казан авыл хуҗалыгы институтын бетергән, ул алтынчы ел инде Питрәч районының «Алга» колхозы председателе булып эшли. Ул хәзер өченче китабын чыгарды. Язганнары тормышның үзеннән, реалистик шигырьләр, сине алар җиргә кайтара, җир кешеләренә якынайта, барысын да якыннан тоясың...

Айдар Хәлимов Ренат Рәхимовның капма-каршысы кебек. Биографиясе ягыннан түгел, Хәлимов та авылны әйбәт белә. Техник училище бетергән, Калмык далаларында нефть эзләүдә катнашкан, Совет Армиясендә хезмәт иткән. Аның да биографиясе шактый бай. Ул язу характеры белән аерыла. Аның шигырьләре давыллы, өермәле, вулкан дияр идем.

Вулкан идем.
Күкрәгемнән чыккан кайнар лава белән
Байтак кына хаталар да күккә чөйдем.

Кайвакыт бар да бергә бутала, шигъри юллар, детальләр, образлар сүз өермәсе эчендә югала. Бәлки, бу вакытлы хәлдер, үтәр!

Беренче чиратта — кеше, тормышның үзе, тормышның фәлсәфәсенә керергә тырышу — Рөстәм Мингалимов белән Ренат Харисов шигырьләре белән бигрәк тә характерлы. Кайбер катлаулы шигырьләрнең нигезендә шушы нәрсә ятмый микән? Фикер бар, осталык, тәҗрибә җитми.

Алар икесе дә бер тирәдәрәк эзләнәләр. Аларда уртаклык күп. Үзең яшәгән дөньяга мөнәсәбәтеңне бары үзеңчә белдер, шәхес буларак шигырьдә үзеңне тап, һичкемне кабатлама. Бу гомумән һәр талантлы шагыйрьнең иҗаттагы критериясе дип уйлыйм мин.

Шигырь — юлларның көтелмәгәнчә борылышы, фикернең көтелмәгәнчә яңгырашы белән шигырь.

...Барам,
җир,
әйләнеп,
эзләремне чорный үзенә
фотопленка сыман.

Мингалимовта мондый юллар күп, образлар анда яңа, кул тимәгән. Әгәр шагыйрьнең шигырь өстендә шушы газаплы эзләнүе бетә икән, ул бүтәннәрне механик рәвештә кабатлап баручыга әйләнә. Ләкин эзләнү авырлаштыру юлы белән бармаска тиеш. Кайбер шигырьләрендә хисне прозаизм басып китә...

Шагыйрьлек нечкә эш.

Дәрдмәнд урынсызга кыерсытылган, урынсызга кагылып кигенгән шагыйрь. Яшь буын аны аз белә. Ул инде тәмам онытылды дип уйлыйсың. Юк икән, онытылып бетмәгән икән. Ул менә башка заманда яшәгән яшь шагыйрьнең яңарган авазы формасында ишетелә башлый. Ренат Харисов шигырьләрен мин шулай кабул иттем. Яңарган авазлар!

Уянды ил —
Кузгалды җил...
Куанды ил —

Һәр күз чәчәк булды...
Тик чәчәккә
Тамчы-тамчы тозлы чык кунды.

Яки менә:

Аңымны юа да мана,
Юа да мана
Замана.
Иске төсләр кушыла бара,
Кушыла бара
Яңага...

Кайдадыр артта Дәрдмәнд басып тора. «Сыгылдырып күл камышын дулкын кага...», «Болыт үтте...» кебек шигырьләрнең алынып киткән юллары күп нәрсәне искә төшерә.

«Татар кызы бии»:

Катлы-катлы итәкләрен
Чеметеп чак-чак,
Ак камырдан кискән кебек
Вак-вак чәкчәк,
Күз карашын тып-тын гына
Аяк кисә,
Кызган майдай
Чыжлый читек
Җиргә тисә...

Шатланып кабул иттем. Чөнки Дәрдмәнднең шигырь техникасын, шигырь формаларын эзләнүче яшь шагыйрь берничек тә читләтеп үтә алмый. Ул шигырьләр канатлы сүз, әйтем, мәкальләрдән торалар. Дәрдмәнднең шигырь диңгезендә илле ел буена батмый йөзгән «Көраб»ын без ерактан таныйбыз. Ренат Харисов үз куллары белән үз «көраб»ларын төзәр, аларны үз юлына чыгарыр.

Бер шагыйрьне икенче шагыйрьдән аерган нәрсә — ул шигырь юлларындагы заман сулышы. Ул сулыш һәр шигырьдә үзенчә тибә, аны бары тоярга гына мөмкин.

Кайбер шагыйрьләр шигырь дөньясына ничектер аларга алдан ук әйтеп куелган шикелле бик табигый юл белән килеп керәләр. Гәрәй Рәхим белән Фаил Шәфигуллинны мин шундыйлардан дияр идем. Аларның шигырьләрен укыгач, шигырьнең формасы турында берәүнең дә күңелендә шик тумый, алар органик, бәхәссез. Шулай булырга тиеш, фәкать шулай гына булырга тиеш, дисең эчеңнән...

Бу буыннан миңа кызык шагыйрьләр чыгар кебек тоела. Мостай Кәримнең беренче шигырьләрен хәтерләткән Тәүфикъ Камалиев, кыска, җылы шигырьләре белән Рифгать Закиров, Заһир Сәмигуллин, Хәйдәр Гатин, Вәсимә Хәйруллина, Фирая Шиһаповалар әле яңа ачылып баралар, тормышның шау-шуы эченнән аларның да үз тавышлары яңгырап куя.

Зөлфәт — поэзиядә бөтенләй яңа исем.

Күз нурларым күкне уяр күк,
Йөрәгемә җирем сыяр күк,
Үз үземне кайчак аңламыйм —
Әллә кеше, әллә алла мин.

Бераз сәер кебек. Заманында Сәгыйть Рәмиев шигырьләре дә сәер яңгырагандыр. Зөлфәтнең башка шигырьләре дә шушындый дәртле, көчле рухлы. Мин аның поэзиядә шул рухны саклавын телим.

Шушы уйланулардан соң бер сорау туа. Яшь шагыйрьнең белеме дә бар, шигырьнең техникасын да белә, шигырьләре басыла, китаплары чыга. Шагыйрь булу өчен шулар җитмимени? Кем ул шагыйрь, кайчан, кайда башлана?

Мин шагыйрьне халык язмышы эченнән эзләргә өйрәнгәнмен. Миндә шагыйрь һәрвакыт чор белән бергә кушылып яңгырады, чор белән бергә алга басты. Такташ дисәм, минем колакта «Алсу» тавышы чыңларга керешә, «Гасырлар һәм минутлар»дан бөек Ленин образы калка, «Киләчәккә хатлар» язып утыручы шагыйрьнең үзен күрәм. Җәлил миндә — үзе бер чор, Туфан — үзе бер чор. Кыскасы, шагыйрьне мин үз чорының давыллары уртасында барган зур шәхес итеп таныдым. Минем карашта ул көрәшче сыйфатында формалашты. Мин кайчакта халыкның көндәлек тормышыннан, көрәшеннән читтә үзенә шагыйрьлек исеме дәгъва иткән кешеләрнең бәхәсләрен тыңлап, күңелемдә шигем көчәя башлый, куркып калам. Шагыйрь — халык улы, шагыйрь — көрәшче. Татар поэзиясенең бөтен традициясе шушы хакта сөйли. Хәзерге яшь шагыйрьләр шул халыкчан традициягә таянып күтәрелерләр.

—◆—

# *Дуслар җыры*

## ПАВЛО ТЫЧИНА



*Украинаның классик шагыйре, академик, Шевченко премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Павло Григорьевич Тычина 1891 елның 27 январенда Чернигов өлкәсе Новобасанский районы Пески авылында туган. Ул бик яшьтән үк шигырьләр яза башлаган һәм үзен сәләтле шагыйрь итеп танытkан.*

*Семинариядә укыган елларында беренче шигырьләрен күренекле украин язучысы М. М. Коцюбинскийга укый, аның алдынгы яшьләр өчен төзегән «Шимбә» түгәрәгенә йөри. М. М. Коцюбинский аның шигырьләрен Максим Горькийга күрсәтә. Италиянең Капри утравында дәваланучы М. Горький Тычинада зур талант барлыгын күрә һәм аңа чын күңелдән уңыш теләп хат яза.*

*Бөек Ватан сугышы елларында Павло Тычина Уфада яшәде, татар һәм башкорт халкының классик шагыйре Мәҗит Гафури турында фәнни хезмәт язды. Бу хезмәт украин, рус һәм башкорт телләрендә басылып чыкты. Халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукай шигырьләрен ул украин теленә тәрҗемә итте, «Сайланма әсәрләр»ен редакцияләде һәм шагыйрь турында мәкаләләр язып бастырды.*

*Советлар Союзы Герое Муса Җәлил белән Павло Григорьевич Тычина якын дус була, Муса аңа үзенең шигырьләрен татар телендә укып күрсәтә. Украина һәм татар әдәбиятларының бу ике вәкиле 1939 елда Киевта Т. Г. Шевченконың 125 еллык юбилей пленумында очрашалар, әдәбият һәм сәнгать турында, иҗат планнары турында сөйләшәләр. Бу чын дусларча очрашу Муса Җәлилнең күңелендә тирән урнашып кала. Ул фашизм тырнагында, Моабит төрмәсендә гомеренең соңгы сәгатьләре якынлашкан вакытта да Павло Тычинаны искә ала, аңа үзенең соңгы сәламен җибәрә. Павло Тычина Мусаның бу сәламен гомерем буена онытачак түгелмен, дигән иде. Ул өлкән яшьтә һәм авыру булуына карамастан, М. Җәлилнең шигырьләрен украин теленә тәрҗемә итте, аның турында мәкаләләр язды, докладлар ясады. Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеенда Киевта комиссия председателе булды һәм Муса турында зур чыгыш ясады.*

*Бу күренекле украин шагыйре 1967 елда Киев шәһәрендә вафат булды.*

*Украинаның классик шагыйре «Муса Җәлил Киевта» дигән шигырен «Литературна Украина» газетасында бастырды. Түбәндә шул шигырьнең татарча тәрҗемәсе бирелә.*

### Муса Җәлил Киевта

**Зал шыгрым тулы**
**кешеләр белән,**
**Анда Шевченко**
**пленумы бара.**
**Яшел пыяла**
**түбәдән кояш**
**Сокланып карый**
**нәкъ безгә таба.**

Залда яңгырый
докладчы тавышы,
Барчабыз тыңлый.
Чырайлар җитди!
«Алексей Толстойдан
соң мин чыгачак.» —
Бу уй шул чакта
Башымнан үтте.

Толстойны тыңлыйм.
Ә күзләр эзли:
Җәлил кайда соң!
Без бит таныштык.
Татарча шигырь
укыды ул миңа,
«Безнең тел белән
Сез бит таныш», дип,

Толстой сөйли:
— Шевченколарга,
Рылеевларга
Бик авыр иде.
Алар җырлаган
хикмәтле сүзләр
Хетагуровка,
Тукайга рух бирде!

Мусага карыйм.
Күзләре нинди!
— Безгә омтылган
дошманга үлем!
Бу сүзләрдән зал
аякка басты.
Муса күзендә очкыннар күрдем.

Шаулашып залга
пионерлар керде,
Әйттеләр безнең
гел уртак уйны.
... Стенадагы Ленин рәсеме
Гүя шул чакта
елмаеп куйды.

САМАТ ШАКИР тәрҗемәсе.

—-◆——

# КЫРЫМ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

*Кырым татарлары хәзер Урта Азия республикаларында, бигрәк тә Үзбәкстанда яшиләр. Аларның үз язучылары, үз композиторлары, җырчылары бар. Ташкентта «Ленин Байрагы» дигән зур форматлы газета чыгаралар, шулай ук ел саен Үзбәкстан матур әдәбият нәшриятында Кырым татарлары телендә китаплар чыгып тора. Үзбәкстан Язучылар союзында татар язучылары секциясе эшли. Өлкән буын язучылар, атап әйткәндә Эшреф Шемьи-Задә, Шамиль Алядин, Йосыф Булат, Решид Мурад, Раим Тынчеров, Амет Мефаевлар, белән берраттән Черкез-Али, Эскәндәр Фазыл кебек талантлы яшьләрне күрсәтергә мөмкин.*

*Безнең укучыларга Ленинградта яшәүче Кырым татар шагыйре Риза Халид иҗаты инде яхшы таныш: журналыбызда аның күп кенә шигырьләре басылды. Татарстан китап нәшриятында аерым китабы да чыкты.*

*Кырым татарларына да безнең язучылар иҗаты яхшы таныш. Алар Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Зәки Нури, Рөстәм Кутуйларны һәм башка язучыларыбызны яхшы беләләр. «Ленин Байрагы» газетасы даими рәвештә Татарстан язучыларының әсәрләрен бастырып тора. Бу — ике кардәш халыкның иҗади бәйләнешенә бик әйбәт дәлил.*

*Журналыбызның бу санында берничә Кырым татар шагыйрә иҗатын укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

*Решид Мурад*

## Яулар кичтем

Яулар кичтем,
Авыр булды барыр юллар,
Үлем белән якалаштым соңгы чиктә,
Ләкин, Зөһрә, һичбер вакыт уйламадым.
Кайчан да бер төшәрмен дип әсирлеккә.

Арсландай ир булса да,
Кыз алдында
Баш ия, дип әйтмәгәннәр аны тиккә.
Килешүе кыен безгә бу сүз белән,
Ләкин үзем төштем сиңа әсирлеккә.

Хәзер мене мәхәббәткә тоткын булып,
Романтика күкләреннән иңәм җиргә,
Мин тормышның кыш кеннәрен үземә алып,
Тик язларын сиңа бирәм,
сиңа, Зөһрә.

## Йолдыз

Бала чакта әнием миңа әйтә иде:
«Һәр кешенең үз йолдызы балкый күктә,
Йолдыз сүнсә, бәхете дә бергә сүнеп,
Кеше мәңге газап чигеп тормыш көтә...»

Уйлый идем: «Ә нигә соң ул байларның
Йолдызлары бер генә дә сүнми икән,
Җир йөзендә яшәп килгән бар бәлаләр
Тик фәкыйрьләр иңнәренә йөкләтелгән?»

Бу сорауга мин бары тик җавап таптым
«Аврора»ның залплары балкышыннан,
Көрәшчеләр тоткан байрак нурларыннан
Җир яктырды, ирек таңы атты шунда.

Золымнардан сүнми торган гаҗәп йолдыз
Кабыздык без азат илнең күкрәгендә,
Миллионнарның бәхете өчен тик бер йолдыз
Нурлар чәчә чал Кремль күкләрендә.

## Композитор

Яшь музыкант бер җыр язып утырганда,
Бомба төшеп күрше йортны тар-мар итте,
Ә таң иртән композитор
теплушкада
Җырны үзе белән алып яуга китте.
Окопларда уйнады ул бу «яз җырын»,
Моңнар сызып скрипка кылларында,
Тыңладылар яшь солдатлар махра тартып,
Автоматны тоткан килеш кулларында.
Горурланып әйтте егет солдатларга:
«Бу сүзләрне язган, — диеп, — татар кызы!»
Җыр атлады гвардия сафларында,
Композитор күп сугышлар кичте үзе.
Тик Будапешт юлларында музыкантның
Шат йөрәге тибүеннән кинәт тынды,
Сугышчылар кая гына бармасыннар,
Аның җыры йөрәкләрдә яңгырап торды.

Еллар, еллар, агым судай сез үтәсез,
Я, әйтегез, нәрсә кала җирдә мәңге?
Җырлар кала ил күңелендә тамыр җәеп,
Һәм йөрәкләр яңгырата шул аһәңне.

Мостафа НОГМАН тәрҗемәләре.

*Риза Халид*

## Татарстан шагыйрьләренә

Иң биек тауның да түбәсе күренә,
Хәтта киң диңгезнең чиге бар, мин беләм.
Җил бул, ис,
Хыялым, дусларым иленә,
Иңенә так та син пар канат, я җилкән.

Сезнең шат күзләрдә кояшның нурларын,
Тукайның ялкынлы утларын мин күрәм.
Давыллы диңгезгә әйләнсен җир шары,
Анда да мин сезне чыгармам күңелемнән.

Әгәр дә дусларны бер зәррә онытсам,
Ялкынлы сүзләр дә йөрәкне якмасын.
Мин сезне сөюем чәчәген корытсам —
Бозлансын, Неваның сулары акмасын.

Чәчәкләр бәйләмен алыгыз сез миннән,
— Егетсең! — димәгез ялкыным янмаса.
Мин сезне беркайчан чыгармам исемнән,
Тәнемдә бер генә тамчы кан калса да.

Әй дустым, кичер син; әйләнде бу башым,
Буш сүзләр кирәкме көрешкән чагында?
Мин сине чүлдәге чишмәгә охшаттым,
Ачылдым йөрәктән, җыр тездем мин монда.

Җитсен бу җырымның һәр юлы, һәр сүзе,
Тез чүксен, хөрмәтләп утырсын янында.
Әйләнсен көтелгән өметкә ул үзе,
Я йомшак җил булып иссен ул җанында.

Мин риза, мин бик шат, мөкатдәс бу җиргә
Баш иеп, «син миңа чын туган» диярга.
Әй дустым, бак миңа син ачык күңелдән,
Ышан син, йөрәгем теләми сүнәргә.

Калырга чарам да юк монда, мин беләм,
Юатып булса да ышандыр тик юлдаш.
Әгәр дә җиһандай картка син яшь дисәң
Йөрәге яшәрер һәм җаны авыртмас.

Мин дә бит нәкъ шулай, йөрәктә чишмәләр,
Чәчкә чал керсә дә, күңелем җырдай яшь...
Күрәм мин: шатлана урманнар һәм чүлләр,
Шуңа ул — сез миңа булдыгыз чын иптәш!

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе.

# Күк миләүшә кебек

Хыялланмадым мин мәхәббәт дип,
Теләмәдем аның килүен:
Уйламадым,
мине кабындырып,
Күңелемә үтеп керүен.

Әмма сөю миңа кинәт килде.
Ачып керде йөрәк ишеген;
Алсу бер гөл булып күзгә бакты,
Күпме рәхәт, михнәт кичердем!

Шулай килде гыйшкым...
Күк күкрәтеп,
Җир тетрәтеп,
охшап киеккә!
— Йөзик бергә, — дидем сөюемә:
Горур да ул,
саф та,
бөек тә!

Шулай килде гыйшкым...
Очам, очам!
Әй йолдызлар, сезгә ашыгам!..
«Ярат безне, өз син!» — дип сиреньнәр,
Гүя сыйпый мине башымнан.

Һәр очраган кулым кыса кебек,
Котлау ява сыман кошлардан...
Сөеклемнең күзе — күк миләүшә,
Иреннәре таңга охшаган.

Нәрсә булды,
белмим,
сорама, дус.
Саф мәхәббәт,
кайнар нурын бәркеп,
Яшен булып үтте йөрәктән,
Давыл булып язгы кырдан узды,
Күкрәгемне ачты кинәттән.

●

Еллар — тормыш китабының бите.
Ул китапны укыйм ашкынып;
Эзем калсын аның битендә, дим,
Юсын аны хисем ташкыны.

Мең сукмакның йотсаң тузаннарын,
Мең китапның тотсаң киңәшен,
Ак калфаклы таулар түбәсенә,
Беләм, дустым, кыю менәрсең.

Диңгезне сөйгәндәй җырларны сөям мин.
Аларда
кояш бар,
давыл бар,
дала бар.
Ялга дип ямьле яр буена килсәм мин,
Йөрәктән дәрт тулы чишмәләр агалар.

Яратам тормышның үзеннән артык мин
Иркәмнең күзләрен — юк алар бүтәндә!
Шул уйчан, акыллы күзләрдә күрәм мин
Диңгезне, җырларны яр буйлап үткәндә.

МӘХМҮТ ХӨСӘЕН тәрҗемәләре.

*Рәмзи Бурнаш*

## Туганнар кабере

Калка күккә мәрмәр ташы
Чыршылар арасыннан,
Гүя изге сакка басып,
Яшь солдат торган сыман.

Көндез аны кояш үбә,
Ә төннәрен — тулган ай.
Юлчы туктап, сыйпап үтә,
Үз улын сыйпагандай.

Мәңге шулай горур калкып,
Торыр басып ул шунда.
Йоклый чөнки кырык батыр
Бу изге таш астында.

●

Ышанмыйм, бәхетле чакта:
— Мин чын дустың, — дигәнгә.
Чын дуслык белене башка
Бәла-каза килгәндә.

Дустым, дим, авыр заманда
Җитәкләсә кулымнан,
Тартып алса, тайпылганда,
Мине хәтәр юлымнан.

## Кояш белән Җил

*(Халык мәсәле)*

Бер заманны Кояш белән Җил очрашып,
Сүз биргәннәр карарга бер көч сынашып.
— Икебезнең, ягъни, кайсы көчле икән? —
Диеп болар шундук юлга чыгып киткән.

Барган чакта тирә-якка карап алар
Шәл ябынган бер хатынга очраганнар.
— Шуның шәлен, — дип куйган Җил, — кем салдырыр,
Арабызда, шөбһәсез, шул көчле булыр!
Шулай дип, Җил тотынган бик нык өрергә.
Хатын, туңып, шәленә ныграк төренгән.
Өрә-өрә Җил туктаган хәлдән таеп,
Хатынга караган Кояш бер елмаеп
Һәм кызганмый җылы нурын аңа сипкән.
Хатын, шәлен кулга алып, алга киткән.
Кояш әйткән шул вакытта: — Күрдеңме, Җил,
Суык түгел, җылы белән бәхетле ил!

*Амет Мефаев*

## Минем теләк

Дуслар миңа шундый сорау бирсәләр:
— Ни телисең Яңа елда? — дисәләр,
Дияр идем:
— Талаш-гауга булмасын!
Дияр идем:
— Сугыш уты янмасын!
Дияр идем:
— Сабый кайгы белмәсен!
Дияр идем:
— Анабыз — җир елмайсын!
Дияр идем: — Эшләр уңсын бар җирдә,
Муллык булсын, бәхет тулсын бар җирдә!

Дуслар белән чәкәшкәндә касәләр:
— Ни телисең Яңа елда? — дисәләр,
Дияр идем:
— Уен-көлке күп булсын!
Дияр идем:
— Кара көннәр юк булсын!
Дияр идем:
— Җир төренсен гөлләргә!
Дияр идем:
— Тик җыр булсын телләрдә!
Дуслар дуска сәлам бирсен һәрвакыт,
Таң елмайсын, кояш көлсен һәрвакыт!

## Сөям

Сөям
көн баткан чагында диңгез карарга,
Уйнаганда шаян дулкын, бәрелеп ярларга.

Сөям
диңгез күкрәгендә аксыл җилкәннәрнең
Ерактан акчарлаклардай үтеп киткәннәрен.

Сөям
кояшның кызарып офыкка батуын,
Киң диңгезнең, тыныч сулап, йокыга талуын.

Сөям
калкып көмеш айның диңгезне нурлавын,
Гүзәлемнең көймәсендә утырып җырлавын.

Сөям
диңгезнең ярсулы, кодрәтле күкрәген,
Дулкыннарның берсен-берсе куышып
күкрәвен.

*Черкез - Али*

●

Хезмәттер адәмгә чын бәхет биргән.
Гүзәлгә хезмәт тик гүзәллек кушар.
Дөньяда хезмәттән тәм таба белгән
Кешенең кышы да язларга охшар.

Күзләрең нур алса әгәр хезмәттән,
Көзең дә, яз кебек, гөлләрен ачар.
Күңелең саф булыр иң саф чишмәдән,
Гүзәллек гомергә янында яшәр.

●

Күзең кебек күзләр күп,
Сүзең кебек сүзләр күп.
Сөйдем, дисәм, йөзеңне,
Йөзең кебек йөзләр күп.
Нигә шулай сулдым соң?
Нигә гашыйк булдым соң?
Синең якты йөзгәме?
Синең татлы сүзгәме?
Тыңла, гүзәл, сүзем хак:
Синдә нидер тойдым мин.
Түгел кашың, күзеңне,
Түгел татлы сүзеңне,
Бәллүр кебек саф һәм пакь
Күңелеңне сөйдем мин!

●

Тәрәзәмне бүген бакча ягыннан
Кинәт исеп киткән җиләс җил ачты.
Җыр тавышы очып керде дә шуннан,
Күңелгә моң салды да йокым качты.

Таң атты дип, йөгереп чыктым мин өйдән,
Күрдем шунда синең җырлап килгәнне.
Таң булмаган, җаным сөйгән яр икән
Караңгыда яктыртучы булмамне.

ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәләре.

*Эскәндәр Фазыл*

## Ана

Мин туган кичәдә ни әйттең син миңа,
Йокысыз шул төндәниләр уйладың?
Хәләл сөт имезгән бердәнбер анам,
Киләчәк өчен син ниләр юрадың?

Син бағып үстердең, чыгардың ак юлга
Һәм бирдең улыңа очарга канат.
Күрсәткән юлыңнан атладым мин алга,
Кавыштым мин сиңа, мөкатдәс хәят.

Яшәү ул бик авыр, катлаулы сынаудыр.
Сынаулар аша мин максатка үтәм.
Бәхеткә бәхетләр өстәүче анадыр,
Шуңарга хөрмәтләп кулыңны үбәм...

## Миләүшә

Тар сукмак буйлатып бакчага
Бергәләп йөрдек без һәр таңда.
Ал яңак алмалар агачтан
Өзәйдем һәрвакыт мин аңа.

Кып-кызыл чәчәктән муенса
Үрәйдек бергәләп тагын без.
Үзәннәр, тугайлар буенда
Уздырдык балалык чагын без.

— Син нинди чәчәкне сөясең? —
Дип бер көн сорадым мин кыздан.
— Миләүшә яраткан чәчәгем, —
Диде дә тотты кыз кулымнан.

Бер бәйләм миләүшә китердем.
Сөйгәнем куанып алсын дип.
Миләүшә чәчәге шикелле
Гомергә хәтердә калсын дип.

Сөеклем исемә төшә дә
Сагышлар каплый шат йөземне,
Яшьлекнең җилләре искәндә
Хәтерлим миләүшә күзлемне.

Ел саен кайтам да, гел монда
Тар сукмак буйлатып мин йөрим.
Миләүшә очраса юлымда
Балалык дустымны хәтерлим.

## Ике күрешү

Хәятта төрлечә күрешү күп була,
Алардан һәртөрле тәэсирләр кала,
Берәүләр йөрәктән юшкыннарны юа,
Берәүләр калдыра мәңгелек яра...

Син киттең... Яшьләнгән күзләрем алдында
Сурәтең хатирә буларак калды.
Шигыремдә, җырымда һәм дәртле күңелемдә
Исемең иң җылы урынны алды.

Бик көттем. Кайтмадың. Югалттым эзеңне,
Көз үтте, кыш үтте, тагын яз килде.
Сагындым, сагындым мин таң йолдызымны:
Кайда син?! Башыңнан ни хәлләр кичте?

Хәятның йөгерек юлында без менә
Күрештек тагын да. Исләрем китте:
— Ни булды? Җан нуры калмаган йөзеңдә,
Әйт, нинди газапта яшьлегең үтте?

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

# ЯКЫН ДУСТЫБЫЗ, АКЫЛЛЫ КИҢӘШЧЕБЕЗ

«Социалистик Татарстан» газетасына илле ел тулды.

Октябрь революциясе коннәрендә туган большевистик газеталар, шул җөмләдән бүгенге «Социалистик Татарстан»ның элгәресе «Эш» газетасы да, хезмәт ияләрен яңа рухта тәрбияләүдә, яшь Совет дәүләтенең эчке һәм тышкы дошманнарына каршы, әеруча, искенең мирасы — наданлык һәм караңгылыкка каршы көрәшкә өндәүдә, нәкъ Ленин билгеләгәнчә, коллектив агитатор һәм коллектив пропагандист кына булмыйча, коллектив оештыручы булarak та партиянең иң көчле коралына әйләнделәр.

1918 елның 12 мартында татар телендә чыккан беренче совет газетасының исеме «Эш» була. Ул Казан губерна советы янындагы мөселман комиссариатының иҗтимагый-политик газетасы сыйфатында чыга. Бүген һәркайсыбыз көтеп алган, яратып укыган «Социалистик Татарстан», югарыда әйтеп узганыбызча, үзенең туу тарихын әнә шул «Эш» газетасыннан башлый. Менә илле ел инде ул ленинчыл матбугатның революцион һәм интернациональ традицияләрен дәвам иттереп, коммунизм төзү көрәшенең алгы сафларында бара.

«Эш» газетасы Казан большевикларының инициативасы белән оештырыла. Газета редколлегиясенә күренекле революционер — большевик Хәсән Урманов билгеләнә.

Газета үзенең беренче санында басылган «Эш» исемле баш мәкаләсендә барлык эшче, крестьян һәм солдат массаларын революция дошманнарына каршы, царизм һәм беренче империалистик сугыш тудырган ачлык, җимереклек, бөлгенлеккә каршы берләшкән көрәшкә өнди. Совет дәүләтенең иҗатчылык характеры турындагы Ленин фикерләрен чагылдырып, баш мәкаләдә болай диелә:

«...Безнең телләгебез эшче фәкыйрь крестьян хөкүмәтне саклап, халкыбыз эчендә тынычлык, тәртип кертү һәм яңа тормышка кирәкле нәрсәләрне тудыру булачак. Безнең планыбыз эш планы. Сүз дәвере үтте, иптәшләр, инде эш дәвере килде».

1920 елның июнендә, Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы оештырылгач, «Эш» газетасы «Татарстан хәбәрләре» дип исемләнә. 1920 елда, матбугат көнендә, газетаның 477 нче саны «Татарстан» исемендә чыга. 1924 елның маенда ул «Кызыл Татарстан» булып, 1951 елның 5 августында «Совет Татарстаны», э инде 1960 елның 27 сентябреннән бирле «Социалистик Татарстан» исеме белән чыгып килә.

Газетаның редакторы булып байтак вакытлар күренекле журналист Вәли Шәфигуллин эшли. Атаклы татар революционеры Мулланур Вахитов белән бергә эшләгән бу коммунист 1921 елның мартында РКП(б)ның X съездында катнаша һәм, партиянең Татарстан оешмасы делегатлары группасында, Владимир Ильич Ленин белән очраша. Бу очрашуда бөек юлбашчы татар әдәбияты һәм җирле матбугат белән дә кызыксына.

Газетаның редакторлары булып шулай ук күренекле татар шагыйре, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Фәтхи Бурнаш, ялкынлы публицист һәм театр тәнкыйтьчесе Мөхәммәт Парсин, партия эшчесе, журналист Салах Атнагулов, язучы һәм галим Фатих Сәйфи-Казанлы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәти, Сафа Дәүләтьяров, Ибраһим Үзбәков, Галим Рәбков һәм башкалар эшләделәр.

Газетаның даими эшендә, иң якыннан торып, мәшһүр әдип һәм галим Г. Ибраһимов катнаша. Галимҗан ага газетага яшьләрдән кадрлар әзерләүдә, газета эшенә олы буын язучыларны тартуда һәм үзе дә ялкынлы каләме белән чиксез зур ярдәм күрсәтә.

Көн саен, сәгать саен миллионнар белән иң тыгыз бәйләнештә торып, үз ана телендә сөйләшеп, киңәшеп, фикерләшеп торган шундый халыкчан газетаның илле еллык эшчәнлеген кыска бер мәкаләдә яктыртуны мөмкин булмаган бер эш дияр идем мин. Бу тарихчылар эше! Безнең тарихчыларыбыз бу эшне уңышлы гына башкаралар да инде. Матбугат битләрендә, радиотапшыруларда бу данлы юбилейга багышланган эчтәлекле мәкаләләр, истәлекләр шактый булды һәм алда да булыр, әлбәттә.

Ләкин кулга каләм алмый калу да мөмкин булмады. Бик күп истәлекле вакыйгалар, каядыр чал тарих сәхифәләрендә калган беренче хәбәр-мәкаләләребез, очерк-хикәяләребез, шигырь-поэмаларыбыз синең битләреңдә балкып тудылар бит, кадерле «Социалистик Татарстан!»

Шатлыгыбыз да, кайгыбыз да, дәртләнеп кабынуыбыз, илһамлануыбыз да синең битләреңдә булды бит, якын дустыбыз «Социалистик Татарстан»!

Менә өстәлемдә ялкынлы публицист, шагыйрь һәм солдат Гадел Кутуйның 1945 ел башында Берлин юлыннан «Кызыл Татарстан» редакциясенә язып җибәргән нәсеренең кульязмасы ята. «Берлин юлында очрашу» дип исемләнгән бу парчаның азагында ул елларда газетаның редакторлары булып эшләгән ике иптәшкә кечкенә хат та язылган. Менә ул:

«Үзбәков һәм Рәбки иптәшләр!

Ишетүем буенча, мин җибәргән материаллар сезгә барып җитә икән. «Кызыл Татарстан»нан күчереп бүтән газеталар да басалар икән. «Тетрә, Берлин» дигәнен бүген Ленинград фронты газетасында күрдем, радио аша тапшыруларын да ишеттем. Димәк, файдалы. Менә тагы бер мәкалә җибәрәм... Эшкә дәрт, дошманга нәфрәт туса, шул җитте... Монда яз туа, җиңү язы!»

Сугышчы шагыйрь үз газетасының тавышы ерак-еракларга, Ленинград фронтларына барып җитүен ишетеп шатлана, алга — җиңүгә дәртләнә, җиңү язын күреп илһамлана...

1952 елның көзендә Казанга кайткач, мин олкән журналист Нәкый Бәхтияров белән очраштым. Ватан сугышы елларында ук «Кызыл Татарстан» редакциясенең хатлар бүлегендә эшләгән бу журналист Муса Җәлил, Гадел Кутуйның фронттан җибәргән кайбер кульязмаларын кадерле истәлек рәвешендә үз архивында саклаган. Авыру журналист, тормышының соңы якынлашуын сизенеп булса кирәк, әлеге истәлекле кульязмаларны миңа тапшырды... Бу истәлекләрдән Мусаның фронт шартларында дәфтәр битенә карандаш белән генә язып җибәргән берничә шигырен соңыннан мин Гази Кашшаф иптәшкә бирдем.

Бу һәм шуңа охшаш башка бик күп фактлар газета белән язучылар арасындагы җылы хисләргә төренгән туганлык турында сөйләмиләрмени!!.

Әйе, «Социалистик Татарстан» битләрендә, аның туган көненнән алып бүгенгесенә кадәр, үзенең иҗат җимешләре белән уртаклашмаган, редакция бусагасыннан атлап керүенә якты чырай очратмаган язучы бармы икән!..

Кырык ел вакыт узса да, ул көнне һич онытачак түгелмен. 1927 елның җәй башларында «Кызыл Татарстан» газетасында минем революцион яшьлек романтикасына карата язылган бер очерк-мәкаләм басылып чыкты. Яшь язучы булырга теләү хыялы белән яшәгән 22 яшьлек берәү өчен республика газетасында зур мәкалә белән чыгуның ничаклы илһамландыргыч бер хәл булуын шуны кичереп күрүченең үзе генә белә торгандыр.

Нәкъ шул ук җәйдә «Кызыл Татарстан» газетасының 2000 саны басылып чыкты. Бу уңайдан Мәдәният йорты залында (бүгенге ТЮЗ театры бинасы) чәй мәҗлесе оештырылды. Татар әдәбияты һәм сәнгатенең иң күренекле, атаклы ирләре җыелган бу мәҗлескә чакырылучылар исемлегенә, ниндидер бер бәхетле язмыш белән, мин дә эләккәнмен. Шушы фактның үзе генә дә — зур бер газета коллективының мондай билгесез яшь берәүне санга санап хөрмәт итүе алдагы зур һәм озын юлга, данлы газета эшенә кабынып дәртләнү өчен җитмәс идемени!..

Бу мәҗлестәге речьләр, истәлекләрдән бигрәк, халыкның сөекле шагыйре Һади Такташның гаҗәеп бер илһамлану белән шигырь укуы истә калган. Менә ул шигырь:

Ике мәңге тутыргансың, «Кызыл Татарстан».
Ә мин
Бүген генә аны ишеттем,
Дөнья куып, бәгырем, йөри-йөри,
Тәбрикләргә сине кичектем!..
Сәлам булсын сиңа!
Ак битләрең
Тыгыз юллар белән каралсын,
Һәрбер битең тарих булып калсын!
Исемең эшче илдә дан алсын.

Айга күптән инде миллион тулган,
Ә ул үзе аны оныткан,
Бүген саташкан ай, кыш дип белеп,
Төн уздырган күктә толыптан.
Ай кебек син ялгыз читтә калма,
Битләреңдә
Миллионнарның бәйлә йөрәген,
Миллион күзләр синең биттә йөрсен,
Шушы минем сиңа теләгем!

Менә ни өчен якын дустыбыз, акыллы киңәшчебез, остазыбыз «Социалистик Татарстан»ның илле еллыгын билгеләп үткән бу көннәрдә кулга каләм алмыйча калу берничек тә мөмкин түгел иде.

Габдрахман **МИНСКИЙ.**

— — ◆ — —

*Тукай премиясенә тәкъдим ителгән әсәрләр турында сөйләшәбез*

*Галимҗан Ахунҗанов*

# МӘКАЛЬ һӘМ ӘЙТЕМ

*«Татар халык мәкальләре»нең соңгы, III томы басылып чыкты. Нәкый ага Исәнбәтнең бу фундаменталь хезмәте хакындагы фикерләре белән уртаклашуларын үтенеп, редакция фәннең төрле тармакларында эшләүче берничә галимгә мөрәҗәгать итте. Сүз аларга бирелә.*

Танылган язучыбыз, күренекле фольклорчыбыз Нәкый ага Исәнбәтнең күп еллык җентекле, тырыш һәм зур хезмәт нәтиҗәсе — «Татар халык мәкальләре» исемле фундаменталь әсәре — басылып чыкты. Берничә дистә мең мәкаль-әйтемне эченә алган бу уникаль җыентыкта халкыбызның бай рухи дөньясы, югары дәрәҗәле сәнгатьчә сүз иҗаты һәм осталыгы бик уңышлы чагылдырыла. Ашаган бәлми — тураган белә дигәндәй, җыентыкның гомуми әһәмияте файдаланучылар уйлаганнан шактый зуррак.

**МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘРНЕ ҖЫЕП ТУПЛАУ—** үзе генә дә искиткеч катлаулы һәм мактауга лаек эш. Н. Исәнбәт исә бу зур һәм киң колачлы эшне бер үзе диярлек башкарып чыккан.

Мәкаль-әйтемнәрне җыеп бастыру, иң элек, аларны барлау, исәпкә алу өчен кирәк. Чөнки без татар телендә күпме канатлы тәгъбир яшәвен чама белән генә дә белә алмый идек әле. Безнең моңа кадәр татар мәкаль-әйтемнәре дип йөрткәнебез, ул нигездә хәзерге Татарстан чикләре эчендә яшәгән халык теленнән, тагын да төгәлрәк әйткәндә, Казан һәм аның тирәсендәге татарлар арасыннан җыелган тәгъбирләр генә иде. Исәнбәт бу традицион рамканы шактый киңәйтте: Казан арты мәкальләрен генә түгел, бәлки чын мәгънәдә татар мәкаль-әйтемнәрен эченә алган җыентык бирде. Икенчедән, Н. Исәнбәткә кадәр чыккан җыентыклар нигездә әдәби тел мәкальләреннән генә төзелә иде. Бу кысаны да бик кыю һәм хаклы рәвештә җимереп, ул җирле сөйләшләргә, хәтта аерым авылларга гына хас мәкаль-әйтемнәрне дә җыентыгына кертә. Өченчедән, моңа кадәрге җыентыкларда мәкальнең бер вариантын (төзүче уенча, иң еш кулланылган, ягъни төп дип саналган вариантны) гына бирәләр иде. Исәнбәт җыентыгы бу ягы белән дә элгәрләреннән тамырдан аерыла: монда вариантларның барысын да алу максат итеп куелган. Дүртенчедән, соңгы 50 — 60 ел эчендә телебезгә килеп кергән мәкаль-әйтемнәр барланмаган, исәпкә алынмаган иде. Гомум халык телендә туган яңа мәкаль-әйтемнәр, язучылар теленнән халыклашкан канатлы тәгъбирләр, башка теләрдән алынган калькалар Исәнбәттә нигездә инвентарьга алынган. Илебездәге һәм телебездәге үзгәрешләрнең турыдантуры нәтиҗәсе буларак, күп кенә искергән мәкальләр яңача әйтелә башлады, мәгънәләре әзме-күпме үзгәрде. Аннан соң, гомумән, телдә мәкаль-әйтемнәрнең китап битләренә кертелми торган бик күп төрләре һәм вариантлары, шулай ук гади сөйләм тәгъбирләре яши. Исәнбәт томнарында бу төрләр дә тиешле урыннарын алганнар. Шул ук вакытта бу өч том моңа кадәрге җыентыкларда, хрестоматияләрдә урнаштырылган яки кульъязмаларда саклланган иске, сирәк мәкаль-әйтемнәрне дә, хәзерге җыючылар биргән дәфтәрләрдәге күп кенә тәгъбирләрне дә эченә алып, җыелма хезмәт ролен үти. Кыскасы, мәкаль-әйтемнәрне, иң гомуми күләмдә барлап, инвентарьга алу эше бу хезмәттә шактый уңышлы гамәлгә ашырылган. Чагыштырып карау өчен, шундый мисал китерик. Русларның атаклы В. Даль җыентыгында, төрле бүлекләрдә кабатланганнарын да санап, 30 меңнән артык мәкаль-әйтем бар. Исәнбәттә бу сан 60 меңгә җитә. Шулай итеп, татар мәкальләренең иң тулы җыелмасы булган бу хезмәт үзенең академик күләме ягыннан безнең илдә элек һәм Октябрьдан соң чыккан мондый типтагы, ягъни бер генә тел мәкальләрен эченә алган барлык җыентыкларга караганда күп тулырак. Тәртип саны сугылмыйча, тердәшиштәшләре янына өстәп кенә бирелгән, шулай ук мисалдаш итеп бүлекчә башларына яки ахырларына урнаштырылган мәкаль-әйтемнәр һәм вариантлар да әллә ни кадәр. Соңгы томда хәтта шундый мисалдашлардан гына төзелгән бүлекчәләр дә

күп. Академик күләм ягыннан карaганда, Исәнбәт җыентыгы, мәсәлән, дөньяга атаклы инглиз җыентыклары (Г. Смит. Инглиз мәкальләренең Оксфорд сүзлеге. 1948 ел) белән бер рәткә куела ала.

**МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘРНЕ ФӘННИ ЭШКӘРТҮ.** Бу өч томны гади җыючылык нәтиҗәсендә генә дөньяга килгән хезмәт дип карау артык берьяклылык булыр иде, әлбәттә. Хезмәтне иҗат итү юлы фән сарайлары аша да үткән. Беренче том башында бирелгән 13 табаклы фәнни «Кереш мәкалә» бер татар мәкальләрен генә түгел, бәлки башка төрки, шулай ук рус, кайбер Көнбатыш һәм Шәрык мәкальләрен дә фольклористик тикшерү-өйрәнү нәтиҗәсендә туган. Өстәвенә, автор монда фольклористика белән чиктәш яки арадаш фәннәрнең яңа сүзе исәпләнгән теоретик тикшеренүләрне дә нигездә исәпкә алган. Шул ук вакытта бу хезмәттә Исәнбәт, үзенең фольклор өлкәсендәге күп еллык теоретик эшчәнлегенә дә йомгак ясап, моңа кадәр басылган китапларындагы, мәкаләләрендәге карашларны тагын да үстерә, киңәйтә, баета.

Моңа кадәр чыккан вак-вак мәкаль-әйтем җыентыкларыбыз нигездә фәнни теорияләргә кермиләр, рус яки чит ил фольклористикасындагы әзме-күпме танылган карашларны күчереп, татар мәкальләренә яраштырып, гомуми сүзләр әйтү белән чикләнәләр иде. Гадәттә мәкаль-әйтемнәргә берничә юллык урын биреп килгән әдәбият дәреслекләрендә дә шушы ук хәл булды. Исәнбәтнең «мәкалә» исеме белән генә бирелгән бу теоретик хезмәте исә, үзенең фәнни диапазоны һәм тулылыгы белән, фольклористика өлкәсендә безнең илдә һәм Көнбатышта мәгълүм булган әзме-күпме әһәмиятле барлык хезмәтләргә караганда киңрәк, камилрәк, эчтәлеклерәк. Автор шул ук вакытта мәкаль-әйтемнәргә карата соңгы вакытта урнаша һәм ныгый башлаган лингвистик карашны да читләтеп үтмәгән. Кереш мәкаләнең беренче җөмләсендә автор «телсез яки җырсыз-моңсыз халык булмаган кебек, мәкальсез халык та юктыр» дисә, әгәрни сүзне традицион караштан башлап китсә, баштагысына дәлил рәвешендәрәк китерелгән икенче җөмләсендә үк инде «халык сүз арасында мәкаль кыстырырга ярата, үз телен аның белән бизи, төзи», ди. Мәкальләрне тел берәмлекләре, сөйләм элементлары һәм чаралары булу ягыннан өйрәнү мәсьәләсе хезмәтнең моннан соңгы битләрендә дә урын ала һәм бераз үстерелә. Әмма гомумән алганда, бу — фольклористик хезмәт.

Кереш мәкаләдә мәкальнең сөйләмдәге гомуми урыны, шулай ук дидактик роле күрсәтелә, аның сөйләм өчен генә яшәгәнлеге икърар ителә, мәгънә төзелеше ягына игътибар ителә. Мәкальләрнең туу-искерүләре, аларның чыганаклары һәм алынмачылык теориясе, аларны тәртипкә салу һәм башка кайбер мәсьәләләр турында әһәмиятле яңа фикерләр әйтелә. Шул исәптән, мәкальләрдә социаль тормыш күренешләренең чагылышы мәсьәләсе тикшерелеп, мәкальләргә вульгар социологик караш шактый уңышлы тәнкыйть ителә. Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: мәкальне тел берәмлеге буларак тикшергәндә, вульгар социологизмның җирлеге тагын да ныграк какшый, дөресрәге, бөтенләй юкка чыга. Чөнки **капитализм**, **коллык** сүзләрен генә түгел, хәтта **алла**, **җен** кебек сүзләрне телдән һәм аңнан көчләп куып булмаган кебек, искергән яки реакцион дип исәпләнгән мәкаль-әйтемнәрне дә телдән куып булмый. Әерым алганда, мондыйларның бер өлеше хәзер ироник мәгънә яки төсмер алып, яңадан телгә кайталар. Ул гына да түгел, хәтта иң реакцион дип саналган һәм хәзерге сөйләмдә ироник кулланыш таба алмаган тәгъбирләр дә шул чорны яки җәмгыятьне тасвирлаган әсәрләр телендә зарури кулланылалар. Инде мәкаль-әйтемнәргә генә түгел, сүзләргә дә хас булган искерү һәм шул сәбәпле телдән төшеп калу мәсьәләсенә килсәк, бу — башка эш.

Теоретик өлештә мәкальләрдә файдаланылган тропларның (телбизәкләрнең) кайберләре һәм стилистик фигураларның бер өлеше тикшерелә. Тик лексик һәм стилистик сурәтләү-сәнгатьләү чараларының бу ике төре монда аерым-аерым каралмый. Мәкальнең эвфоник төзелеше, аваз һәм интонация белән бизәкләү чаралары киңрәк яктыртыла.

Исәнбәт җыентыгы, һичшиксез, тарихка керә торган хезмәт. Анда әйтелгән фикерләргә, ясалган нәтиҗәләргә бик күпләр зур игътибар бирәчәк, берничә буын зур ышану һәм ихтирам белән колак салачак. Шуңа күрә, Исәнбәт хезмәтендә кузгатылган берничә актуаль мәсьәләне тагын да ачыкларга һәм үстерергә теләү йөзеннән, бер-ике фикер әйтү зарури кебек тоела.

Күпләр өчен бүген дә әле шактый чуалчык булган **ӘЙТЕМ** мәсьәләсен Исәнбәт «Кереш мәкалә»дә уңышлы хәл иткән. Әмма шушы популяр китапның чыгуына инде сигез еллап вакыт узуга карамастан, практикада әйтем белән мәкаль төшенчәләре һаман утырып җитми, әйтем һәм мәкаль сүзләре берсе урынына икенчесе кулланыла.

**ӘЙТЕМ** сүзе бездә әле киң таралмаган һәм нигездә, әдәби термин буларак, фәнни әдәбиятта гына кулланыла. Ләкин бу өлкәдә дә әле ул утырып җитүдән ерак тора. Әйтем сүзе гел диярлек мәкаль сүзе белән, дөресрәге, аның артыннан кулланыла. Һәм алар арасында практик аерма ясалмый. Ул гына да түгел, үзе генә кулланылганда, әйтем сүзе мәкаль диясе урында әйтелә яки киресенчә була.

Мондый терминологик буталчыклыкның үз сәбәпләре бар. Татар телендә генә түгел, бәлки гомумән филология өлкәсендә мәкаль-әйтем мәсьәләсенең һәр яктан алып тикшерелгәне булмады. Теориядә алар хәзергә кадәр я фольклор әсәрләре дип, я тел берәмлекләре, аның сурәтләү-сәнгатьләү чаралары дип, ләкин һәр ике очракта да нигездә бер генә яклы каралып килделәр. Шуңа күрә бу категорияләрне тулы күзаллау мөмкин булмады;

әзме-күпме бердәм һәм ныклы караш урнашмаганлыктан, әйтемне «чама белән» генә билгеләү практикасы өстенлек саклап килә. Аннан соң, хәзерге ике теллелек шартларында русчадагы **пословицы и поговорки** тәгъбиренә иярү дә бик табигый хәл. Бу хәл тәрҗемә әдәбият теле өчен бигрәк хас. Руслар исә көндәлек сөйләмдә генә түгел, хәтта филология буенча махсус хезмәтләрдә дә **пословица, поговорка** сүзләрен берсе урынына икенчесен теләсә ничек кулланалар.

Тарихка күз салыйк. Татар телендә чыккан беренче җыентыкларда, хрестоматияләрдә, календарьларда, кульъязмаларда ук инде, мәкальләр белән рәттән, әзме-күпме санда әйтемнәр дә элек-электән үк урнаштырылып килгән. Мәсәлән, Х. Бәдигый 1912 елда чыккан җыентыгында, «Борынгылар әйткән сүзләр» һәм «Читләтеп сөйләү» дигән ике бүлек ясап, боларның баштагысына нигездә мәкальләрне, соңгысына әйтемнәрне урнаштыра. Ләкин аларның атамалары, үз терминнары булмый әле. 1927 елгы Җ. Вәлиди сүзлегендә **әйтем** сүзе бөтенләй юк. Нигездә, Октябрьдән соң кереп халыклашкан **мәкаль** термины кулланышта чагыштырмача нык урнашса да, әйтем төшенчәсе бездә утызынчы еллардан соң гына аерып карала башлаганлыктан, термины да шул чорда гына мәйданга килә. Ул елларда ил күләмендә гомуми башлангыч уку кертелә, бердәм мәктәп программалары һәм стандарт дәреслекләр буенча укыту гамәлгә ашырыла. Русларныкы үрнәгендә төзелгән тел-әдәбият дәреслекләрендә, **пословицы и поговорки** дигәнгә ияреп, **мәкальләр һәм әйтемнәр** дип язу гадәткә кереп китә. Икенче яктан, гомумән, Октябрьдән соң рус культурасының һәм теленең татар халкына йогынтысы кискен көчәя. Марксизм-ленинизм кебек алдынгы теориянең безгә рус теленнән һәм рус фәненнән килүе дә татар филологларының рус гуманитар фәннәрендәге теорияләргә киң фронт буйлап йөз тота башлавында зур роль уйный. Интеллигенция вәкилләре үзләренең мөстәкыйль хезмәтләрендә дә, рус аналогиясе буенча, **мәкальләр һәм әйтемнәр** дип яза башлыйлар. Мәсәлән, Г. Гали 1934 елда шагыйрь М. Крыймовка язган ачык хатында: «Борчак ату, стенага борчак бәрү, борчакны сибә дә сибә кебек әйтемнәрнең нинди мәгънәдә йөрүләрен уйлап карагыз», ди. Әйтем категориясе теориядә дә танылa башлый, әдәбият дәреслекләрендә телгә алына. Лекин әйтем төшенчәсенең һәм сүзенең язма тел кулланышына керүе генә әле һич тә аның халыклашуын күрсәтми. 1940 елгы «Русча-татарча сүзлек», мәсәлән, **поговорка** сүзен **әйтем** дип түгел, ә «халык телендә әйтелә торган кыска сүзләр, сөйләм, мәкаль» дип тәрҗемә итә. Х. Ярми җыентыгының[1] теоретик сүз башында **мәкаль** һәм **әйтем** терминнары мәсьәләсе бөтенләй куелмый, мәкаль-әйтемнәргә билгеләмә бирелми. 1966 елдгы «Татарча-русча сүзлек» бу терминны артык күп мәгънәле итеп күрсәтә, ягъни, русларга ияреп, теләсә ничек куллану практикасын чагылдыра. Кыскасы, әйтем төшенчәсе һәм термины дөрес мәгънәдә урнашып җитә алмый әле.

Рус мәкаль-әйтемнәре өлкәсендә фәнни тикшеренү эшләрен башлап җибәрүче И. Снегирев әйтемнәрнең типик үрнәкләре итеп «как снег на голову»; «как две капли воды» тәгъбирләрен китерә. Атаклы рус сүзлекчесе һәм мәкальчесе В. Даль әйтемне читләтеп әйтелгән тәгъбир дип билгели[1] һәм бу категориянең типик мисаллары итеп «остался с носом», «нашла коса на камень» тәгъбирләрен күрсәтә. Нигездә дөрес булган бу билгеләмә хәзерге көнгәчә үзенең көчен югалтмаган. Хәзерге төрле типтагы сүзлекләргә, җыентыкларга урнаштырылган сүз башларында, әдәбият сүзлекләрендә, дәреслекләрдә **поговорка** терминына нигездә Даль биргән мәгънә салына. Ниһаять, махсус лингвистик әдәбиятта да **поговорка** термины дөрес мәгънәдә фәнни санкция алды.

Теориядә эш шулай торса да, практикада мәкаль һәм әйтемне бер-берсеннән аерып урнаштырган бер җыентыкның да дөньяга чыкканы юк. Аларны гел бергә җыеп һәм кушып, аралаштырып бирәләр. Ул гына да түгел, «Пословицы» исеме астында чыккан җыентыкларга әйтем икәнлеге ап-ачык күренеп торган тәгъбирләрне дә урнаштыралар. Киресенчә дә була. Шулай ук дәреслекләрдә, календарьларда, вакытлы матбугат битләрендә баганалап яки төркемләп бирелгән мәкальләрнең башына, гәрчә анда бер генә әйтем булмаса да, «Пословицы и поговорки» дип куела. Бу хәл татар матбугатына да шул ук дәрәҗәдә хас. Мәсәлән, 1967 елгы числолыкның 11 август битендә, «Төрек халык әйтемнәре» һәм «Япон халык мәкальләре» дигән ике бүлекчәгә аерып, ун мәкаль биргәннәр. Арада бер генә әйтем дә юк. Исәнбәт әйтемне мәкальдән, дөресрәге, мәкальне әйтемнән сүздә генә түгел, практикада аерып күрсәтте. Өч том мәкаль арасына анда-санда гына килеп эләккән әйтемнәрнең күбесе «әйтем» дип искәртеп үтелгән. Тик аның: «Әйтемнәр — сөйләмдә кулланыла торган төрле киная, чагыштыру, ошату шикелле хосусый бер карашны белдергән һәм башка җөмләгә ияртеп әйтелә торган төрле телбизәк чаралары (троплар, фигуралар), идиомалар, характерлы кереш сүзләр һәм башка шундый шигъри тәгъбирләр була» (218 бит), дигән тасвирламасы артык киң һәм бераз томанлырак кебек. Әйтемнәрне «башка җөмләгә ияртеп әйтелә торган телбизәк чаралары» дип карау — яртылаш кына дөрес. Моннан әйтем җөмләнең бер кисәге яки өлеше булып кына йөри икән дигән фикер аңлашыла. Ләкин әйтем сөйләмдә, җөмлә кисәге булып йөргән кебек, үзе мөстәкыйль җөмлә булып та килә. Мәсәлән: **Кайный каным**, болыт өсләрендә Бөркет

[1] Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. 1960 ел. Төзүче Х. Ярми.

[1] Пословицы русского народа. Сборник В. Даля. Москва. Рус телендә. 1957 ел.

булып очасым килә (Ф. Кәрим); Ярлы-ябагайның, билгеле инде, **кесә төпләре тишек** (Г. Бәширов). Аннан соң, әйтемнәрнең кайберләре телдә тик җөмлә рәвешендә генә яшиләр һәм сөйләмдә дә шул формада кулланылалар. **Таң ата да кич була, акылың алтын икән** кебек әйтемнәр шундыйлар. Инде «башка җөмләгә ияртеп әйтү»не берәр җөмләдәге фикерне куәтләү, җанландырып җибәрү дип аңласак (болай аңлап та була), әйтемне теләсә нинди шигъри тәгъбир, шул исәптән мәкаль белән бер тактага куйган булабыз. Әйтемне «сөйләмдә кулланыла торган тәгъбир» дип карау, бер яктан, бик дөрес. Димәк, Исәнбәт әйтемне, традициягә ияреп, фольклор әсәре дип кенә карамый, ә дөрес, лингвистик карашка якыная. Әмма «сөйләмдә **кулланыла»** торган һәр тәгъбир, шул исәптән «шигъри тәгъбир» дә, әйтем булмый, була алмый. Чөнки сөйләмдә исәпсез күп «шигъри тәгъбирләр», ягъни сурәтләү-сәнгатьләү чаралары кулланылган, кулланыла һәм кулланылачак. Ләкин аларның барысы да тотрыклы тәгъбиргә әйләнеп, ягъни халыклашып, гомуми һәм традицион куллanышка кереп китә алмаган, алмый һәм алмаячак. Бу ике очрак — Исәнбәт билгеләмәсендәге төгәлсезлек кенә, әлбәттә, Әмма шул төгәлсезлек, күргәнебезчә, әйтемне киңрәк аңларга урын калдыра. Җыеп әйткәндә, Исәнбәт әйтемнең практик асылын дөрес тотып алган, аның төп билгеләрен нигездә уңышлы күрсәткән. Аның билгеләмәсе, гомумән, фольклористика өлкәсендә чын мәгънәдә соңгы сүз.

Моңа кадәр чыккан мәкаль-әйтем җыентыкларында әз-мәз урнаштырыла килгән әйтемнәр нигездә ритм-рифмалы, тапкырүткен булулары белән күзгә нык ташлана торган, чагыштырмача озын текстлы булалалар иде. Мәсәлән: **сусыз юа, җилсез киптерә; теленең тупсасы, авызының туктасы юк; ачык чырай, такта чәй** һ. б. ш. **Алтын куллы, күз кызу, бармак белән санарлык, түбә күккә тию** кебек тәгъбирләр хакында исә без бөтенләй башка карашта идек. Махсус тикшерү бу соңгы төрләрнең дә озын текстлы әйтемнәр белән тулысынча бердәй икәнлеген күрсәтә.

**МӘКАЛЬНЕҢ ӘЙТЕМНӘН АЕРМАСЫ** хакында Исәнбәттә әйтелгәннәргә тагын берничә генә сүз өстәргә кирәктер. Төп аерма шул: мәкаль дидактик мәгънәгә ия, әйтем алай түгел. Икенче дәрәҗәдәге аермалар да бар. Иң элек, һәр мәкаль хөкем була, әйтемнәрнең исә бик әзе генә хөкем белдерә. Димәк, әйтем хөкем белдерми диган сүз дөрес түгел. Мәсәлән, **авызыңа бал да май** әйтемендә логик ия (субъект) һәм хәбәр дә (предикат) бар. Бу җөмләдә, ягъни әйтемдә, «яхшы хәбәрең рәхмәткә лаек» диган хөкем белдерелгән. Мәкаль — җөмлә, әйтем исә аның кисәге генә була, диган караш киң таралган. Мондый караш та төгәл түгел. **Акылың алтын икән, иштең ишәк чумарын** һәм башка күп әйтемнәр, мәсәлән, җөмлә формасында гына яшиләр.

**УРТА-АРАДАШ ТӨРЛӘР** мәсьәләсе дә махсус карауны сорый.

Кай тәгъбирләрнең мәкаль яки әйтем булуы контекстка бәйле. Мәсәлән, **үгезе үлгән — уртагы аерылган** тәгъбире «исәпхисапны өзеп бетергән кешең белән уртак эшең булмаска тиеш» диган дидактик мәгънәдәге хөкемне белдерә. Димәк, ул мәкаль. Шул ук тәгъбир «аның минем белән бүлешәсе нәрсәсе калмаган» диган мәгънәдә дә йөри. Бу очракта ул — әйтем. Контекстка карап төрле мәгънәдә йөри торган мондый тәгъбирләр байтак: **ашарына ипи юк — этенең аты Карабай; биредә — Алабай, аргы якта — ялагай** (Исәнбәттә); **бер тиен куян — ун тиен зыян; тыштан ялтырый, эчтән калтырый; атын урлаткач, сараен бикләгән...**

Арадаш формаларның икенче төрен **яхшыдан яман туган** тибындагы тәгъбирләр тәшкил итә. Җыентыкта-сүзлектә генә торганда, бу тәгъбирне «яхшыдан яман туарга мөмкин» диган дидактик мәгънәдә аңларга мөмкин. Әмма кулланышта ул эпитет, тасвирлама функциясендә генә йөри һәм хөкем түгел, төшенчә генә белдерә, дидактик мәгънәсе дә булмый. **Ат юк, арба юк, аннан кала бары да юк** тәгъбире дә шундый.

Өченче төргә **өлешеңә тигән көмешең** тибындагы тәгъбирләр керә. Әлеге мәкальне белмәгән, аны беренче тапкыр (мәсәлән, яшьләр) җыентыкта гына очраткан кеше, һичшиксез, бу — әйтем дип уйлый. Ләкин кулланышта бу тәгъбир «бар кадәр бәхетеңнән-уңышыңнан канәгать булырга кирәк» диган дидактик мәгънәдә, ягъни мәкаль булып кына йөри. Яки менә **диңгездән бер тамчы, дуңгыздан бер кыл** диган, ягъни форма ягыннан тулысынча охшаш ике тәгъбирне алыйк. Боларның баштагысы «бик әз» диган төшенчә генә белдерә, ягъни әйтем була. Ә соңгысы русларның **с паршивой овцы хоть шерсти клок** мәкаленә тулысынча тәңгәл йөри.

Мондый арадаш төрләрнең кайберләрен тыныш билгеләре ярдәмендә күрсәтеп, аерып булыр иде. Мәсәлән, **ике чабата бер кием** тәгъбире «барыбер», «икесе дә бер иш» диган мәгънәләрдә әйтем була. «Бер иш булган кешеләр үзара тиң булалар» диган мәгънәдә исә ул мәкаль була һәм бу очракта аның язылышы да **ике чабата — бер кием** рәвешен ала. Мондый арадаш төрләр Исәнбәт җыентыгында да күп. Аларның кайберләре әйтем дип күрсәтеп үтелгән, ләкин тыныш билгеләренең куелышына игътибар ителмәгән.

Грамматик хәбәре фигыль белән белдерелгән мәкальне дә шушы уңайдан карарга кирәк. Бу мәсьәлә буенча махсус тикшеренүләр булмаганлыктан, кулланышта грамматик формасын үзгәрткән мәкаль әйтемгә әйләнә, диган караш белән генә чикләнәләр. Мәкальнең җөмләлек билгеләре дә югалып, ул җөмлә кисәге формасында гына кулланылса, әлеге караш буенча, аның әйтемгә әйләнүе инде бөтенләй шөбһәсез санала. Әгәр без бу фикерне

дөрес дип саныйбыз икән, мондый һәр тәгъбир мәкаль дә, әйтем дә була, дигән нәтиҗә ясарга тиешбез. Болай булгач, әйтемнәр дә ике төрле булып чыга: беренче төре — сүзлек-җыентыкларда да «Әйтемнәр» яки «Фразеология» исеме астында урнаштырыла торган әйтемнәр. Икенче төре — мәкальнең җөмләлек формасын үзгәртеп кулланганда «барлыкка килә торган» әйтемнәр. Шушы караштан торган бер төзүче, мәсәлән, берсенә мәкальләрне, икенчесенә әйтемнәрне генә кертеп, бер үк вакытта яки бер-бер артлы ике җыентык чыгарса, бер шиксез, аларның беренчесенә **тимерне кызуында сук; җиде кат үлчә, бер кат кис** кебек тәгъбирләрне, икенчесенә **тимерне кызуында сугу, җиде кат үлчәп, бер кат кисү** кебекләрне кертер иде. Тик тарихка мондый хәл мәгълүм түгел. Бу очрак җентекләп тикшерүне, мәкаль-әйтемнәргә төрле яктан, беренче чиратта, телдәге һәм сөйләмдәге үзенчәлекләре ягыннан килеп карауны кетә әле.

**МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМ ҖЫЕНТЫКЛАРЫНЫҢ ТИБЫ** аларның төзелү максатына бәйле. Бүгенге җанлы сөйләмдә кулланыла торган тәгъбирләрне генә эченә алган җыентык-сүзлекләр иң киң таралган типка керә. Болардагы мәкаль-әйтемнәрнең саны биш йөз белән мең арасында тирбәлә. Мәсәлән, Х. Гали җыентыгы (Мәкальләр һәм әйтемнәр. 1941) шундый.

Икенче тип җыентыкта 1500—2000 чамасы мәкаль-әйтем була. Бу типның практик әһәмияте, иң элек, тәрҗемә һәм язучылык эшендә сизелә. Мәсәлән, Х. Ярми җыентыгы, К. Мәргәннең «Башкорт халык мәкальләре» (Өфе, 1960) шундыйлар.

Өченче тип — җыелма җыентыклар. Мәсәлән, В. Даль җыентыгы шушы типка карый. «Көнчыгыш халыкларының мәкаль-әйтемнәре» (Мәскәү. 1961 ел. Төзүчесе Ю. Брегель), «Егерме биш телдән җыелган дөнья мәкальләре хәзинәсе» (Нью-Йорк. 1946 ел.) кебек бәрничә тел мәкальләреннән төзелгән җыентыклар да шушы рәткә баса. Илебездәге милли телләрнең мәкаль-әйтем җыентыкларыннан бу типка, беренче буларак, Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» керә.

Исәнбәт җыентыгы гомуми максаттан чыгып төзелгән. Ягъни үз өлкәсендә беренче тәҗрибә булган бу хәзинә-китап, бүтән телләрдәге барлык диярлек лингвистик һәм фольклористик элгәрләре нинди юлдан китсә, шул юлны сайлаган, ләкин аны инде югарырак баскычта кабатлаган: аларга хас күп җитешсезлекләрдән арынган, шактый мәсьәләләрне фәннең соңгы казанышлары нигезендә хәл иткән.

**МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘРНЕ ТӨРКЕМЛӘҮ** җыентыкның тибына бәйле. Билгеле булганча, мәкальләр, башка төр фразеологик тәгъбирләр кебек үк, тел материалы булалар. Сүз күрке — мәкаль, красна речь пословицей дип юкка әйтмибездер ич. К. Насыйриның «һәр телнең үзенә махсус әмсал вә кәльмәләре буладыр» дип (Фәвәкиһелҗөләсә. 1884 ел. 583 бит), ягъни мәкальләр белән «кәлимәләр»не бер рәткә куеп каравы һич тә очраклы түгел. Исәнбәт бу факт белән нык исәпләшеп, мәкальләрне төркемләгәндә лингвистик, дөресрәге, логик-лингвистик юлны сайлаган. Мәкальләрне һәм сүзләрне лингвистик тикшерү бу ике категория арасында күп уртаклык һәм охшашлык булуын күрсәтә. Шул исәптән, аларны төркемләүдә дә аналогия бар: мәкаль-әйтемнәрне тәртипкә салу ысулы телнең төп материалы булган сүзләрне классификацияләү ысулы белән бик якын тора. Сүзләрне тәртипкә салуда ике төп ысулдан файдаланалар. Аларның беренчесе һәм иң таралганы — алфавит ысулы. Мәкаль-әйтемнәрне төркемләүдә дә бу ысул өлешчә файдаланыла. Ләкин укучы өчен бу тәртип нигезендә аңа электән таныш сүзләрне-тәгъбирләрне эзләп караучда гына файдалы. Әмма тематик классификация дә билгеле бер чиккә кадәр генә үзен аклый. Чөнки фразеологиянең барлык төрләрен традицион тематик классификация кысаларына гына сыйдырып бетерү — мөмкин булмаган эш. Мәсәлән, **ни чәчсәң, шуны урырсың** мәкале: 1) нәрсә орлыгы (арпамы, бодаймы яки башкамы) чәчү, 2) нинди сыйфатлыны чәчү, 3) күп яки әз чәчү, 4) гомумән, чәчү-чәчмәү, 5) теләсә нинди эшнең нәтиҗәсен, файдасын-зарарын үзеңә татып карау турында сүз барганда һ. б. ш. күп очракларда кулланыла. Матур әдәбиятта һәм бүгенге җанлы сөйләмдә ул күбесенчә «эшләгән явызлыгың үзеңә кайта» дигән мәгънәдә йөри. Димәк, без бу мәкальне ким дигәндә алты бүлеккә кертергә тиеш булабыз. Өч томдагы мәкальләрнең шактый өлеше шундый. Мәкаль, гомумән, киң мәгънәле булып, аның сөйләмне сәнгатьләү мөмкинлекләре дә кулланышының һәр аерым очрагында башкаларыннан үзгә булырга мөмкин. Сүзләрне төркемләүнең икенче ысулы «сүзләр һәм әйберләр» методы (Исәнбәттә: «әйбер методы») дип йөртелә. Бу очракта әйберләрнең үз төркемнәре нигез итеп алынып, әйберләрне атаучы сүзләр шул нигездә төркемләнә. Мәсәлән, Ф. Дорнзайфның «Немец теленең әйбер төркемнәре буенча тәртипкә салынган сүзлек составы» (Берлин. 1959 ел) исемле хезмәте шундый. Монда барлык сүзләр 20 бүлеккә аерып урнаштырылган. Баштагы ике бүлек табигать дөньясына карый. Беренчесе «Анорганик дөнья. Материя» (Исәнбәттә: «Нәрсә»), икенчесе «Үсемлекләр. Хайваннар. Кеше (физиологик яктан)» дип атала. һәр бүлек эчендә ваграк бүлекчәләр бирелгән. Исәнбәт тә мәкаль-әйтемнәрне «Хезмәт», «Табигать дөньясы», «Кеше», «Йорт-көнкүреш», «Ил», «Милек», «Сыйныфлар», «Рухи дөнья» кебек зур бүлекләргә аерып бирә. 950 иң вак бүлекчә эчендәге тәгъбирләр инде алфавит тәртибендә тора. Ягъни, төп бүлекләр эчендәге тәгъбирләрне урнаштыру «сүзләр һәм әйберләр» методына ияреп төркемләүне хәтерләтә. Дөресрәге, шул үк ысул белән эшләнгән, тик мәкальләрнең үзенчәлеге генә сакланган. Бу алым — өч томдагы мәкаль-әйтемнәрне иң әзлекле төркемләүнең бердәнбер дөрес ысулы.

Моның өстенә Исәнбәт, алфавит принцибыннан тулысынча файдаланып, тематик төркемләүне дә өлешчә саклаган. Берәр нәрсәне тасвирлауга багышланган мәкальләрнең зур күпчелеге, алфавитлап бирү нәтиҗәсендә, янәшә туры килгән, һәм мондый тәгъбирләр шушы хәлдә дә төркем-төркем булып оешканнар. Төрле урында бирелергә тиеш булып та, мәгънә ягыннан бердәй яисә якын мәкаль-әйтемнәр үзләренең төрдәшләре яки мәгънәдәшләре янына өстәлеп, шулай ук бүлекчә ахырына яки башына мисалдаш итеп урнаштырылганнар. Мәсәлән, соңгы ике томдагы барлык бүлекчәләр янында диярлек мисалдаш мәкаль-әйтемнәрдән дә өстәмә бүлекчә бирелгән. Бу — мәкаль-әйтемнәрне төркемләү практикасында яңа күренешләрдән. Җыентыкның тибы аның максатына җавап бирә; ә эчке классификация, үз чиратында, китапның тибыннан чыгып эшләнгән. Гомумән, бу яктан да җыентык уңышлы, төзек, камил.

**ҖЫЕНТЫКНЫҢ СОСТАВЫ** турыдан-туры авторның теоретик принцибына бәйле. Ә теория, ягъни мәкаль-әйтемнәр турындагы фән әле туып кына килә. Традиция буенча, алар фольклор әсәрләре рәтеннән каралалар. Шул ук вакытта, сөйләм чаралары буларак, тел фәнендә дә тикшереләләр. Монда да капма-каршы фикерләр бар.

Сөйләмдә нәрсәләр бар икән дип «сөзеп» (Исәнбәт әйткәнчә) караганда, тел белгеченең җәтмәсенә, «сүз» дигән «вак маймычлар» рәтеннән, мәкаль-әйтем кебек «бәртәсләр, чуртаннар» да керә. Кайвакыт мәкаль-әйтем урынына кулланылган табышмак, такмак, җыр, шигырь һ. б. әсәр өзеге килеп эләгә. Ләкин монысы инде бөтенләй башка мәсьәлә — мәкаль-әйтемнең барлыкка килү мәсьәләсе. Әлеге табышмак, такмак, җыр яки шигъри өзек, контексттан читкә чыкмый караганда, мәкаль яки әйтем булып торалар, ягъни табышмак та, такмак та... түгелләр. Чөнки алар мәкаль яши торган «өйгә» килеп кергән булып чыктылар, ә «үз өемдә — үз көөм». Тел, сөйләм-мәкаль яши торган «өй» ул. «Мәкальләр телнең бер элементы, тел чарасы буларак... дәвамлы яшиләр» (Исәнбәт). Мәкале шунда булгач, аның «хикмәтен» дә шуннан эзләргә кирәк буладыр инде. Ләкин юлының бу төшенә килеп җиткәч, Исәнбәт, юнәлешен үзгәртеп, саф фольклор ягына тайпылган. Мәкаль-әйтемне фольклор әсәре дигән традицион карашны бер яклы гына аңлап абсолютлаштыру, иң элек, чынлыкта да әсәр булган мәзәкләрне җыентыкка кертүдә күренә. Дөрес, алар күпчелек очракта мәкальнең килеп чыгышын ачарга, мәгънәсен аңларга ярдәм итү йөзеннән китерелгәннәр. Шуның өстенә соңгы томда аларның гомуми саны да, һәркайсының күләме дә бик нык киметелгән. Ләкин шулай да алар еш кына «кызык өчен», ягъни әсәрләр буларак, укыр өчен генә урнаштырылганнар. Мәкаль җыентыгын фольклор җыентыгына әйләндерүгә юл тотылган. Икенчедән, бу караш мәкаль булмаган тәгъбирләрне алуда чагылган. Менә, мәсәлән, **кыз баланың тәрбиясе читен** тәгъбире. Ул әсәрме-түгелме, анысы икенче мәсьәлә. Ләкин «сүз күрке — мәкаль» дигән шартка җавап бирмәве бәхәссез. Кемнең итәгенә төшсә, шуныкы яна дигәндәй, кемдә нәрсә кайгысы: башына төшкән берәү аны «олы-карының тәрбиясе читен» ди. Гомумән, авыру кешенең тәрбиясе читен, ир баланың тәрбиясе читен, олы малның тәрбиясе читен, алмагачның тәрбиясе читен, кыяр-помидорның тәрбиясе читен кебек көндәлек көнкүрештәге гадәти фразалар бик күпләр. Аннан соң, мәкальләрнең төзелешендә, эфоник булмаса да, лексик һәм стилистик сурәтләү-сәнгатьләү чаралары, кагыйдә буларак, табылалар. Бу фразада исә болар бөтенләй юк. Яки **уттай эш өстендә шар сугып йөрмиләр** тәгъбирен алыйк. Тәзүче аны Г. Насрыйдан алынган дип авторын да күрсәтә. Авторлы булу-булмауның монда катнашы юк, билгеле. Чөнки күп мәртәбә данлыклырак авторларның яратып укыла торган (массовый!) әсәрләрендәге матур афоризмнар, әлеге тәгъбиргә караганда күп тапкыр сәнгатьлерәк, мәкальчәрәк яңгырашлы тәгъбирләр дә бик сирәк очракта гына халыклашып, ягъни мәкальләшеп китәләр. Еш куллану тәгъбирне күңелдә калдыруның шарты. Димәк, кулланышка кереп китмәгән теләсә нинди афоризм да мәкальгә әйләнми, афоризм гына булып кала. Бер мисал: «Картлар арасында чын кешенең үзенә атап яңа мәкаль дөньяга килде. **Мәгъсүмә килде — бәрәкәт инде,** диләр иде алар» (Соц. Тат.). Бу мисал нәрсәне күрсәтә? — Берәр авылда мәкальләшеп киткән фраза да гомум телгә кереп китә алмый, ягъни чын мәкальгә әйләнә алмый дигән сүз. Матбугат битләрендә төрле кампания уңае белән әзме-күпме кулланылып, соңыннан онытыла торган өндәмә-лозунг кебек тәгъбирләрне дә мәкаль-әйтемнәр дип күрсәтү һәм җыентыкларга кертү еш очрый. Бу практика һәм караш, күргәнебезчә, нигезле түгел.

Шигъри цитаталар җыентыкка мул кертелгән, ләкин аларны «Халык мәкальләре» дип аталган китапта бирү уңышлы түгел. Бу практика фольклористик әдәбиятта да тәнкыйтьләнде инде. Дәрдмәнднең мондагы «Ала кошларга бакмакчы, Газизем, булма такмакчы; Матур гөлләргә былбыл бул, назакәт багына сакчы» дигән цитатасы Исәнбәт билгеләмәсенә дә ачыктан-ачык каршы килә. Аның махсус канатлы тәгъбирләр җыентыгына да керүе икеле, чөнки аны үз стилендә, китаби сөйләмдә дә кайчан да булса әзме-күпме актив кулланылган дип булмый. Н. А. Добролюбов үткән йөздә үк инде: «Халыкта саклана торган мәкальне генә халык мәкале дип атау дөресрәк булмас микән?» — дигән иде.

Мәкаль калыбына салып төзелгән теләсә нинди уңышлы тәгъбирне җыентыкка кертү-кертмәү мәсьәләсе ике яклы. Бер яктан, без аны мәкаль дип таный алмыйбыз. Дөресрәге, ул үзе сөйләмдә кулланылмый, «җәтмәгә керми». Икенче яктан, әгәр ул җыентыкка кергән икән инде, бу факт белән санашмый да булмый. Бәлки ул хисапсыз күп уңышсыз калькаларның

беразын гына булса да җиңәр, бәлки аларның кайберләрен тел осталарыбыз яки халкыбыз күтәреп алыр.

Мондый тип җыентыкның әле безнең илдәге бер халыкта да чыкканы юк. Үзеннән үзе аңлашылганча, сан-микъдар үзгәрешләре сыйфат үзгәрешен китереп чыгара. Моңа кадәр чыгып килгән гадәттәге җыентыкларга бер-ике битлек сүз башы сыман кыска гына мәкалә язу җиткән булса, Исәнбәт алдына бу проблема бөтен тулылыгы белән килеп баса һәм аны теге яки бу дәрәҗәдә чишмичә булмый. Теория белән шөгыльләнү Исәнбәт өчен үзмаксат түгел, бәлки җыентыгының кычкырып торган сорауларына җавап бирү булды. Сарыкның егылганы да күренми, дөянең сөрлеккәне дә күренә дигәндәй, китапның зур күләмле булуы сәбәпле, мондагы барлы-юклы кимчелекләр, бәлки, арифметика күзлегеннән караганда, купаеп күренә торгандыр. Ләкин практика өлкәсендә дә, теориядә дә беренче тәҗрибә булган бу тер җыентыкка теге яки бу дәрәҗәдә төрле хәл ителеп бетмәгән нәрсәләрнең хас булуы бик табигый һәм зарури. Аннан соң гомуми «файдалы коэффициент» эчендә мондый гына «ак тап» һәм «кара нокталар» — диңгездәге берничә тамчы гына. Алар барысы да диярлек — үсеш кимчелекләре.

Исәнбәт кебек зур эшлекләләр турында сүз йөрткәндә В. И. Ленинның түбәндәге сүзләрен искә төшерү урынлы булыр кебек: «Тарихи хезмәтләр турында тарихи эшлекләләрнең хәзерге таләпләр белән чагыштырганда нәрсәне **бирмәүләренә** карап түгел, бәлки аларның үз элгәрләре белән чагыштырганда **нинди яңа нәрсә бирүләренә** карап хөкем ителә» (Әсәрләр. 2 том. 172 бит).

Мәкальләр өлкәсендә зур юлга чыккан Исәнбәт шактый **проблемалар**ны хәл иткән, тагын шуның кадәрен күтәреп чыккан һ. б. Җыентык чыкканнан соң безнең алга тагын да яңа сораулар килеп баса, чөнки бу мәсьәләгә төрле кеше төрлечә, беренче чиратта, үз ихтыяҗларыннан чыгып карый. Бу сорауларның кайберләренә җавап алу өчен, күмәк көч белән генә хәл итәрдәй гомумиләштерүләр, бөтен бер коллектив көченнән генә килердәй статистик тикшеренүләр һәм күп техник хезмәт таләп ителә яки озак еллар кирәк була. Югарыда телгә алынып, хәл ителеп бетмәгән дигән мәсьәләләрнең күпчелеге шушы төргә карый.

**Бүрәнә аркылы бүре күрү, дуга белән печән чабу, тел бистәсе** кебек төрләрне алып карыйк. Алар гел кире хис белдерәләр. Шундый эшләр эшләүче кешене теге яки бу дәрәҗәдә шелтәләп, алар нинди генә формада кулланылуларына һәм нинди генә интонация белән әйтелүләренә карамастан, ахыр чиктә алай эшләргә ярамаганлыкны аңлаталар, үзләренчә мораль уку булып яңгырыйлар. Икенче төрле әйткәндә, берәүгә «дуга белән печән чабасың» дип әйттең ни, «дуга белән печән чапма» дип әйттең ни, мөрәҗәгать бер мәгънәдә — шелтә дип кенә кабул ителә. Шунлыктан булса кирәк, мондый тәгъбирләрнең **дуга белән печән чабу** кебек формалары гадәттәге сүзлекләрдә, **дуга белән печән чапма** формасы фольклор җыентыгында мәкаль дип бирелә. **Кәкрене кыекка саплама; Кеше кубызына биемә! Авызыңнан тере саескан очырма** шикелле мондый тәгъбирләр Исәнбәттә шактый. Бу мәсьәлә хәл итүне сорый.

Икенче проблема — мәкальнең вариантлары (төрдәшләре-иштәшләре) мәсьәләсе. Җанлы сөйләмне һәм матур әдәбият телен күзәтүдән күренгәнчә, кеше һәр аерым очракта мәкальдән иҗади файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, әдәби персонажлар, бер диалог эчендә, бер сөйләшү вакытында кулланылган мәкальне, кагыйдә буларак, үзгәрешсез калдырмыйлар. Бер генә мисалга мөрәҗәгать итик. **Бүредән курыккан — урманга бармаган** мәкале бүгенге кулланышта түбәндәге вариацияләрдә яши: **бүредән курыккан — урманга бармый** (яки: **бармас, бармасын** һ. б.); **бүредән курыксаң, урманга барма** (яки: **бармыйсың, бармаска кирәк, барырга кирәкми, барырга ярамый** һ. б.); **бүредән куркасың икән — урманга барма** (барлык югарыдагы вариацияләре белән); **бүредән курыккач, урманга барма** һ. б. Бу вариацияләргә иярсәң, вариантларга ук килеп җителә: **бүреләрдән курыктисаң, урманга бармау яхшырак** (Тукай). **Яхшырак** урынына **хәерлерәк** һ. б. ш. сүзләр кулланылмас дип һич әйтә алмыйбыз. **Бүредән куркып, урманга бармый булмый** кебек перифрастик форма һәр мәкаль-әйтемгә диярлек хас. Бу соңгысын **бүредән куркам дип, урманга бармый булмый** (яки: **бармый булдыра алмыйсың, бармый булмас, бармый** торып булмый) һ. б. ш. бик күп рәвештә борып әйтәләр. **Бүредән курыкканга — урманга бармаска кирәк** вариантының тагын үз вариацияләре бар. **Бүредән курыккан кеше урманга бармас** рәвешендә куллану да бик табигый. Монысының да төрчәләрен танымый булмый. **Кеше** сүзе урынына **адәм** дип тә сөйлиләр, һәм бу очракта да «бормалаулар» шул ук санда була. **Бүредән курыксаң, урманга кермә** варианты да пассив түгел. **Бүредән курыксаң, урманга йөрмә** формасы да әдәбиятта очрый һәм бер диалектта бар. Боларның да үз чиратында тиешле вариацияләрен инкарь итеп булмый. **Курыккан** сүзе урынына башка берәр фигыль кулланылмас дип шулай ук әйтә алмыйбыз. **Аюдан курыккан — урманга бармас** дигәне дә шул ук мәгънәдә йөри бит әле аның. Ләкин монысы инде төрдәш белән мәгънәдәш, ягъни вариант белән синоним арасындагы урта-арадаш форма мәсьәләсе. Анысына кагылмаганда да, **бүредән курыккан — урманга бармаган** мәкаленең кимендә мең варианты һәм вариациясе — күз алдыбызда. Бу юлларны укыган һәр кеше монда тагын күп өстәмәләр кертә ала әле. Шуның өстенә җирле сөйләшләргә хас лексик, морфологик яки фонетик һ. б. төрчәләрне китереп кушсак, дөресрәге, кабатласак, әлеге сан, үтә саранланып әйткәндә, дистә меңнәр белән исәп-

ләнәчәк. Ә шушы ук төрләрнең искергәннәрен кая куябыз? Аннан соң, контекстка җайлаштыру йөзеннән төрлечә «бормалап» куллану, шул исәптән, шигырь метрикасына туры китереп үзгәртү очраклары да бик еш күзәтелә. Җыеп әйткәндә, куллануышта мәкальнең традицион формадан тегә яки бу дәрәҗәдә тайпылуы үзе бер кагыйдәгә әйләнә. Мәсьәләнең шундый ук әһәмиятле тагын бер ягы бар. Кешенең хәтеренә мәкальнең мәгънәсе аның формасына караганда ныграк кереп утыра һәм шулай булгач, озаграк саклана. Шуңа күрә, мәкальне кулланырга теләүче кеше, аның тәгәл формасын (текстындагы сүзләрне, грамматик формаларны һәм стилистик алымнарны) ачык хәтерләмәсә дә, мәгънәсен барыбер әйтеп бирә. Синтаксик яки шигъри формаларның нинди икәнен хәтерләп бетермәгәнгә күрә генә мәкальне әйтүдән тыелып кала алмый ич инде ул. — Ничек диләр соң әле... фәлән диләрме, шундыйрак бер сүз бар бит, — дип ул үзенең исендә калган кадәр тәгәллек белән (ә кайчак яңа формалар да табып) мәкальне сүзенә кыстырып җибәрә. Шартларына карап, мондый үрнәкләр дә зарури рәвештә халыклашып китәләр. Асылда бер үк мәкальнең кимендә мең үрнәгеннән ничәсен җыентыкка алабыз? Утызынмы? Ә калган 970 е ни өчен алынмый? Икенче яктан, алырга дигән утызның барысы да тигез хокуклымы яки берсе төп, иң әһәмиятлесеме? Исәнбәт җыентыгында шундый үрнәкләр күп: **атны урлаткач, абзарны бикләмиләр; ат урлангач, абзар бикләүдә файда юк; атын алдырган — абзарын бикләгән; атын алдыргач, капкасын бикләгән; атын урлаткач — абзарын ныгыткан; атын урлаткач, сараен ныгыткан** һ. б. ш. Югарыдагы уйланулар шушы уңай белән туды. Шул ук вакытта революционер демократ Н. А. Добролюбовның: «Мәкальләрнең систематик басмасында төрле төрдән булган барлык вариантларны бер вариантка кайтарырга кирәк булачак ич», — дигән нигезле фикере дә бар[1].

**ЙОМГАКЛАП** әйткәндә, Нәкый ага, күп елларга сузылган хезмәтен кызганмыйча һәм зур тырышлык куеп, илебез тарихында билгеле эзләрләренә караганда күп баерак эчтәлекле капиталь җыентык эшләде. Халкыбызның рухи дөньясын танып белү юлында бу өч том — зур һәм кадерле хәзинә. Иң тулы мәгънәдә киң катлау файдаланучылар бу китапны яратып каршыладылар, зур кызыксыну белән укыйлар һәм китабына да, авторына да ихтирам белән карыйлар.

Яшь буынны, киләчәк җәмгыять кешесен тәрбияләү өчен киң колачлы көрәш барган бүгенге көндә бу китап — бик актуаль, кирәкле кулланма. Монда туплап бирелгән мәкаль-әйтемнәр рухи культурабызның югары баскычта торуын тагын бер кат дәлилләп, эш сөючән татар халкының мораль йөзе югары булуын, күңеле сафлыгын һ. б. ш кешелеклелек сыйфатларын күрсәтәләр. Зур хәрефтән язылa торган Кешене олылап, хезмәткә дан җырлап, мондагы мәкальләр шул ук вакытта кешедәге барлык кире сыйфатларны катгый кире кагалар, кара искелек тамгасы буларак сакланып калган бу сыйфатлардан арынырга ярдәм итәләр.

Теоретик әһәмияте белән дә бу — фундаменталь әсәр. Ул фольклористика өлкәсендәге барлык карашларны исәпкә алып, критик анализ нигезендә гомумиләштерү һәм үстерү нәтиҗәсе буларак әйтелгән фәнни сүз. Монда хәл ителгән, тикшерелгән мәсьәләләрнең әһәмиятләрен санап торырга урын тар, шулай да бер нәрсәнең астына сызып әйтәсе килә: ӘЙТЕМ төшенчәсе һәм терминын Исәнбәттәгечә мәгънәдә куллану матбугатыбызда ныгысын иде.

Бу китап шул ук вакытта мәкаль-әйтемнәр өлкәсендәге эшләрне дәвам иттерәчәк кешеләргә кадерле бүләк, тикшеренүчеләр өчен мул азык бирә торган бай чыганак, база, тагын да зуррак кыйммәтләр иҗат итү өчен салынган ышанычлы нигез. Яңа илләргә юл ярып баручы мәһабәт корабтай, ул күп кенә яңа проблемалар кузгатты, аларны чишү юнәлешләрен билгеләде, бу өлкәдә яңа перспективалар ачты. Бу хезмәт татар телендәге мәкаль-әйтем фәненә нигез булып яткан бер таш.

Чын мәгънәдә тарихка керергә лаеклы бу өч томлык фундаменталь хезмәт — бүгенге татар тел культурасының югары баскычта торуын янә бер расльй торган җанлы дәлил, тел сәнгатебезнең мәңге яшел агачында өлгереп, Октябрьның 50 еллыгы алдыннан гомуми өстәлгә килгән кадерле җимеш. Материал җыюда катнашкан киң җәмәгатьчелек, аны китап хәленә китереп дөньяга чыгарышуда күп көч куйган дәүләт оешмалары, үз өлешләрен керткән нәшрият хезмәткәрләре тел культурабызның бу әһәмиятле казанышы белән хаклы рәвештә горурлана алалар.

[1] Н. А. Добролюбов. Полн. собр. соч. Т. 6, Л. 1934, стр. 502.

— — ◆ — —

*Фатих Урманчеев*

# ХАЛЫК ХИКМӘТЕ ӘСӘРЛӘРЕ

«Татар халык мәкальләре»нә язган кереш хезмәтендә, аерым мәкальләр һәм алар белән рәттән урнаштырылган аңлатмаларда Нәкый ага Исәнбәт милли фольклористиканың гаять әһәмиятле практик һәм теоретик мәсьәләләрен күтәрә, ул мәсьәләләрне төрле яклап тикшерә һәм хәл итә. Г. Ахунҗановның мәкаль томнары чыгу уңае белән язган мәкаләсендә дә шул ук фикер әйтелә. Мәкальләрне җыеп туплауда һәм фәнни эшкәртүдә Н. Исәнбәт китапларының әһәмияте, аның теоретик фикерләре һәм билгеләмәләре рецензент тарафыннан хаклы рәвештә югары бәяләнгән. Аның бу бәясе белән килешмәскә мөмкин түгел. Г. Ахунҗанов «Татар халык мәкальләр»ен башка телләрдә басылып чыккан күп кенә җыентыклар белән чагыштыра, аның әһәмиятен кире кагылмаслык аргументлар белән дәлилли.

Рецензент Н. Исәнбәт хезмәтендә күтәрелгән һәм җентекләп тикшерелгән мәсьәләләрнең иң әһәмиятлесенә — мәкаль һәм әйтемнәрнең спецификасына, әйтемнәрнең мәкальләрдән аермасына, урта-арадаш төрләргә шактый киң туктала. Мәсьәләне тагы да тирәнрәк тикшерү һәм ачыклау юнәлешендә яңа фикерләр әйтә.

«Татар халык мәкальләр»ен рецензент, хаклы рәвештә, фольклористик хезмәт дип билгели. Чөнки Н. Исәнбәт үзе дә мәкальләрне халык иҗаты әсәрләре дип исәпли»[1]. Г. Ахунҗанов та: бу — ялгыш караш, мәкальләр фольклор әсәрләре түгел дип, кистереп әйтми. Тик ул мәкальләрне һәм әйтемнәрне тел берәмлекләре рәтенә кертә һәм аларның шактый кызыклы лингвистик үзенчәлекләрен ачыклый. Рецензия нигездә лингвистик рухта язылган. Күрәсең, шуңа күрәдер, анда, безнеңчә, бәхәсле фикерләр дә бар. Рецензияне укыгач, бер җитди сорау туа: мәкальләрне фольклор әсәрләре дип карауның фәнни нигезе бармы, әллә ул берьяклы гына карашмы? Әнә шул сорауга җавап эзләп карыйк.

Рус, казакъ, башкорт, үзбәк һәм башка телләрдәге фольклар җыентыкларының, гади хрестоматияләрнең, югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслекләрнең һәммәсендә мәкаль-әйтемгә багышланган бүлекләр табарга мөмкин. Халык иҗатының бу төре турында язылган махсус тикшеренүләрдә дә аларның фольклор әсәрләре булуы турында кат-кат әйтелгән. Татар филологиясендә дә мәкальләр шигъри әсәрләр дип аталалар, халык иҗатының башка жанрлары белән рәттән саналалар һәм тикшереләләр. Кыскасы, мәкальләрнең халык иҗаты әсәрләре булуы — фольклор фәнендә күптән таныйлган хакыйкать.

Г. Ахунҗанов исә мәкаль-әйтемнәр тел берәмлеге, алар фразеология составында өйрәнелергә тиешләр, дигән карашны яклый. И. Оссовецкий мәкаләсеннән алынган бу фикер В. Аникин, В. Гусев кебек күренекле фольклорчылар тарафыннан күптән тәнкыйтьләнгән иде инде[2]. Димәк, И. Оссовецкий карашын фольклорчыларның уртак фикере дип булмый.

Әйтик, фольклор фәне бу мәсьәләдә ялгыш позиция сайлаган, ди. Мәкальләрне халык иҗаты әсәрләре рәтенә кертеп, бик күп галимнәр берьяклы караштә торалар, ди. Бәлки бу, чыннан да, шулайдыр? Рецензент фикеренчә бит «мәкальләрне һәм әйтемнәрне тел берәмлеге дип исәпләү, аларны лингвистик позициядә торып тикшерү — һичшиксез, дөрес караш һәм ул соңгы елларда фәндә урнаша һәм ныгый бара».

Карап карыйк. Рус фразеологиясенең аңлатмалы сүзлеген төзү уңае белән язылган проектның авторы А. Бабкин «фольклор жанры булган мәкальләрнең барысы да фразеологик сүзлектә аңлатылу объекты була алмыйлар», ди. Ул сүзлектә урын алырга тиешле мәкальләрнең үрнәкләрен китерә. Проект буенча фикер алышуда катнашкан кешеләр дә бу мәсьәләдә бер фикергә килә алмадылар. Чөнки арада мәкальләр фразеологик сүзлек объекты була алмыйлар, дип раслаучылар да бар иде. Бу проект буенча әзерләнә торган сүзлекнең әлегә басылып чыкканы юк. Ә менә 1967 елда «Рус теленең фразеологик сүзлеге» исемле икенче бер яңа хезмәт дөнья күрде. Әмма сүзлектәге фразеологик берәмлекләр арасына мәкальләр кертелмәгән. Авторлары «мәкальләр дә, әйтемнәр дә лингвистик төшенчәләр түгел», дип исәплиләр (15 бит). Хәзерге рус әдәби теленең 17 томнан торган сүзлегендә дә мәкальләр фразеологик берәмлекләр дип саналмыйлар. Алар, әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр, цитаталар белән рәттән, аерым сүзләрнең мәгънәсен аңлату өчен кулланылалар. Мондый мисалларны тагы да китереп булыр иде. Әйтик, «Рус мәкальләре һәм әйтемнәре сүзлеге»н төзүче В. Жуков: «Тел белемендә мәкальләргә һәм әйтемнәргә һәркем тарафыннан да дөрес дип кабул ителерлек фикер урнашканы юк», дип яза. Күрәсез, мәкальләргә лингвистик карашның урнашуын исбат итүгә караганда, шуның кире кагылуын дәлилләү җиңелрәк икән.

---

[1] Н. Исәнбәт фикеренчә: «Китап дүрт томда, өчесе мәкальләр, соңгысы әйтемнәр итеп төзелә» (1 том. 256 бит). Шуңа күрә, биредә әйтем мәсьәләсен дә күтәрү иртәрәк булыр.

[2] В. А. Аникин. Русские народные пословицы, поговорки, загадки и детский фольклор. 1957 ел. 10 бит; В. Е. Гусев. Эстетика фольклора. Мәскәү. 1967 ел. 113 бит.

Тарихтан мәсьәләнең үзенә күчик. И. Оссовецкий фикеренчә, мәкальләр, фольклорның башка жанрлары кебек, «башкарылмыйлар», ә бәлки телдә яшиләр, сөйләмдә кулланылалар. Янәсе, шул яклары белән алар халык иҗатының башка төрләреннән аерылып торалар. Чыннан да, мәкальләр халык җырлары кебек җырланмыйлар да, әкиятләр кебек махсус сөйләнмиләр дә. Аерым такмак-такмазалар, кайбер мәзәкләр, халык иҗаты әсәрләренең мотивлары, детальләре, профессиональ сәнгать әсәрләреннән алынган өзекләр, цитаталар кебек, алар сөйләмдә кулланылалар гына. Бәлки, нәкъ менә шушы күренеш үзе мәкальләргә генә хас специфик үзенчәлектер. Халык иҗатының һәрбер төре үзенчә яши ич. Бәетләр әйтелә, җырлар җырлана, әкиятләр сөйләнә. Хәер, биредә бик күп галимнәр тарафыннан әйтелгән фикерләрне кабатлап, фольклор теориясен сөйләп тору кирәк булмас. Н. Исәнбәт җыентыкларының кереш мәкаләсендә һәм аның башка хезмәтләрендә бу турыда күп мәгълүматлар китерелгән һәм тирән мәгънәле фикерләр әйтелгән. Кыскасы, халык иҗаты жанрының спецификасы хакында сөйләгәндә, аның бер генә үзенчәлегеннән — яшәү формасыннан чыгып кына фикер йөртү котылгысыз рәвештә берьяклылыкка китерә. Шуңа күрә Н. Исәнбәт мәкальләрне төрле яклап тикшерә. Аларның барлыкка килүе, туу-үлүләре, яшәүчәнлекләре, эчтәлеге, тематикасы, фәлсәфәсе, шигъри асылы һәм башка үзенчәлекләрен ачыклый. Жанрның спецификасын киң фәнни позициядә торып, җентекләп һәм төрле яклап тикшергәнгә күрә, аның фикер-билгеләмәләре ышандыра, объектив дәреслеккә туры килә.

Рецензент фикеренчә, кайбер галимнәр традиция буенча гына мәкальләрне әле һаман да фольклор әсәре дип йөртәләр икән. Дөньякүләм фольклористикада исә бу традиция бик ерактан башлана һәм тора-бара филология фәнендә тирән тамырлар җәя. Прогрессив традиция буларак, ул татар фольклористикасына да килеп керә. Г. Тукай, Г. Рәхим, Г. Ибраһимов, Г. Толымбай һәм Х. Ярми, И. Надиров хезмәтләрендә шул традиция чагыла. Н. Исәнбәт тә мәкальләрне берничә мәртәбә «халык хикмәте әсәрләре», «халык иҗаты әсәре», «мөстәкыйль әсәр» дип атый. һәм ул, безнеңчә, һичшиксез, хаклы. Автор гомуми фольклористиканың күркәм традицияләрен дәвам итә, аны оригиналь фәнни күзәтүләр, әһәмиятле яңа фикерләр белән баета.

Төрле халыклар иҗатында эчтәлеге, төп мотивлары, сюжет һәм композициясе, шигъри үезнчәлекләре белән бер-берсенә охшаш әсәрләр шактый күп. Халыкара сюжетлар, гомуми урыннар, уртак алымнар фольклор жанрларының һәркайсында диярлек очрый. Шуңа күрә һәрбер халыкның фольклорына, аның аерым жанрларына хас милли үзенчәлекләрне өйрәнү һәм ачыклау фольклористиканың гаять әһәмиятле һәм катлаулы проблемаларыннан санала. Җыентыкка язган кереш хезмәтендә, бигрәк тә аның «Татар халык мәкальләренең хосуси яклары, үзенчәлекләре» дип исемләнгән төп өлешендә Н. Исәнбәт әнә шул мәсьәләне күтәрә һәм уңышлы башкарып чыга. Иң элек автор биредә безнең мәкальләр ничек барлыкка килгән дигән сорауга тулы һәм ышанырлык җавап бирә. Ул халык мәкальләренең барлыкка килүе сәнгатьнең бик борынгы дәверләре, ыруглык җәмгыяте чорлары белән бәйле булуын ачыклый. Н. Исәнбәт халыкның рухи тормышында зур урын тоткан чичәнлек традицияләре, мәкальләрне иҗат итүдә, таратуда кульязма һәм язма китапларның роле турында кыйммәтле фикерләр әйтә.

Жанрның тарихын автор татар халкының иҗтимагый тормышы белән бәйләп тикшерә. Исәнбәт хезмәте мәкальләрнең барлыкка килү чорыннан башлап бүгенге көнгә кадәр үткән тарихын, гаять үзенчәлекле, халык тормышы кебек катлаулы юлын күз алдына китерә. Н. Исәнбәт мәкальләрне халык иҗатының башка төрләре, җырчы-чичәннәр иҗаты, борынгы дастаннар, риваять һәм легендалар, мәсәлләр, мәзәкләр белән бәйләп тикшерә.

Н. Исәнбәт хезмәтендә «бармак башыдай кечкенә әсәр» булган мәкальләрнең шигъри үзенчәлекләре, тел-стиль чаралары, композициясе, алардагы антитезалар, киная, астан көлү кебек шигъри алымнар да җентекләп тикшерелә. Автор үзенең һәрбер теоретик фикерен, шулай ук мәкальләрнең эстетик асылы турындагыларын да, конкрет мисаллар белән дәлилләп бара. Мәкальләрдә киң таралган янәшәлекләр турында, мәсәлән, ул болай яза: «Мәкальләрнең куш юллы яки күп юллы булганының башында, гадәттә, табигатьтән яки тормыштан алынган берәр бизәкчә (орнамент) бирелә дә аннан төп мәгънәне аңлаткан буыны әйтелә» (1том. 150 бит). Мисаллар рәвешендә ул түбәндәге мәкальләрне китерә: «Агачына күрә алмасы, анасына күрә баласы», «Кайта чапкан яу яман, кайтып килгән кыз яман»... Шундый янәшәлекләрнең килеп чыгуын ул халыкның тормыш шартлары, карашлары, борынгы бабаларыбызның «табигатьне үзләредәй җанлы» дип ышанулары белән бәйләп өйрәнә.

Мәкальләрнең үлчәмен, ритмикасын һәм метрикасын тикшерү нәтиҗәсендә Н. Исәнбәт түбәндәге фикергә килә: «...мәкальләр сөйләм әсәре булсалар да, күпчелегендә көйләм шигырь хасиятләренә дә ия булып торалар. Шул яклары белән мәкальләр соңгы елларда татар шигырь төзелеше турында чыккан бәхәсләр өчен дә бик әһәмиятле чыганак булып төшәләр дип беләм» (1 том. 199 бит). һәм чыннан да, күптән түгел «Казан утлары» журналында Х. Госманның «Халыкның үзеннән» дигән мәкаләсе басылып чыкты (1967 ел. 11 сан). Татар шигыренең хәлиткеч спецификасын аңлатыр өчен, Х. Госман халык иҗатына, халык мәкальләренә мөрәҗәгать итә. Чөнки мәкальләр — искиткеч камилләшкән, шигъри әсәрләргә хас төп сыйфатларны берләштергән жанр. Ул гына да түгел, язма шигырьнең орлыгы, нигезе мәкаль һәм табышмаклардан алын-

ган. Кагыйдә буларак, мәкальләр билгеле бер шигырь төзелеше нигезендә барлыкка киләләр. Әнә шул сыйфатлары гына да аларны башка төр фразеологик берәмлекләрдән аерып карарга мөмкинлек бирә. Бернинди шигъри системага нигезләнмәгән тел берәмлекләре ярдәмендә генә татар шигыре төзелеше мәсьәләсен күтәреп булыр иде микән?..

Мәкальләрнең Н. Исәнбәт хезмәтендә ачыкланган үзенчәлекләре аларны халык иҗатының, хәтта язма әдәбиятның да барлык төр шигъри әсәрләре белән рәттән куеп өйрәнергә мөмкинлек бирә һәм, һичшиксез, фольклор жанры булуын раслый.

Ниһаять, «Татар халык мәкальләре»ндәге аңлатмалар, риваять һәм легендалар, мәсәлләр, мәзәкләр турында берничә сүз. Г. Ахунҗанов фикеренчә, «мәкаль-әйтем фольклор әсәре дигән традицион карашны берьяклы гына аңлап абсолютлаштыру, иң элек, чынлыкта да әсәр булган мәзәкләрне җыентыкка кертүдә күренә». Безнеңчә, объектив дөреслеккә туры килә торган традицион карашны бер дә абсолютлаштырып торасы юк. Җыентыкка мәзәкләр кертү белән мәкаль-әйтемне әсәр дип аңлау арасында исә бернинди бәйләнеш юк. Мәкальләрне әсәр дисәк тә, әсәр түгел — тел берәмлеге дисәк тә, мәзәкләр җыентыкка кергән булыр иде. Чөнки алар кирәк. Җыентыкта мәкальләргә бернинди мөнәсәбәте булмаган әсәрләр юк дип әйтергә мөмкин. Рецензент үзе үк дөрес күрсәткәнчә, алар аерым мәкальләрнең конкрет чыганакларын ачыкларга ярдәм итә, мәкальләрнең мәгънәсен тирәнрәк һәм дөресрәк аңларга булыша, жанрлар арасындагы бәйләнешләрне, уртаклыкларны билгели. Шул ук вакытта аларның күпчелеге — халык иҗатының мөстәкыйль әсәрләре. Гомумән, җыентыктагы мәкальләрне һәм алар белән рәттән килгән аңлатмаларны, төрле әсәрләрне бер-берсеннән аерып карау мөмкин түгел. Чыннан да, алар берберсен баетып, тулыландырып торалар һәм хәзерге татар фольклористикасына гаять күп яңа мәгълүматлар өстиләр. Төрки халыклар иҗатында билгеле булган Җирән Чичән, Алдар Күсә, татар халык иҗатына хас милли персонажлар — Үлмәс Сылу, Рәхми Тылмач, Мәнди, Мокыт һәм башкаларның безнең фольклорда шактый таралган образлар булуы XX йөздә чыккан башка фольклористик җыентыкларда яки хезмәтләрдә бу кадәр киң һәм тулы чагылганы юк иде. Янсә тагын бер мисал. Татар мифологиясе, халкыбызның борынгы ышанулары, гореф-гадәтләре, йолалары безнең фольклор фәнендә бик акрын өйрәнелә. Аларны өйрәнүчеләр өчен Н. Исәнбәт җыентыклары — бай конкрет материаллар һәм фәнни күзәтүләр чыганагы. Мәсьәләнең бу ягына кагылгач, тагын бер проблема турында бер-ике сүз әйтәсе килә. Халык иҗатының төп өлеше борынгы әсәрләр дип исәпләнә. Әмма мәсьәләгә конкретрак килгәндә, без, гадәттә, фараз итүләр белән чикләнергә мәҗбүр булабыз. Фәнни аппараты бик бай Исәнбәт томнары аерым әсәрләрнең туу-яшәү чорларын күрсәтеп бара. Шуңа күрә алар халык иҗатын тарихи аспектта өйрәнү өчен дә җитди чыганак булып торалар. Әйтик, без татар халык иҗатының Болгар янсә Казан дәүләте чорына хас үзенчәлекләрен өйрәнергә уйлыйбыз икән, «Татар халык мәкальләр»ен һич тә читләтеп үтә алмыйбыз.

Тулаем алганда, мәкаль томнары татар фольклористикасының әллә никадәр проблемаларын күтәрә: халык тарихы һәм фольклор; борынгы дәвер фольклоры; халык иҗаты эстетикасы; татар халык иҗатының милли үзенчәлекләре; төрле халыклар, бигрәк тә төрки халыклар иҗаты арасындагы уртаклыклар һ. б., һ. б.

Китапларга мәкаль булмаган материалларның да кертелүе турында тагы шуны әйтергә кирәк. Халык иҗаты җыентыкларында аерым әсәрләргә киң аңлатмалар бирү, башка жанр әсәрләреннән янәшәлекләр китерү фәнни практикада шактый киң таралган күренеш. Һәм ул озак эзләнүләрне, фәнни тикшеренүләрне таләп итә. Н. Исәнбәт җыентыгы моның шулай икәнен бик ачык күрсәтә.

«Татар халык мәкальләре» кебек фундаменталь хезмәттә бернинди дә кимчелек юк, кайсы яктан гына карасаң да, алар идеаль томнар дип әйтү бөтенләй үк дөрес булмас иде, әлбәттә. Мәсәлән, башка теләрдән китерелгән янәшәлекләр арасында аерым ялгышлар да очрый. Мәкаль кайсы телдән алынса, шул тел алфавиты һәм орфографиясе нигезендә бирелергә тиеш иде. Әйтик, немец, француз, инглиз телләрендәгеләре кебек. Әмма рус алфавитын үзләштергән төрки телләрдән алынган мәкальләрнең кайберсе шактый буталчык бирелгән. Казакъ теленнән алынган мәкальләрне, мәсәлән, казакъча да, татарча да дөрес укып булмый. Мондый вак җитешсезлекләр рецензент тарафыннан да дөрес күрсәтелгән. Мәсәлән, ул мәкаль дип тәкъдим ителгән аерым әсәрләрнең жанр таләпләренә тулысынча җавап бирмәүләренә игътибар итә һәм конкрет мисаллар да китерә.

«Татар халык мәкальләре» кебек зур күләмле хезмәттән аерым вак-төяк кимчелекләр табарга мөмкин, әлбәттә. Әмма кабатлап әйтик, Нәкый ага Исәнбәтнең күп еллык эзләнүләр нәтиҗәсе булган фәнни хезмәте совет фольклористикасының прогрессив традицияләрен дәвам итә. Ул татар халык иҗатын өйрәнүнең яңа чоры — аерым жанрларның теориясен һәм тарихын һәрьяклап тикшерү, бер жанрга караган әсәрләрне мөмкин кадәр тулы итеп бастырып чыгару этабы башлануын күрсәткән хезмәтләрнең классик үрнәге.

——◆——

*Миркасыйм Госманов*

# МӘКАЛЬЛӘР — ТАРИХИ ЧЫГАНАК

Җир түп-түгәрәк, тормыш гаҗәеп катлаулы. Мәкальләр дә шулай. Аларга һәркем үзенчә якын килә. Телче, мәсәлән, тота да аларны тел берәмлеге буларак тикшерә. Фольклор галиме исә, сүзне үз ягына борып, фольклор жанры буларак, мәкальләрнең урынын билгели, аларның үзенчәлекләрен аңлата. Берәр әдәбиятчы, әйтик, шигырь белгечә эшкә алынса, мәкальләрнең шигъри хосусиятләрен ачып күрсәтер иде. Атеист та читтә кала алмый, этнограф белән сүзлекче дә...

Мәкальләр тирәсендә төпченеп йөрүчеләрнең саны болар белән генә чикләнми әле. Дөньяда тарихчылар дигән халык та бар. Әмма шундый сорау туарга мөмкин: тарих язганда мәкальләргә таянып буламы соң? Әйе, проблема катлаулы. Килеп тотындыңмы, теоретик сораулар да, практик мәсьәләләр дә башыңа ишелеп төшәчәк. «Бу әле баласы, мичтә ята анасы» дип, бер түтәй әйтмешли, кечерәк, хосусыйрак мәсьәләләрдән олыраклары килеп чыгачак. Шуңа күрә бирәдә андый мәсьәләләрнең барысына да тукталмыйбыз. Хәттә аларны санап чыгуны да бурыч итеп куймыйбыз. Бары мәкальләрдә тарих язар өчен материал бармы? дигән сорауга гына җавап эзләп карарбыз. «Күршең сукыр булса, күзеңне кыс», ди халык. Шулай итеп, башка каләмдәшләрнең тәҗрибәсеннән чыгып, мин дә мәсьәләнең бер генә ягына тукталам.

Моннан йөзләгән еллар элек халкыбыз күчмә тормыш кичергән, диләр. Янәсе, тирмәләрдә торып, атларга атланып, сахраларда күченеп йөргәннәр. Ышаныйк, ди. Ләкин бер сорау туу бик ихтимал: бабаларыбыз яшәгән ул тирмәләр ничегрәк булган? Моңа конкрет җавап бирерлек язма истәлекләр бездә юк диярлек. Ә борынгы сәяхәтчеләрнең (Плано Карпини, В. Рубрук, Ибн Баттута һ. б.) хәбәрләренә килсәк, шөбһәләнергә туры килә. Татар дип алар я монголларны, яки казакъ һәм нугайларның бабаларын атаганнар. Кыскасы, борынгы бабаларыбызның «тирмә» дигәннәрен көрд һәм иран кабиләләре яши торган чатырлардан, Алтайдагы вак-вак төрки кабиләләр файдаланган кабык куышлардан, яисә якутлар уйлап тапкан тирә чумнардан аеру шактый кыен. Дөрес, сүзне артык куертып тормыйча, аналогияләр ярдәмендә дә фикер йөртеп булыр иде. Мәсәлән, безгә иң якын булган төрки халыклардан башкорт һәм казакъларның тирмәләрен алырга мөмкин. Ләкин аналогия дәлилсез кала. Һәм берәр скептик галим: «Кайда факт? Китер документ!» — дип өстәлгә сукса...

Чыннан да, кайда алар? Мәшһүр Рәшид әд-дин әсәре дә, төпченүче Плано Карпини язмалары да, татарларны гел күзәтеп торган рус елъязмалары да бирәдә ярдәм итә алмыйлар. Татарларның борынгы тарихи әсәрләре исә, аларның серле тирмәләре кебек үк, юкка чыкканнар. Нишләргә? Менә шунда инде безгә халык иҗаты әсәрләре — мәкальләр ярдәмгә килә. «Ай-һай минем үз өем, киң сараем, бүз өем», — дигән бераү (13295)[1]. Икенчесе исә «Киез өем — бүз өем, керсәм-чыксам — үз өем», — дип шөкер иткән (13307). Бу ике мәкальдән иң элек борынгы өйләрнең ак төстәге (бүз) киез белән ябылган булуын беләбез. Ә «Түгәрәк өйнең түре юк» дигән мәкаль исә аның формасы турында хәбәр итә. «Ишектән кереп, төнлектән чыкма» (13387), «Төнгә кунак — төнлек ябуы» (16712) кебекләреннән шул өйнең, кешә кереп чыгарлык ишегеннән тыш, төнлек дигән тагын бер тишеге булуын да ачыклыйбыз. Ә нигә кирәк булган ул? Моңа да мәкаль җавап бирә: «Төнлегеннән җил өрми, ишегеннән кеше керми» (13402). Димәк, өйгә һава һәм яктылык керсен өчен ясалган, төннәрен ябып куя торган махсус тишек икән ул төнлек дигәннәре... Кыскасы, мәкальләр ярдәмендә борынгы татар тирмәсенең кыяфәтен күзаллап була икән. Ул ак киездән эшләнгән, түгәрәк формалы, ишеге һәм ябыла торган төнлеге бар. Димәк, борынгы татар тирмәсе элекке күчмә башкорт һәм казакъларның җыелма өйләренә охшаган булган икән. Менә инде баягы коры аналогия документлар белән тәэмин ителде, материаль көчкә әверелде.

Әмма күчмә тормышның атрибуты бер тирмә генә түгел. Сахраларда күченеп йөрер өчен транспорт та кирәк. Бу мәсьәләдә дә татар мәкальләре бай мәгълүмат бирәләр. Ат образы тирәсендә оешкан хикмәтләрнең меңләгән булулары, халыкның «ир канаты — ат», «атсыз егет ир булмас» дип чыгарган кискен хөкеме, уңган егет белән булдыклы ирне, игелекле яхшы хатынны да атка чагыштырып сынаулары очраклы хәл түгел, әлбәттә. Мисалга 5589—6346 һәм 10506—10758 номерлары белән бирелгән мәкальләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Дөрес, ир-егет өчен яхшы ат җир сукалап, иген игәргә дә бик кирәк. Ләкин, игътибар белән каралса, әлегә мәкальләрнең форма һәм эчтәлек ягыннан иң борынгыларында сүзнең м е н е ш аты турында баруын аңлавы читен түгел. «Кызлы өйгә кырык ат бәйләнер» (8845) дигән мисалда да сүз камыт кием, арба тарткан игенче алашасы түгел, ә менеш аты турында бара. Табигый, соңгы дәвер, утрак тормыш чорында туган мәкальләрдә дә ат образы еш очрый. Арбага җигелеп, сука сөйрәгән килеш тә хикмәтләргә кер-

[1] Җаялар эчендәге саннар Н. Исәнбәт китапларындагы мәкальләрнең тәртибен күрсәтә.

гән ул. Мондый мисаллар тирмә һәм ат образы белән генә дә чикләнми. Татарлар арасында язылып алынган хикмәтләр арасында казакъ, нугай һәм башка халыкларда киң таралган Алдар, Коркыт Ата, Җирән Чичән кебек шәхесләргә нисбәт ителә торган канатлы сүзләрнең еш очравы да (2972, 3088, 19893, 19368, 19390, 2934, 11203, 11204, 13295, 14977, 15152 һ. б.) игътибарга лаек. Аларның язмага теркәлмәгәннәре тагы да күбрәк булырга тиеш.

Тарихи җәһәттән мәкальләрнең иң зур әһәмияте итеп, аларда сакланып калган борынгы социаль-иҗтимагый атамаларны күрсәтергә кирәк. Ихтыяҗсыз бернинди сүз туып яши алмый, махсус атамалар бигрәк тә. Димәк, халык телендә теге яки бу исемнең булуы шул исем белән аталган затның да аның тормышында нинди дер урын биләвен күрсәтә. Бер мисалга киңрәк тукталыйк.

Кайбер язма чыганакларда мәгънәсе ачылып җитмәгән «карачи» дигән сүз очрый. Контексттан чыгып, сүзнең берәр олы дәрәҗә белдерүен шәйләргә мөмкин. Урта Азия һәм Кырым ханлыклары тарихларына караган материалларда бар бу сүз. Ләкин социаль тарихи терминология — бик четрекле өлкә, анда җиңелчә аналогияләр белән генә котылып булмый. Атама төрле халыкта төрле мәгънәдә йөргән кебек, теге яки бу халыкның үзендә дә төрле дәвердә төрле функция үтәгән. Фикер аңлаешлырак булсын өчен, «карачи»ны куеп торып, «чура» сүзен алыйк. Үзбәк телендә ул «чури» формасында кол хатынкыз, ягъни кәнизәкне белдерә. Кыргыздагы «чор»да шул ук мәгънәдә. Караим телендә исә ул «хезмәткәр» мәгънәсендә йөри. Шул ук тамырдан үзгәргән уйгурча «җора» җәпнең (икенең) берсен белдереп, дуска карата да кулланыла. Казакъ телендә «чура» (шора) мирза, бәк, би мәгънәләрендә әйтелә. Ә татар теленә килсәк, чура атамасының кемгәдер экономик һәм политик бәйләнеше булган затны белдерүен аңлап була. Ләкин төрле дәвердә ул төрле төсмер алган. Мәсәлән, Алтын Урда чорында ханнарның политик вассалы, гаскәр башы булган кешеләргә әйтелгән [1]. Соңрак исә, мәсәлән, XVII гасырда крепостнойларны да чура дип атаганнар. Кыскасы, социаль тарихи терминология бик зур саклык һәм конкретлык таләп итә. Биредә фәлән телдә шулай дип кенә котылып булмый. «Карачи» сүзе белән дә шундый ук хәл килеп чыгу ихтимал. Моннан котылу өчен бу сүзнең татар телендәге мәгънәсен табарга кирәк. Әмма, алда әйтелгәнчә, безнең тарихи язма чыганакларыбыз юк дәрәҗәсендә. Ярдәмгә тагы да мәкальләр килә. Урта гасырларда иҗат ителеп, телдән телгә күчә-күчә, безнең көннәргә килеп җиткән борынгы мәкальләр арасында «Карачи хан төсендә, хатын ир төсендә», «Хан карачисыз булмас, дау арачысыз булмас», «Ханның эше карачига, байның эше уракчыга төшәр» кебек хикмәтләр бар. Сүзнең мәгънәсен «Келәмгә биргесез алача бар, ханга биргесез карача бар» мәкале тагын да яхшырак ачыклый. Димәк, «карачи» дигәнебез дәүләт административ системасында иң югарыда торган дәрәҗәләрнең (баш киңәшче, хан урынбасары һ. б.) берсе икән [2].

Бүгенге телебездән төшеп калган, әмма мәкальләрдә сакланган тархан, аталык, сәет, ясавыл, чиру кебек атамалар белән дә (1042, 11605, 11825, 12507, 14225, 19433, 26217) шундый ук тәҗрибә ясап булыр иде. Ә менә «түрә» сүзенә махсус тукталырга кирәк. Элекке телебездә бу сүзнең чиновник, башлык мәгънәләрендә йөрүе мәгълүм. Түрәләр, әлбәттә, сыйнфый җәмгыять, дәүләт өчен зарури социаль категория. Моны халык та билгеләп уза: «Җир түбәсез булмас, ил түрәсез булмас». Халык шул ук вакытта түрәләрнең социаль һәм мораль йөзләрен дә яхшы белгән: «Елан еланның койрыгын узмас, түрә түрәнең бойрыгын бозмас», «Бер түрәгә дау килсә, түрәләр сөенер, күп түрәгә дау килсә, түрәләр берегер». Болар, әлбәттә, билгеле фактлар. Ләкин хикмәт шунда, халык мәкальләре безгә түрә сүзенең бик борынгы бер мәгънәсен дә бирә. Мәсәлән, «Аталы үз түрәсен үз итәр», «Батыр уртак, бай уртак, түрәсе гадел би уртак» кебек мәкальләрдән түрә сүзенең хөкем мәгънәсендә йөрүен дә ачыклыйбыз. Борынгы татарларда гамәлдә булган юридик нормаларны тикшерүчеләр өчен мондый фактларның әһәмияте бәхәссез.

Борынгы мәкальләрдә «кол» дип атала торган бер социаль катлам турында да хәбәрләр бар. «Кол» турында күп сөйләп торасы юк кебек. Аның мәгънәсе билгеле. Әмма «кол» сүзеннән чыгып, бездә дә борынгы Юнан дәүләте һәм Рим империясендәге кебек классик кол биләүчелек төзелеше булган икән дип уйларга ярамый. Ике башка дәвер, кабатланмас иҗтимагый шартлар. Бездә кол биләүчелек феодализм строе белән бергә үрелеп үскән. Икенчерәк итеп әйткәндә, татарлардагы «кол»ның мәгънәсе киңрәк. «Сатсам — полым [3], асрасам — колым», «Күп уйлаган кол кача алмас», «Колда көн булмас, йөгерек атта сын булмас»... Бу мәкальләр кол биләүчелекнең татарларда шактый киң таралган булуы турында сөйлиләр. «Коллаучыга кыз ошатып булмас» дигән мәкаль исә коллар белән махсус сәүдә итүчеләр булуы хакында хәбәр итә. Ләкин татарларда хатын-кыз колларның махсус исемнәре дә булган. Мәсәлән, «көң». Бу факт безнең тарихи әдәбиятта бөтенләй чагылмаган. Ә аның мисаллары шактый: «Кызын асрый белмәгән көң итәр, улын асрый белмәгән кол итәр», «Кол кияүгә көң җиңгә».

[1] «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 6 сан. 151 бит.

[2] 26194 номерлы мәкальгә бирелгән аңлатмада «карачи» «свита» (сарай хәдимнәре) сыйфатында тәкъдим ителә. Мондый аңлатма чынбарлыкны чагылдырып җиткерми, әлбәттә.

[3] Пол — Алтын Урда дәверендә акча берәмлеге.

Әгәр бу мәкальләрдә сүз гомумән яисә борынгырак дәверләрдәге коллар турында барса, «Ат ирдән, кол баярдан качар» дигәнендә колдан бигрәк крепостной күздә тотыла. Димәк, колның мәгънәсе дә төрле дәвердә төрлечә булган икән.

Борынгы җәмгыятьнең төрле катламнары турында сөйләгән кебек, мәкальләр шул чордагы хәрби төзелеш, сугыш кораллары хакында да кызыклы гына мәгълүматлар бирәләр. Сүзне озакка сузмас өчен, бер генә мисал китерик: «Батыр бер уклык». Ә бу уклар үзләре нинди булган соң? Моңа да мәкальләр җавап бирә: «Бер агачтан уклык та чыгар, сөңге саплык та чыгар», «һәр кәкре агачтан җәя булмый, һәр төзеннән ук булмый». Димәк, ук нык, төз агачтан ясала торган булган. Өченче мәкальдән укның башында тимер булуын аңлыйсың (27476). Ләкин бездә «Юньсез ир — йонсыз ук» дигән мәкаль дә бар. Күрәсез, җәя укларының сабына йон да кыстырганнар икән. Тик нинди йон ул? Тагын мәкальләр могҗиза күрсәтә башлый: «Ике карчыга сугышканда, киекчегә йон файда», «Кара кошка ук тиган, каерылып караса — үз йоны». Шулай итеп, төз агачны юнып сап ясаганнар, аның башына тимер куеп, төп ягына кош кауырые кыстырганнар. һәм ук әзер...

Мондый мисалларның санын күп мәртәбәләр арттырып булыр иде. һәм без язма истәлекләр аз сакланган чорлар турында шундый ук гыйбрәтле мисаллар табар идек (мәкальләрнең спецификасын ачыграк күрсәтер өчен, югарыда кайбер яхшы билгеле фактларга да киңрәк тукталдык). Татар халкының борынгы ышанычы, йола һәм гореф-гадәте хакында да, кием-салым, савыт-сабасы турында да мәкальләрдән мәгълүматлар табар идек. Элекке халык календаре, халык медицинасы турында белергә теләсәк тә, без мәкальләргә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрбез. Шулай ук бу сүз энҗеләреннән тагын халкыбызның төрле һөнәр-кәсепкә карата нинди мөнәсәбәттә булуын, аның туган ил, тыныч хезмәт турындагы уйларын да белербез.

Ләкин бер нәрсәне ассызымлап әйтергә кирәк: мәкальләр нигезендә генә «фәлән елны мондый вакыйга, теге елны шундый эшләр булган» дип тарих язып булмый. Шуның белән бергә, югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, мәкальләргә таянып бик катлаулы мәсьәләләргә ачыклык кертергә мөмкин. Мәкальләр безгә тарих канвасын түгел, бәлки катлаулы узганның аерым детальләрен бирәләр. Язма чыганаклар аз вакытта мондый аерым фактлар да алтын бәясенә йөри. Кыскасы, халыкның социаль-иҗтимагый тарихын, борынгы рухи культурасын, материаль байлыгын тикшергән гыйльми хезмәтләрдә мәкальләребез фикерләрне раслаучы дәлилләр, иллюстрацион материаллар һәм ачыклаучы фактлар булып хезмәт итә алалар. Ә бу аз нәрсә түгел. Язма истәлекләрдә күп вакытта нәкъ менә шундый моментлар җитеп бетми. Димәк, чыганак буларак, мәкальләр бик әһәмиятле, шул ук вакытта үзенчәлекле байлык икән.

Татар мәкальләре тарихи юнәлештә бер дә тикшерелмәгән әле. Фәнебезнең бу өлкәсе башлану алдында гына тора. һәм киләчәктә берәр галим мәкальләрне тарихи планда тикшереп чыгарга теләсә, ул Нәкый ага Исәнбәтнең хезмәтенә мөрәҗәгать итмичә бер адым да атлый алмаячак. Чөнки мәкальләребезнең бетмәстәкәнмәс байлыгын ачу, ул хәзинәнең культурабыз, тарихыбыз өчен зарури катламнары белән якыннан танышу бары шушы җыелма аша гына мөмкин булды. Бу өч томның материалы беркайчан да искермәячәк. Бүгенге көн тарихчылары гына түгел, киләчәк буын галимнәре дә аксакал әдибебез алдында бурычлы булачаклар.

Шулар өстенә, Исәнбәт җыелмасының әһәмияте бер татар дөньясы белән генә дә чикләнми. Бу хезмәт фольклористикабызны олы юл, киң мәйданга чыгарып, барлык СССР халыклары культурасының олы дәрьясына мул өлеш булып кушылды. Халкыбыз хикмәтләре үлемсезлеккә күчтеләр. Алар белән бергә галим хезмәте дә вакыт киңлекләренә узды.


—◆—

*Рафаэль Мостафин*

# БАТЫРЛАР ЕЛМАЕП ҮЛДЕЛӘР

## *Өченче очерк*

Почтальон чит ил маркалары ябыштырылган зур гына бер хат китерде. Юка кәгазьләргә юл араларын да калдырмыйча машинка белән язылган ул хат Италиянең Кремона шәһәреннән, инде миңа таныш булган Рениеро Ланфрединидан иде.



*Рениеро Ланфредини.*

Рениеро Ланфредини — Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең соңгы көннәрен күреп белгән бердәнбер кеше. Ул берничә ай Берлиндагы Шпандау төрмәсендә Җәлил һәм Фуат Булатов белән бер камерада утырган. Җәлилчеләрне үлемгә алып киткәннәрен үз күзләре белән күргән. Ә төрмәдән азат ителгәннән соң, үзе кичергән хәлләрне тасвирлап, «Тоткынлыктагы көндәлегем» исемле бер китап та язган. Ләкин аны дөньяга чыгара алмаган. Аның язуына караганда, китап бастыру Италиядә бик кыйммәткә төшә икән.

Минем үтенечем буенча, шул көндәлекләренең җәлилчеләргә кагылышлы өлешен Ланфредини Казанга җибәргән. Аның язмалары белән таныштыра башлаганчы, Рениеро Ланфрединиының үзе турында берничә сүз.

Җәлил һәм җәлилчеләрнең фашистларга каршы алып барган тиңдәшсез көрәшләре мәгълүм булгач, алар хакында материал җыю эше башлана. Башта бу эшкә татар язучылары Гази Кашшаф, Шәйхи Мануур, рус язучылары Юрий Корольков, Константин Симонов, Бельгия шагыйре Роже Бодар алына. Тагын күпмедер вакыт узгач, немец публицисты, Советлар Союзының якын дусты һәм Муса поэзиясен чын күңеленнән яратучы Леон Небенцаль дә кушыла. Ул элекке немец төрмәләре архивларыннан Җәлил һәм аның көрәштәшләренә кагылышлы документларны эзләтә. Аның үтенече буенча, архив хезмәткәрләре фашизм тарафыннан корбан ителгән кешеләрнең исемнәре теркәлгән йөзләрчә томнарны

карап чыгалар, җәзалап үтерелгән әсирләрнең меңнәрчә карточкаларын тикшерәләр. Әмма бу эзләнүләр көткән нәтиҗәне бирми. Хәер, моңа әллә ни гаҗәпләнерлек тә түгел. Бердән, гитлерчылар тарафыннан юк ителгән миллионнарча корбаннар арасыннан берничә кешенең документларын табу салам кибәненнән энә эзләү кебек читен һәм ышанычсыз эш. Икенчедән, төрмә архивлары үзләре дә тулы сакланмаган. Кайберләренә Берлинны утка тотканда зыян тигән, ә кайберләрен качып киткәндә гестапочылар үзләре юкка чыгарганнар.

Архивларда эзләнү уңай нәтиҗә бирмәгәч, Леон Небенцаль башка юл белән китә. Ул Гитлер төрмәләрендә рухани булып эшләгән кешеләрнең барысына да хатлар яза, алардан Муса Җәлил һәм унике татар тоткыны турында сорый. Озак та үтми, Небенцальгә Шпандау төрмәсенең элекке руханиы Георгий Юрыткодан җавап килә. Ул 1944 елның җәендә Шпандау төрмәсендә унике татар тоткыны утырганлыгын яхшы хәтерли һәм аларның барысы да шул елның көзендә җәзалап үтерелгән булырга тиешләр, дип җавап бирә. «Мин, — ди ул, — Муса Җәлилне дә хәтерлим. Католик рухание буларак, аның янына кереп йөрдем. Аңа Гете китапларын алып килә идем. Яхшы күңелле, тыныч табигатьле кеше булганга ихтирам итә идем мин аны. Мусаны Шпандау төрмәсендәге тоткын иптәшләре дә бик яраталар иде. Камерада ул бер инженер белән утырды, ләкин мин аның исемен хәтерләмим[1]. Җәлил миңа якташларын рус солдатларына каршы сугышмаска өндәгәне өчен үлемгә хөкем ителгәнлеген сөйләде».

Небенцаль җәлилчеләрнең ничек һәм кайда җәзалап үтерелүләрен сорагач, Юрытко бу мәсьәләдә хәтеренә ышанып җитә алмавын әйтә. «Әмма, минем уемча, тоткын татарларның барысын да аткан булырга тиешләр. Тоткыннарны, гадәттә, Шпандаудан берничә километр көньяк-көнбатыштагы Зеебург тирында аталар иде», — ди.

Муса Җәлил турындагы романына материал җыю нияте белән, 1958 елда Шәйхи Маннур Германиягә бара һәм Гатовта (Көнбатыш Берлин) яшәүче Георгий Юрытко белән очрашып сөйләшә. Юрытко Шәйхи Маннурга да Муса Җәлилне бик мактап сөйли. Әмма шагыйрьгә шәхси китапханәсеннән Гетенең «Фауст»ын алып килүен әйтүдән башка, телгә алырлык яңа мәгълүматлар бирә алмый. Ш. Маннур Муса кулында булган «Фауст» китабын карарга тели, тик, кызганычка каршы, Юрыткода ул китап сакланмаган икән. Сораштыра торгач, Юрытко Җәлил һәм Булатов белән бер камерада алар кебек үк үлем җәзасына хөкем ителгән, әмма хөкем карары үзгәртелеп, соңыннан исән калган ниндидер бер Италия солдаты да утырганлыгын әйтә. Әмма Юрытко ул кешенең исем-фамилиясен хәтерләми. Ш. Маннур сораштыруын дәвам итә һәм шунда, сүз арасында, Юрытко ул итальянга Дантеның итальян телендә басылган «Иләһи комедия»сен укырга биреп торган булуын исенә төшерә. Бәхеткә каршы, ул китап Юрыткода әле дә исән була. Бик җентекләп карый торгач, Ш. Маннур әлеге китапның бер битендә карандаш белән итальянча язылган язу очрата. Утыз җиде яшьлек хәрби әсир Рениеро Ланфредини булган ул Италия кешесе. Китапка Ланфредини үзенең Италиядәге адресын да язып калдырган икән.

Ш. Маннур китапның Ланфредини язган битен Юрыткодан сорап ала һәм аны Леон Небенцальгә күрсәтә. Шул ук көнне Небенцаль Италиягә хат яза. Әсирлектән кайтканнан соң тору урынын сигез тапкыр алыштырган булуына да карамастан, Италия почтасы барыбер ахыр чиктә Ланфрединины эзләп таба һәм хатны аңа тапшыра.

Үзенең элекке язмалары нигезендә, Рениеро Ланфредини Мусаның фашистлар тоткынлыгындагы тормышын ачыкларлык кайбер яңа фактлар китерә. Шулардан иң әһәмиятлесе җәлилчеләрне кайчан җәзага тарту мәсьәләсенә карый.

Мәгълүм булганча, Мусаның «Моабит дәфтәрләре»ндәге соңгы шигыре 1944 елның 1 гыйнварында язылган. Шуннан чыгып, Мусаларны 1944 елның гыйнварында җәзалап үтергәннәр дип уйлаганнар иде (Җәлил турындагы күп кенә мәкаләләрдә һәм фәнни хезмәтләрдә дә шул ук дата күрсәтелеп килде). Әмма соңыннан, Мусаның дусты һәм көрәштәше Абдулла Алиш язган хат Бельгия аша туган илгә килеп җиткәннән соң, бу датаның бик үк дөрес түгеллеге ачыкланды. Алиш хатында: «Суд 1944 елның

[1] Сүз Фуат Булатов турында бара — Р. М.

7 февралендә Дрезден шәһәрендә булырга тиеш», диелгән. Шулай ук кемнәр хөкемгә тартыласы һәм ни өчен гаепләнәчәге дә әйтелгән. «Легионерлар дип аталып йөртелә торган татар хәрби әсирләре арасында листовкалар таратуда гаепләнеп, 1943 елның августында кулга алындым. Минем белән түбәндәге иптәшләр дә кулга алынды:

1 Муса Җәлил — Казан шагыйре.
2 Гариф Шабаев — финанс хезмәткәре, Ташкенттан.
3 Сәйфелмелеков — Үзбәкстан сәүдә халык комиссары урынбасары.
4 Фуат Булатов — Казан инженеры.
5 Әхмәт Симаев — Мәскәү журналисты һәм легионнан 20—25 кеше.

Без Берлин төрмәсендә ярты ел утырдык. Килдем, көрәштем, киттем. Күрәсең, безнең язмыш шулайдыр инде. Без соңгы сулышыбызга кадәр үз халкыбызга турылыклы булып калабыз. Эх, яшисе килә, сезне күреп баштан кичкәннәрне сөйлисе килә, кадерлеләрем... Бик күп язган һәм язарга уйлаган әйберләр безнең белән китә...»

1944 елның 28 январенда язылган бу хаттан күренгәнчә, Абдулла Алиш судның кайчан булырга тиешлеген яхшы белгән һәм үзләренә үлем җәзасы биреләчәгенә дә шикләнмәгән.

Шушы хатка нигезләнеп, җәлилчеләрне 1944 елның 7 февралендә үтерелгән булырга тиешләр дип саный башлаганнар иде. Ләкин соңыннан, хөкем карары чыгарылганнан ары да, аларның ярты ел төрмәдә ятканлыклары мәгълүм булды.

Леон Небенцаль, Роже Бодар һәм Константин Симоновларның эзләнүләре нәтиҗәсендә, Моабит төрмәсендә шагыйрь белән бер камерада утырган Бельгия патриоты Андре Тиммерманс табылды. Шуннан соң Җәлил тормышының ул чоры шактый ачыклана төште. Андре Мусаны 1944 елның январь ахырындамы, февраль башындамы Дрезден шәһәренә судка алып китүләрен һәм шуннан соң берничә ай шагыйрь язмышы хакында берни дә белми яшәве турында сөйли.

Гитлерга һөҗүм ясалганнан соң, 1944 елның август башларында, башка политик тоткыннар белән бергә, Андре Тиммермансны Моабиттан Шпандау төрмәсенә күчерәләр. Анда берничә көн яшәгәч, төрмә ишек алдына алып чыккан вакытта, ул бер тоткынның төрмә тәрәзәсеннән пышылдап кына нидер әйтергә чамалавын сизенә. Әмма кемгә мөрәҗәгать итүен төшенеп җитә алмый. Икенче көнне шул ук тәрәзәдән тагын пышылдаган тавыш ишетә һәм шунда төрмәнең түбән катындагы бер тәрәзәдән Муса йөзен күреп кала. Йөрергә алып чыккан вакытта әсирләргә тукталып торырга рөхсәт ителмәсә дә, ботинка бавын бәйләгән булып, Тиммерманс шагыйрь йөзе күренгән тәрәзә каршында берничә секунд тоткарланып тора. Шул арада Җәлил аңа, пышылдап кына, үзләренә суд булганлыгын һәм тиздән барысының да башларын кисәчәкләрен әйтә.

Тиммерманс бу хәлдән соң ничек тә Мусаның үзен күрергә уйлый. Һәм ул бер көнне, ничектер җаен туры китереп, Мусалар катындагы тоткыннар юына торган душка эләгә. Һәм шунда, чыннан да, шагыйрьне очрата. Алар ун минутлап бер душ астында юыналар. Надзирательләр карап торганлыктан, әллә ни күп сөйләшә алмасалар да, Муса Андрега үзен дә, иптәшләрен дә үлем җәзасына хөкем иткәнлекләрен тагын бер тапкыр әйтә.

Җәлилчеләрнең Шпандау төрмәсендәге хәлләре турында моңарчы билгеле нәрсәләр менә шушылар гына иде.

Җәлилчеләрне кайчан һәм ничек үтергәнлекләрен сорап, Гази Кашшаф белән бергәләп Ланфрединига хат язган идек. Җавап итеп ул безгә түбәндәге хатны җибәрде:

«Кремона. 24. I. 1967.

Хөрмәтле совет язучылары!

Кичә, 1967 елның 23 январенда, Сезнең хатыгызны алдым. Тоткарланмыйча җавап бирәм.


Шагыйрь Муса Җәлилнең үлгән көне шул элек мин әйткәнчә — 1944 елның 25 августы. Аны мин яхшы хәтерлим, чөнки нәкъ шул көнне, татар дусларымның

коточкыч хәлгә дучар ителүләрен күргәч, үземә үлем карары чыгарулары турында әйтеп, Берлиндагы Италия илчесе Анфузога хат язарга карар кылдым.

1944 елның 25 августында иртәнге сәгать алтыда безнең камерага төрмә сакчыларыннан ике кеше килеп керде. Алар, кулларындагы исемлеккә карап, өч татарны чакырып алдылар һәм тиз генә киенергә куштылар. Ни өчен киенергә кирәклеген сорагач, сәбәбен белмәүләрен әйттеләр. Ләкин татарлар соңгы сәгатьләре җитүен шундук сизенделәр. Татарлар киенгәндә камерадан чыгып торган сакчылар яңадан әйләнеп керделәр. Татарларның берсе үзе белән кечкенә фоторәсем алып китте. Чыгып барышлый, инде беркайчан да күрешмәячәгебезне белеп, без дусларча кочаклаштык. Ул арада башка камерадагы татарлар да коридорга чыккан һәм үзара борчылып сөйләшәләр иде. Мин ишеккә килдем һәм Муса белән гадәттәгечә «сәлам»[1] дип исәнләштем. Аннары аларның барысын да коридордан алып чыгып киттеләр.

Бераз вакыт үткәч, сакчылар татарларның әйберләрен һәм төрле кәгазьләрен алып киттеләр. Берәр сәгатьтән башка сакчылар килеп, татарлардан калган барлык әйберләрен: тәлинкәләрен, кашыкларын, одеялларын исемлеккә теркәделәр. Аннары ул исемлеккә миннән имза куйдырттылар. Бу хәлләр дусларымны үлемгә алып барган минутларда булды.

Сәгать унберде минем камерага Георгий Юрытко атакай керде һәм татарларның барысы да сәгать унда асылганлыгын әйтте. «Татарлар үлгәндә дә елмаеп үлделәр», — диде ул. Шул ук көнне җәлилчеләр белән бергә бер немец сержантын да асканнар.



*Фашистлар төрмәсендәге камераларның берсе. Хәзерге күренеш.*

Камерада өч көн бер үзем генә яшәдем һәм шунда, аш керткән вакытларында, төрмә сакчылары миңа берничә тапкыр татарларның «аллес капут» (барысы да үле) икәнлекләрен әйттеләр.

Мин 1944 елның 25 августыннан соң да Шпандауда тордым һәм, әгәр татарлар исән калган булса, Юрытко атакайданмы яки башка кешеләрдәнме ишеткән булыр идем. «Башка төрмәгә күчермәделәр микән?» дип сорыйсыз. Белмим. Алай булырга тиеш түгел. Юрытко атакайдан башка, татарларны белгән кешене хәтерләмим. Мин белгән

[1] Бу сүз Ланфредини хатында да татарча язылган.

һәм үземнең «Тоткынлыктагы көндәлегем»дә язган барлык нәрсәм — менә шулар. «Көндәлек» хәзер Римдә, бер нәшрият карамагында. Бастырып чыгарып булырмы — анысын киләчәк күрсәтер. Мин үземне шактый яхшы хис итәм, әммә һәрвакыт врачлар күзәтүе астында яшим.

Немец төрмәләрендәге коточкыч хәлләрне тетрәнеп искә алам. Шул ук вакытта яхшы дусларымны — әсир татарларны да онытмыйм.

Хөрмәтле язучы әфәнделәр, шагыйрь Муса Җәлилнең хатынына һәм кызына миннән кайнар сәлам тапшыруыгызны үтенәм.

Минем бик беләсем килә, шагыйрьнең тормышы турында китап яздылар микән?

Барыгызга да кайнар сәлам.
Хөрмәт белән, Ланфредини Рениеро».

Без Ланфрединидан Мусаларны үлемгә алып киткәннән соң Шпандауда күпме яшәвен сорап язган идек. Ул менә болай җавап бирде: «Мин Шпандауда 1945 елның 6 январена кадәр тордым. Әгәр татар дусларым Шпандау камераларында яисә коридорында булган булса, ул хакта я Юрытко атакайдан яки башка дусларымнан ишетер идем».

Ирекка чыгу белән Ланфредини, Шпандау төрмәсендәге хәлләрне тасвирлап, «Тоткынлыктагы көндәлегем» исемле китап яза. Ә Юрытко көндәлек алып бармаган. Шунлыктан аның язмаларында Юрытко белмәгән күп кенә мөһим мәгълүматлар бар. Аннары, Шпандауда көн дә булып торган үтерүләргә инде ияләшеп беткәнлектән, Юрытконың җәлилчеләрнең үлеменә әллә ни зур игътибар итмәве һәм күп нәрсәләрне оныткан булуы да гаҗәп түгел.

«Минем янга, 53 камерага, — дип яза Ланфредини, — Юрытко атакай атнага ике-өч мәртәбә кереп йөри иде һәм һәрвакыт Муса Җәлил һәм аның иптәшләре белән бик ягымлы сөйләшә торган иде. Һәм мин аңламыйм, нигә ул аларны үтергән көнне — 1944 елның 25 августын — хәтерләми икән? Аларның үтерелгәнлеген шул ук көнне үзе миңа әйтте бит. Юрытко атакай ул көнне татарлар белән бергә асылган католик сержант янына да керергә тиеш булган — бу хакта миңа үзе әйтте».

Сүз уңаенда, бу немец сержанты турында берничә сүз әйтеп китим. Җәлилчеләр белән бергә, шулай ук листовкалар таратуда гаепләнеп, нииндидер бер хәрби немец та хөкем ителгән. Әсирлектә булган кайбер кешеләрдән бу хакта моңарчы да ишетергә туры килгәләгән иде. Инде менә Ланфредини да шуны раслый. Ләкин, кызганычка каршы, ул сержантның исем-фамилиясе дә, язмышы да ачыкланмаган әле. Әмма шунысы игътибарга лаек: немец халкының үзе арасыннан да фашизмга каршы көрәштә совет патриотларына ярдәм итүчеләр булган.

Җәлилчеләрнең кайчан үтерелүе хакында әйткән сүзләрен раслар өчен, Ланфредини 1944 елның 25 августында, үзен кичерүләрен сорап, Берлиндагы Италия илчесенә язган гаризасының күчермәсен дә җибәргән. Аның төп нөсхәсе Берлиндагы Италия илчелегендә сакланган булган. Ланфредини аны адвокаты аркылы соратып алган.

Шулай итеп, Ланфредини җибәргән материаллар Җәлил һәм аның иптәшләренең үтерелү көнен ачыклауга мөмкинлек бирде. Ләкин бу датага икеләнүсез ышану өчен, аның тагын кайбер документлар белән раслануы кирәк иде.

Германия Демократик Республикасының күренекле адвокаты доктор Кауль аркылы Леон Небенцаль, 1944 елның 25 августында җәзалап үтерелгән кешеләрнең картотекаларын тикшерүне үтенеп, Көнбатыш Берлиндагы Плетцензее төрмәсенә язу җибәртә. Нәтиҗәдә, чыннан да, йөзләрчә кешеләрнең кәгазьләре арасыннан Әхмәт Симаев карточкасы да табыла. Бу карточкада һөнәре буенча журналист, дине ягыннан — мөселман, 1915 елда туган Әхмәт Симаев дигән кешенең 1944 елның 25 августында иртәнге сәгать сигездә Плетцензее төрмәсенә китерелгәнлеге һәм шул ук көнне иртәнге сәгать унда үтерелгәнлеге язылган. Шулай итеп, хәзер Ланфредини сүзләренең дөреслеге тулысынча расланды.

Нигә бер генә карточка табылган? Башка татарларныкы кая китте икән?

Моның сәбәпләре төрлечә булырга мөмкин.

Беренчедән, төрмә архивы, ихтимал, тулы түгелдер. Дөрес, Плетцензее доку-

ментларына сугыш вакытында зыян килмәгән. Ләкин ул документларның бер өлешен американлылар сугыштан соң Вашингтонга алып киткәннәр.

Икенчедән, Плетцензее төрмәсендә элек рухани хезмәтен башкарган Һарольд Пельхауның сөйләвенә караганда, 1944 ел август аеның икенче яртысыннан, ягъни Гитлерга һөҗүм булганнан соң, фашист палачларына эш шундый күбәеп киткән, хәтта алар үтерелгән кешеләрнең документларын тиешенчә тутырып торырга да өлгерә алмый башлаганнар. Шунлыктан алар 10—15 кешедән торган группадан нибары бер кешегә генә карточка язганнар. Көнбатыш Берлиннан җибәрелгән Әхмәт Симаев карточкасының да бик ашыгыч тутырылганлыгы күренеп тора: утызга якын графаның нибары биш-алтысына гына җавап язылган, ә башкалары буш калган.

Юрытко белән Ланфредини сүзләре арасындагы каршылыкны ничектер үзара бәйләү нияте белән Шәйхи Маннур бу мәсьәләдә үз версиясен алга куя. Шпандау төрмәсеннән алып чыккач, тоткыннарны, ихтимал, икегә бүлгәннәрдер, ди ул. Штатски кием киеп йөргән һәм элек «Идел-Урал» комитетында эшләгән кеше буларак, Әхмәт Симаевны Плетцензеегә алып барып асканнар, ә башкаларын Зеебург тирында атып үтергәннәрдер, ди. Үзенең «Муса» романында да шул фикерне үткәрә. Җәлил һәм аның иптәшләрен ничек атуларын җентекләп сурәтли.

Ләкин бу фикерне күпмедер дәлилләү өчен ике шарт кирәк. Беренчедән, җәлилчеләр группасында бары тик бер генә кешенең штатски кием киеп йөргәнлеген һәм, икенчедән, атылу «өстенлеге» хәрбиләргә карата гына кулланылуын ачыкларга кирәк.

Шушы турыда сорашып язгач, Ланфредини миңа татарларның яртысы хәрби киемнән, яртысы, шул исәптән Җәлил дә, граждански киемнән иделәр дип җавап бирде. Соңрак язган хатларының берсендә исә: «Хәтерем ялгышмаса, Әхмәт Симаев немец мундиры киеп йөри иде», — дип язды. Ниһаять, Ланфредининың әйтүенчә, атып үтерелү «өстенлеге» бары тик очучыларга гына бирелгән булган. Башка төр гаскәр сугышчыларын ничек телиләр — шулай үтергәннәр.

Җәлилчеләр группасындагы башка кешеләрнең карточкалары, бәлки, тиешенчә җентекләп эзләнмәгәнгә табылмагандыр. Плетцензее төрмәсенә мөрәҗәгать итеп караучылар Леон Небенцальгә кадәр дә булды. Әмма һәрвакыт «югарыда күрсәтелгән кешеләр җәзалап үтерелгәннәр исемлегендә юк» диган җавап кына килә иде.

1967 елның мартында мин Германия Демократик Республикасында һәм Көнбатыш Берлинда булып кайттым. Шунда Леон Небенцальдән тагын бер тапкыр Плетцензее төрмәсенә мөрәҗәгать итеп каравын сорадым. Нәтиҗәдә Җәлил группасындагы тагын бер кешене — Гариф Шабаевны үтерү турындагы карточка табылды. Шабаев та Әхмәт Симаев белән бер көнне һәм бер үк сәгатьтә үтерелгән. Бу факт Рениеро Ланфредини сүзләренең дөреслеген тагын бер тапкыр раслый.

Татарстан язучылар союзы Ланфрединины Советлар Союзына килеп, Мәскәүне һәм Казанны күреп китәргә чакырган иде. Ләкин ул килә алмавын хәбәр итте.

«1963 елда мин инфаркт белән авырдым. Шуннан бирле врачлар күзәтүе астында яшим... Минем гомеремне унбиш елга әлеге шул Германия кыскартты...» — дип язды ул.

1967 елның көзендә Ланфрединига икенче тапкыр инфаркт булган. Соңгы хатларын ул үзе яза алмаган, больница палатасындагы иптәшенә әйтеп торып кына яздырган. Авыру булуына карамастан, Ланфредини бер хатымны да җавапсыз калдырмады. Күп санлы сорауларымның барысына да тулы җавап бирә килде. «Шагыйрьнең соңгы көннәре турында дөресен сөйләүне үз бурычым итеп саныйм. Мин Муса Җәлилне һәрвакыт хәтеремдә саклаячакмын, чөнки ул минем дустым, тормышымның иң авыр чактагы дустым иде», — дип язды ул.

Үзенең үтенече буенча, мин аңа, итальянчага тәрҗемә иттереп, Җәлил биографиясен һәм альбомын җибәргән идем. Мусаның шундый зур хөрмәткә лаек шагыйрь булуын күреп, Ланфредини бик сөенгән һәм гаҗәпләнгән: «Мин Мусаны моңарчы да зур шагыйрь дип исәпли идем. Ләкин Казандагы иң зур театрларның берсе аның исемен йөртерлек дәрәҗәдә үк атаклы кеше икәнлеген белми идем», — дип язды ул.

Альбомнан бер камерада утырган иптәшләрен — Муса Җәлил белән Фуат Булатов рәсемнәрен шундук танып алган. Башка татар тоткыннарын да таныган, әмма аларның исемнәре аның хәтерендә сакланмаган.



*Рениеро Ланфредини хатыны Паола белән Кремона шәһәре урамында.*

Без Ланфредини белән бер ел чамасы язышып тордык. Һәм менә 1967 елның августында аңардан миңа алдан искәртеп киткән әлеге язмалар килеп төште.

Рим нәшриятларының берсендә әле һаман дөнья күрә алмый яткан «Тоткынлыктагы көндәлегем»нең үзе түгел бу. Ланфредини үз язмаларының Шпандау төрмәсенә һәм Муса Җәлилгә бәйләнешле өзекләрен генә сайлап җибәргән. Безнең үтенечебезне искә алып, Ланфредини үзе турында кайбер мәгълүматлар һәм аның өстеннән алып барылган тикшеренү документларының фотокүчермәләрен дә җибәргән. Аның язмышы икенче бөтен дөнья сугышы елларындагы катлаулы вакыйгаларга катнашкан меңнәрчә итальяннар язмышына бик охшаш һәм шул ук вакытта шактый гыйбрәтле дә.

Рениеро Ланфредини 1907 елның 9 апрелендә Виаданада (Мантуя) туа, белем ала, аннары кечерәк кенә конторада эшли. Икенче бөтен дөнья сугышы башлангач, армия хезмәтенә алына.

1943 елда Муссолини хөкүмәте бәреп төшерелгәч, Бадольо җитәкчелегендә төзелгән яңа хөкүмәт фашистик партияне тарата һәм официаль төстә Германиягә каршы сугыш игълан итә. Бадольо армиясе сафларында Ланфредини туган илен басып алган фашистларга каршы сугышка китә. Ләкин аңа озак сугышырга туры килми. Фронтка килүенең беренче көнендә үк әсирлеккә эләгә һәм, хәрби әсир буларак, Германиягә эшкә озатыла. Шундагы бер хәрби предприятиедә эшләгәндә Ланфредини үзе кебек үк фашизмны күрәлмаучы бернича чех әсире белән танышып, дуслашып китә. Ләкин ул саксызлык күрсәтә: фашизмга каршы нәфрәт белдереп, бер чех дустына язулар язып бирә. Шул язуларының берсе гестапога эләгә һәм

Ланфредини кулга алына. Аны «немец халкының катгый ихтыярын — сугышны җиңүгәчә дәвам иттерергә дигән теләгән тоткарларга» тырышуда гаепләлиләр. Ланфредининың чех әсиренә адресланган язуларында, фашист судьялары фикеренчә, аеруча «хәтәр» яңгыраган өзекләр аның өстеннән алып барылган тикшерену материалларында сакланган. Аларда гади итальян солдатының ул вакыттагы уйлары, теләк-омтылышлары бик ачык чагылган: «Мин 1943 елның сентябрендә Италиягә басып кергән немецләргә каршы көрәштем. Үлсәм — үләм, әмма немецларның эсэс гаскәрләренә хезмәт итмәячәкмен. Германиядә нинди коточкыч хәлләргә юлыгуымны язып тормыйм. Нюрнбергта безгә номерлар бирделәр. Безне кеше ите белән сату итүчеләр алдында чишенергә мәҗбүр иттеләр. Без, итальяннар, Эфиопияне, Сицилияне, Ливияне югалттык. Берлинда утыручы башкисәр һәм тиран аркасында безнең барлык шәһәрләребез җимерелеп бетте. Ул беренче һөҗүмен Австриягә, аннары сезнең кадерле илегезгә — Чехословакиягә ясады. Аннары барлык милләтләргә каршы китте. Никадәр фаҗига һәм кайгы китерде ул кешеләргә... Кая карама — ут, кан. Әле сугыш бетмәгән, хәлләр тагын кыенлашыр әле. Һәркайда фәкыйрьлек, ачлык. Бөтен дөнья әлеге шул Берлиндагы бер кеше аркасында сыкрана.

Гомуми дошманга карата мин дә Сезнең белән бер фикердә. Вакыты якынлашып килә. Берлиндагы теге хәшәрәт үләчәк. Сезнең илегез — героик Чехословакия өчен дә азатлык сәгате сугар.

Хәзер мине кеше уникешәр сәгать эшләтәләр, ләкин алар барыбер җиңеләчәк. Италиядә хәрби әсирләрне болай эшләтмиләр. Мин сезне кайчакта заводта күргәли идем. Тик Сезнең белән бер тапкыр да сөйләшкәнем булмады, чөнки Сезне немецлар, алай гына да түгел, нацистлар дип уйлый идем. Ләкин хәзер, сезне белгәч, миңа тормыш җиңеләеп киткән төсле булды».

Ланфредини үз эше буенча чыгарылган хөкем карарының копиясен дә җибәрде. Менә ул:

«Берлиндагы армия үзәк трибуналының немец халкы исеменнән хөкем карары.

1907 елның 9 апрелендә Виаданада туган, немец коралы көчләре җиңеләчәк дигән коткы таратуда гаепләнгән Италия солдаты (концентрацион лагерь XIII А Сульцбаке Роземберг) Рениеро Ланфредини өстеннән алып барылган тикшерү нәтиҗәләрен карау өчен 1944 елның 23 маенда хәрби трибунал җыйналды. Анда судья булып адвокат Земмехель, прокурор — капитан Мозаниец, адвокат-яклаучы — адвокат Денике, секретарь — Шульц әфәнделәр катнашты.

Немец коралы көчләре җиңеләчәк дип коткы таратканы өчен, гаепләнүче үлем җәзасына хөкем ителде.

Үлем карары чыгарылу турында илчелеккә шундук түбәндәге адрес буенча хәбәр ителде:

Берлин — 8

Вильгельмштрассе 74/76».

Шушы карарның күчермәсен фашистлар Германиясенең чит ил эшләре министрлыгы Италия илчелегенә җибәрә һәм, алу белән, үзләренә хәбәр итүне сорый. Чөнки, закон буенча, карар җиренә җиткерелгәнче өч ай вакыт үтәргә тиеш. Һәм бу вакыт карар чыгарылу көненнән түгел, бәлки илчелек карарны алу көненнән исәпләнә икән.

«1944 елның февралендә, — дип яза Ланфредини, — мине Пассаудан Сульцбаке Роземберг концлагерена күчерделәр һәм лагерь уртасындагы агач баракка яптылар. Бик ныклап саклана торган ул баракта бельгиялеләр, французлар һәм югославлар да булып, алар барысы да хөкем карары чыгарылуын көтәләр иде. Гамбургта хөкем ителгән әсирләрне Аусвицтагы үлем лагерена җибәрделәр. Лагерьдагы тоткыннарны күршедәге Сульцбаке шәһәрендә эшләтәләр иде.

Рус солдатларын иң куркыныч һәм иң хурлыклы эшләргә йөртәләр иде (мәсәлән, шартламый калган бомбаларны җыю һ. б.).

Безгә, итальяннарга һәм русларга, немецлар аеруча начар карый иде. Бельгиялеләр һәм французлар ташлаган тәмәке төпчекләрен җыеп русларга биргән вакытларым әле дә исемдә. Ул төпчекләрне дә иркенләп җыеп булмый, күрсәләр, хәзер

атарга гына торалар иде. Руслар кебек үк, безгә дә Кызыл Хач бернәрсә дә җибәрми иде. Безгә бирелә торган икмәк, әлбәттә, җитәрлек түгел, ә бельгиялеләргә һәм французларга Кызыл Хач атна саен посылка җибәреп тора иде.

Тикшерену тәмамланганнан соң, 1944 елның апрелендә мине кулга алырга ордер килде. Мине лагерь төрмәсенә яптылар һәм анда биш көн тоткач, Берлинга алып барып, Тегель төрмәсенә яптылар. Микем камерага немец мундиры кигән бер русны кертеп ташладылар. Без аның белән өч көн тордык. Аннары миннән кыскача гына сорау алдылар да яңадан элеге концлагерь төрмәсенә алып кайттылар. Лагерь ишек алдына йөрергә алып чыккан чакларда мин русларны да күрәм, ләкин без күз карашлары һәм елмаюлар аша гына аңлаша идек.

1944 елның 23 маенда мине үлемгә хөкем иттеләр. 1944 елның 4 июнендә, үлемгә хөкем ителгән немецлар белән бергә, мине Шпандау төрмәсенә алып киттеләр. Шпандау төрмәсе миңа куркыныч һәм erткыч кош төсле күренде. Ике-өч капка аша үткәннән соң, мине беренче каттагы беренче коридорга алып керделәр. Камера ишекләренә үлемгә хөкем ителгән кешеләрнең исемлеге язылган карточкалар эленгән иде.

Яңа килгән тоткыннарны камераларга урнаштыра башладылар. Миңа да чират җитте. Барлык әйберләремне алырга куштылар һәм, бер камерага кертеп, мине шунда бикләп куйдылар. Шагыйрь Муса Җәлил һәм Булатов камерасы иде бу. Таныштык. Алар мине бик җылы каршыладылар. Шагыйрь ябык, әмма шактый нык күренә, күз карашы үткен һәм акыллы иде. Чәчләре күзенә төшеп тора. Киеме — гражданский кием. Өстендә аксыл-коңгырт костюм. Булатов тәбәнәгрәк буйлы һәм сәламәт йөзле базыграк кеше булып, өстендә солдат мундиры иде[1]. Муса да, Булатов та миңа бик яхшы мөгамәлә күрсәттеләр, идәндә яткан салам түшәкне алып, урын-җир дә әзерләп куйдылар. Каяндыр котелок сыман банка һәм кашык та табып бирделәр.

Беренче көн бик тынгысыз узды. Әле анда, әле монда чакыртып йөдәттеләр. Соңыннан складка алып барып, сәләмә киемнәремне тапшырттылар. Бары шуннан соң гына камерага кайттым. Шагыйрь үзен Әхмәт[2] дип атады, ләкин Булатов аның чын исемен һәм зур шагыйрь икәнлеген әйтте. Булатов шагыйрьне бик хөрмәт итә иде.


Шпандауда көн тәртибе болай иде: йокыдан тору — сәгать алтыда. Җиденче яртыда кофе эчәбез. Ләкин аның исеме генә кофе иде. Сигезенче яртыда камерада авырулар юкмы дип сорап киләләр (авыру булса, врач чакырту өчен). Сәгать тугызда, уникешәр кешелек төркемнәргә бүлеп, төрмә ишек алдына йөрергә алып чыгалар[3]. Йөрергә чыккач тоткыннарга үзара сөйләшү бик катгый тыела. Шулай да кайчакта, җаен табып, азрак сөйләшкәләргә мөмкин. Йөргәннән соң, камераларга алып керәләр. Әнә шул вакытта шагыйрь үзенең татар дуслары белән ниндидер язулар алыша һәм татар телендә Булатов белән шул язулар хакында нидер сөйләшә. Соңыннан ул язуларны юк итәләр. Сәгать унберде — аш өләшү: биш кисәк бәрәңге салынган шулпа бирәләр. Көндезге сәгать бердә почта китерәләр[4]. Почта өләшкәннән соң —

[1] Муса «Идел-Урал» легионында тормаган һәм кулга алынганга кадәр гражданский киемдә йөргән. Аның кайбер иптәшләрен легионда кулга алганнар, шунлыктан алар немец мундирында булган.

[2] Бу башта безгә сәер тоелды. Ланфредини Мусаны Әхмәт Симаев белән буташтырмый микән дип шикләнгән идек. Ләкин алай түгел икән. Рәсемнәрен күрү белән, Ланфредини Җәлилне дә, Симаевны да шундук танып алган. Теге чакта Муса, ихтимал, үзенең иптәшләре турында сөйләгән булгандыр, ә Ланфредини, немецча тиешенчә белмәгәнлектән, аны ялгыш аңлагандыр. Сөйләвенә караганда, Ланфредини ул вакытта, чыннан да, немецча бик аз белгән.

[3] Иртән йөрергә алып чыкканда тоткыннарга гимнастика ясау рөхсәт ителә торган булган. Хатларының берсендә Ланфредини Муса Җәлилнең һәр көн иртән гимнастика ясавын әйтеп язган иде.

[4] Ланфредини бер хатында: «Үлемгә хөкем ителгән кешеләргә кайбер өстенлекләр бирелә: без немец газеталарын һәм китапларын укый алабыз... Хат язарга, хат алырга һәм өйдән яисә Кызыл Хач тарафыннан җибәрелгән посылкалар алырга да рөхсәт ителә иде. Ләкин минем беркайчан да бернәрсә дә алганым булмады», дип язган иде. Ә икенче бер хатында: «Муса төрмә кибетеннән немец газеталары сатып алып укый һәм аларның эчтәлеген сөйләп бирә торган иде», — дип язды. Әмма хат язышу ирекe совет әсирләренә рөхсәт ителмәгән булса кирәк. Чөнки, Юрыткоиың әйтүенә караганда, шагыйрь үзенең бер-ике хатын төрмәдән аңа биреп чыгарган.



*Шпандау төрмәсе.*

ял. Әледән-әле коридорда кычкырган, сөйләшкән тавышлар ишетелеп тора, әмма кемнәр һәм ник кычкырышканын беркайчан да белеп булмый. Безнең коридор көнен-төнен сак астында тора иде. Кичке сәгать дүрттә — кичке аш: өстенә бер тамчы джем ягылган һәм кечкенә генә маргарин кисәге куелган юп-юка икмәк телеме. Кичке алтыда надзиратель килеп керә. Безне — үлемгә хөкем ителгән кешеләрне — бөтенләй чишендереп, киемнәребезне коридорга алып чыга. Аннары кулларыбызга богау сала һәм без шул хәлдә йокларга ятабыз. Иртән, богауларыбызны салдыргач, киемнәребезне алып кереп бирәләр. Һәр көн шулай эшләнә. Кичке сигездә ут сүндерелә, һәм камерада тынлык урнаша. Бары тик надзирательләрнең аяк тавышлары гына ишетелеп тора. Төн уртасында кинәт ут яндыралар һәм безне карап йөриләр. Үлемгә хөкем ителгәннәрне аеруча каты күзәтәләр. Аерым үтә явызларын исәпкә алмаганда, сакчылар бик үк начар кешеләр түгел. Барысы да диярлек сугыш инвалидлары: кайсының күзе, кайсының кулы юк.

Католик динендәге кеше булганга, бер көнне үз яныма төрмәдәге католик руханины Юрытко атакайны чакырттым. Георгий Юрытко шундук килеп җитте. Соңыннан да килгәләп йөрде. Юрытко шагыйрь белән озаклап сөйләшеп утырырга ярата иде. Төрмәдә протестант пасторлары да бар иде. Әмма алар беркайчан да безнең янга кермәделәр...

Төрмәдә мөселман руханилары юк иде.

Аллага ышануым ул авыр көннәрдә миңа бик ярдәм итте. Шул инану аркасында, миңа барлык кешеләр дә туганнарым булып тоела иде.

Болар Сезнең өчен кызыклы булыр дип уйлыйм. Үз тарафымнан Сезгә аз булса да ярдәм итә алуыма бик шатмын. Мин Сезгә бөтенесен дә тәфтишләп, хәтта «Көндәлегем»ә язылмаганнарны да өстәп сөйләргә тырышам. Татарларның хәле ничек булганын бары мин генә беләм, чөнки соңгы көннәрдә бары мин генә алар белән бергә булдым.

Шпандау төрмәсендә эшләр ничек иде соң? Тоткыннарны китерү һәм алып китүдән башка, дүшәмбе көнне анда берниндн дә яңалык булмый иде. Эшләре тикшере-

леп, хөкем карары чыгарылган кешеләрне я башка төрмәгә, яисә концлагерьга озаталар иде ул көнне. Сишәмбе көнне тагын шул ук хәл кабатлана иде.

Кайбер көннәрне иртәнге сәгать тугызда камерага граждански киемдәге кешеләр керә. Минем уемча, алар фабрика хезмәткәрләре иде. Алар кәгазь китерәләр, ә ул кәгазьләрдән без мармелад төрү өчен капчыклар ясыйбыз. Шагыйрь эшен җиренә җиткереп, яратып эшли. Булатов алай ук түгел.

Атнаның иң начар көннәре — чәршәмбе, җомга, шимбә. Үлемгә хөкем ителгән кешеләрне шул көннәрдә җәзалыйлар. Чәршәмбе һәм җомга көннәрендә пехота солдатларын, шимбә көнне авиация солдатларын.

Пехотачыларны Берлиннан егерме километр ераклыктагы Бранденбургка алып барып, башларын чабалар, ә авиаторларны, Геринг боерыгы буенча, атып үтерәләр иде.

Ул көннәрне иртәнге сәгать биштә камерага кырыс кыяфәтле кораллы солдатлар килеп керә. Хөкем ителгән кешеләрнең исемнәрен игълан итәләр һәм генерал Фроммның аларның үтенечләрен кире какканлыгын, ягъни үлем карары расланганлыгын әйтәләр [1]. Җәзаланырга тиешле кешеләрнең саны көненә биш-алтыдан алып тугызга кадәр була. Һәр көн иртән менә ишек ачылыр да безнең исемнәрне атарлар дип көтә идек. Сәгать алтынчы яртыда җәзаланырга тиеш кешеләрне коридордан алып чыгып китәләр. Бу хәл тыныч кына үтми, кайчакта ул тоткыннар бик нык тавыш куптаралар. Хатыннары, әниләре, бала-чагалары хакына булса да исән калдыруларын үтенеп, аллага ялваралар. Алар шундый җан өзгеч итеп ачыргаланалар — андый чакта таш йөрәк тә түзә алмас иде. Кайчакта үлемгә баручыларның рухын күтәрергә тырышучы Юрытко тавышы да ишетелгәләп куя. Кемнәрне үлемгә алып китүләрен иртән йөрергә чыккач кына беләбез, әле кичә генә бергә прогулкада йөргән кешеләрнең кайберләре безнең арада булмый инде. Безне үтерү яки үтермәү мәсьәләсе генерал Фроммга бәйле. Сине асаргамы, кичерергәме яисә эшеңне яңадан карарга җибәрергәме — барысын да ул хәл итә. Үлемгә хөкем ителгән һәр кеше янына да Юрытко атакай керә иде. 1944 елның 20 июленнән соң Фромм урынына Гиммлер билгеләнде. Татарларны үлемгә ул хөкем итте. Үлемгә хөкем ителгән немецларны карар җиренә җиткерелгәнче өч ай чамасы, ә башка ил хәрби әсирләрен кайчакта еллар буена төрмәдә тоталар иде (мәсәлән, эшне кабат тикшерү кирәк булса h. б. [2]).

Төрмәдә эчке тәртипләр менә шулай иде. Хәзер шагыйрь Муса Җәлил һәм Булатов белән үзара нинди мөнәсәбәттә булганыбызны сөйлим.

Мин аларга башымнан узган хәлләрне сөйләп бирдем. Мәсьәлә җитди икән, әмма кичерүләренә һәм үлем карарын бүтән җәзага алмаштыруларына өметләнергә була, диде Муса.

Бадольо солдатын кичерү... Бу миңа һич тә мөмкин булмастай тоелды.

Шагыйрь камерада булмаган вакытларда (мунчага яисә врачка киткәндә) Булатов миңа аның зур язучы икәнлеген сөйли иде. Муса һәрвакыт һәркемгә яхшы мөгамәлә кыла иде. Түземле, тыйнак, беркайчан да кызмый, юкка кешене рәнҗетми. Ләкин үз дәрәҗәсен белә, хәтта надзирательләр алдында да артык исе китми. Шагыйрь миңа

---

[1] Бер хатында Ланфредини бу хакта тулырак итеп язган иде: «Сакчы хөкем ителгән кешеләрнең исем-фамилияләре язылган исемлекне тотып керә дә: «Синең көнең бетте — үлем җәзасы расланган!» дип кычкыра. Шуннан соң хөкем ителгән кеше иптәшләре белән хушлаша да коридорга, үзе кебек үк, үлемгә баручылар янына чыгып китә».

[2] Хатларының берсендә Ланфредини бу турыда киңрәк, җентекләбрәк язган иде: «Үзенең үтенече буенча, якшәмбе көннәрендә, төш вакытында, Җәлилне күрше камерадагы татар дуслары янына да кертәләр иде. Ул анда берәр сәгать чамасы була. Алар камерасыннан Җәлил шатланып һәм канатланып чыга һәм бик рухланып Булатов белән нидер сөйләшә иде. Якшәмбе көннәрендә мине һәрвакыт күрше камералардагы итальян дусларым яки күрше татарлар чакыра (төрмә алфавиты белән су трубасына шакып). Аларның соравы буенча, мин үз илемнең җырларын җырлыйм, шулай итеп, аз булса да күңелләрен ачам. Соңыннан мин һәрвакыт изге китапта язылган дини шигырьләрне җырлый идем.

үзен ничек кулга алуларын һәм ничек хөкем итүләрен дә сөйләгән иде. Әмма хәзер, егерме елдан соң, аның сүзләрен тулысынча хәтерләмим инде. Әгәр мин дөрес аңлаган булсам, шагыйрь башта Берлиндамы, әллә Германиянең кайсыдыр башка бер шәһәрендәме иректә яшәгәнлеген сөйләде... Анда ул нәрсә белән шөгыльләнгәндер, анысын хәтерләмим. Бары тик чагыштырмача иректә булганын гына беләм. Сугышудан мәгънә юк, чөнки иртәме-соңмы сез барыбер оттырачаксыз, дип, немецлар арасында листовка таратканнар. Аларны үз араларыннан берсе саткан. Аннары барысын да кулга алганнар. Судка кадәр аларның төрлесе төрле төрмәдә утырган. Немецлар алар белән бик каты кыланган. Җәлил миңа үз тәнендәге күп санлы җәза һәм кыйнау эзләрен күрсәтте. Әгәр мин дөрес аңлаган булсам, татарларның барысына да суд Дрезденда ясалган һәм аларның барысын да үлемгә хөкем иткәннәр. Судтан соң, Германиянең күп төрмәләре аша үтеп, Шпандауга килеп эләккәннәр. Алар Германиягә һәм фюрерга каршы пропаганда алып баручыларны гаепкә тарта торган параграф буенча хөкем ителгәннәр. Мин Шпандауга килгәндә татарлар анда елга якын яткannар иде [1]. Булатов белән шагыйрь үзләренең исән калуларына ышана башлаганнар иде инде. Хөкем карары чыгарылганнан соң күп вакыт үткән, шунлыктан өметләнергә дә мөмкинлек калган иде. Күңеле төшенке, уйчан чакларында шагыйрь бик күп яза иде [2]. Нәрсә яза — анысын мин белми идем. Язган әйберләрен кат-кат укый да ертып ташлый ул. Ә кайчакта тирән уйга чума. «Немецларның да язмышы мөшкеллеккә калачак», — дип куя. Ул миңа рус дәүләтенең төзелеше, парламентның ике палатадан торганлыгын аңлатты. «Рус хөкүмәте башлыклары мондый тоткыннарны беркайчан да кичерми калмас иде; гаеплеләрне, әлбәттә, җәзага тартырлар (Себергә эшкә җибәрерләр), әмма гомерләрен саклап калырлар иде», — дигән сүзләре хәтердә калган. Ул үз илен бик еш искә ала иде. Әгәр үлсәм, илем мине онытмаска тиеш дия иде. Шагыйрь шулай ук туганнарын — хатынын, кызын һәм анасын да бик еш телгә ала иде. Андый чакта күзләреннән мөлдерәп яшьләр тама иде. Ашарга китергән бәрәңгеләрне бөлүне без һәрвакыт Мусага тапшыра идек һәм ул һәрвакыт зуррак бәрәңгеләрне Булатовка янсә миңа бирергә тырыша иде.

Атна саен безгә җидешәр сигарет бирәләр (бары тик үлемгә хөкем ителгәннәргә генә бирелә) иде. Тәмәке тартмаганга күрә, мин үз өлешемне шагыйрьгә янсә Булатовка бирәм [3]. Һәр җомгада эчке киемнәрне алыштырабыз. Ләкин минем ул турыда сөйлисем дә килми, чөнки бу кием алыштыру түгел, бәлки үзе бер җәза иде. Мунча керү, медицина тикшерүе, эчке киемнәрне алыштыру — болар барысы да формаль нәрсәләр иде. Камерага килеп керәләр дә, анадан тума чишендереп, бөтен кием-салымнарыбызны җентекләп тикшерәләр. Әгәр шунда рөхсәт ителмәгән берәр әйбер чыкса — беттең... Кайчакта эсэсчы солдатлар да тентү ясап китәләр иде...

Безнең бердәнбер юанычыбыз — төрмә стеналарындагы язуларны уку. Камера стеналары төрле милләт кешеләре язып калдырган исемнәр белән чуарланган... Булатов аз сүзле иде, арада иң күп сөйләшүче, әлбәттә, мин идем. Камерага кергән саен, Юрытко шагыйрьдән: «Итальян үзен ничек хис итә?» — дип сорый. Шагыйрь аңа: «Ул яхшы кеше», — дип җавап бирә иде. Юрытко шагыйрь белән бик озак гәпләшеп утырырга ярата иде: бу атнада кемнәрне үтерүләрен һәм башка шуныңише яңалыкларны сөйли. Шагыйрьнең язуларын да башка камерадагы татарларга шул Юрытко алып китә һәм икенче көнне тегеләрнең җавапларын да ул алып килә иде. Чиста

---

[1] Ланфредини Җәлилне дөрес аңламаган, күрәсең. Аның белән очрашканга кадәр җәлилчеләр Шпандауда, күп дигәндә, ике ай гына яшәгән булырга тиешләр, чөнки, Дрезден төрмәсе стенасындагы язуга караганда, 1944 елның 24 мартында алар әле Дрезденда булганнар.

[2] Соңыннан җибәргән хатларының берсендә Ланфредини Мусаның күңеле төшенке вакытта гына түгел, бәлки даими рәвештә, көн дә язганлыгын хәбәр итте.

[3] Муса Җәлилнең беркайчан да тәмәке тартмавы мәгълүм. Шунлыктан мин Ланфрединидан: «Әллә шагыйрь төрмәдә тәмәке тарта идеме?» — дип сорадым. Ул: «Юк, тартмады. Сигаретларны ул күрше камерадагы дуслары өчен ала иде», — дип җавап бирде.

кәгазь, икмәк, теш щеткасы кебек әйберләрне дә безгә шул Юрытко алып бирде. Бик әйбәт кеше иде ул.

Көннәрнең берендә шагыйрь итальян телен өйрәнергә теләвен әйтте. Мин аны өйрәтә башладым. Сүзләрне ул бик тиз отып ала, аннары кабатлап йөри. Иртә-кичләрен мине итальянча сәламли иде. 1944 елның 20 июлендә Гитлерга һөҗүм булганлыгын без төрмә сакчыларыннан белдек. Күңелләребездә зур ышаныч туды... Ләкин, һөҗүмнең уңышсыз булуын ишеткәч, шагыйрьнең күңеле сүрелде[1]. Фюрер үлгән булса, шагыйрь, бәлки, исән калыр иде. Фромм эшеннән алынганнан соң безнең эшләрне Гиммлер кулына тапшырдылар, ул аларның барын да бик тиз хәл итте... Хәзер инде көнен ә унҗидешәр кешене җәзалый башладылар. Татарларны асып үтерергә дигән карарга да шул ук Гиммлер кул куйды.

Камерада без бертуганнардай яшәдек. Камерабыз һәрвакыт чиста була иде. Хәтта төрмә надзирательләре дә мактый иде. Бер-беребезне бик хөрмәт итә идек. Башка татарлар да миңа шундый әйбәт мөнәсәбәттә булдылар. Күрәсең, аларга шагыйрь минем турыда сөйләгән булгандыр. Без үзара «сәлам» дип исәнләшә идек. 1944 елның 15 августында надзиратель мине башка камерага күчерде. Шагыйрь белән Булатов моңа бик гаҗәпләнделәр, әмма немецлар белән бәхәсләшеп булмый. Мине күчергән камера Җәлилләрнекеннән ерак түгел иде. Тәрәзәсе ишек алдына карап тора. Шуннан мин шагыйрьнең гимнастика ясаганын күрә идем. Йөрергә алып чыккан вакытларда мин тагын шагыйрь һәм Булатов белән очраша башладым. Хәзер мин **Абдулла, Батталов, Симаев**[2] исемле татар дусларым камерасында тора башладым. Мин аларны элек тә яхшы беләм, чөнки йөрергә чыкканда бер төркемгә эләгә идек. Алар өчесе дә хәрби киемнән. Барысы да мине якын итәләр, шулай да миңа шагыйрь һәм Булатов камерасында яхшырак иде. Җае чыкканда мин шагыйрь белән тәрәзә аша да сөйләшкәли идем...

Аннары 1944 елның 25 август көне килде. Иртәнге сәгать алтыда камерага керделәр һәм алдагы хатларымда язган аяныч хәл булды. Нигә алтыда, ә биштә түгел? Анысын белмим. Татарларны шул ук көнне сәгать унда асып үтергәннәр. Сезнең өчен, синьора Җәлил һәм аның кызы өчен, мин үзем белгәннәрнең барысын да тулы итеп язарга тырыштым. Хәтта «Көндәлегем»дә боларның бөтенесе дә юктыр дип уйлыйм.

Мин, бары тик мин генә шагыйрь һәм татарлар белән соңгы көннәрендә бергә булдым, аларны үлемгә алып китүләрен күреп калдым. Алар минем белән итальянча һәм үзләренчә «сәлам» дип хушлашып киттеләр. Алар үзләрен бик тыныч тоттылар. Юрытко атакай миңа: «Татарлар елмаеп үлделәр», диде. Минем күңелемдә алар һәрвакыт бик кадерле истәлек булып саклана[3].

Хөрмәтле язучы әфәнделәр, Юрытко атакай сүзләрен беркайчан да онытмагыз: **«Татарлар елмаеп үлделәр».**

Бу язмаларымны язганда мин бик төгәл һәм гадел булырга тырыштым. Мин — язучы түгел. Әдәби итеп яза алмаган булсам, гафу итегез. Бу аяныч вакыйгалардан соң егерме өч ел үткәч бер файдам тияр дип һич тә уйламаган идем. Әгәр тагы

---

[1] Алдан язган хатларының берсендә Ланфредини шагыйрьнең күңеле һәрвакыт күтәренке, рухы көр булды, ул минем дә күңелемне төшермәскә, рухымны күтәрергә тырыша иде, дип язды. «Ләкин аның да күңеле төшкән чаклары була иде. Мәсәлән, Гитлерга ясалган һөҗүмнең уңышсыз чыкканлыгын белгәч, берничә көн бик борчылып, беркем белән дә сөйләшмичә боегып йөрде».

[2] Ул өч кеше — Абдулла Алиш, Абдулла Батталов һәм Әхмәт Симаев булган. Ланфредини аларны Җәлил альбомындагы рәсемнәреннән таныды.

[3] Җәлилнең биографиясе һәм альбомы белән танышып чыккач, Ланфредини нигә тугыз гына кеше күрсәтелгәнлеген сорап язды. Мин аңа җәлилчеләрнең өчесе әлегә билгесез булуын әйтеп яздым. Шуннан соң ул миңа: «Җәзалап үтерелгән (1944 ел 25 августында) татарлар барысы унике кеше иде. Җәлилдән тыш, журналистлар һәм инженерлар арасында анда немец хәрби формасы кигән тагын өч кеше бар иде, ләкин мин аларның исемнәрен хәтерләмим. Тик аларның барысын да «нацистлар режимына каршы пропаганда алып барганлыклары өчен» асканнарын гына беләм», — дип язды.

бирәр нәрсә кирәк булса — языгыз. Мөмкин кадәр тулырак итеп җавап бирергә тырышырмын. Синьора Җәлилгә һәм Җәлилнең кызына кайнар сәлам тапшырыгыз.

Һәр яклап уңыш телим Сезгә, әфәнделәр.

Ланфредини».

Алда әйтеп үтелгәнчә, җәлилчеләрне аскан көнне, ягъни 1944 елның 25 августында, Ланфредини, үзен кичерүләрен үтенеп, Италия илчесенә хат язган. Илчелек, аның үтенечен яклап, фашистлар министры Гиммлерга түбәндәге язуны җибәргән:

**«Кулга алынган солдат Ланфредини Реннероны гафу итү турында үтенеч.**

Италия фашистлар республикасы илчелеге немец кораллы көчләре җиңеләчәк диюдә гаепләнгән, 1944 елның 23 маенда Үзәк Хәрби трибунал тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителгән Италия гражданины Ланфрединины кичерүне үтенә. Хөкем карары илчелек аркылы 1944 елның 2 октябрендә алынды. Илчелек һич тә гаепләнүче тарафыннан фюрер дәүләтенә карата әйтелгән сүзләрне зыянсыз һәм авыр җәзага хөкем итәрлек факт түгел дип бәхәсләшми. Икенче яктан, без ул кешенең нинди шартларда булуын һәм шәхси үзенчәлеген исәпкә алуны үтенәбез. Ул шартларда аның әлеге сүзләрне алдан уйлап әйтүе һәм әйткән сүзләренең максаты — немец гражданнарына зыян китерү булуы мөмкин түгел. Безнең уебызча, трибунал мәсьәләнең шул якларын искә алмаган, шуңа күрә хөкем карары юридик тәнкыйтьне күтәрә алмый. Безнең фикеребезчә, бу очрак фюрерның 1939 ел, 16 октябрьдә игълан иткән кайбер әсирләрне кичерү турындагы боерыгына туры килә.

Гаепләнүче әйткән сүзләр немец халкының хәрби рухына җитди куркыныч тудырмый, чөнки ул андый мөмкинлектән бик ерак торган: танышлары аз, алар белән дә турыдан-туры аңлаша алмаган. Шундый куркыныч булса гына 5 статья буенча карар чыгару мөмкин булыр иде.

Ланфредини язган хатларда немец гражданнарына йогынты ясарга омтылу юк. Болардан тыш, хөкем ителгән кешенең бу хатларны язган чактагы рухи халәте үк андый нияте булуга юл куймый: аның тормышы политикадан бөтенләй читтә һәм хатларының эчтәлеге дә вак-төяк нәрсәләр турында гына. Ә начар ниятләрне тормышка ашыру өчен, мәсьәләне халыкка җиткерергә омтылыш кирәк. Безнең уебызча, монда сүз бик үк җитди булмаган очрак турында бара һәм гаепләнүчегә карата кирәгеннән артык җәза бирелгән. Шунлыктан без хөкем карарын яңадан бер кат тикшерүне һәм гаепләнүчене кичерүне үтенәбез. (Һич югында, төрмәгә ябу белән алыштыруны.)

Ланфредини хатларын мораль яктан бик төшенке вакытта язган. Италиядә ул сугышның кешеләргә, аларның йорт-җирләренә һәм, табигый рәвештә, барлык итальяннарның горурлыгы булган сәнгать әсәрләренә китергән бик зур зыяннарын күргән. Германиядә ул күнегелмәгән бик авыр эшләрдә эшләгән, бик кыен шартларда яшәгән. Шунлыктан аның рухы төшкән һәм ул сугыш китергән кыенлыклар турында сүз алып барган. Болардан тыш, ул үзенең мондый хәлгә төшүенә немец хөкүмәте түгел, бәлки Бадольо гаепле булуын оныткан. Чөнки ул немец газеталарын укымаган һәм немец радиосын тыңламаган. Шуңа күрә политик белеме ягыннан бик артка калган. Ул бөтенләй диярлек немецча сөйләшә белмәгән һәм хәрби тәртипләрне өйрәнеп өлгерә алмаган.

Солдатта да нибары бер ай, Италия армиясе җиңелер алдыннан гына булган ул һәм анда да хәрби күнекмә ала алмаган.

Ул авыр эшкә һәм кыенлыкларга иялэшмәгән. Алты ай буена өеннән берниндри хәбәр алмаган. Менә шушы хәлләрдән чыгып, Ланфредини теге хатларны рухы төшенке, күңеле китек вакытта гына язган дип уйларга була. Ланфредининың беркайчан да немец гражданнары белән бәйләнешкә керергә һәм аларга үз фикерләрен әйтергә тырышмавы да аның файдасына сөйли. Киресенчә, ул һәрвакыт алардан читтәрәк (102 битне карагыз) йөргән, димәк, берниндри дә тискәре тәэсир ясый алмаган.

Менә шушы хәлләрдән чыгып, без Ланфредини Реннероны кичерүне үтенеп мөрәҗәгать итү нигезле дип саныйбыз.

Министр әфәнде, безнең адвокатка тиешле кеше белән очрашырга мөмкинлек бирсәгез, сезгә бик бурычлы булыр идек. Берлин, 8. 11. 1944 ел».

Бик дини кеше булуын исәпкә алып, Юрытко да Ланфрединины кичерүләрен үтенгән. Нәтиҗәдә үлем җәзасы 15 елга төрмәгә ябу белән алыштырылган.

Җәлил һәм аның иптәшләренең кичерелү мөмкинлекләре булганмы соң?

Әлбәттә, фашистлар җәлилчеләрнең Гитлер режимына аңлы рәвештә каршы баручы һәм фашист армиясен таркату өчен күп эшләр башкарган кешеләр икәнлеген бик яхшы белгәннәр. Ләкин нигә соң яшерен эш алып барган җәлилчеләрне фашистлар кулга алу белән үк юк итмәгәннәр, нигә елдан артык төрмәләрдә тотканнар?

Фашистлар киләчәкне күз алдында тотканнар һәм политик максатлардан чыгып эш иткәннәр булса кирәк. Гитлерчылар үзләре оештырган «Идел-Урал» легионын Совет Армиясенә каршы көрәштә файдалану ниятеннән әле һаман кире кайтмаган булганнар, күрәсең. Җәлилчеләрнең хәрби әсирләр арасында дәрәҗәләре зур булуын белеп, аларны үз якларына аударырга өметләнгәннәр. Шул максат белән, гадел хөкем иткән атлы булып, ике тапкыр (Берлинда һәм Дрезденда) суд комедиясен ясаганнар. Суд алдыннан җәлилчеләр камераларына адвокат (татар ак эмигранты) һәм мулла кертеп, тоткыннарны судта гафу үтенергә дә үгетләп караганнар. Ләкин совет патриотлары аларның ул кармагына эләкмәгән, дошман алдында түбәнлеккә төшүгә караганда үлемне артыграк күреп, үгетләүчеләрне камераларыннан куып чыгарганнар.

Ланфредини 1945 елның маенда Совет Армиясе частьләре тарафыннан азат ителә. Әйтүенә караганда, азат иткәннән соң бер рус полковнигы аның белән дусларча сөйләшеп тә торган һәм алар шатлыктан бергәләп азрак рус аракысы да эчкәннәр. Аннары, сәламәтлеге начарлану сәбәпле, Ланфрединины «үз эшләрен бик яхшы белүче ягымлы руслар» госпитаденә салганнар. Анда бераз дәваланганнан соң, 1945 елның 10 июнендә ул үз иленә кайтып китә. «Русларга рәхмәтем һәм хөрмәтем бик зур минем, чөнки җирдәге барлык кешеләр — бертуган», — дип яза Ланфредини.

Муса Җәлилнең безгә билгеле соңгы шигыре 1944 елның беренче январенда язылган. Ләкин шагыйрь шуннан соң да сигез айга якын исән булган бит әле. Шул сигез ай эчендә бер дә иҗат итми тормагандыр лабаса! Кая язды икән Җәлил шигырьләрен? һәм аның ул әсәрләрен табарга аз гына булса да өмет бармы икән?

Ланфрединидан мин менә шул хакта сорашып хат язгач, ул болай дип җавап бирде:

«Мин Җәлил белән бер камерада утырганда төрмә дирекциясе унбиш көннән унбиш көнгә безгә китаплар бирә иде. Немецча белмәвем сәбәпле, миңа, гадәттә, рәсемле журналлар бирәләр иде. Шагыйрь исә, киресенчә, калын китаплар укый һәм немецча бик яхшы белә иде. Әнә шул үзе укый торган китапларда берәр яки артышар гына чиста бит тапса да, ул анда нидер яза иде. Төрмә китапханәсеннән аның шул чакта язган берәр әйберен тапканыгыз бармы?»

Димәк, Шпандау төрмәсендә китапханә булган икән?! һәм ул китапханәдәге китапларда Җәлилнең язмалары да булырга тиеш!

Бу безнең өчен бик мөһим һәм көтелмәгән яңалык иде. Мин яңадан җентеклебрәк сорашып хат язгач, Ланфредини: «Шпандауда китапханә булганмы-юкмы — белмим, әмма һәр унбиш көн саен төрмәне саклаучы немец солдатларының безгә китаплар кертеп һәм алдан китергәннәрен алып китеп йөрүләре хәтеремдә. Берлиндагы Тегель төрмәсендә дә шул ук хәл иде. Димәк, һәр төрмәнең үз китапханәсе булган булырга тиеш», — дип җавап бирде.

Шпандау төрмәсендә китапханә булганмы, әгәр булса, аның китаплары кайда икәнлеген әйтүләрен үтенеп, мин Көнбатыш Берлиндагы байтак кына официаль кешеләргә мөрәҗәгать иткән идем. Кызганычка каршы, берсеннән дә уңай җавап алганым юк әле.

Җәлилнең берәр төрле блокноты булдымы икән? Нинди дә булса кәгазьләре калдымы икән аның? Бу сорауларыма каршы Ланфредини түбәндәге җавапны язды: «Шагыйрь үзе укый торган китапларда очраган буш битләргә яза иде. (Минем турыда да нидер язганлыгын әйтте ул бер вакыт.) Ләкин аның бернинди дә куен дәфтәре юк, чөнки камерада һәр көн тентү үткәрелеп тора һәм безне, үлемгә хөкем ителгән-

нәрне, аеруча җентекләп тикшерәләр иде. Әгәр берәр төрле язу тапсалар, каты җәзага тарталар иде. Җәлил бик күп язды, ләкин соңыннан язган әйберләрен ерткалап ташлый торган иде...»

Язган әйберләрен ертып ташлау шагыйрьгә бик кызганыч булгандыр, әлбәттә. Әмма көненә өчәр-дүртәр тентеп торгач, башкача нишләсен соң?

«Шагыйрь миңа үзенең адресын да биргән иде. Ләкин бер тентү вакытында аны немецлар алып китте», — дип язды Ланфредини. Шуның өстенә, Мусаны үлемгә алып киткән вакытта Ланфредини башка камерада булган, шунлыктан шагыйрь аңа соңгы үтенечен дә әйтә алмаган.

Шулай булса да, җәлилчеләргә кайбер кәгазьләр тотарга рөхсәт ителгән булса кирәк. Чөнки, миңа язган хатларының берсендә, Ланфредини үлемгә киткәндә тоткыннар үзләренең барлык кәгазьләрен камерада калдырып китүләрен әйтеп язган иде.

Бәлки, ул кәгазьләрдә Муса Җәлилнең шигырьләре дә булгандыр, дип уйлаган идек без. Хәзер ышанып әйтә алабыз: әйе, чыннан да, булган икән.

Эзләнә торгач, шагыйрь төрмәдә утырган вакытта аның янына төрмәгә Илдар Идриси дигән бер татар килгәләп йөргәнлеге билгеле булды. Илдарның ата-аналары әле революциягә кадәр үк Германиягә күчеп киткән булганнар. Илдар үзе Германиядә туган, әмма шулай да үз илен, туган телен сагына торган кеше булган. Җәлилне дә шуңа хөрмәт иткәндер, күрәсең. Илдар шагыйрьгә берничә тапкыр икмәк, чиста эчке киемнәр һәм кәгазь алып килгән. Ә соңгы килүендә (1944 елның август ахырында була бу хәл) надзиратель аңа барлык татарларның да җәзалап үтерелүен әйтә һәм Җәлилнең әйберләрен алып чыгып бирә. Шул әйберләр арасында шагыйрьнең төрмәдә төшкән рәсеме, чүпрәккә төрелгән һәм вак кына хәрефләр белән язылган егерме битләп шигырьләре дә була.

Ул шигырьләр һәм Илдар Идриси нинди язмышка дучар булгандыр — анысын бүгенгә тикле белә алганыбыз юк әле. Илдар үзе дә, фашистларга каршы эш алып баруда гаепләнеп, төрмәгә ябылган, имеш, дигән хәбәрләр дә бар. Әгәр ул исән калган булса, барыннан да элек, аны Төркиядән эзләргә кирәктер, чөнки аның атасы, Галимҗан Идриси, Төркия подданные булган. Бу юнәлештә эзләнүләр алып барылса да, кызганычка каршы, әлегә уңай нәтиҗә биргәне юк.

*Автордан. Бу материал басылып яткан көннәрдә Италиядән күңелсез хәбәр килде. 1967 елның 12 декабрендә Рениеро Ланфредини инфаркт авыруыннан үлгән. Тоткынлыкта Муса Җәлил белән бер камерада утырган, ә соңгы елларда шагыйрь турында кыйммәтле мәгълүматлар биргән Р. Ланфредини тормышының ахыргы көннәренә кадәр безнең дустыбыз булып калды. Без, татар язучылары, мәрхүмнең хатыны Паоланың кайгысын чын күңелдән уртаклашабыз.*

*Шул ук көннәрдә Германиядән тагын бер мәгълүмат килде. «Известия» газетасының Берлиндагы үз хәбәрчесе С. Тосунян Леон Небенцальнең җәлилчеләр турында яңа документлар тапканлыгын хәбәр итте. Төрмә архивындагы рәсми язу буенча, Муса Җәлилне 1944 елның 25 августында уникe сәгать 18 минутта гильотинода үтергәннәр. Әхмәт Симаев, Әхәт Аднашев, Абдулла Алишев, Сәлим Бухаров, Абдулла Батталов, Фуат Булатов, Зиннәт Хәсәнов, Гайнан Курмашев, Гариф Шабаев, Фуат Сәйфелмөлековларны да шул ук көнне юк иткәннәр. Бу яңа мәгълүматның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Чөнки бу Җәлил һәм аның иптәшләренең кайчан җәзалап үтерелүләрен төгәл күрсәтә торган рәсми документ. Л. Небенцаль тапкан документларның тагын бер әһәмияте шунда, аларда моңарчы билгеле булмаган ике патриотның исем-фамилиясе күрсәтелгән. Алар: Әхәт Аднашев һәм Сәлим Бухаров. Кемнәр алар? Кайда туып-үскәннәр? Бездә әле бу хакта берниндн мәгълүмат та юк. Бәлки, безнең журналны укучылар арасында ул кешеләрне белүчеләр килеп чыгар?*

*Берлинда табылган бу яңа документлар турында тулырак мәгълүматлар журналыбызның алдагы саннарында биреләчәк.*

*Лэбибэ Ихсанова*

# ҖИР ХУҖАЛАРЫ

*Очерк*

Ясап куйган чәйгә кагылмады Венера. Озын керфекләренә кунган яшь бөртеген Мәгъсүмә апасына сиздермәс өчен чиккән яулыгының почмагы белән сөрткәли-сөрткәли, алма күк кызарган йөзен аска иеп тик утырды. Бүген аның иптәш кызларын партиягә алдылар. Биш кызны берьюлы. Венераны артык яшь диделәр. Шул да булдымы инде коммунистик хезмәт алдынгылары бригадасының эше. Эштә дә, ялда да, кайда гына, нәрсә генә эшләсәк тә бергә булырга дип ант итүләре юкка гына булды микәнни? Венера да бит партиягә кергән иптәшләреннән бер яшы белән дә ким түгел. Сөтне дә ул күптәнге партия члены Мәрьямниса апасыннан бик аз гына ким сава. Шулай булгач, аны гына аерып калдырырга ни хаклары бар аларның? Нигә соң аны гына бала-чага итәләр?

Менә шуларның барысы турында да колхоз парторгы Мәгъсүмә апасына сөйләп бирергә дип килгән иде Венера. Тик парторг кына сүзләрен җайлап китереп әйтә-әйтә кызның күңелендәге уйларын какшатып бара бит әле. Ул сөйләгән сүзләрне ишеткәне бар инде Венераның. Партиягә керүнең бик җаваплы эш икәнен дә, партиягә, халыкка файда китерерлек булганда гына шундый җаваплылыкны өстеңә алырга кирәген дә әйткәннәр иде аңа. Мәгъсүмә апасы да шуны ук сөйли. Ләкин ул әллә ничек үзенчә итеп, ышандырырлык итеп сөйли. Ул сөйләгәндә әниеңне тыңлап утыргандай хис итәсең. Менә шуңа күрә дә Венера аңа күз яшен күрсәтүдән ояла, башын күтәреп карарга кыймый, чиккән яулыгының почмагын бөтәрләп тик утыра.

Ә Мәгъсүмә апасы кызның уңайсызлануын күрмәмешкә салына. Дөресен генә әйткәндә, күптән инде аның бу чандыр кызны кочаклап алып бер сөясе һәм бик гади генә итеп:

— Балакаем, шулай инде ул яшь чакта, һәрвакыт олы буласы килә. Кайтсын иде әле миңа синең күк чакларым. Комсомолында ут уйнатыр идем. Исеме үк яшьләр оешмасы бит аның. Ни җитә соң яшьлеккә? Җырласаң да, биесәң дә килешә. Җир җимертеп эшен дә эшлисең, — дип кенә әйтер иде. Әллә ул сүзне бик ерактан башлап ялгыштымы? Партиянең бурычларын, аның тоткан ролен бу балалар китаплардан су урынына эчкән кешеләр ләбаса инде. Юктыр, ялгышмагандыр. Китап — китап инде ул. Каршыңда утырган кеше үз башыннан үткән хәлләрне үз теле белән сөйләп биргәндә бөтенләй башка була ул. Ә Мәгъсүмәнең, гомерен партия эшендә үткәргән кешенең, яшьләргә сөйләр сүзләре дә, бирер киңәше дә күп аның. 1937 елны Нормабашта колхоз председателе булып эшли башлаган иде, шуннан бирле халык арасында. Райисполком председателе урынбасары да, райком пропагандисты да, МТС та парторг та... Инде менә бишенче ел Беренче Май колхозында...

Ясап куйган чәйгә кагылмады Венера. Клубта иптәшләрем көтә, дип чыгып китте. Ышандымы ул парторгның сүзенә? Иптәшләренә булган үпкәсе басылдымы кызның? Тынычландымы ул?

Капка келәсе шалтырап төшүгә, Мәгъсүмә, урам як тәрәзәгә килеп, тышка карады. Түгәрәк ай кар өстенә зәңгәрсу нур пәрдәсе япкан. Тәрәзәләрдән төшкән кызгылт-сары ут кайчылары исә, ат юлына кадәр сузылып, шул пәрдәне телгәләп-телгәләп алган. Капка төбеннән килгән тар сукмактан олы юлга чыкты да Венера йөгерә-атлый клубка менеп китте. Башы югары, адымнары җиңел иде кызның. «Ышанган», — дип куйды парторг җиңел сулап.

Кыз инде күздән дә югалды. Ә Мәгъсүмәнең тәрәзә яныннан китәсе килми иде әле. Яртылаш боз каплаган пыяладан салкынча саф һава йөзгә бәрә. Күз алдында бөтен дөнья ап-ак булып җәелеп ята. Ни арада явып өлгергән шулхәтле кар? Бурап-бурап яуды да, ак мамыктай йомшак һәм көпшәк булып, бөтен җирне каплап алды. Инеш буендагы тирәкләр нечкә җепләрдән үрелгән челтәр ябынганнармыни — ап-ак бәскә төренеп калганнар. Таулар ышыгында утыргангадыр, җил какмыйча шулай матур булып челтәрләнгәннәр ул агач башлары. Тау битенең үзенә дә инде түшәк-түшәк кар яткан.

Мәгъсүмә күңеле белән минут эчендә әллә кайлардан урап кайтты да тәрәзә пәрдәсен тартып куйды.

— Быел җирдә дым күп булыр. Көз дә явымлы килде, — дип уйлады ул, шатланып.

Аның фатир хуҗасы Камәр әби тавышсыз гына табак-савыт җыештырып йөри иде. Мәгъсүмә дә килеп булыша башлады. Сүнгән самоварны күтәреп, мич алдына илтеп утыртты. Өстәл өстен сөртеп алды да кәгазьләрен таратып ташлады. Бүген аның райком өчен отчет язасы бар. Ләкин Венера белән сөйләшүдән соң урыныннан купкан күңелне тыеп, тиз генә эшкә кушып булмас, ахры. Мәгъсүмәнең эшкә утырырга нияте барын күргәч, Камәр әби дә, башына шәлен генә бөркәнеп, йомыш табып, күршесенә кереп китте.

Көзге пычракларда аяк атларга куркып торышлы иде, хәзер ярый инде, теләгән җиреңә йөгереп барып кайтырга була. Яуды да соң быел кар! Йомышың төшеп, урамның каршы ягындагы күршеңә керергә дә аптырап торырсың. Ә бит һәр баруның кирәге бар, дигәндәй, әзмы дөнья мәшәкате. Фермасына барып сыерын сау, бозавын кара, тракторын кабызып урманына кит, азыгын китер, бала-чагаңны мәктәпкә озат, кибетенә барып чәй-шикәрен алып кайт. Яшьләре тагын, кара төн дип тормыйлар, өстән ява димиләр — кич җиттеме, клубына йөгерәләр. Тездән пычрак ерарга тәмам интеккән иде Шытсу халкы, аяк асты катырып җиргә кырпак төшүгә, иркен сулыш алды.

Менә инде кыш уртасы да узып бара. Күз ачкысыз җылы бураннары, буран артыннан килгән сыкылы җепшек көннәре, шул арада тагын чатнама аяз салкыннары белән вакыт үтә дә үтә. Кыш өстендә бераз басылып торган крестьян тормышының, язгы нурлар уятып җибәргәндәй, һәртөрле мәшәкатьләре белән тагын җанланып чагы җитә.

Кәгазьдә саннар, саннар... Яңа төзелгән һәм төзеләчәк объектларның планнары. Электрлы, радиолы яңа салынган йортлар да, кич саен гөрләп торган клуб та, колхоз пекарнясы да онытылмаган. Яңа салынган медпункт та, су буендагы таш мәктәп тә, 800 башлык сарык фермасы һәм кормокухня да калмаган. Өй саен тырылдап торган мотоциклы, әлегә дүрт кенә булса да, телевизоры да искә алынган. Умартачылык, яшелчә һәм җимеш бакчасыннан алынган керем дә теркәлгән.

Ой, парторг, тукта! Соң син саннар белән мавыгып исемнәрне онытасың түгелме? Шул кирпечләрне салучы Шәмсенурлар, тонналап-тонналап сөт савучы Мәрьямнисалар, Венералар, көзен-язын, кышын-җәен юлда йөрүче шофер Мөсәвирләр, зоотехник Исмәгыйльләрне искә алырга кирәк түгелме? Исемнәр, фамилияләр... Югары һәм Түбән Шытсу, Чәпки Саба, Мамалай, Елыш, Сат Ключ авылларының кешеләре — Беренче Май колхозы колхозчылары. Аларның да бит үз җирләрендә ят булып, үзләре тапкан байлыктан мәхрүм булып яшәгән чаклары бар иде. Менә шушы кырларга, менә шушы урманнарга Кәрим байлар, Гобәй купецлар, алпавыт Крышкиннар, Нырты монахлары хуҗа булып торган көннәр әллә ни ерак та түгел әле. Илле елдан артык кына вакыт үткән, бәгырьне телгән, ул каргалган көннәрне әле дә сөйли Шытсу халкы. Шул вакытта күргән газапларны әле дә искә ала. Яшьләргә гыйбрәт итеп сөйли ул аларны.

Юк, саннар, планнар, җансыз биналар гына түгел, тере кешеләр, шушы җирнең хаклы хуҗалары, үзе белән бергә авырлыкны кичкән авыл халкы тора парторгның отчетында. Онытырга ярыймы соң аларны — бу җирләрнең чын хуҗаларын. Әнә бригадир Ислам Мөхетдиновны гына алыйк. Аның әтисе турында ишеткәне бар Мәгъсүмәнең. Гомере буе җир тырнап, кул көче белән көн күргән бер кеше була ул. Бер вакыт шулай Исламның әнисе мунча ягарга була да, яңа себерке бәйләп кайтырга дип, картын урманга җибәрә. Ерак барасы түгел, урман авыл өстенә аварга тора. Тик икенче читенең генә кайларга барып беткәнен белми Мөхетдин карт. Үткәндә-сүткәндә урман итәгенә кергәләп чыкса да, аркылысын буена иңләп

йөри алганы юк аның. Себерке саплары кискәләп кайтканы бар анысы, әмма бакчаңа киртә-мазар кирәк булса, байга гозер белән барасың инде. Анда да әҗерен эшләп кайтара-кайтара кара тирең чыга.

Матур урман үзе каһәр. Җаныңа нинди агач кирәк — шул бар. Ул аланнары, ул чишмәләре дисеңме. Шуңа да шул кышның кыш буе Казанда яшәгән байлар, җәй җиттеме, бу тирәләргә киләләр. Бер өзлексез кырда, яланда. Бер-берсе белән кунак-кунак уйныйлар. Кәрим байның да ул көнне Крышкиннарга кунакка баруы була. Тирә-яктагы гүзәллеккә сокланып килгәндә, алан читендә үскән ялгыз каенның ботагына менеп атланган картка күзе төшә аның. Тиз генә атын туктата, янына салган берданкасын кулына ала. Үзенең кучере белән каен төбенә килеп баса да картка кычкыра. Мөхетдин карт нишләргә дә белми. Сикереп кенә төшәр иде, агач төбендә мылтык төбәп бай тора. Ул да түгел, байның кучере балта алып килеп, каен төбенә чаба башлый. Нишләсен карт, ходасын телгә алып, күзләрен чытырдатып йома да, каен кәүсәсен кочаклаган көе, дер-дер калтырап тора башлый. Башта ышанмый ул, куркыталар гына дип уйлый. Әмма мәлгунь кучер чаба да чаба балтасын. Әнә ул эшләпәсен яшел чирәмгә салып ташлый. Түбәтәен селтәп, такыр башын җилләтеп ала, учларына төкереп, яңадан балтасына тотына. Ул да булмый, зар елагандай сузып кына шыгырдап куя каен агачы һәм ботагына атланып утырган Мөхетдин карт белән бергә гөрст итеп җиргә ава.

Күрәселәре моның белән генә бетми әле картның. Бай аны кыйный-кыйный авылга алып кайтып, келәткә ябып куя. Мөхетдин картларның мунчасы суынып бетә, көтеп-көтеп тә кайтмагач, тәмам хафага калган хатын авыл буйлап ирен эзләп китә. Аңа картның Кәрим бай келәтендә икәнен әйтәләр. Ялынып, ялварып карый хатын, әмма Мөхетдинне ирекккә чыгару урынына, бай аның хатынын да кыйнап, ире янына ябып куя...

Менә шул кешеләрнең балалары, оныклары белән эшли хәзер Мәгъсүмә. Әмма бүген уйлары гел сүтелеп кенә тора әле аның. Кемне генә күз алдына китереп бастырса да, ниндидер бер онытылмас вакыйга белән үткәннәр килеп керә парторгның күңеленә. Шытсуда үткән биш ел гомер эчендә нинди генә хәлләр кичермәде ул. Хәзер генә ул Мәгъсүмә апа дип өзелеп торалар. Ә ул чагында...

* * *

Менә Сезнең булачак парторгыгыз дип, райкомда гади генә киенгән чандыр буйлы, олыгаеп килгән бер ханымны күрсәткәч, Беренче Май колхозы председателе Гобәйдулла Хуҗин әллә ни куану күрсәтмәде. Киресенчә, райком секретаре белән икәүдән-икәү калган бер арада:

— Катырак куллы бер ир кеше булмаган икән шунда. Колхозның хәлен беләсез бит. Хатын-кызлар минем үземдә дә җитәрлек, — дип ризасызлык белдерде.

— Гобәйдулла абзый, соңыннан үзең дә рәхмәт әйтерсең әле, — диде секретарь, председательнең иңбашына дустанә сугып. — Гомере буе партия эшендә эшләгән, дөньяны күп күргән хатын ул.

Бу сүзләр генә юата алмады председательне. Чыннан да, бик авыр иде колхозның хәле ул елларда. Сугыш елларында да бирешмәгән, ел тәүлегенә колхоздан бер грамм да икмәк алмый эшләсә дә, бер йодрыктай нык торган халык, җиңү килгәч туарылып китте. Ил кайгысы зур чакта үз кайгысын онытып торган кешеләр хуҗалыкларын, үз көннәрен кайгырту ягын карый башладылар. Сугыштан кайткан ирләрнең бер ишләре читкә чыгып акча эшләү турында кайгыртса, икенчеләре, исән кайткан шатлыктан, ике дөньяны бер итеп йөри башладылар. Колхоз эше исә һаман да шул ябык йөзле, чая күзле хатыннар җилкәсендә калды. Елкылдап торган егәрле атлары да юк иде бит әле җитмәсә, машиналары да җитәрлек түгел иде.

Алар һәркайсы үз уйларына бирелеп, юл буе сөйләшми кайттылар ул көнне.

Ә бераз вакыттан инде председательгә бер-бер артлы сүз ишеттерә башладылар.

— Яңа килгән парторг чөгендер базы янында завхозның ачкычларын тартып алган. Үз белдеге белән аны икенче кешегә биргән.

— Абдуллина чәчүлек ашлыкны яңадан үлчәргә кушкан.

— Менә күр дә тор, председатель, печатеңне ала әле ул синең...

Печать өчен аптырамый председатель. Колхозны аннан шәбрәк алып баручы табыла икән, әйдә ала бирсен. Берәү дә гомерлеккә килеп утырмаган бу урынга, эшкә файдасы гына тисен. Тик монда кире-

сәнчә килеп чыкмагае әле. Ул яңа кешә бирәдәге халыкның җаен белеп бетерми торып, бик каты бөгеп ташламасын тагын. Агачны да бик кисәк бөксәң, шартлап сына.

Безнең халык белән эшләгәндә каты кул гына җитми, акыллы баш та кирәк әле шуның янына. Нинди кешә ул Абдуллина? Эшкә ничегрәк җигелер? Дуамалланып килеп тотыныр да, булдыра алмагач, ташлап китеп барырмы?

Кешә сүзенә колак салгаласа да Хуҗин, аның үз фикере, үз хөкеме. Әлегә ул карый, күзәтә. Кайвакытларда эченнән генә: «Эх, рәхәтләнеп бер ирләрчә сөйләшеп тә булмый бит», — дигән вакытлары да була. Әмма никадәр генә сузса да, парторг белән күзгә-күз карап сөйләшер көн бик җиткән иде инде.

Бу көнне парторг үзе дә көтеп йөргән икән.

— Гобәйдулла абзый, качыш уйнар чак түгел, сөйләшергә кирәк безгә, — диде ул бер кичне нәрәттән соң.

— Сөйләшик соң, сөйләшәсе сүзләр бар, парторг.

Күз карашы йомшак иде председательнең. Вакытсыз җыерчык баскан йөзе дә тыныч, әмма тавышы нык, кире кайтарып сүз әйтмәслек итеп, кистереп чыга.

Шул вакыт райкомда булган сөйләшүне хәтерләде Мәгъсүмә.

— Җиңел булмас. Колхозчылар арасында тәртипне ныгытырга кирәк. Бу авылда эчүчелек тә шактый көчле. Бюрода колхоз бухгалтеры Хаҗиәхмәтов Галимҗан, зоотехник Әдһәмов Исмәгыйльләр бар. Шуларга таян, — диделәр аңа.

Авыр буласын белде Мәгъсүмә. Ләкин беренче тапкыр гына түгел бит инде. Сабада да, Янильдә дә, Кукмарада да — һәрвакыт яңа җирдә, яңа кешеләр белән эшне башлап җибәрергә туры килде аңа. Эшнең җаен, кешеләрнең холкын, гадәтен белеп алганчы, бик кыен була иде, әлбәттә. Андый чакта Мәгъсүмәнең күңеленә мәрхүмә әнкәсенең сүзләре килә: «Кулыңның көче җитмәсә, тешең белән тарт», — дип әйтә иде ул. Ә бирәдә теш белән тартырлык эшләр шактый күренә әле...

Иртән ул фермада булган иде.

— Малларны атна-ун көн түздерә алсак, кырга куарбыз. Тырышыйк инде, кызлар. Менә күрерсез, ферманы беренче урынга чыгарабыз әле, — дип, ул сыер савучы кызларның күңелен күрергә теләде. Көлделәр генә үзеннән. Берсе юлга төшеп калган бер уч саламны күтәреп, парторгның борын төбенә төртте.

— Менә шуның беләнме? — диде ул, ачуын тыеп кала алмыйча.

Икенчесе гаепле кешедәй уңайсызланып:

— Ул малкайларның үз сөтләрен үзләренә эчергән чакларыбыз да булды инде, Мәгъсүмә апа, — дип куйды.

Юк, үгетләүдән һәм акыл өйрәтүдән башларга түгел эшне, ә ниндидер бүтән бер чара табарга кирәк иде.

Менә шулар турында председатель белән бик озак сөйләште ул. Нәтиҗәсе булмады түгел, икенче көнне үк фермадагы сыерлар өчен колхозчылардан бәрәңге җыю башланды. Яңа гына чокырдан чыгарган бәрәңгесен төяп фермага иң элек председатель Гобәйдулла үзе килеп җитте. Аннан кала колхоз активлары, бюро членнары, коммунистлар һәм күп кенә башка колхозчылар килде. Шулай итеп малларны тартып-сузып булса да, яшел үләнгә кадәр тернәкләндерерлек азык җыелды.

Әнә шул көннәрдә фермада сыер савучы Мәрьямниса Мәүлиева белән дуслашты ул. Гадәтенчә, Мәгъсүмә ферма кызлары янына килгән иде. Яңа парторгның сүз белән генә сыйлаучы түгел, эшләп тә күрсәтә ала торган кешә икәнен белгәч, бу юлы кызлар аны уен-көлке, шаян сүз, ачык йөз белән каршы алдылар. Учак өстенә күмеп пешерелгән кайнар бәрәңге белән сыйладылар. Озаклап, чын күңелдән сөйләшеп утырдылар.

Беренче Май көнендә Мәрьямниса парторгны кунакка чакырды. Яңарак кына тормыш башлап җибәргән яшь семьяның кунаклары да күбесе үзләре шикелле үк яшь кешеләр иде. Арада Мәгъсүмә күк елкән яшьтәгеләре дә бар. Әмма бу түгәрәк табында һәркайсы үзен иркен тота. Яңа гына бөреләр уяна башлаган җылы язгы төнгә каршы ачып куйган тәрәзәдән авыл өстенә гаҗәеп бер моң тарала. Сузып уйнаган гармонь тавышына кушылып, яшьләр татар халкының борынгы, моңлы көйләрен җырлыйлар. Гаҗәп, бу күңел нигә дип әнә шул хәсрәтле, кайгылы көйләргә ныграк тартыла икән? Шаян сүзләргә язылган матур-матур җырларыбыз да бар ләбаса. Ә менә шушындый бәйрәм кичендә дә «Зөлхиҗә»ләргә, «Рәйхан»нарга, «Карурман»нарга моңаеп утырабыз. Дөресен генә әйткәндә, Мәгъсүмә үзе дә өзелеп ярата

ул көйләрне, дөньясын онытып тыңлап утыра. Гасырлар буе килгән моң-зарны берничә дистә еллар гына оныттыра алмый күрәсең. Ул еллардан калган бәетләр, җырлар, гыйбрәтле вакыйгалар бабаларыбыздан аталарыбызга, аталарыбыздан безгә килеп җиткән. Без аларны балаларыбызга, оныкларыбызга җиткерик. Гыйбрәт өчен, хәзерге тормышның тәмен белсеннәр өчен, ямен югалтмасыннар өчен җиткерик.

Яшь киленнең уңган кулы бәйләгән челтәрләр белән бизәлгән бу кунакчыл йортта бик күп, бик күп тапкырлар тыңлады инде ул җырларны парторг. Хәер, соңгы елларда башка җырлар да ишетелә башлады биредә:

**Сандугачны почта итик**
**Арабызда йөрергә...**

Бәйрәм саен җыелалар алар. Болай очрашырга да җае чыгып кына тора. Райком члены Мәрьямниса конференциялардән кайтса, күчтәнәчтән авыз иттерергә дә чакырмый калмый. Казаннан Кызыл Байрак ордены тагып кайткач та ул, иптәшләрен җыеп, шатлыгын бүлеште.

Беренче Майда яшәгән саен, танышлары, дуслары арта барды парторгның. Китапханә мөдире Разия Зәйнуллина да бик булыша аңар. Икесе бер авылда торганга гына түгел, эшләре буенча да бик еш очрашалар. Китапханәгә яшьләр күп йөри. Разия аларда китапка мәхәббәт тәрбияләп кенә калмый, бик еш кына дөнья хәлләре турында сөйләшеп утыралар. Мондый кичләрдә анда парторг та була. Яшьләрнең укылган әсәрләре турында фикер алышуларын, киләчәк турында хыялланууларын тыңлавы күңелле андый кичәләрдә...

* * *

Киез итекләрен кага-кага Камәр әби кайтып керде.

— Теге юньсез тагын эчкән. Урам бетереп җырлап кайта, күрсәң иде, бер ходаем, дуңгыз урынына аунаган, — дип кемнедер тирги-тирги мамык шәлен салып чөйгә элде. Аркасы белән җылы мичкә сөялде.

— Ничә әйттем инде, әнием, өстеңә киеп йөр диеп, җиңел генә чыгасың да китәсең, — дип Мәгъсүмә бераз шелтәләп алды.

Фатир хуҗасын әнием дип йөри ул. Камәр әби үзе дә бик ярата аны. Районнан яңа парторг килә, Камәрттәй, синдә тыныч, үзеңә куярбыз әле аны дигәч, бик үк ризалык бирәсе килмәгән иде карчыкның. Пешергән ашыңны, җәйгән урыныңны ошатмый торган бер кыланчык нәрсә булса нишләрсең. Авыл җирендәге күк булмый ул читтән килгән кеше, дип уйлаган иде. Зур соры күзле, ябыграк озынча битле, чәчен дә авылча итеп, уртадан ачып тараган олы яшьтәге хатынны күргәч, бик тиз тынычланды үзе. Картаймыш көнемдә иптәш булыр, ялгыз башыңа көн итүе дә кыен, чирләп-нитеп китсәң, бер чүмеч су бирүчем дә юк бит янымда, дип уйлады. Сөлек кебек уллары сугышта вафат булып, берсеннән-берсе яшь кызлар белән калгач, кара төннәр буе офтанып, керфек какмый чыккан чаклары бар иде Камәр түтинең. Илдә чыпчык үлми, диләр бит. Еллар авыр булса да, үсеп буйга җиттеләр тагын кызлары. Әниләре аларны урынлы-җирле итеп, бер-бер артлы ияләренә тапшыра торды. Җан биргәнгә җүн бирә дигәндәй, ялгыз яшәргә туры килмәде тагын үзенә. Бик тиз ияләшеп киттеләр шул бер-берсенә. Хәер, авыл халкының да Мәгъсүмә димәгән көне юк. Кайсы йомыш белән килә, кайсы зарын сөйли, гаризасын яздыра, хатын укыта.

Яраталар шул. Нихәл итәсең. Югыйсә усаллык та бар инде үзендә. Бер вакыт шулай Гобәйдулла ферма малларына дип кукуруз чабарга куштырган. Бер әйткәннәр бригадирга, тыңламаган, ике әйткәннәр. Бигрәк авыр кузгала торган нәрсә булган шул. Мәгъсүмә фермага барып чыкса, малларга әле дә кукуруз бирелмәгән булуын күргән. Шуннан бу дуамалланып, чалгы алган да тотынган чабарга, тотынган чабарга. Ике ир, дүрт хатын җыеп өлгерә алмыйлар, ди. Соңыннан авыл халкында сүз китте, бригадир парторгның күзенә күренергә куркып, кукуруз арасында качып торган, ди шул вакытта.

Икенче бер вакыт, кайсы булгандыр инде, тракторчыларның берсе отпуска сорап кергән икән. Гөнаһ шомлыгына каршы, Мәгъсүмәгә туры килгән бу. Шуннан счетны алган да Мәгъсүмә тегенең эчеп калдырган көннәрен санап чыгарган. Тәптөгәл 42 көн җыелган бит моның. Отпусканы эчеп бетергәнсең син. Җитмәсә, никхәтле прогул да ясагансың, — дип, бөтен халык алдында йөзен кызарткан юньсезнең.

Узган ел колхоз акчага кучкәндә нәрсә булды? Башта халык ышанмады, вакытында

бирә алмасалар, икмәксез дә, акчасыз да утырырбыз, дип уйладылар. Өйгә кайтып керә алмады балакаем ул көннәрдә. Кешегә бит аңар барысын да әйтеп бирергә кирәк. Күрше авылларда күпмешәр акча алып эшләгәнне күрсәтергә. Хәзер менә акча санап кына утыра, ди Хәйдәр карт, теге чакта ышанмыйча ул да йөргән ие. Әйдә, санасын, ун бала үстереп җәфалангание, хәзер рәхәтен күрсен, әнә кызлары Флера белән Венера ай саен йөзәр сумны кайтарып кына торалар, ди үзенә. Ничәмә ничә мең кешегә җиткерерлек шул хәтле акчаларны кайдан алалар? дип уйлый Камәр түти үзе дә, аптырап.

Әгәр ул бу турыда Мәгъсүмәдән сораса, әйтер иде ул аңар. «Безнең сыерларыбыз хәзер өчәр мең литр сөт бирә бит. Җирләребездән яңгырсыз елны да уникешәр центнер ашлык алабыз. Бакчадан, умартадан күпме доход килә. Бөртеген дә әрәм итми барлап тоткач җыела икән ул, әнием», — дияр иде.

...Камәр түти нәрсәдер язып утырган Мәгъсүмәне бүлдереп, кинәт кенә башына килгән сорауны бирергә кыймады. Авыз эченнән догасын укып, җылы түшәгенә менеп ятты.

* * *

Тәрәзә турыннан кинәт кенә җыр тавышы ишетелде һәм кинәт кенә узып та китте ул. Парторгның колагына әллә керде, әллә юк бу моң, ул башын күтәрмәде. Инде кызу-кызу яза иде ул. Җир хуҗалары, аларның хезмәтләре, аларның җиңүләре, килачәккә планнары турында партиягә отчет яза ул.

Җыр тавышын ишетүгә, Камәр түти генә, Мамалилар машина белән клубка килгәннәр ие, китеп баралар, ахры. Иренмәгәч иренми икән бу яшьләр дип, ут яктысына арты белән борылып ятты.

Тәрәзә янындагы кечкенә өстәлгә башын иеп, Беренче Май колхозы парторгы Мәгъсүмә Абдуллина бик озак эшләп утырды. Аның күз алдыннан биш авылның кешеләре, аларның язмышлары, киләчәге үтте ул кичне. Язмышлары якты, киләчәге матур аларның.



*Ямил Мостафин*

# БРОНЗАДАГЫ ҖӨЙЛӘР

*Очерк*

Инде чирек гасыр узды, ә 1942 елгы салкыннар бик күпләрнең хәтерендә әле: чыпчыклар очып барган җирләреннән туңып тәгәри, атларның колакларыннан-борыннарыннан кан китә, төннәрен агачлар шартлап ярыла. Суык сөяккә генә түгел, үзәккә үтә...

Шулай да ул елны Мәскәүне саклаучыларның бу салкыннарга исләре китмәде.

Шундый салкын февраль көннәренең берсендә биш дивизион «Катюша» минометларыннан торган оператив группа, полковник Барый Юсупов командалыгында Төньяк-көнбатыш фронтка китәргә приказ алды.

Старая Русса районында немецларның танклар белән көчәйтелгән дивизиясе һөҗүм итеп килә, ә аңа каршы безнең моңа хәтле сугышларда шактый таушалган өч йөз кешелек бер полк кына оборона тота иде. Юсупов группасына дошманның күп тапкырлар өстен булган көчен тоткарлау бурычы куелды. Каты салкыннарга карамастан, тирән кар ерып, «Катюша»лар Старая Русса районына юнәлде. Машиналарга юлны көрәк белән кар казып салырга туры килде. Шундый салкында да солдатлар манма тиргә баттылар. Тәбәнәк кенә буйлы, киң җилкәле, нык гәүдәле полковник Юсупов, үзенең «Эмка»сына утырып, колоннаның әле башына, әле койрыгына йөреп торды. Полковник вакыт-вакыт, «Эмка»сын туктатып, кулына көрәк ала, солдатларга көрткә баткан машинаны чыгарырга булыша иде. Буран торган саен котырды, җил бер көрәк алып ташлаган урынга икеләтә, өчләтә артыграк итеп кар тутыра иде.

Юсупов, туктап калган колоннаны үзенең урынбасарына калдырып, ике шофер белән, җиңел машинада полк урнашкан позициягә китеп барды.

— Иртәнгә тиешле урынга барып җитү өчен бөтен көчне куегыз, — диде ул үзенең урынбасарына. — Ә мин, сез килеп җиткәнче, андагы хәлләр белән танышa торам.

— Аңлашыла, иптәш полковник.

«Катюша»лар командиры позициягә килеп җиткәндә, таң беленә башлаган иде инде. Анда өч йөз кызылармеец бары тик яндыргыч сыекча тутырылган шешәләр һәм берничә дистә танкка каршы граната белән дошман дивизиясенә, танкларына каршы торырга әзерләнә иде.

Очраклы рәвештә сакланып калган бер йортка «хәрби совет» җыйналды. Командирлар танкка каршы торучылар өчен тирән окоплар казырга һәм тирә-юньдәге карны, танклар окопларны күмә алмаслык итеп, таптарга дигән карар чыгардылар.

«Катюша»лар әле һаман килеп җитмәгән иде. Кызылармеецлар куе зәңгәр комбинезон кигән, позицияләр буйлап, окопларны ничек казырга күрсәтеп, хуҗаларча йөргән базык гәүдәле, киң яңаклы полковникка өмет белән карадылар.

— Окопларны шахмат тәртибендә казыгыз, — дип өйрәтте полковник, — танк бер окоп янына килгәндә, икенчесеннән аның моторына атарлык булсын. — Юсупов шу-

лай диде дә окопка сикереп төште һәм дошман танкысын ничек каршы алырга, аңа ничек тиз итеп граната ташларга өйрәтә башлады.

— Танкны аны этне үртәгән кебек котыртырга кирәк, — диде ул. — Ләкин ташлатмә. Үзегез беләсез, аның теше корыч. Әгәр, җайлы вакыт туры китереп, граната ыргытсаң, эше бетте аның.

Полковникның бу сүзләре кызылармеецларның күңелләрен күтәреп җибәрде. Кайберәүләр мәзәкләргә үк керештеләр:

— Әйдә, күбрәк килсеннәр. Күрмәгәннәрен күреп китәрләр!

— Иң мөһиме, иптәшләр, танкларга оборонаны өзеп эчкә үтәргә ирек бирмәскә, пехотаны алардан үз вакытында аерып өлгерергә кирәк. Нык торырга. Ә «Катюша»лар менә-менә килеп җитәчәк. Алар сезне кыен хәлдә калдырмаслар. — Юсупов, карга кадап куелган кечкенә кызыл флагка күрсәтеп, сүзен дәвам итте: — Менә бу мина иң башлап килүче танкны шартлатырга тиеш. Алар һәр вакыт «дуңгыз борыны» рәвешендә һөҗүм итәләр. Александр Невскийны оныткannар, күрәсең.

Менә, салкын һаваны тетрәтеп, танклар гөрелтесе ишетелде.

— Без көткәнне белгәннәр, ахры. Кунак итәргә әзерләник үзләрен, — дип шаяртты «Катюша»лар командиры.

Озакламый танклар үзләре дә, искәнгәндәй, юан имән агачларын әйләнеп үтәүтә, ташбака кебек үрмәләп, позициягә якынлаштылар. Алдан соры төскә буялган командир танкысы килә иде.

— Полковник дөрес әйткән икән. Кара әле, чыннан да, дуңгыз борынына охшап киләләр.

— Күрәсең, танклар белән беренче генә очрашуы түгел. Этне үртәгән кебек үртәргә кирәк, ди бит.

— Минадан куркалар, — дип Юсупов та сүзгә кушылды, — сакланып киләләр.

— Их, унлап кына мина булса да күрсәтер идек күрмәгәннәрен. Бер генә бит, — дип ачыргаланды полк командиры.

— Бер мина да эшкә ярый, — диде Юсупов. — Ун, унбиш, егерме танк... Пехота да алардан калмый килә.

Алдан килгән танк оборона позициясенә бәреп керде. Кемдер аңа төбәп яндыргыч сыекча тутырылган шешә ыргытты, ләкин тидерә алмады. Танк аңа таба борылды.

— Минадан читкә тайпыла хәшәрәт, — диде полковник һәм сул як җилкәсенә ике яндыргыч шешә, уң ягына ике граната салынган сумкалар асып, үлем машинасына таба атлады.

Юсупов танкка граната ташлады һәм минага таба чигенде. Ә мина утыз метрлап артта иде әле.

Танкны йөртүче, Юсупов уйлаганча, граната шартлавына игътибар итте. Танк боргаланды һәм немец комбинезон кигән кешенең әкрен генә артка чигенүен күрде. Бу кешенең корыч тауга бер дә исе китмичә, тыныч кына арты белән артка чигенүе немецка гаҗәп тоелды.

— Изеп үт үзен! — дип боерды аңа танк командиры. Башнясына тәре төшерелгән танк, юлындагы агачларны ватыпсындырып, кешегә таба ыргылды.

— Бик әйбәт. Әздән килә, — дип уйлады Юсупов. — Минаны гына үтим, эшең бетте, фашист... Нигә дип атмый әле ул. — Шуны уйлап өлгермәде, танк аударган агач ботагы башындагы каскасын бәреп төшерде, икенче бер ботак ялангач башка бәрелде. Җылы кан күзне томалады. Танк бик якын иде инде.

«Чыннан да, нәкъ этне үртәгән кебек котырта», — дип уйладылар бу хәлне күзәтеп торган сугышчылар.

Берничә минут элек үзәккә үткән суык сизелми иде инде. Юсуповка эссе иде. Әлбәттә, ул читкә шуышса, танктан күренмәслек урында яшеренеп кала алыр иде. Ләкин полковник үзе турында уйламады. Аның ничек кенә булса да үз дигәненә ирешәсе килде — алдан килгән танк әлеге минага эләгеп шартларга тиеш!

Менә мина аның артында, ул моны күрмәде, чамалап тойды. Юсупов кечкенә флагны аягы белән аударды да артка атлады.

Шул вакыт кинәт танк Юсупов өстенә ут сиптерде. Утка чыдамлы комбинезон тотәргә кереште, битенең бер ягы бик нык пеште, бармаклар күпереп чыкты.

«Кара син хәшәрәтне, — дип уйлап алды полковник, — менә ни өчен атмаган икән ул. Пулемет урынына огнемет куйган»... Каты шартлау дулкыныннан Юсупов җиргә ауды. Уң кулы хәрәкәтләнми башлады, калак сөяге турысында комбинезон теткәләнеп беткән иде: аның уң як гәүдәсенә уннарча ярчык керде. (Соңыннан Мәскәү госпиталендә Юсупов гәүдәсеннән утыз өч ярчык алдылар.)

Позициядә танклар белән каты бәрелеш бара иде. «Катюшалар» командиры

моңа кадәр аңа игътибар итәргә өлгермәде, танк белән мавыгып китте.

Юсупов, ярым һушсыз хәлендә, танкның бер урында әйләнүен һәм туктап калуын күрде. Менә алгы люк капкачы ачылды, озын буйлы немец сыны күренде. Ул, яртылаш гәүдәсе белән бөгелеп, танкны караштырды да люкны ачык калдырып, яңадан эчкә кереп югалды.

Юсупов ничек итеп сул кулы белән ачык люкка граната ташлавын үзе дә хәтерләми.

Танк эчендәге каты шартлау тавышыннан гына аңына килде ул.

Полковник ялкын элеп алган танкка тагын бер тапкыр күз ташлады да урманга таба шуышты. Аннан аягына басты, шартлаулар, гөрелтеләр тавышыннан бу сугышның кем ягына хәл ителәсен чамалады. «Немец бу урыннан оборона аша үтә алмаячак! Әй, «Катюша»лар килеп өлгергән булса», — дип уйлап алды ул.

— Hände hoch! — дигән тавыштан полковник кинәт сискәнеп китте. Уң кулы белән кесәдәге пистолетына үрелергә исәпләде, ләкин кул аның теләгенә буйсынмады. Автомат көбәге белән башына суккач, ул егылды. Ләкин аңын югалтмады, күзләрен ачып немецка карады: ул төшләрен ыржайтып елмая иде. «Әһә, шпалларны күргәннәр, әсир итәргә телиләр... Барып чыкмас...» дип уйлап алды ул.

Юсупов сиздермәстән генә сул кулы белән сумкага тыгылды, яндыргыч сыекча тутырылган шешәне алды. Немец моны күргәч, кинәт каушап калды, нәрсәдер кычкырып якындагы каен агачы артына яшеренде. Аның артыннан шешә очты. Ул каенга бәрелеп ватылды, сыекча фашистка да тиде. Аны ялкын чорнап алды һәм ул кар өстендә тәгәрәргә кереште. Ә полковник, ярым һушсыз хәлендә, күптән түгел генә «хәрби совет» үткәрелгән йортка таба шуышты... Полковник, баскыч тоткасына ябышып, аягына басты. Тирә-якта тыптын кебек иде. Мондый тынлык сугышта гайре табигый булып тоела. Ләкин өстә немец бомбардировщиклары оча, бик түбәнтен очалар алар, бомбалар ташлыйлар, пулеметлардан аталар.

Юсупов сул кулы белән тоткага ныграк ябышты, ләкин шул вакыт бу йорт үзе дә, тирә яктагы агачлар да аның өстенә ишелеп төштеләр кебек тоелды...

...Полковник Юсуповны сугыш кырыннан бик озак эзләделәр, үлгәннәр арасыннан да, яралылар арасыннан да таба алмадылар. Әлеге йорт җимерекләре астыннан мәетләрне чыгарганда гына аны комбинезоны буенча танып алдылар, ә мондый киемне «Катюша» кешеләре генә кия иде...

Авыр яралы полковник Юсуповны Мәскәүгә, Үзәк хәрби госпитальгә самолет белән китерделәр.

— Бу батыр кешене үлемнән саклап калу өчен бөтен көчегезне куегыз, — дип телефоннан шалтыратты Төньяк-көнбатыш фронты командующие. — Әгәр мөмкин түгел икән, бөтен хәрби шартларны китереп, хөрмәтләп күмегез!..

— Аны саклап калырга тырышабыз, — дип җавап бирде аңа профессор Тихомиров.

Полковник Юсуповның гомере бик күп көннәр һәм төннәр дәвамында кыл өстендә торды. Аны саклап калу өчен күренекле галимнәр, врачлар бөтен сәләтләрен биреп көрәштеләр. Һәм, ниһаять, хирург Петр Васильевич Мандрык:

— Полковник Юсупов яшиячәк! — дигән җылы сүз әйтте.

...Совет кораллы көчләренең җимергеч удары нәтиҗәсендә немецлар Мәскәү астыннан чигенгәч, Совет Армиясенең Политик идарәсенә атаклы скульптор Вера Игнатьевна Мухина килеп, Ватан сугышының чын героен күрсәтүләрен сорый.

Идарәдәге җаваплы кешеләр барысы да бердәм булып Юсупов фамилиясен атыйлар. Шунысын да онытмаска кирәк: бу вакытта совет сугышчылары арасында батырлык массовый күренеш иде. Димәк, батырларның да батыры кем? Мондый кеше итеп Барый Юсупов фамилиясе күрсәтелә.

Скульптор батырны бик тиз эзләп таба. Юсуповның битендәге тирән кызыл җөйләргә дә, бер күзен каплап торган тасмага да скульпторның исе китми, ул аның образында буыннардан буыннарга сакланып калырга тиешле батыр кешене күрә. Һәм эшкә керешә.

Көннәрнең берендә:

— Барый Абдуллович, сезгә шулай утыру кыен түгелме? — дип сорый.

— Юк, — дип җавап бирә Юсупов. — Мин уйланып утырам. Үткәннәрне искә төшерәм, хыялланам...

Әйе, батырларның батыры булып әверелгән бу кешенең уйланыр һәм хыялланыр нәрсәләре дә күп иде.

Кем иде соң ул?

Әлмәт дигән бер татар авылында туа ул. Шаян, шук булып үсте, бала вакытта ук каберлеккә барып, төн уздыру аның өчен берни тормый иде. Җәй көннәрендә Зәй елгасында унар тапкыр су коена торган иде. Әле иптәш малайлары белән кемнең күпме коенуы турында бәхәсләшерләр дә иде.

— Мин биш тапкыр коендым.

Эссе кояш кыздыруына карамастан, тешләре тешкә тиеп калтыранган икенче малай:

— Мин җиде коендым, әле тагын керәм, — ди, ә үзе күлмәген тизрәк киярга ашыга.

Ә Барый иртәдән бирле инде Зәй буенда. Ул да бүтәннәрдән калышмый. Менә ул тәкъдим кертә: — «Әйдәгез, аркан йөзешле уйныйбыз», — ди. Һәм күлмәген сала да Зәйгә чума. Малайларга шул гына кирәк, алар да чумалар. Ә Барый ярдан эчкә йөзә. Башка малайлар да аның артыннан йөзеп карамакчы, әмма агым тиз, читкә алып китә. Ә Барый үз дигәнен итмәкче: һаман алга, каршы якка таба колач сала.

Бу тәвәккәллеге өчен нык эләкте өйдә Барыйга. Ник дисәң, елганың тирән урынында, чоңгылга эләгеп, көч-хәл белән генә котылып калды ул. Авыз-борынына су керде, сулап булмый башлады. Ярый әле якында гына балыкчы бабай бар иде, ул колагыннан тартып чыгарды — югыйсә, балыкларга азык булып Зәй суы төбенә китәсе икән...

Менә бер заман Әлмәттә хәбәр таралды: инде патша юк икән, халык үзенә үзе хуҗа икән. Күпләрнең моңа ышанып та бетәсе килми иде. Ләкин бу хәбәрләрнең дөреслеген тормыш үзе күрсәтте: фронттан кайткан солдатлар бөтен кеше дә тигез хокуклы булып, байлар кулындагы җирләрне ярлылар арасында бүләргә кирәклеген сөйләргә, моны Ленин сүзләре белән аныкларга керештеләр...

Күп тә үтмәде, бу тирәләр җир һәм азатлык өчен көрәш плацдармына әверелде. Ак чехлар да уздыбиредән, авыл кешеләрен Колчак бандалары да талады. Әлмәт авылы әле аклар, әле кызыллар кулына берничә мәртәбә күчте. Барый кызыллар яклы иде, хәтта ул аларга аклар турында хәбәрләр дә җиткереп торды. Нургали бай бу турыда акларга белдерде. Аны шомпол белән кыйнадылар, кулларын ат койрыгына бәйләп, сөйрәттеләр. Ничек исән калгандыр ул, моны үзе дә хәтерләми. Аңына килгәндә, авылда кызыллар иде инде.

Азрак хәл алгач, аякка баскач, Барый Юсупов хәрби кеше булырга, азатлык алган ярлы халыкны якларга үз-үзенә сүз бирде.

...Барый Юсуповның тормышы гаҗәп кызыклы һәм катлаулы. Казанда кызыл командирлар курсын тәмамлагач, ул Урта Азиягә — Кушкага җибәрелә. Ә егерменче елларда анда хезмәт итү бик авыр була: басмачылар һәм башка шундый бандитлар ярлы халыкның властька килүе белән ризалашырга теләмиләр, өстәвенә бизгәк авыруы бик күпләрне аяктан ега.

Юсупов организмы һич кенә дә бу климатка күнегә алмый. Аңа берничә тапкыр хезмәт урынын алмаштырырга тәкъдим ясыйлар.

— Азрак түзеп карыйм әле, — ди ул командованиегә. — Минем урынга килачәк яңа кешегә дә күнегү өчен шактый вакыт кирәк бит...

Ләкин көннәрнең берендә Юсуповны авыру тәмам аяктан ега һәм аны, аңсыз хәлендә, Кушкадан алып китәләр.

...Хәзер Юсуповка инде алтмыш яшь. Шулай да бик көр күңелле ул, үз көченә, кешеләргә нык ышана. Сугыш аның бер күзен, сәламәтлеген алып калган булса да, үз тормышыннан бик канәгать.

— Мин бәхетле, — ди ул. — Үз гомеремдә яхшы кешеләрне күп күрдем. Алар миңа дәрт бирделәр, үз-үземә һәм кешеләргә карата зур ышаныч тудырдылар. Мин сугышта гарип калуыма һич тә кыенсынмыйм, чөнки мин Мәскәүне сакладым. Улыма да, оныгыма да минем өчен беркайчан да кызарырга туры килмәс. Константин Эдуардович Циолковский белән очрашкач, ул әйткән сүзләр минем яшәвемнең мәгънәсе булып әверелде. «Батырлык физик һәм рухи көчләрнең киеренкелеген таләп итә, — дигән иде ул. — Янгын вакытында баланы коткарып калу, яки поездны һәлакәттән коткару — болар да, әлбәттә, батырлык. Чын батырлык ләкин, егетем, катлаулырак. Мин Владимир Ильич Ленин, Киров, Горький, Павлов кебек кешеләрнең тормышын чын батырлык дип саныйм... Әйе, аларның зур идея белән сугарылган киеренке хезмәтләрен мин чын батырлыкка тиңлим».

Бөек галимнең бу сүзләрен истә тотып, мин батырлыкны бервакытта да үзмаксат итеп куймадым...

Константин Эдуардовичның үзенең дә бөтен тормышы даими батырлыктан гыйбарәт иде бит...

Нәкъ менә шуңа күрә дә Академиядә укыганда да, училищеда укытканда да, фронтта гвардия минометларының оператив группасы белән командалык иткәндә дә, армиядән демобилизацияләнгәч, колхоз белән җитәкчелек иткәндә дә — ул бөтен көчен биреп, янып эшли.

Фронтта дошманнарны да рәхимсез яндыра ул. Аның кул астындагы «Катюша»лар Ново-Фоминск, Тула, Мәскәү тирәләрендә немецларның котын очыра. «Катюша» залпларыннан соң, фашистларның танк колонналары, орудиеләре, машиналары эреп, металл өеменә, меңнәрчә солдатлары күмерләнеп янган мәеткә әверелә...

Полковник Юсупов үзенә тапшырылган бу яңа коралның барлык мөмкинлекләрен бик оста файдалана.

Ничектер чәй янына туры килеп, генерал Панфилов юкка гына котламый аны.

— Зур җиңүгә ирештегез сез! — ди ул.— Үземнең батырлар исеменнән сезнең алда баш иям һәм бу залпларыгыз өчен рәхмәтемне белдерәм. Дошманның югалтулары ничек?

— Хәбәрләр әлегә тулы түгел, — дип җавап бирә полковник Юсупов. — Ләкин беренче залпның нәтиҗәләре билгеле инде: фашистларның 17 танкысы, 20 минометы, 5 орудиесе җимерелгән. Мәетләрне санау мөмкин булмаган. Иң мөһиме: дошман группировкасы юк ителгән.

Соңрак Юсуповка легендар генерал Доватор белән дә эш йөртергә туры килә. Шулай ук алар землянкада бергәләп утырып чәй эчәләр һәм алда торган операция турында киңәшәләр. Бу очрашу турында Юсупов түбәндәгеләрне сөйли:

«Доваторның атлы корпусы дошман тылына үтәргә приказ алды. Ә мин аңа тылга узу өчен «Катюша»лар белән дошман оборонасын өзәргә тиеш идем.

— Әһә! — диде Доватор. — Приказдагы сүзләргә игътибар итегез. «Дошманның оборонасы аша юлны чистартырга», диелгән. Димәк, фашистлар инде һөҗүм итмиләр, оборонага күчкәннәр, дигән сүз бит бу. Тиздән качу ягын карый башларлар!

Икәүләшеп картада оборонаны өзү урынын билгеләдек.

— Шикләнмәгез, иптәш генерал, — дидем мин. — «Катюша»лар үз эшләрен җиренә җиткереп башкарырлар. Атларыгыз көл таптап үтәрләр. Безнең залплардан соң анда корал тотып сезгә каршы сугышырлык җан иясе калмас.

Герой белән соңгы очрашуым икәнен мин ул вакытта күз алдыма да китермәдем. «Катюша»лар аларга юл ачып бирде. Ә Доватор бу рейдтан әйләнеп кайта алмады»...

Полковник Юсупов командалыгындагы «Катюша»лар группасы сугышларның егерме көне эчендә генә дә 200 дән артык торак пунктын азат итүгә актив катнаша. Бу вакыт эчендә тулы булмаган исәпләүләр буенча гына да Гитлер армиясенең ун меңнән артык солдатын һәм офицерын теге дөньяга олактыра, дистәләрчә танкларын һәм орудиеләрен юк итә.

Оператив группага сугышларда кискен хәлләрдә калырга да туры килә. Бу үз юлында һәр нәрсәне яндыра торган «җәһәннәм тубын» кулга төшерү өчен Гитлер барлык көчне куярга приказ бирә. Реактив минометларның берсен генә булса да кулга төшерү өчен ни генә эшләми дошман. Шуңа күрә Совет командованиесе һәр машинаны миналаштырырга приказ бирә. Куркыныч шартларда реактив җайланманы юк итү өчен кнопкага гына басарга кирәк була. Капитан Флеров җитәкчелегендәге «Катюша»лар батареясы, чолганышка эләккәч, әнә шулай һәлак була.

1941 елның ноябрендә Юсупов кул астындагы ике дивизион шундый ук куркыныч хәлгә кала.*

«41 елның ноябрендә, — дип сөйли бу турыда Юсупов үзенең истәлекләрендә, — генерал Гост һәм Хюппер командалыгындагы танклар Мәскәүне штурмларга ташландылар. Аларга каршы барлык төр орудиеләр куелды. Есипово авылы янында хәтта зениткалар да туры наводка белән танкларга каршы аттылар. Кечкенә биштә автоматчылар утырткан дошман танклары урман эченнән безне әйләнеп үттеләр. Ике яклап юл читендә торган ике «Катюша» дивизионына чолганышта калу куркынычы туды. Шул вакыт 16 нчы армиянең артиллерия начальнигы (хәзер артиллерия маршалы) В. И. Казаков кулына винтовка алды һәм тирә-ягындагы солдатларга:

— Минем команда буенча залп белән генә атарга! — дип команда бирде.

Пехота ярдәмендә мин дивизионнарны тылга алып чыга алдым. 28 ноябрь иртәсендә Черная Грязь районында өч дивизион «Катюша» дошман өстенә җиде

залп бирделәр. Ә икенче көнне гвардия минометчылары, ярдәмгә беркетелгән танклар һәм артиллерия белән берлектә, ким дигәндә бер дивизия гитлерчыларның көлен күккә очырдылар.

Черная Грязь районы Мәскәү оборонасының соңгы сызыгы иде. Мин ут позицияләрен бары тик фронт буйлап кына алыштырырга приказ бирдем. Бер генә машина да ярты адым да артка чигенмәде.

Соңыннан без Клин белән Теряева Слобода арасында гына да дошманның меңнән артык җимерек танкларын, тупларын, машиналарын, ун меңнән артык мәетләрен санадык!..

* * *

Мәскәүдә Третьяков галлереясын көн саен меңнәрчә кеше карый. Полковник Юсуповның Вера Игнатьевна Мухина эшләгән бронза скульптурасы янында һәрвакыт халык күп була. Күренекле совет художнигының иң яхшы эшләреннән берсе ул.

Аларның күбесе скульптурада сурәтләнгән бу кешенең исән-сау икәнлеген дә белми, шулай да какшамас ихтыяр көче, ныклы ышаныч балкып торган бу образның һәр деталең күңелендә калдырырга тырыша. Киң яңаклы йөзендәге җөйләр, күзен бәйләгән тасма скульптурада сурәтләнгән кешенең какшамас характерлы, батыр булуын әйтеп тора.



*Полковник Б. Юсуповның В. И. Мухина эшләгән бюсты.*

Әйе, ул тормышта да шулай: тыныч та, нык та, дәртле һәм көр күңелле дә.

Барый Юсупов башлангыч партия оешмасы белән җитәкчелек итәргә дә, укучылар, сугышчылар алдында чыгыш ясарга да вакыт таба.

Әйе, үзе исән вакытта ук бронза булып сәнгатьтә гәүдәләнгән бу кешенең яшь буынга сөйләр сүзләре күп.

*В. Хангильдин*

# КӨТЕЛМӘГӘН БЕР ОЧРАШУ

**1914** елның җәе. Июньнең соңгы атнасы иде бугай. Сукыр эчәк авыруыннан дәвалану максаты белән Казанга сәфәр иттем: Казан больницаларында, операция ясап, бу чирне төзәтәләр дигәннәр иде.

Пароходтан төшкәч, извозчик мине «Болгар» номерларына китереп куйды. Мин беренче кат шулай бу тарихи бинада булдым. Габдулла Тукай торган бүлмәне дә күрсәттеләр. Ләкин шагыйрь үзе дөньяда юк иде инде, аның үзен күрү насыйп булмады. Шунда эшләүчеләр шагыйрь турында кайбер эпизодлар гына сөйләделәр.

Уфадагы таныш-белешләрем миңа турыдан-туры земский больницага мөрәҗәгать итәргә киңәш биргәннәр иде. «Болгар»дагы агай-эне белән аңлашкач, ул киңәшне куеп торырга туры килде. Алар миңа «иң элек бер мөселман докторына күренү яхшы булыр» диделәр һәм шунда ук үзләре белгән бер врач эшли торган клиниканың адресын язып бирделәр, анда бару юлын да өйрәттеләр.

Бу — университет каршысындагы клиника, мөселман доктор дигәннәре исә барыбызга да мәгълүм профессор Әбүбәкер ага Терегулов булып чыкты. Ул әле күптән түгел генә студент мундирыннан аерылган бер яшь врач иде. Аның киңәше буенча, соңыннан мин бер карт профессорның өенә бардым һәм земский больницада консилиумнан да үттем. Һәммәсе дә мине бик яхшы кабул иттеләр һәм, бер тавыштан диярлек, чиремнең әле куркынычлы түгеллеген, билгеле режим саклап яшәгәндә, операциясез үк төзәлергә мөмкинлеген әйттеләр. Бу хәбәр мине гаять шатландырды, Казанны тамаша итү өчен дә миңа көч һәм дәрт бирде.

Казанга беренче килүем иде. Шәһәрнең үземне кызыксындырган урыннарын, беренче чиратта татарлар яшәгән бистә һәм тирәләрен карап йөрдем. Атаклы Кабан күле тирәләрен әйләндем, Болак буйлап үттем. Ләкин күземә иң нык ташланган урыннар «Печән базары» һәм шуның тирәсендәге урамнар булды. Анда татарларның мыж килеп торуы, ыгы-зыгысы, чыннан да, ургылып, кайнап торган зур казанны хәтерләтә иде. Г. Тукайның «...Кисекбаш» исемле поэмасындагы картина һәм һәртөрле образлар монда бөтенләй тере килеш минем күз алдымнан кичтеләр.

Монда чын искелек күренешләре арасында яңалык чаткылары да күзгә ачык чалынды. Яңалык күренешләре бигрәк тә татар телендәге нәшрият эшләрендә, китап сәүдәсендә һәм вакытлы матбугат өлкәсендә иде булса кирәк. Шуларга карап, ул чакта мин Казан татарларының Уфадагылардан гомумән өстенлеге, культура һәм аңлылык якларыннан да алдынгылыгы турында бер нәтиҗәгә килә язган идем. Ләкин, күп тә үтмәстән, бу уемның өлешчә генә дөреслеген аңладым.

Казанда минем күз күргән таныш-белешләрем әле берничә генә иде. Ә сангa алып, уртак сүз табардай якыннарым тагын да азрак. Шуларның берсе — «Кояш» газетасы редакторы Зәкәрия ага Мәрҗәни (Садретдинов) булды. Бу зат — Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укыткан зур белемле кешеләрнең (мөдәррисләрнең) берсе, минем дә укытучым булган кеше.

Бер көнне, иртә белән, мин «Кояш» газетасы редакциясендә булдым. Зәкәрия ага белән беркадәр вакыт әңгәмәләшеп утырдык. Аннары, урынымнан кузгалып, саубуллашмакчы идем, ул мине туктатты да:

— Ашыкма, Казанга синең беренче килүең бит. Фатих белән таныш түгелдерсең, озакламый ул килергә тиеш, мин сине аның белән таныштырырмын. Ул Уфадан килүчеләр белән әңгәмәләшергә бик ярата, — диде.

Мин аптырап калдым:

— Кем соң ул Фатих?

Зәкәрия ага:

— Фатих Әмирхан бездә эшли бит, озакламый килеп җитәр, күрерсең, — диде дә өстәлендәге бер газетаны миңа биреп:

— Тик утырырга иренсәң, менә газетабызның бүгенге санын караштыра тор, — диде.

Күзләрем газетада булса да, уем Фатих Әмирханда иде. Матбугат һәм әдәбият буенча ул миңа да таныш, ә үзен күргәнем юк. Әсәрләрен укуым буенча, ул минем күз алдымда ничектер шактый кырыс, каты телле, шуграк бер кеше булып гәүдәләнә иде. Уйга калдым: «Мин соң андый кеше белән ничек сөйләшермен. Ул мине санга алырмы? Ул бит танылган язучы, әдип, ә мин шәкертлектән әле генә чыгып килә торган яшь бер мөгаллим. Матбугат, әдәбият мәйданнары белән әле минем танышлыгым да бик чикле, аның сорауларына дөрес җавап бирә алырмынмы соң?»

Шул арада кемдер:

— Фатих абый килде, — дип эндәште.

Ф. Әмирхан өстәле артына килеп утыргач, Зәкәрия ага, утырган урыныннан кузгалып, мине аңа тәкъдим итте: үзенең элекке шәкерте, хәзерге көндә мөгаллим булуымны һәм Уфада эшләвемне әйтеп, безне күрештерде.

Очрашу мин уйлаганча авыр да, катлаулы да булмады. Фатих сүзне бик гади нәрсәләрдән, хәл-әхвәл сорашудан башлап җибәрде. Мин Казанга нинди максат белән килүемне һәм беренче тапкыр килүемне әйттем. Ул минем Казанда алган беренче тәэсирләрем белән кызыксынды. Казанга бик кыска вакытка гына килүем аркасында, шәһәр белән артык күп таныша алмавымны әйтеп, күргән кайбер урыннар турындагы тәэсирләремне генә белдерә алдым. Шуларга таянып, Казанда медицина эшчеләренең өйбәтлеген, татарлар арасында да нәшрият һәм матбугат эшләренең киң колач ала баруын чамалавым турында берничә сүз әйттем. Уфадагылар белән чагыштырганда, Казан татарларының гомуми аң һәм культура якларыннан да өстенрәк булулары ихтимал дигән фикер белдердем.

Нәкъ менә шушы урында Фатих, мине туктатып, сүзне үзе алды. Ул минем Казан турындагы фикерләремнең күбесе белән килешүен әйтте һәм медицина белән нәшрият, матбугат эшләренең зурлыгы турында үзеннән дә кайбер фактлар, мисаллар өстәп куйды. Әмма соңгы фикерем белән килешмәде.

— Аңлылык ягыннан Уфа татарлары алдарак баралар, — диде ул.

Шул фикерен исбат итү өчен, берничә мисал да китерде.

— Менә сезгә бер мисал, — диде ул, үткен күзләре белән миңа текәлеп карап, — сез әле укудан яңарак кына аерылган бер егет, мөгаллим. Шушы киемнәрегездә сез Уфа татарлары арасында иркенләп йөри аласыз, сезне беркем дә гаепләми (минем өстемдә костюм, ак яка, галстук, башымда эшләпә — һәммәсе дә җәдитчә иде). Бездә бит шәкерт һәм мөгаллимнәр татар ягында сезнеңчә киенеп йөри алмыйлар әле. Күрәсез, хөрмәтле мөхәрриребез Зәкәрия абзый да әле һаман казаки кия, — дип көлдерде. Аннары, өстәлендәге эшләпәгә кулы белән ишарә итеп: — Беләсезме, менә мондый эшләпәне Казанның татар ягында фәкать мин генә киеп йөрим. Печән базары яныннан үткәндә, мондый киемнәрем өчен миңа да кәфер печәте басып калгалыйлар, — диде. Көлештек.

Аннары ул Казан белән Уфадагы хатын-кызлар хәлен чагыштырып үтте:

— Уфада бит хатын-кызлар йөреш-торышта һәм ирләр белән аралашуда үзләрен шактый иркен тоталар. Казанда исә әле безнең гимназисткаларыбыз да аңа ирешә алганнары юк. Татар ягында алар йөзләрен ирләргә күрсәтә алмыйлар. Алай гына да түгел, Уфадагы кызлар мәктәпләрендә хәтта ир укытучылар, мөгаллимнәр дә укыта икән. Дөресме?

Бу фактны мин һәм Зәкәрия ага — икебез дә расладык. Шулай да Уфадагы кызлар мәктәпләренең кайберләрендә ир укытучылар килеп кергәч, кызларның уңайсызлану фактларын да сөйләдем.

— Андый мәктәпләрдә укучы кызларның кайберләре, ир укытучы класска кергәч, йөзләрен шәлләре яки яулык почмаклары белән каплыйлар икән. Арада хәтта укытучыга аркасы белән борылып, артка таба карап утыра торганнары да очрый, дип сөйлиләр, — дидем.

Бергәләп көлештек. Безнең утырышыбыз да шуның белән тәмамланды. Бу минем Фатих Әмирхан белән көтелмәгән бер очрашуым булды. Шунда мин аның кырыс та, һавалы да түгел, киресенчә, башкаларга игътибарлы, мөлаем бер кеше булуын аңладым.

# ХАЛЫК ОНЫТМАС!

„Азат хатын» журналының былтыргы соңгы номерында Чүпрәле районыннан алынган бер хәбәр укыдым. Кара Китә авылы халкы шунда туып үскән, шунда кулына каләм алган, аннары зур шагыйрь булып җитешкән, Бөек Ватан сугышы давылларын иелми-сыгылмый кичкән Шәрәф Мөдәррис исемен клубка биргән. Шагыйрь исеме клубка! Мин чиксез сөендем. Димәк, хәзер анда көн саен шагыйрь исемен телгә алалар. Өч йөз кеше сыйдырышлы клуб залында утыручы Кара Китәлеләрнең һәрберсе авылдашлары Шәрәф Мөдәррис белән күңеленнән сөйләшә, китапханәдә аның китапларын кулга ала. Иркен сәхнәдән дә аның сабыр, әкрен тавышы яңгырар кебек. Ул авылдашларын көн саен күреп тора, аларның фидакарь эшләренә соклана, кайсы берсе белән әкрен генә бәхәсләшә дә кебек...

Мин шагыйрь Шәрәф Мөдәррисне яхшы белә идем. Әдәбиятка да бер еллардарак килдек, бергә янып эшләргә хыялландык. Шәрәф Мөдәррис үзен генә белгән, үзен генә сөйгән шагыйрь түгел иде. Ул бүтән язучыларны, художникларны, композиторларны, артистларны чын күңеленнән ярата, хөрмәт итә, алар турында озын-озын мәкаләләр яза иде. Ә без, исәннәр, шуларның барысын да эшлибезме? Бүген арабызда булмаган артистларны, композиторларны, художникларны, язучыларны тиешенчә искә алабызмы? Аларның исеме, тузан баскан кебек, әкрен-әкрен онытылмыймы?

Мин бөтен кеше тарафыннан да танылган зур әдипләр, зур сәнгать эшлекләре турында гына әйтмим. Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев, Хәлил Әбҗәлилов безнең сәнгать күгебездә һәрвакыт якты йолдызлар булырлар, аларның исемнәре беркайчан да үлмәс, торган саен киңрәк яңгыраш табар. Ә бүтәннәр, тавышлары азрак яңгыраган, талантларын ачарга да өлгерә алмыйча арабыздан китеп баручылар? Без бит аларга: син фәлән-фәләнне эшләмәдең, дип бәйләнә алмыйбыз. Алар хәзинәләрендә булганның барысын да исәннәргә биреп калдырганнар. Тиешле хөрмәт күрсәтү — исәннәр эше. Алар бу турыда уйларга тиешләр.

Мин хаксызга онытылган яки ярым онытылып барган бик күп исемнәрне санар идем. Беренчедән, никадәр тырышып санасам да, ул исемлек тулы булмас, икенчедән, монысы иң мөһиме, урыннардагы иптәшләр безнең авыл яки безнең шәһәр кешеләрен телгә алмаганнар икән, димәк, алар лаек түгел, дип караулары бар. Искедән калган шаукым яши бит, аннары югарыдан ишетелгән сүзгә генә колак салучы җитәкчеләр дә бетмәгән әле. Билгеле, һәр авылдан сәнгать эшлекләре чыкмаган, ләкин кайберсеннән берничәшәр булуы да бик мөмкин. Аларның барысының да исемен клубка бирергә димәгән. Бездә беркем исеме белән дә аталмаган китапханәләр, мәктәпләр, колхозлар, урамнар, мәйданнар, пионер дружиналары, авыл һәм мәктәп музейлары һәм башкалар бар. Бәлки, комсомоллар утырткан бакчага теге яки бу язучының бюстын да куярлар, теге яки бу авылда атаклы авылдашлары исемендәге түгәрәкләр оештырырлар, аерым конкурслар үткәрерләр. Халык уйлап табуга бик маһир, ирке чикләнмәгәч, ул һәммәсенә җитешер. Элек барысы өчен рөхсәт кирәк иде, син аны эшләмә, моны эшлә, дип әмер биру бар иде. Хәзер барысы да халыкның үз иркендә. Минемчә, бу бик яхшы, моның кадерен генә белергә кирәк. Аяныч күренешләр аз булдымы, бертөрлелек басмаган идеме? Кайсы гына шәһәрдән үтмә — бер үк исемдәге урамнар, кайсы гына республиканың колхозлары исемләгән алып күз йөртмә — тагын шул ук хәл иде. Хәлбуки, алар бу җирләрдә яшәмәгәннәр дә, тормаганнар да, эшләмәгәннәр дә. Күршеләре кушкан, болар да кушкан. Шул гына. Җирле поэтик исемнәр онытылган, шушы тирәләрдә торучы кешеләрнең йөрәкләренә якын кешеләрнең исемнәрен кушу — тыйнаксызлык саналган.

Халык күңеле белән шагыйрьнең, художникның, матурлыкның кадерен һәм тәмен белә. Үз тирәсеннән чыккан талантларга аның рәхмәте бигрәк тә зур. Кара Китә халкы үз баласы шагыйрь Шәрәф Мөдәррисне искә алган икән, башкалар үзләренең кадерле ул-кызларын нигә онытсыннар. Билгеле, төрле киртәләр дә, бәхәсләр дә булыр, ләкин халык үз сүзен әйтми калмый бит.

«Азат хатын»дагы кечкенә генә хәбәр миңа шундый фикерләр уятты миндә. Аларны укучылар белән уртаклашуны да кирәк санадым. Алар ни әйтерләр икән?

**ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ.**

# КӘРВАНСАРАЙ

„Бу бина стеналары янында 1918 елның 4 апрелендә дутовчыларга каршы көрәштә һәлак булган татар һәм башкорт кызыл гвардиячеләре күмелде».

Әле күптән түгел генә Оренбургтагы Кәрвансарай стенасына куелган мемориаль тактага шул сүзләр язылган.

Узган гасырның иң әйбәт архитектура истәлекләреннән берсе булган Оренбург Кәрвансарае татар һәм башкорт халыклары тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән.

XIX гасырның кырыгынчы елларында салынган ул сарайның кыскача тарихы болай. 1836 елда Оренбург генерал-губернаторы В. Перовский башкорт һәм татар кантоннары башлыкларына мөрәҗәгать итеп: «...Оренбургка үз йомышлары һәм хөкүмәт эше белән килүче башкорт һәм татарларның шәһәрдә тукталу өчен берниндиә урыннары юк... Шушы кыенлыкны бетерү өчен, мин җәмагать йорты, ягъни Кәрвансарай, төзи башларга җыенам. Анда барлык татар һәм башкортлар берниндиә түләүсез торып китә алыр иде», — ди.

Власть вәкилләре ул Кәрвансарайны җәмагать йорты итеп кенә калмаска, бәлки анда җирле мөселман халкына фән укытырга һәм һөнәр өйрәтергә дә вәгъдә итәләр.

Губерна башлыгы татар һәм башкортларның хәлен яхшырту турында кайгыртмый, билгеле. Кәрвансарай төзү аңа, барыннан да элек, дипломатик чара буларак, ягъни үзләрен изүгә каршы әледәнәле баш күтәреп торган җирле халыкны тынычландыру өчен, кирәк була.

Генерал-губернаторның сарай төзергә акча җыю турындагы мөрәҗәгатен башкорт халкы хуплап кабул итә һәм, озак та үтми, кирәк кадәрле сумманы җыеп та бирәләр.

Кәрвансарайның проектын эшләүне ике кешегә: атаклы Петербург архитекторы Александр Брюлловка (художник Карл Брюлловның туганы) һәм Казан университетын тәзүче архитектор М. Коринфскийга тәкъдим итәләр. Соңыннан Коринфский проекты кире кагыла, чөнки ул «...корылманың характерына туры килми, хәтта мәчете дә христиан чиркәвенә тартым» эшләнгән була. Ә А. Брюллов проекты уңышлы дип табыла.



Кэрвансарайны төзүдә нигездә татар һәм башкортлар эшли. Һәр елны төзелеш сезонында полклардан һәм кантоннардан махсус билгеләнгән кешеләр җибәрелеп тора. Сарай 1846 елның 30 августында төзелеп бетә.

Менә шул вакыттан бирле Оренбургка матурлык биреп торучы бу мәһабәт бина шәһәргә килгән һәр кешене сокландыра. 1847 елда Оренбургка сөргенгә җибәрелгән Т. Г. Шевченко Кэрвансарай турында: «Мин Сакмар елгасы аша чыккан вакытта кояш яңа гына баткан иде әле. Еракта иң элек күзэмә мәчетле һәм бик матур манаралы зур алсу төстәге бина күренде», — дип язган. 1929 елда Оренбургка барган А. В. Луначарский да: «Кэрвансарай бик кызыклы. Уртасында мәһабәт архитектура корылмасы эшләнгән», — диган.

Кэрвансарайның тарихына кайтыйк. Сарай төзелеп бетәр кеннәрдә Оренбургка генерал-губернатор итеп В. Обручев диган кешене билгелиләр. В. Обручев татар-башкорт культурасын күтәрүгә юнәлдерелгән барлык чараларга каршы кеше була. Һәм ул, Кэрвансарай төзелеп бетү белән, аны башкортлардан тартып ала да яртысын үз квартирасы итә, ә яртысына губерна канцеляриесен урнаштыра.

Бу хәл башкорт халкы арасында зур ризасызлык тудыра. Кэрвансарайны үзләренә кайтарып бирүне таләп итү хәрәкәте башлана. Патша власте вәкилләре халыкны бары тик куркытып кына тынычландыралар.

Бары тик Совет власте гына Кэрвансарайны халыкның үзенә кире кайтара.

1966 елда Мәскәүдә Б. Кәлимуллинның Кэрвансарай турында китабы басылып чыкты. Ул китапта автор 1918 елда В. И. Ленин белән элекке Башкортстан өлкә бюросы председателе һәм Милләтләр Халык Комиссариаты каршындагы мөселман эшләре буенча Комиссариат члены Ш. Манатов арасында булган сөйләшүгә дә тукталып үткән. Кэрвансарайны башкортларга кире кайтарып бирү турындагы декрет проектын В. И. Ленин зур кызыксыну белән укып чыккан һәм: «Кэрвансарай әлегә тикле башкортларга кайтарылмадымыни? Аны тизрәк бирергә кирәк», — диган. Аннары проекттагы «башкорт йорты» диган сүзләр урынына «башкорт халык йорты» дип язып куйган.

1918 елның февраль аенда Кэрвансарайны башкортларга бирү турында декрет игълан ителә. Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты 1918 елның 6 февралендә хезмәт ияләре һәм солдатлар депутатлары Советының Оренбург башкарма комитетына түбәндәге телеграмманы җибәрә: «Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты карары нигезендә, Оренбургтагы Башкорт халык йорты һәм «Кэрвансарай» исемендәге мәчет тулысынча башкорт хезмәт иясе халкы карамагына тапшырыла. Бу турыда бөтен халыкка җиткерүегезне үтенәбез».

1921 елда Кэрвансарайда башкорт педагогия техникумы оештырыла һәм 1936 елга кадәр эшләп килә. Бу уку йорты халык мәгарифе өлкәсендә милли кадрлар әзерләүдә мөһим роль тота. Башкорт язучыларыннан Сәгыйт Алиш, Баязит Бикбай, Габдулла Амантай да заманында шул техникумда укыганнар.

Дәүләт тарафыннан саклана һәм өйрәнелә торган кыйммәтле архитектура истәлеге буларак, Кэрвансарай 1960 елда махсус исемлеккә алына.

Октябрь революциясе чорында да Кэрвансарайның әһәмияте зур була: ул үзенә күрә Оренбург «Смольные» хезмәтен үти. Хәрби-революцион комитет та шунда урнаша, Оренбург өлкәсендә Совет власте да шунда игълан ителә.

Хәзер Кэрвансарайда Оренбург территориаль геология идарәсе урнашкан. Ә сарай ишек алдындагы мәчеттә 1953 елдан бирле планетарий эшләп килә.

Кэрвансарайның хәле соңгы елларда борчылу тудыра башлаган иде. Стеналарында урыны-урыны белән керамикасы купкалаган, ремонт ясалмаганлыктан, манарасына менәргә рөхсәт ителми һәм, гомумән, Кэрвансарайга җитди ремонт ясау кирәк иде.

Һәм менә узган ел ул кыйммәтле истәлекне реконструкцияләү эше башланды. Махсус комиссия килеп, сарайны реставрацияләү планын төзеде.

Хәзер Кэрвансарайның утыз тугыз метр биеклегендәге манарасына төзелеш баскычлары ясалды — реставрация эшләре шуннан башланды. Сарайның стеналары да бик әйбәтләп ремонтланачак. Кыскасы, халык осталары кулы белән төзелгән ул мәһабәт истәлек яңадан элекке хәленә кайтарылачак.

М. МЕРЗАБЕКОВ.

## Әдәбият тарихыннан материаллар

# ШӘКЕРТЛӘРНЕҢ АВЫЗ ИҖАТЫ

Чорма кәрнизендәге чүп-чар эчендә тузанга батып яткан гарәпчә китаплар арасыннан бер дәфтәр табып алдым. Киндер белән тышланган ул дәфтәрнең беренче битенә: «Ошбу дәфтәрнең сахибе Габделхак ибне Бәдретдин әль Кукчәви» дип язылган, эчендә — коръән хәдисләре. Дәфтәрдәге язмалар безнең гасыр башына туры килә. Сахибе Габделхак ибне Бәдретдин 1895—1900 еллар тирәсендә Сатыш мәдрәсәсендә белем алган кеше икән. Әнә шул хәдисләр язылган дәфтәр битләренең читләренә — буш калган урыннарга җырлар күчерелгән. Җырларның бер өлешен шәкертнең энесе Сөнгатулла ибне Бәдретдин дә өстәгән. Анысы шул ук мәдрәсәдә 1905—1909 елларда укыган.

Мәгълүм булганча, Казан арты яшьләре Кышкар, Курса, Казиле кебек мәдрәсәләрдә белем алган. Вяткага таба — Мәчкәрә һәм Буби мәдрәсәләре зур уку йортларыннан исәпләнгән. Теләче — Саба ягында исә белем учакларының заманына күрә зурысы Сатыш булган. Гасыр башында анда дөньяви фәннәргә омтылыш, ислах өчен көрәш көчәя. Шәкертләрнең әдәбият белән кызыксынулары арта. Шул чорда бу мәдрәсәдә Миргазиз Укмасый укый һәм үзенең беренче шигырьләрен иҗат итә...

«Казан утлары» журналының 1966 елгы бер санында, мәдрәсә фольклорына кагылып, Н. Исәнбәт: «Ул бездә үзенә бер кызыклы һәм өйрәнелмәгән өлкә», дигән иде. Дөрес сүзгә җавап юк, диләр. Кайбер фән эшлеклеләребез «шәкертләр фольклоры» дигән сүздән ни өчендер куркып кала торган булдылар. «Шәкертләр? — дип гаҗәпләнделәр алар. — Мәдрәсә җимеше бит ул!» Хәлбуки, мәдрәсәдә укучы шәкертләрнең зур күпчелеге буразнадан, камыл арасыннан чыккан крестьян егетләре булган. Халкыбыз элек-электән гыйлемгә зур ихтирам белән караган. Хәреф таныган кешенең крестьян агай алдында дәрәҗәсе үскән. «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе», «Мәдрәсәләрдә пыяла ишек» дип, халык әнә шул үз күз алдында булган бердәнбер гыйлем учагына олы йорт итеп караган. Бу — шиксез.

Аннан килеп, әнә шул буразна, камыл эчендә, авыр хезмәттә, табигать кочагында саф әхлаклы булып җитешкән крестьян малае мәдрәсәгә кереп язарга өйрәнсен дә җыр яки бәет иҗат итми калсын, имеш! Ул әле укый-яза белмәгән көе дә ат саклаганда, тегермәндә чират көткәндә, аулак өйдә күпме-күпме тел шомарткан, иҗат иткән! Мәдрәсәгә килгәч инде ул үзенең анда алган белемен җыр чыгару өчен дә файдаланган: китап исеме, коръән хәдисеннән бер-бер өзек, хәлфәдән ишеткән берәр афоризм — барысы да җырга кертелгән. Болай матуррак, көтелмәгәнрәк була ич! Моңа кадәр җырны ул: «Иртә торып тышка чыксам, сөяләм баганага», дип кенә башлый иде. Хәзер, шалишь аның белән, ул укымышлы кеше! Шуңа күрә инде ул җырны да болайрак төзи:

> «Калә рәсулулла» диеп
> Укыганың «Мишкать»ме?

Әмма моңа карап кына ул җырларның төп рухы, эчтәлеге үзгәрмәгән, элеккечә, халык авыз иҗатындагыча калган. Габделхак ибне Бәдретдин дәфтәреннән сайлап алынган түбәндәге җырлар да әнә шул турыда сөйли.

М. МӘҺДИЕВ.

# Җырлар

«Мулла Җәләл»[1] нең сахибе[2] «Мөхаккыйкет дәвани»[3],
Гыйшкым төшкән сән җаныйга, табиб тапмый дәваны.

Укыганым «Сөлләм»[4] иде, инде төштем «Хикмәт»кә[5],
Ашаганым күмәч иде, инде калдым икмәккә.

Кимә итек, ки читек — читек мәсихле[6] итәр,
Ярны сөйсәң, шәкертне сөй, шәкерт бәхетле итәр.

Мәдрәсәнең бер талибе[7] сиксән төрле хат таный,
Мине дисәң, мине сөйсәң бераз сабыр ит җаный.

Йөз галимнең мөсалифы[8] Габделкадир Җөрҗани[9],
Шул җанашым килеп керсә, балкытадыр дөньяны.

Кызарып кояш чыкты инде таш мәдрәсә артыннан,
Күп дәресем калды инде сән җаныем артыннан.

Бәнем бик сөйгән китабым — «Мәсаилел һидая»[10],
Нурлы йөзеңне күрсәм дә шул буладыр кифая[11].

Һавада нөҗүм[12] никадәр, суда сәмәк[13] шулкадәр,
Сәнең кальбең[14] нәмиданым[15] бәнем гыйшкым шулкадәр.

Исле майлар сөрткән икән, килә күлмәгеннән ис,
Язга собраниега[16] барып без булырбыз мөдәррис.

«Мәвакиф»[17] карый белмәгәч, «Гакаид»[18] башламыйлар,
Ташламыйм дип ант итмиләр, ант иткәч ташламыйлар.

Биек тауларның башында кошлар агач башында,
Зөләйханың васфы[19] бардыр синең дәкыйк[20] кашында.

Фиракыңның[21] уты, җаный, һәр хәсрәттән әгъладыр[22],
Әгәр мәхрүм висалеңдән[23] бәнем үлемем әүлядыр[24].

---

[1] «Мулла Җәләл» — китап исеме.
[2] Сахибе — хуҗасы.
[3] «Мөхаккыйкет дәвани — китап исеме.
[4] «Сөлләм» — китап исеме.
[5] «Хикмәт» — китап исеме.
[6] Мәсих — сөртелгән, чиста мәгънәсендә.
[7] Талиб — шәкерт, студент.
[8] Мөсалиф — юлдаш.
[9] Берәр китапның авторы булырга тиеш.
[10] Китап исеме.
[11] Кифая — шул җитә мәгънәсендә.
[12] Нөҗүм — йолдызлар.
[13] Сәмәк — балык.
[14] Калеб — күңел.
[15] Нәмиданым — белмим (фарсы).
[16] Собрание — бу урында «Мәхкәмән Шәргыя».
[17] «Мәвакиф» — китап исеме.
[18] «Гакаид» — китап исеме.
[19] Васыф — сыйфат, билге.
[20] Дәкыйк — нәзек.
[21] Фирак — аерылышу.
[22] Әгъла — иң югары (көчле).
[23] Висаль — кавышу, очрашу.
[24] Әүля — артыграк.

Тәрәзәннен төпләрендә нинди гөлләр үсәдер,
Кил, җанкәем, бер кавышыйк гыйшкын үзәк өзәдер.

Сәхраларга чыккаймын, төрле якка йөргәймен,
Гүзәлемнен йөзләрен нихәл итеп күргәймен.

«Шәрхемулла»[1] дәресендә шәкерт карый «Мөхәррәм»[2],
Син җанкәем ятка китсән, инни әхават[3] тә хәрам.

«Каләл казыя»[4] дип алдык без бу көнге дәресне,
Син җаныемны күргәчтен башым тулы ләместин[5].

«Исагуҗи»[6] тәмам булгач, укый шәкерт «Шәмсия»[7]
Фил җәннәти хурелгаенем[8], кара чәчен шәл сина.

«Гакаид»ның дәресендә сөеп карыйм хашия[9],
Фил хәкыйкать[10] әнә гашыйк, җаныем, кара кашына.

«Мохтасар»[11]ның дәресендә караганым «Җамигый»[12],
Сәнен белән мөгамәләм булса иде даими.

Укый торган китабымнын исеме «Хикмәтелгаен»,
Син җаныем күк булса булыр җәннәттә хурелгаен.

Җанкәем кара кашларын, сагындыра башладын,
Ахры бәне ташлавындыр, хат та язмый башладын.

Мендем тауга, кистем каен кыйблаларга чалкаен,
Ак беләген ястык итеп йоклый микән җанкаем.

Алпавытнын бакчасында үсә диләр пар кавын,
Җанын сөйгән ярын белән торсан иде бер кавым.

Тәмәке тартсам оят, аракы эчсәм кыйбат,
Икесенә дә кыймасан, мич башына мен дә ят.

И дусларым, мин нишлием, бутылка утыз биш тиен,
Парлап алсам җитмеш тиен, ялгыз башым нишлием.

Аракы эчтем әзрәк, мине орышты хәз(е)рәт,
Мине орышкач хәз(е)рәт, эчми йөрдем әзрәк.

---

1 «Шәрхемулла» — дәреслек исеме.
2 «Мөхәррәм» — дәреслек исеме.
3 Әхават — кыз туганнар. Бу урында туганнарым хәрам булсын диген мәгънәдә.
4 «Каләл казыя» — грамматика дәреслеге (?).
5 Ләмес — тоту, тию (бу урында башым катып калды).
6 «Исагуҗи» — дәреслек исеме.
7 «Шәмсия» — дәреслек исеме.
8 Фил җәннәти хурелгаенем — җәннәттәге кара күзем.
9 Хашия — комментарий.
10 Фил хәкыйкать — чынлыкта.
11 «Мохтасар» — дәреслек исеме.
12 «Җамигый» — дәреслек исеме.

# Ә. Камалга 60 яшь

## ДРАМАТУРГ ҮТКӘН ЮЛ



1921 елның октябре, кич, Казан. Алты егет Вахитов клубы ишегеннән ишәк алып керә алмый азапланалар. Ишәк терәлгән дә каткан. Аннары җиргә ук сузылып ята. Артык акча чыгарудан курыкмасаң, тот та бугазына пычак сал! Ишәкне кыйнап та, типкәләп тә урыныннан кузгата алмагач, тирләп-пешкән егетләрнең берсе:

— Күтәреп кертик булмаса, кире беткән нәрсәне. Юкса гримга соңга калабыз! — дип кычкыра. Һәм алты егет күз ачып йомганчы ишәкне күтәреп алып кереп китәләр.

Нинди кешеләр соң болар? Нинди ишәкле спектакль уйныйлар? Алар артист Габдрахман Кушай бенефисендә катнашучы артистлар. Бүген монда Кушай бенефисенә «Хуҗа Насретдин әфәнде» дигән 5 пәрдәле яңа комедия куела. Мәгълүм ишәк тә шул спектакльдә уйнату өчен зоопарктан прокатка китерелгән. Комедия авторы Әнәс Камал. Әйе, әйе, тууына 60 ел, иҗади эшчәнлегенә 50 ел тулган Әнәс Камал. Аңа бу әсәрне язганда нибары 13 кенә яшь була.

1924 елларда Татар дәүләт театры төзелгән була инде. Ләкин артистларга бенефис үткәрү элеккечә үк дәвам иттерелә. Артист Ш. Фәхриев тә бенефис үткәрергә җыена. Һәм Әнәскә «Чегән бәете» дигән бәет китереп биреп, пьеса язарга куша. Бәет тиздән «Чегән бәете белән качкан мулла кызы Хәмидә» дигән 4 пәрдәле драмага әйләнә.

1925 елны Әнәс Камал агасы артист Габдулла Камал I өчен өч пәрдәле «Җизнәкәй» дигән музкомедия яза. Әсәрне Габдулла Камал үзе оештырган вакытлы күчмә труппада сәхнәгә куя. Үкенечкә каршы, Әнәснең балалык елларында язган бу әсәрләре барысы да юкка чыккан. Аларның сыйфат яклары ничек булгандыр, анысын әйтүе кыен. Ләкин, замандашларының сөйләүләренә караганда, ул әсәрләр шул чорларның таләпләре югарылыгында булганнар булса кирәк.

II

Әнәс ничек кинәт кенә мондый уңышка ирешкән, ничек яшь кенә башы белән мондый әсәрләр яза алган соң? Монда хәйран калырлык, гадәттән тыш хәл түгелме? дип баш катырырлык бернәрсә дә юк. Беренчедән, Әнәс татар драматургиясенең атасы Галиәсгар Камал семьясында туа һәм тәрбияләнә. Икенчедән, аны «Сәйяр» труппасының Габдулла Кариев, Касыйм Шамил кебек өлкәннәре 8 яшендә чагында ук сәхнәгә тартып мендерәләр. Бу хәл 1916 елларда була. Әнәс труппаның Шәрык клубында үткәрелгән кичәләрдәге концерт номерларында, хорларда катнаша, шигырьләр сөйли. 1918 елны Әнәскә рольләр дә бирә башлыйлар. Ул Габдулла Кариев белән бергә Мирхәйдәр Фәйзинең «Чәчәкләр арасында» дигән ике пәрдәле пьесасында Якты корт ролен, Ярулла Вәлинең «Ачлык кушты» драмасында сатылган кыз Мәһисылуның беренче энесен, «Галиябану»да кечкенә Садри ролен уйный. Кыскасы, труппаның үз баласына әверелә.

«Сәйяр» труппасы Татар дәүләт академия театрына әйләндерелгәч, аның янында Касыйм Шамил җитәкчелегендә балалар труппасы оештырыла. Кечкенә Әнәс, мәктәптә укуына карамастан, труппа оештырылган көннән үк артист итеп алына, аның спектакльләрендә актив катнаша һәм 1927 елга, труппа бетерелгәнгә чаклы эшли. «Тычканга үлем, мәчегә көлке» (К. Шамил) әсәрендә генерал Жантурин, «Чәлдерүчеләр»дә (Кави Ишмури) Васька безпризорный, «Бабайның сакалын кискәннәр»дә (Т. Ченәкәй) бабай, «Робин Гуд»та (Эмма Шамил тәрҗемәсе) көтүче рольләрен башкара.

Балалык елларында салынган менә шушы ике-өч чүпрә Әнәсне гомерлеккә театр арбасына җигә. Ул 1928 елны Казан сәнгать техникумының театр бүлегенә укырга керә һәм шунда укыган вакытында 1929 елда Габделхак Нагаев оештырган эшче дәүләт театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли, театр өчен кече форма әсәрләре яза. 1931 елда театр техникумын тәмамлагач Татарстан мәгариф халык комиссариаты оештырган беренче берләшкән колхоз-совхоз театрына сәнгать эшләре җитәкчесе итеп җибәрелә һәм шунда Хуҗа Шоңкаров белән берлектә 1934 елга чаклы режиссер да, артист та, художник та, хәтта соңрак директор да булып хезмәт итә. Шоңкаров белән Әнәс Камал оештырган шушы беренче колхоз-совхоз театры нигезендә соңыннан Сабир ага Өметбаев җитәкчелегендә чын профессиональ театр — Минзәлә театры үсеп чыга.

III

Театр техникумын бетереп режиссер профессиясе алу, театрда күп еллар эшләү, шигырьләр язып шагыйрь булырга, повестьлар, романнар язып әдип булырга хыялланган Әнәс әдәбиятның иң кыен, иң катлаулы, иң газаплы һәм иң шау-шулы жанры — драматургиягә кереп китә. Ул 1927—28 елларда «Биш миңле Гайнетдин» дигән 4 пәрдәле пьеса язып бастыра. 1931 елны «Ике көч» дигән өч пәрдәле драма, 1932 елны «Давыл» дигән 10 картиналы драма иҗат итә. Шуннан соңгы елларда бер-бер артлы «Үз кеше», «Туй», «Яз якынлаша», «Иске Казанда», «Сәлам хат», «Март бу-

# Безнең календарь

**ДӘРҖИЯ АППАКОВА**

*(1898—1948)*



*Татар совет балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән талантлы прозаик һәм драматург Дәрҗия Аппакованың тууына 70 ел тулды.*

*Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппакова 1898 елның 2 мартында Татарстан АССРның Ширәмәт районы, Байгыл авылында ярлы крестьян семьясында туа. Үзенең бала чагын ул матур табигатьле шушы авылда үткәрә. Унөч яшь тулгач, ата-аналары Дәрҗияне керәшен татарлары өчен Казанда ачылган укытучылар мәктәбенә бирәләр. Бу мәктәпне тәмамлагач, Аппакова башта Казанда укытучылык эшенә калдырыла. Ә 1918 елда ул, укытучы булып, үз авылына кайта.*

*1919—21 елларда керәшен татарлары өчен чыга торган «Кызыл әләм» газетасының хәбәрчесе булып эшли. 1922 елда югары совет-партия мәктәбенең клуб работниклары әзерли торган бүлегенә укырга керә. Биредә укыганда, Казан зур драма театры каршындагы студиягә иреклe тыңлаучы булып йөри.*

*1925—28 елларда Дәрҗия комсомолның Казан өлкә комитетында инструктор булып эшли, ә 1928 елда Үзбәкстанга күчеп, яңадан укытучылык эшен дәвам итә. Ташкентта яшәгән чорда аның әдәби эшчәнлеге башлана. Үзенең беренче әсәрләрен ул рус һәм үзбәк телләрендә бастыра.*

*Дәрҗия Аппакованың тәүге әсәрләре үзбәк хатын-кызларының Октябрьга кадәрге авыр тормышын, аларның совет чорында гына җәмгыятьнең тулы хокуклы члены булып әверелүләрен чагылдыра. 1933—35 еллар арасында иҗат иткән «Михнәт» романында автор Үзбәкстанда авыл хуҗалыгын күмәкләштерү процессын сурәтли һәм совет халкының контрреволюция көчләренә, кулакларга каршы кискен көрәшен гәүдәләндерә. «Мәмәт һәм карт Амон» хикәясендә төрекмән халкы тормышы күрсәтелсә, «Люли» повестенда чегән балаларының үткәндәге газаплы көннәре тасвирлана.*

*Аппакова «Кечкенә Бануның тарихы» (1938 ел) әсәре белән укучылар арасында киң танылды. Бу повесть рус, татар, үзбәк, хәтта инглиз телләрендә басылып чыга. Әсәрдә Бөек Октябрь революциясенә кадәр татар авылларындагы батракларның тормышы чын художникларча чагылдырыла. Автор кечкенә Бану образы аша балаларның үткәндәге күңелсез язмышларын бирә, көрәшеп яулаган бәхетле, азат тормышның матурлыгына куана.*

*1943 елда Дәрҗия Аппакова Казанга кайта. Биредә яшәгәндә «Илдус», «Тапкыр егет», «Бишек җыры», «Үлмәс» һәм «Камыр батыр» пьесаларын яза, «Дүрт әкият» исемле җыентыгы басылып чыга.*

*Язучы үзенең энергиясен, иҗат көчен балалар әдәбиятына багышлады. Аның балаларга эстетик тәрбия бирү ягыннан зур әһәмияткә ия булган «Илдус», «Тапкыр егет» кебек пьесалары мәктәп сәхнәләрендә кабат-кабат куелып киләләр. Хикәя, әкиятләре балалар тарафыннан сөелеп укылалар. Д. Аппакованың иң яхшы әсәрләре «Шыгырдавыклы башмаклар» (1948), «Хикәяләр һәм пьесалар» (1953) дигән сайланмаларына тупланганнар. Татарстан китап нәшрияты аның әсәрләрен рус телендә дә бастырып чыгарды. Аның халык легендалары мотивларына нигезләнеп язылган «Тапкыр егет» драмасы республика театрлары сәхнәләрендә күп еллар буенча зур уңыш белән барды.*

*Дәрҗия балаларның эчке дөньясын, тормышка карашларын, тойгыларын, теләкләрен, үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнгән талантлы язучы иде. Аның әсәрләрендә без Ватанга, партиягә бирелгән патриотлар, хезмәт сөючән, үзара дус яшәүче мәктәп балалары белән очрашабыз, мәктәп, пионер отрядлары тормышы белән танышабыз, совет халкының героик хезмәтен күрәбез.*

*Ләкин вакытсыз үлем аны 1948 елда безнең арабыздан алып китте.*

Нур ГАЙСИН.

## РАХМАН ИЛЬЯС

*Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган татар совет язучысы Рахман Ильяс (1908—1943) үзенең кыска гына иҗат гомерендә әдәбиятыбызга матур-матур әсәрләр калдырды.*

*Рахман Ильяс әдәбиятка утызынчы елларда килеп керә. Грозный нефтьчеләре тормышын чагылдырган хикәя һәм очерклар яза. Драматургия өлкәсендә дә эшли. Аның «Әндәр карт», «Зәйнүш дускай», «Танышлар», «Фонтан», «Таулар тетри» исемле әсәрләре өлкән буын укучыларга яхшы таныш. Р. Ильясның 1935 елда «Таулар арасында», 1941 елда «Кавказ хикәяләре» исемле хикәяләр җыентыклары басылып чыкты. Аның нефть промышленносте эшчеләре тормышын сурәтләп язылган «Горизонт» исемле повесте совет чоры татар әдәбиятында производство темасына язылган әсәрләр арасында, хаклы рәвештә, күренекле урыннарның берсен алып тора.*

*Шушы елның 25 мартында Рахман Ильясның туууына 60 ел тулды.*



## МӨХӘММӘТ ГАЛИ



*Татар халкының әдәбиятын һәм культурасын үстерү юлында кырык елдан артык эшләп килгән күренекле язучы Мөхәммәт Галинең туууына 24 мартта 75 ел тулды.*

*Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк авыл тормышы турында язган хикәяләре белән танылган, революциянең беренче елларыннан башлап совет матбугатында актив эшләп килгән күренекле язучы Мөхәммәт Галинең (1893—1952) иҗаты татар совет культурасының бик күп тармакларында якты эз калдырган. Аның ган язганнан әллә ни күп булмаган, ләкин гаять үзенчәлекле стильдә иҗат ителгән хикәяләре, очерклары, драма әсәрләре, Тукай, Г. Камал, Ш. Камал турындагы истәлекләре һәм әдәбият тарихын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләре бүгенге көндә дә әһәмиятләрен югалтмаганнар.*

## ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ

*Фатих Сәйфи-Казанлы — әдәбиятыбызга утыз ел буенча турылыклы хезмәт иткән әдип. Ул күп кенә мәкаләләр, хикәяләр, драма һәм комедияләр авторы. Аның әсәрләрендә халкыбызның тормышы һәм культурасының үсеше үзенчәлекле рәвештә чагылып килде. Сәйфи-Казанлы үзенең әсәрләре һәм тәнкыйть мәкаләләре аша татар әдәбиятының демократик һәм социалистик юнәлештә үсешен, җәмгыятьтәге демократик һәм социалистик тенденцияләрне яклап килде.*



*Шушы елның март аенда туууына 80 ел тулган Ф. Сәйфи-Казанлының «Талак», «Зимагур», «Крушниклар», «Двор өендә», «Һани», «Елан токымы», «Кызыл эшелон», «Корбый иптәш», «Беренче адымнар» исемле хикәяләре һәм повестьлары, «Җәмәгать хадиме», «Ямьсез тормыш», «Дошманнар», «Зәбәрҗәт» исемле драма һәм комедияләре әле хәзер дә актуаль яңгырыйлар һәм укучылар тарафыннан яратып укыйлар.*

# КЫЙММӘТЛЕ ӘСӘР

Мин Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» дигән автобиографик повестен «Казан утлары» битләреннән бер кат укып чыктым. Бу әсәрне тагын һәм тагын укырмын әле.

Укучы буларак, «Туган ягым — яшел бишек» повестен мин бик кыйммәтле әсәр итеп саныйм. Бу әсәрне укыгач мин олы язучыбызның тормышы белән тулырак таныштым, аның эш сөючән тату гаиләдә үскәнен белдем. Татар хатын-кызларына хас булган бик күп матур сыйфатларны күрдем. Алар әсәрдә нәкъ тормыштагыча эшчән, тыйнак, тиешенчә оялчан, үзләренең намусларын яшьтән үк саклаучаннар итеп бирелгән.

Барыннан да бигрәк, бу әсәрнең матур теле ошады миңа. Ул укучыларга да ошар, һичшиксез, күпләрне сокландырыр.

Повесть гаять дәрәҗәдә оста итеп, тирбәлдереп кенә, гади татар теле белән язылган. Үтәли күренмәле саф чишмә сулары ничек салмак кына агып торса, олы әдибебезнең күңел байлыгы да бу әсәрдә шулай ага төсле тоелды миңа.

Әсәр күп яктан зур әһәмияткә ия. Туган телебезнең искиткеч байлыгын, гүзәллеген, олылыгын раслау белән бергә, хезмәт халкының, кыен чакларда да төшенкелеккә бирелмичә, алгы көнгә өмет баглавы бик ачык сурәтләгән анда. Әсәрнең «Давыл алдыннан», «Җир, хөррият!» дигән бүлекләре аеруча тирән тәэсир итте миңа.

ВӘЛИ БУЛАТОВ,
Оренбург өлкәсе, Абдуллин районы,
Яңа Якуп авылы.

●

**КАДЕРЛЕ РЕДАКЦИЯ!**

Мин И. Гази абыйның барлык әсәрләрен дә укып бардым. Ә «Онытылмас еллар», «Канатланыр чак» әсәрләрен укучылар белән бергә укыдык. Хәлимнең язмышы өчен бергәләп кайгырдык, борчылдык. «Канатланыр чак» басылып чыккач, ничек шатлануыбыз турында язмыйча да аңлашылыр төсле!

И. Газиның журналның узган елгы 2 нче санында басылган «Малайлыкта кунакта»сын тагын укучылар белән бергәләп укып чыктык.

Кадерле дуслар, «Казан утлары» журналы аша Ибраһим абыйга бездән зур рәхмәт, тыныч картлык, тынгысыз иҗат эшендә моңа кадәр ирешелмәгән уңышлар теләвебезне белдерсәгез иде.

Башкортстан АССР,
Бишбүләк районы
Ново-Васильевка мәктәбе
әдәбият түгәрәге членнары
исеменнән С. ГАНИЕВА.

—◆—

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Шушы елның март аенда бөек рус язучысы Алексей Максимович Горькийның тууына 100 ел тулды. Бу зур юбилейны республикабыз җәмәгатьчелеге киң итеп билгеләп үтте. Иҗат союзларында, югары уку йортларында, фәнни учреждениеләрдә, мәктәпләрдә, культура сарайларында, клубларда һәм китапханәләрдә бөек язучы иҗатына багышланган җыелышлар, докладлар, лекцияләр, әдәби кичәләр, конференцияләр булып үтте, китап күргәзмәләре оештырылды.

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан язучылары союзы, Казандагы А. М. Горький музее, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институты январь аенда Казанда А. М. Горькийның тууына 100 ел тулуга багышланган XVII фәнни конференция үткәрделәр.

Конференцияне Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры профессор М. Мөхәррәмов ачты. Филология фәннәре докторы Б. А. Бялик (Мәскәү, СССР Фәннәр академиясенең Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты) үзенең докладында Горький әсәрләрендәге гуманизм һәм шәхес ирege, иҗат ирege мәсьәләләренә тукталды. Филология фәннәре докторы М. Гайнуллин М. Горький иҗатының татар әдәбиятына йогынтысы турында сөйләде. Н. А. Пешкова, И. Ф. Шаляпина, язучылардан М. Әмир, Г. Минский, С. Әдһәмова бөек язучы турында истәлекләр белән чыктылар.

Болардан тыш конференциядә филология фәннәре докторы Н. А. Гуляев (Казан университеты), филология фәннәре кандидаты М. Хасанов (Казан), филология фәннәре докторы Г. Б. Тагер (Мәскәү), А. М. Горький архивы директоры С. С. Зилина, профессор Б. А. Дехтерев (Мәскәү), тарих фәннәре докторы Р. Нафигов (Казан), филология фәннәре кандидаты А. А. Тарасова (Мәскәү), филология фәннәре кандидаты Л. М. Фарбер (Горький), филология фәннәре кандидаты Л. И. Янкина (Куйбышев) һ. б. фән эшлеклеләре докладлар, гыйльми белдерүләр белән чыктылар.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБЫНДА

Габдулла Тукай исемендәге клубта узган елллардагы кебек быел да даими рәвештә «Әдәби җомга»лар үткәрелә.

1967—68 елгы әдәби сезон узган елның октябрь аенда ук ачылган иде. Аннан соң анда дистәләгән әдәби кичәләр үткәрелде. Бер «Җомга»да язучылар һәм шагыйрьләр әдәбият сөючеләрне үзләренең Октябрьгә, Ленинга багышланган яңа әсәрләре белән таныштырсалар, икенчесе — яшь һәм башлап язучылар иҗатына, бүтәннәре аерым язучыларның юбилейларына багышланды. Мәсәлән, 1967 ел ахырында клубта күренекле татар язучысы М. Галәүнең тууына 80 ел тулу көне билгеләп үтелде. А. Шамов, М. Әмир, Г. Бәширов, Х. Туфан һәм башкалар язучы турында истәлекләр белән чыктылар. Яшь әдәбият белгече Ф. Гыйльманова М. Галәүнең тормышы һәм иҗаты турында доклад ясады.

* * *

Язучылар, шагыйрьләр, күп санлы әдәбият сөючеләр бирегә, шулай ук, шагыйрь С. Урайскийның тууына 60 ел тулу көнен дә билгеләп үттеләр. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турындагы докладны Б. Камалов ясады. Ф. Хөсни, Ә. Юныс һ. б. язучылар шагыйрь турында истәлекләр сөйләделәр.

* * *

**12 январьда** исә клубта Татарстанның халык артисты Касыйм Шамилгә 75 яшь, иҗади эшчәнлегенә 55 ел тулу уңае белән зур кичә үткәрелде.

* * *

**26 январь** көнне бирегә «Татар халык көйләре» темасына лекция-концерт оештырылды. Анда композиторлардан А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Ф. Әхмәдиев, җырчылардан З. Хисмәтуллина, Т. Якупов, З. Әхтәмова катнашты. Лекция-концертны лектор Ф. Вәлиева алып барды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт шәһәренең музыка училищесында студентлар белән очрашып, Г. Ахунов Татарстан язучыларының эшчәнлекләре, үзенең иҗат планнары турында сөйләде.

* * *


Бүлекнең чираттагы утырышында С. Сөләйманованың «Кама таңнары» исемле яңа шигырьләр циклы укып тикшерелде. Фикер алышуда Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, С. Кальметов, Ә. Ильясов һәм Н. Касыймов катнашты.


# ТАТАРСТАН ТАҢНАРЫ

**Ш. КАПКАЕВ** музыкасы

**Г. АФЗАЛ** сүзләре

*Бу җыр Октябрьның 50 еллыгына багышлап үткәрелгән конкурста өченче бүләк алды.*






1. Дулкынланып тирбәлә җыр:
«Сандугач кунмас инде;
Ямьле булса да торган җир,
Туган җир булмас инде».
Сакта торам ил чигендә,
Басмаган җир калмады;
Кайда йөрсәм дә күңелдә
Татарстан таңнары.

2. Таныш чәчәкләр җыясың
Болынга чыгасың да;
Әллә ничек үз тоясың
Аен да, кояшын да.
Кошлары сайрый тирәктә,
Сыгылып үсә таллары...
Кайда йөрсәм дә йөрәктә
Татарстан таңнары.

3. Зәңгәр тәрәзә каршында
Үрмәле гөлләр үсә.
Чишмә буе тау астында
Фирүзә җилләр исә.
Кызара җәйләр ничендә
Алмаларның аллары,
Кайда йөрсәм дә исемдә
Татарстан таңнары.

4. Тургай тавышларында да,
Елга камышларында.
Җанга якын моңнары бар
Сөю сагышларында.
Басуларда эшләп үсә
Кызларның уңганнары,
Сагындырып искә төшә
Татарстан таңнары.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

# Казан утлары

(ОГНИ КАЗАНИ)

39

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210